# КАЗАН УТЛАРЫ

9. 1993



# Рашат Низамиев

## Утызынчы август

Әле сине өстән өркетәләр,
Тарткалыйлар сине әле астан.
Татар халкы дигән җисемеңне
Саклап кала килдең, Татарстан!

Ут һәм кылыч белән куркытканнар:
Көл буласың яки кол буласың...
Шул чакта да югалтмаган халкым
Догасын һәм якты кыйбыласын.

Дүрт гасырлык тарих катламнарын
Ватып-ярып чыкты байрагыбыз!
Яшь барстай яшь-яшь Ватанымның
Мускуллары инде, ай-һай, тыгыз.

Рәсәй белән мөнәсәбәтләрне
Тигез итеп корыр чакларыбыз.
Берәүне дә рәнҗетерлек түгел
Мәртәбәле, горур хакларыбыз!

Без әйтәбез: дәүләтчелек диеп,
Алар әйтә: милләтчелек диеп.
Очты инде тарих чүплегенә
Сөйләшүләр йодрык-фәлән төеп.

Сөембикә манарасы сыман,
Илем-җирем аягүрә баскан.
Йөрәгемдә бүген җыр тирбәлә:
Яшә, сөеклебез Татарстан!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**9**

**(851)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Ә. БАЯН. Көнбагышлар. *Шигырьләр* ........ 3
Ф. ЗЫЯТДИН. Көн вә төн. *Повесть* ........ 9
Ф. ГАБДРӘХИМ. Кичер мине, халкым! *Шигырьләр* ........ 99
М. ВӘЛИ. Качу. ........ 104
Ш. МАННАП. Уйлану мизгелләре. *Шигырьләр* ........ 152
М. ШИҺАПОВ. Бәхилләшмим — саубуллашам. *Шигырьләр* ........ 159


ПУБЛИЦИСТИКА


Р. ХӘКИМ. Империя кояшы батканда. *(Милләт һәм дәүләт турында уйланулар)* ........ 162


ДИСКУССИЯ ДӘВАМ ИТӘ


И. ХӘСӘНОВ. Тормышына күрә әдәбияты. 177
Ә. МОТЫЙГУЛЛИНА. Аналар рухы исән ........ 182

Латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре ........ 185
Безнең календарь ........ 186
Бер сорауга — бер җавап ........ 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повести Ф. ЗИЯТДИНОВА «День и ночь»; М. ВАЛИЕВА «Побег»; стихи А. БАЯНА, Ф. ГАБДРАХИМА, Ш. МАННАПОВА, М. ШИГАПОВА.
«Публицистика»: статья Р. ХАКИМА «Крах империи».
«Литера1турная критика»: статьи И. ХАСАНОВА. «Литература — зеркало жизни», А. МОТЫГУЛЛИНОЙ «Жив дух матерей».
Навыки чтения на основе латинской графики.
Интервью с министром информации и печати И. Г. Ахметзяновым.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: «Прикосновение» — картина уфимского художника Р. Кадырова; известный писатель, критик Т. Галиуллин.


*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.08.93 ел. Басарга кул куелды 7.09.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 25 957. Заказ Я-486. Бәясе 30 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Әхсән Баян

### Көнбагышлар

Сез төшкәндер күктән, көнбагышлар,
Сез — җирдәге нәни кояшчыклар.
Якты өстәп кырга, бакчаларга,
Уйный сары чуклар — алтын уклар.

Ямь сирписез җәйгә, кояшчыклар,
Җилләрдә тик сибелә моң-сагышлар.
Сары төстә, сабыр башыгызда
Хатирәләр, еллар һәм язмышлар.

Кояшчыклар, сезгә бу җирдәге
Барча җаннар якыннар бит — дуслар.
Шул җаннарның уй-хисләрен җыеп,
Башларыгыз иелә, көнбагышлар.

Сүрелгәндә кояш кайнарлыгы,
Сирпегез сез яңа юанычлар.
Сары чукларыгыз тагын, тагын
Вәгъдә итсен илгә куанычлар.

Сүрелмәгез, нәни кояшчыклар,
Көнбагышлар, көнбагышлар!..

*Август, 1991*

---

Әхсәт БАЯН (1927) — *шагыйрь, прозаик, драматург; татар һәм урыс телендә басылган күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Печән чабам

Төшемдә мин бик еш печән чабам,
Бар көчемә селтәп чалгымны.
Алып килә төшләр эссе җәйне,
Эссе җәйле үсмер чагымны.

Кетер-кетер кыяк үлән кыела,
Кыяклардан чыклар коела.
Чыклы үлән, чуклы чәчкәләрдән
Йөрер сукмакларым җыела.

Өмет офыгыннан көлә кояш,
Сөенечләрем чаба шул таба.
Тик соңынтын чорный кара ялкын,
Күзне-битне пешереп, тир ага.

Кара ялкын каплый офыгымны,
Кайнар томан тула зиһенгә.
Кинәт сизәм: куллар бушап калган,
Чалгым ята үлән эчендә.

Ник икәнен соңлап аңладым шул:
Минем арттан килгән бер агай
Ашыктырган мине, янсын диеп,
Мәче-наян тычкан кугандай.

Сер бирмәскә иде минем ният:
«Бирешермен сиңа, кара, көт!»
Тик төртелеп менә чалгым сынды —
Көткән мине яшерен кара төп.

Янган аттай сукмагыма аусам,
Әй көләчәк иде агаем!
Максатына ирешкәнен аның —
Янганымны — кайткач аңладым.

Калтыранып ятам ихатада.
Бизгәк тота... җирне, күкнеме?
Каян килә явызлыклар диеп,
Аптыраулар шулай күп булды.

Алда көтә кемнең яман уе?
Абынып шул кара төпләргә,
Туры килде яшь түгәргә ялгыз,
Сер сиздермәс өчен читләргә.

Кайчак төштә бизгәк әле дә тота,
Бизгәк тота бары минеме?
Калтырана бугай дөнья үзе,
Тота бизгәк әллә җирнеме?

Әй, заманым, зинһар аңлат шуны:
Ник калтырыйм тагын, ник янам?

Төшемдә мин бик еш печән чабам,
Сынык чалгы тотып уянам.

*1988—1993*

## Булдырдыгыз

Үкчәләргә безнең баскан буын,
Үпкәләргә безгә хакыгыз юк:
Борылып-борылып артка карый торып,
Җитәкләргә сезне куллар суздык.

Аякларга чалына килүегез
Тоелды тик ялгыш абыну кебек.
Үкчә канап, суелып беткәндә дә,
Аксап-туксап, тыныч атлый бирдек.

Базар юлын безнең белмәүләрне
Хаклысыздыр юрап гариплеккә.
Кулыбызны сез тибәреп читкә,
Ашыктыгыз алга һәм биеккә.

Мондый узыш таныш безгә бик тә —
АКШны бит уза яздык берчак!
Чалбар төбе күренә язгач кына,
Оялудан тынып, калдык туктап.

Безнең буын шулай кыюсызрак
Булып чыкты. Ә сез? Булдырдыгыз!
Шау-гөр килеп, уздыгыз да безне —
Бөеклеккә, әллә бөлгенлеккә? —
Ыргылдыгыз.

Булдырдыгыз!

*1993*

* * *

Дөньяны мин үзгәртергә килдем.
Башлык булыр, дидем, җирдә хаклык.
Хак бәхетне һичкем алмас тартып,
Рәнҗетәлмәс һичкем көчсезне —
Өлкәннәрне, толны, үксезне.

Мин — хакыйкать һәм гаделлек колы,
Әйткән сүз нык — атылган ук иде.
Кайтып кире, тик, үземә тиде.
Хаклыкны мин яклый алмадым.
Үз итмәде мине заманым...

Мин үз күрдем аның аргамагын.
Аның белән бәхет дигән кошны
Илгә кайтарырга Тәңрем кушты.

Баш бирмәгәч ләкин чабышкым,
Ялларына аның ябыштым.

Ярсыган ат, ярсыганмын мин дә.
Кай якларга чапкан аргамагым,
Сизмәгәнмен, уйлый алмаганмын.
Атым чапкан башка тормышка,
Ташлап мине талаш, ызгышка.

Үзгәртмәкче идем мин дөньяны,
Төзәтмәкче идем гариплекне.
Тик үзгәрдем үзем: өмет бетте,
Хәзер инде үзем көчсезмен,
Инде менә үзем үксезмен.

Тормыш түгел, сатыш, тартыш монда.
Алдау, талау — иң зур акыл көче.
Үз җиремдә — мин ят, мин чит кеше,
Тик күзәтеп утырам базарны.
Күлмәк ертып, бәйлим ярамны.

*1993*

## Әле дә булса...

Ак карларга тамган яшь тамчылар
Ашыктылар язга, язларга.
Ашыгалар, күрәм, әле дә булса,
Әле дә булса,
Дәрьяларга кушылып шауларга.

Еракларда калган очрашулар,
Юлдаш булалмаган чибәрләр,
Сөю була язган хатирәләр
Әле дә булса,
Әле дә булса озата киләләр.

Җилгә очкан уйлар, ымсынулар,
Уйнап кына кочкан сылулар
Тын кичләрдә яфрак шавы аша
Әле дә булса:
«Син исәнме?!» — диеп сорыйлар.

Язмыш дигән еллар дәрьясында
Сулык-сулык тибә чишмәләр.
Чишмәләрдәй тибеп, ерак моңнар
Әле дә булса
Ник соң, ник соң искә төшәләр?!

Әле дә булса, әле дә булса!

*1992*

* * *

Ник аердың син мәңгелек
Бәхетеннән оҗмахның?

Төшереп гөнаһлы җиргә,
Җәзага мине тарттың.

Иң зур газапларны гәрчә
Син үзеңә алгансың.
Тик... алманы үзең теләп
Син татып карагансың.

Үкенергә юк сиңа җай,
Син аны табалмассың.
Иблис сине алдагандай,
Мине син алдагансың.

Алдавыңны, арбавыңны
Дәвам итәсең гел син.
Гомер буе җан теләсең
Әз-мәз мизгелләр өчен.

Китик лә кабат җәннәткә...
Юк дисеңме чарасы?
Юк шул! Һәркем бакчасында
Үсә үзенең алмасы.

Һәм ләззәтле, һәм ачы.

*1993*

* * *

Хуш инде дип кул бирәсең,
Шаяртасың, көләсең.
Мин сизәм: син уйларыма
Уелган тере рәсем.

Аерылуның ни икәнен
Без белмәбез, күрәсең:
Мин онытa белмәм сине,
Син онтыла белмәссең.

*1988*

* * *

Дөньядагы барча хатын-кызның
Үзлекләрен күбрәк күрергә
Теләп кемдер тырыша сан җыярга,
Чибәрләрдән тәкыя үрергә.

Шулай булды инде, син — бердәнбер,
Кемнәр генәниләр әйтмәсен.
Синдә табам дөньядагы барча
Хатын-кызның бөтен хасиятен.

*1993*

* * *

Үлгәннәрне тиргәп, батыр булып
Мөмкин икән, тәки, яшәргә.
Ил ышангач шуңа, бәгъзеләрнең
Шик-шөбһәсе нигә, нәрсәгә?

Үлгәннәрнең бар бит гаепләре,
Булганнан да әле күбрәктер.
Тиргәүченең өстенлеге шунда
Түгел диеп инде кем әйтер?

Серен моның белә гипнозчылар,
Буа торган безнең күзләрне.
Ымсындырып залны юк нәрсәгә,
Башка гамәл кыла үзләре...

Кабер ачып мәет күчерергә
Аларга соң намус кушканмы?
Хакны раслыйм диеп, зират айкап
Йөргән куллар — кала чистамы?

Тарих чүплегеннән гәүһәр чүпләп,
Аз табылса — кемдер бик әрни.
«Ахмакларны сөя хезмәт» диеп,
Хәзинәләр түренә үрмәли.

Белә: аннан гаделлек һәм тәртип
Сорап гавам теңкә кортмасын.
Ил, талавын аның шәйләмичә:
«Батыр, яшә!» — диеп, кул чапсын.

*1988—1993*

* * *

Күпме генә эзләсәң дә
Көтелмәс ачыш ясау:
Шигырь максаты — шигърият,
Яшәү максаты — яшәү.

Мөмкин төсле бу фикергә
Тиз һәм җиңел килергә.
Тик — баш ваткач һәркем үзе,
Җитми кайчак гомер дә.

*1993*


Казан утлары
китапханәсе
Фарсил Зыятдин
Көн вә төн



## Фарсил Зыятдин

# КӨН ВӘ ТӨН

ПОВЕСТЬ

Госманны тикшерүче янына чакырдылар. Тикшерүче белән очрашкач, аның зәңгәр күзләре зур булып ачылды, яңаклары тартышып куйды, йөзенә гаҗәпләнү чалымнары чыкты.

— Нәрсә шаккаттың, утыр! — диде тикшерүче дорфа гына, аннары, бераз йомшара төшеп: — Аптырама, егет, мин сине озак тоткарламам,— дип өстәде.— Бер нәрсәне ачыклыйсы бар иде. Бәлки, беләсеңдер дә, сезнең лаборатория мөдире Карпинский кулга алынды бит...

Госман агарынды, гаҗәпләнүе шомлы куркуга әверелде. Ирексездән тез буыннары калтырый башлады. Нәрсә булган, ни өчен? Коткадыр ла... Әллә соң, ходаем, власть алышынганмы? Кем соң, нинди кеше бу тикшерүче? Шәкүрне озата килгән ат карагына шундый да охшаган үзе. Юктыр ла, ялгышамдыр...

Тикшерүчене үтәли күрергә теләгәндәй, үзе дә сизмәстән, Госман гәүдәсе белән алга табарак иелә төште.

— Коткы бу, иптәш тикшерүче! Селекционер Карпинскийның бер генә гаебен дә белмим мин.

— Барысын да белүең мәҗбүри түгел. Менә бу кәгазьдәге аңлатманы раслап кул куйсаң, шул җиткән.

Тикшерүче кулдан язылган бер бит кәгазь сузды. Кемдер үзенең имзасын куеп өлгергән бу кәгазьдә мондый юллар бар иде: «... селекционер Карпинский совет фәненә карата астыртын төстә корткычлык эше алып бара. Буржуйлар тегермәненә су коя. Бигрәк тә Мендель, Морган кебек буржуаз галимнәрнең ялган теориясен кулланма итеп, фәнни эзләнүләр, тәҗрибәләр үткәрә. Бу — бөек юлбашчыбыз Сталинның тәгълиматларын инкарь итү. Шуңа күрә халык дошманына безнең арада урын булмаска тиеш».

---

Фарсил ЗЫЯТДИН (1937) — *галим һәм әдип. Берничә китап авторы. Казанда яши.*

Имзаны танырлык түгел иде. Канаевмы, Капкаевмы шунда...
Госманның күз аллары карангыланып китте. Кем өяр икән мондый пычракны?! Әле быел гына институт бетереп селекция үзәгенә килгән Капкаевмы әллә?!
— Ну,— диде тикшерүче,— дөрес язылган бит, әйеме?
— Мин берни дә әйтә алмыйм, иптәш тикшерүче. Бер генә дәлилем дә юк.
— Юк, дисең? Фикердәшеңне яклап калмакчы буласыңмы? Кара аны, халык дошманын яклаган өчен башыңнан сыйпамаслар.
— Әйттем бит инде берни дә белмим дип.
— Боргаланып маташма, безгә барысы да мәгълүм. Мендельне изучать иттеңме? Иттең!
— Мендель дисезме? Китапханәдә бар иде андый китап. Мин аны укырга гына алып тордым.
— Иптәш Сталинның күрсәтмәләре сиңа закон түгелмени? Генетика — безнең фәннең дошманы, дигән ул, кем... Закиров, төшенәсеңме?
— Ә бит укымаска димәгән. Дошманга каршы көрәшү өчен аның ни уйлаганын, тактикасын өйрәнергә кирәк. Иптәш Сталин менә шундый фикер дә әйткән, ялгышмасам...
— Хитришь, Закиров! Алайса, генетик Вавилов белән хат алышуыңны ничек аңларга? Менә нәрсә яза ул...
Тикшерүче хатны кычкырып укый башлады. «Кызык, бу хат бирегә ничек килеп эләкте икән?! Укыгач та өстәл тартмасына салып куйган идем, югыйсә. Кем житкерде икән? Тулай торакта шымчы бар, димәк!»
Хатны укып бетергәч, тикшерүче урыныннан торып, Госманга таба атлады.
— Менә шулай, Закиров. Боргаланып маташыр урының юк. Тәк шту, Вавилов сиңа генетика буенча эзләнүләр алып барырга, язышып торырга кушкан. Саллы дәлил бу. Тагын халык дошманы Камай белән очрашуыңны өстәсәк, менә нәрсә көтә сине!— Тикшерүче бармаклары белән «рәшәткә» ясап күрсәтте.
Госман сискәнеп китте. Уйнап түгел, чынлап сөйли бит бу юньсез!..
Әгәр дә ул теге ат карагы Фалис булса, утыртыр, ике дә уйлап тормас. Әллә соң кем икәнен төпченеп карарга мы? Ул Буранчы якларын искә төшермәкче булып авызын ачкан иде, вакытында тукталып калды. Башыннан хәтәр уй йөгереп узды: «Тиле дә инде мин... Әгәр таный калса, ни эшләтергә белер бу!»
— Ну, ну, нәрсә әйтмәкче идең?— диде тикшерүче, елмаеп.— Госман җавап бирмәгәч, үзе үк дәвам итте: — Ярый, ихтыярың. Авыл малайлары шулай куркак була инде алар. Үзең кай яклардан соң?
Госман аптырап калды. Дөресен әйтергәме? Әгәр чынлап та теге бәндә булып, мине таный калса? Хәер, аңа минем кайдан булуым мәгълүмдер инде. Иң мөһиме — шик тумасын.
— Буранчыдан,— диде ул, дулкынлануын басарга тырышып.— Башкортстан чигендә үк.
— Ерак икән,— диде тикшерүче тыныч кына.— Ул якларда булырга туры килгәне юк. Халык ничегрәк яши?
— Тормыш әйбәтләнә. Колхозлар ныгый.
— Туган якларны кайтып күрәсең киләдер, шәт?
— Килә, әлбәттә. Шуңа да туган-үскән як бит ул.
— Алайса, сузма, тизрәк кул куй хатка.
— Минем бер гаебем дә юк. Аңлыйсызмы? Камайның халык дошманы булуына да ышанмыйм. Мин аңа реактивлар алырга гына бардым.
— Реактив дисеңме? Монысы тагын нәрсә? Шартлаткыч түгелме соң ул?

Бу сүзләрдән соң Госман тикшерүченең чынлап та надан булуын чамалады. Шулай да җавап бирергә ашыкты:

— Нинди шартлаткыч булсын ди! Лабораториядә анализлар ясау өчен кирәкле нәрсә генә ич ул.

— Хатка монысын да өстә. Карпинский өчен алып кайттым диген. Синең ике дошман арасында арадашчы булуыңны күрсәтә ул. Сузма, Закиров!

— Мин бернәрсә дә язмыйм. Гаебем юк.

— Алайса, кул куй!

— Кул да куймыйм. Язылганнар дөрес түгел.

— Соңгы тапкыр әйтәм, Закиров! Юкса, башыңны Себердә черетәчәкмен!

Бу минутларда Госман абыйсын исенә төшерде. Аның кыюлыгы, куркусыз үлеме егеткә көч өстәгәндәй булды.

— Теләсә нишләтегез. Кул куймыйм!

Шул арада ишектә шәмдәй төз гәүдәле сакчы күренде. Тикшерүче, аңа ымлап:

— Чирканчык алдырыгыз! — дип фәрман бирде.

Егетнең рухын сындыру озак дәвам итте. Аны төштән соң гына, канга баткан, аңын югалткан хәлдә, үзе кебек үк ачы язмыш көткән, хәлсезләнгән тоткыннар янына кертеп ыргыттылар. Азмы-күпме кыймылдар хәле булган тоткыннар аның янына шуышты.

— Әбәү, нинди егетне харап иткәннәр!..

— Шулкадәр кыйнамасалар, кансызлр!..

— Үзеңә аз эләктемени кичә?

— Алардан ни игелек көтәсең? Беләсезме, минем бармакларны тимер кыскыч белән ничек итеп изделәр?!

— Ярый әле, башка җиреңне измәгәннәр! Анысы бигрәк яман, түзмәле түгел, ди. «Эрерәк кошларның» телен әнә шулайрак чишәләр икән.

Тоткыннар арасыннан берәү егетне таныды булса кирәк:

— Бәй, бу теге аспирант бит... Селекция үзәгендә эшләүче, — диде. Аннары Госманны уңайлырак урынга күчерде, җайлап яткырып, киемнәрен рәтләде, баш астына бишмәт кисәге кыстырды.

Госман кинәт ыңгырашып куйды, сөйләнә-саташа башлады:

— Җитәр, каерма кулны! Ә-ә, әнкәй бәгърем, синмени бу?! Абый кайда? Үтерделәр?! Шахмаймы? Ат караклары килгән! Кыйныйлар! Хуш, Буранчы!

Госманның хәтереннән, өерелеп, истәлекләр уза иде...

* * *

Ул чактагы Буранчы авылын онытып буламы соң?! Йортлары, гөмбәләрне хәтерләтеп, көлсу туфракка зәгыйфь тамырлары белән ябышып утыра. Якын-тирәдә урманы дисәң, урманы, суы дисәң, юньле суы юк. Бер карасаң, бу җирләрнең нинди ямен, нинди тәмен табып утырганнардыр бирегә Буранчының тәүге кешеләре? Кем белә, бәлки, түрәләренең бихисап салымнарыннан качып килгәннәрдер алар бу тирәләргә?

Ә бүген исә авыл халкы өчен шушы авылдан да, шушы кырлардан да, аның уңдырышсыз көлсу туфрагыннан да якынрак урын юк кебек. Һәр кеше, һәр гаилә шушы туфракка тамыр җибәреп, шул җирләрдә кыш чыгарлык арыш яисә бодай үстереп, алдагы язларга һәм язмышына ышанып яши.

... Госманга унберенче яшь кенә киткән иде. Әнисенең бердәнбер таянычы ул хәзер. Сугышта яраланып, аягын югалтып, хәлсезләнеп кайткан абыйсы Хафиз да, җиде яшьлек сеңлесе Хәмидә дә әле кул

арасына кирәрлек түгел. Әтиләре исә Герман сугышыннан әйләнеп кайта алмады. Сания түтәй, көтеп-көтеп тә ире кайтмагач, бөтен авырлыкны үз җилкәсенә салып, тормыш арбасын төптән җигелеп тарта башлады.

Революция дулкыны Буранчы авылын да читләтеп үтмәде. Бирегә әледән-әле йә аклар, йә кызыллар сугылып, авыл яшьләрен үзләре белән сугышка алып китә торды. Бер килүдә аклар Госманның абыйсы Хафизны да үзләре белән китәргә мәҗбүр иттеләр. Әмма берничә атнадан Хафиз акларга каршы сугышып йөри иде инде. Ул көрәшкән атлы эскадрон аклар өчен яшен ташына әверелде. Ә Хафиз үзен чын батыр итеп танытты. Көчле күкрәк, киң җилкә! Дошман һәрчак бу батырдан читтәрәк булу ягын караган диләр.

Әмма егерменче елны, каты яраланып, Хафиз да лазаретка эләкте.

... Язын, авыл халкы кәлҗемәгә дип черек бәрәңге казып яткан чакта, җигүле ат белән бер солдат килеп төште. Арбада гәүдәсе кечерәеп, кыскарып калган Хафиз утыра иде. Озата килгән санитар аяксыз Хафизны өйгә күтәреп кертте дә, чолан почмагына аның шинелен элеп, ярты капчык чамасы он калдырып китеп тә барды.

— Улым җаным, нишләттеләр сине?! — Сания, әйтер сүзен әйтеп бетерә алмыйча, күз яшьләренә буылып еларга кереште. — Харап кына иткәннәр икән үзеңне!

Хафиз исә әнисен тынычландыра башлады:

— Баш исән булсын, әнкәй, бер җае чыгар, борчылма. Миңа да эш табылыр. Буранчы җирләре авылны да туйдырыр, илгә дә өлеш чыгарыр әле... Шулай бит, энекәш?

Госман, абыйсына башлап сүз кушарга кыймыйча, башын кагып куйды.

Хафиз түш кесәсеннән бер уч акча чыгарды да әнисенә сузды:

— Менә, бар байлыгым шушында, әнкәй. Миңа Югары оч Габдрахман абыйдан тире эшкәртә торган ышкы белән тиречә пычагын алып кайтырга кирәк. Теләгән бер кешене итекле дә, башмаклы да итәрмен...

Хафиз теккән башмакны яратып киделәр авылда. Тик тектерүче генә сирәк булды. Башмак дип барлы-юклы икмәгенне биргәнче, яланаяк йөрүең хәерлерәк иде ул көннәрдә. Шулай да Хафиз эшсез утырмады. Үз һөнәренә акрынлап энесе Госманны да өйрәтте. Әмма булган ризыкны саклабрак тотарга, билне кысыбрак буарга туры килде.

... Ул көнне Госман караңгылы-яктылы ук уянды да абыйсы янына килде, аңа күзләрен тутырып карады:

— Абый, карале, әллә Сулы Чокырга барып, бурсык-фәлән аулап карыйммы икән? Элек тоткалый идек бит.

Хафиз яратып, энесенең иннәренә кәрәктәй кулларын салды:

— Бар, энем, тик саграк бул. Бурсыкның холкын үзең беләсең, — диде ул. Әйтеп бетермәгән сүзе калган сыман, озак кына күзләре белән энесен озатып калды.

Госман зират почмагына кереп күмелергә дә өлгермәде, авылга җилдереп атлылар килеп керде. Һәркайсында — мылтык, ә арбаларында хәтта пулемет та бар. Кызыллар дисәң, кызыллар түгел, аклар да түгел сыман. Ничек кенә танымакчы булса да, Хафиз боларның кемлеген тәгаен генә аера алмады. Бер-бер артлы арбадан сикерешеп төшеп, алар йортларга сибелделәр. Чолан-базларны, абзар-кураларны актарып, күзләренә нәрсә чалынса, шуны арбага ташый башладылар.

Чират күрше Сәет бабайларга җитте. Эзләп-эзләп тә йортыннан берни тапмагач, абзардан аның атын алып чыктылар. Сәет бабай, атының ялына ябышып, бирмәскә тырышкандай итте:

— Юк, бирмим! Адәмнәр бит сез, кызгана белегез! Шушы аттан башка бернәрсәм дә юк бит минем...

— Җибәр атны, йолкыш! Теге дөньяга олагасың килмәсә, кит юл өстеннән!

Сәет бабай Шахмай атаманның сүзләрен ишетмәде, бахбае артыннан сөйрәлә бирде. Ул әле һаман да бу бәндәләрнең миһербанлылык күрсәтүләренә өмет итә иде. Ни әйтсәң дә, бүре түгелләр ич, ике аяклы кешеләр...

Шулчак һаваны мылтык тавышы яңгыратты. Сәет бабай атының алдына көлтәдәй шуышып төште. Җирән кашка исә, хәлне аңлагандай, әче итеп кешнәде дә, куш тоякларын атаманның маңгаена чәпәде. Бандитлар атаман белән булашкан арада, Җирән кашка, ычкынып китеп, Сулы Чокырга таба элдертте.

Бу хәлдән ачулары тагын да кабарган бандитлар халыкны ыграк җәберләргә керештеләр. Госманнарның күршесе Хәсән булган ашлыгын нык яшергән иде, бу йорттан берни дә алып чыга алмадылар. Ләкин барысы да әйбәт кенә үтеп китте дип торганда, бандитлар Хәсәнне төрткәләп чыгардылар да ишекне эчтән бикләп куйдылар. Хатыны эчтә калды Коралланган өч бандитка Миңсылу берүзе ничек каршы торалсын ди? Әче итеп бер кычкырды да тынып калды: авызын томаладылар, ахрысы. Акылын җуяр дәрәҗәгә җиткән Хәсән бар көченә ишекне каерырга кереште. Ләкин ул хатынына берничек тә ярдәм итә алмады, эчке яктан атылган кургашын аны шундук аяктан екты.

Авыл өстенә килгән каза Госманнар йортын да читләтеп узмады. Кермичә үттеләр, ахры, дип торганда гына, сул кулын иске чүпрәк белән бәйләгән карсак кына буйлы бер бандит йөгереп керде. Аны күргәч, Хәмидә мич башына менеп китте, әниләре, коты очып, стенага барып сөялде.

Тик Хафиз гына, керүчегә артык әһәмият бирмичә, киез итеккә олтан салуын дәвам итте.

Бандит иң элек ишек борысына элеп куелган шинельне эләктерде. Әмма, Хафизның башындагы кызыл йолдызы ялтырап торган фуражканы күргәч, башта тынып калды, аннары, усал елмаеп Хафизга таба атлады:

— Кызыллар исе килә. Бу исне мин бик өнәп бетермим, егет!

Хафиз да бандитка карап елмайды һәм аны, бармагы белән ишарәләп, әйтер сүзе бар сыман кыяфәттә, үзе янына чакырды. Тегесе исә кулындагы шинельне бер читкә томырды да, наганын чыгарып, Хафизга ташланды. Тешләрен ыржайтып, наган көпшәсен Хафизның иягенә үк терәде.

Бер мизгелне алар, бер-берсенә текәлгән килеш, сүзсез калдылар. Шунда Хафиз, айнып киткәндәй:

— О-о, Макар! Кайдадыр очрашкан идек бит без синең белән,— диде.

Котырынган бандит наганын Хафизның тешләренә үк терәде, авызын канга батырды:

— Ну, кызыл эт! Әйт соңгы сүзеңне Макарга!

Күрәсең, Макар килә башлагач, Хафиз олтан сала торган безен җиң очына яшергән булгандыр. Күз ачып йомган арада очлы безне тартып чыгарды да бандитның бугазына батырды. Макар, канга тончыга-тончыга, өстәлгә капланды. Ишектә тагын берничә бандит күренде. Алар шундук Хафизга ут ачтылар. Күкрәге ядрәдән телгәләнеп беткәч кенә тынып калды егет.

Тәмам шашынган бандитлар, стенага сөялгән килеш өнсез калган Сания түтәйнең башына приклад белән тондырдылар да, чыгып тайдылар. Сания түтәй чак ишетелерлек итеп: «Башкисәрләр!» — дип пышылдады да, һушы китеп, идәнгә сыгылып төште.

Сания түтәй кич белән генә аңына килгәндәй булды. Әмма ул үз акылында түгел иде инде. Менә ул тәрәзә төбендә яткан бәрәңге тукмагын табып алды да әйләндерә-әйләндерә уйнарга керешге. Аны иплэп кенә чүпрәккә төрде, башына иске шәлен бәйләде. Йөзендә елмаю бил-

геләре чагылып үтте: гомеренең иң якты минутларын исенә төшергәндер, ахрысы. Тукмакны нәние кебек итеп кулында тибрәтергә кереште:

— Йокла, бәбкәм Хафиз, йокла! Менә үсәрсең дә әниеңә ярдәм итә башларсың. Йокла, бәбкәм, йокла!

Госман белән Хәмидә, бу хәлдән гаҗизләнеп, ни эшләргә белмичә аптырап сүзсез калдылар.

* * *

Бандитлар өере, болай да ярлы яшәгән Буранчы халкының барлы-юклы он-ярмаларын, кош-кортларын талап, мәетләр калдырып, яшен-картын кара кайгыга батырып, үз юлларына олактылар.

Икенче көнне Госман абыйсын җирләп кайтты, күгәнс белән каерып ташланган ишекне рәтләде, кош-кортсыз калган тавык кетәген сүтеп, мичкә ягып җибәрде. Өй эче җылынып киткәндәй булса да, күңелдәге боз аз гына да эремәде. Госман тәмам аптырашка калган иде. Баз түренә яшереп куйган ике чиләк чамасы бәрәңгедән, бер чиләк алабутадан башка өйдә бер мыскал ризык әсәре калмады. Инде ни эшләргә? Таяныр кешесе дә юк. Өйдә төп таяныч хәзер ул үзе. Йоклаганда да бәби итеп торган тукмагыннан аерылмый торган газиз әнкәсе дә, Хәмидә дә аннан ярдәм көтәләр. Күпме генә уйласаң да, очына чыгарлык түгел. Кырларда иксез-чиксез бушлык, әче суык җанны өшетә. Тик бер ала карга гына чүплектә нәрсәдер чемченеп йөри. Аның да яшисе килә бит, ул да җан иясе... Суыктан бөрешкән шул ала карга белән берничә чыпчык тотып кайтты Госман ул көнне. Бер-ике бәрәңге янына шуларны салып пешергәч, эчкә җылы кереп киткәндәй булды. Ләкин бу рәхәт озакка бармады. Госманнан күрмәкче, бүтәннәр дә тота башлады чыпчыкларны. Ике-өч көн дигәндә, авылда чыпчык та күренми башлады. Кырлар гына түгел, йорт тирәләре дә бушап калды. Ара-тирә кое сиртмәсе шыгырдаганны исәпкә алмаганда, авыл шомлы бер тынлыкка чумган иде.

Менә шул тынлыкны бозып зират капкасы ачылды. Сания түтәй, тукмагын кочаклаган килеш, әле кар да каплап өлгермәгән яңа кабер янына килеп утырды...

Әнисен өйдә тапмагач, Госман сеңлесе янына килде:

— Әни кайда Хәмидә? Ничек күрми калдык соң әле без аны?

— Беркөнне Салкын Чишмә буеннан алып кайткан идем, шунда китмәдеме икән?

— Эзләп кайтыйм әле мин аны. Ә син мичкә яга тор, Хәмидә, ярыймы?

Госман капкадан да чыгып өлгермәде, аны Бәләкәй әби туктатты:

— Балам, әниегез зиратка таба китте. Туңып-нитеп үлә күрмәсен, бичара... Сезгә дә бирде дөнья кирәкне, балакайларым.

Кечкенә генә булса да, әле нык бу карчык бирешергә уйламый иде. Аның тып-тып басып йөрүе генә дә нигәдер башкаларда яшәүгә ышаныч уята сыман. Госман да: «Бәләкәй әби дә бирешмәгәнне, нигә безгә сынатып торырга әле?!» — дип уйлап куйды.

Госман зиратка килгәндә, Сания түтәй анда юк иде инде. Кая китәр икән тагын? Якын-тирәдә беркем күренми. Кайсы якка чыгып китте икән? Эзе буйлап бармый булмас...Хафизның кабере яныннан бер генә эз узган: капкага түгел, ә кире якка юнәлгән. Кайчандыр Госманның әтисе тоткан койма кыйшайган, байтак тактасы бөтенләй кубып төшкән. Әнисе шул ачыклыктан чыккан да туп-туры Озын Куак ягына киткән. Әнә, инде куаклар арасына кереп бара. Анда кышын да туңмый торган сазлы урыннар бар ич! Үзен-үзе харап итә күрмәсен тагын, ашыгырга кирәк...

Госман, әнисен житәкләп, кояш баеганда гына кайтып керде. Шулай итеп, тагын бер мәшәкать артты. Аз гына карамый тордыңмы, күзе кая карый, шунда чыга да китә әниләре. Эзли-эзли хәлдән таясың...

Көннәр шулай үтә торды. Бер бәрәңгене дә икегә бүлеп кенә ашарга туры килә башлады. Язгы кояш җылырак карый башласа да, яшел үләнгә әле ерак, бик ерак иде. Беренче кара каргалар килер вакыт та җитте.

...Кинәт Госманның күзе очкынланып китте. Моннан берничә ел элек абыйсы белән Мөшеге урманына барган чагын исенә төшерде ул. Әле дә хәтерендә: бик күп имән чикләвеге күргән иде ул анда. Хәтта ашап та карады әле. Авызны бөрештерсә дә тәме болай ярыйсы сыман иде. Шул тәм әле дә авызында саклана кебек.

Әнисе һәм сеңлесе белән хушлашты да, аркасына абыйсыннан калган солдат капчыгын асып, Мөшеге урманына җыенды Госман.

— Әнкәйгә күз-колак була күр, сеңлем,— диде дә, һәркайсысына икешәр бәрәңге калдырып, юлга чыкты.

Әллә имән чикләвеге үзе аз булган, әллә җыеп бетергәннәр — көне буе йөрсә дә, ярты чиләктән ары чикләвек таба алмады Госман. Юлда буран чыгып, күкне томалагач, төнгә каравылчы карт йортында калырга булды ул.

Каравылчы аны кырыс каршы алды:

— Ничек шәйләмичә керәсе иттең? Үзеңне тотып ашарлар дип тә курыкмыйсың... Әнә, күрше авылда Касыйм дигән кешенең базыннан унике адәм башы тапканнар, ди. Хәер сорашып йөргән кешеләрнең башлары алар.

— Сиңа ышанам мин, бабакай. Әйбәт кеше син. Хәтерлисеңме, Хафиз абый белән кереп төн кунган идек без монда?

— Буранчы Хафизмы?

— Әйе.

— Син шуның энесе буласыңмыни инде? Батыр егет иде, мәрхүм. Әнә, Макарны ничек итеп теге дөньяга озаткан. Хәзер аны тирә-юньдә белмәгән кеше юк. Шахмай карак аткан, диләр үзен.

— Шахмай дисеңме? Каян беләсең син аны, бабай?

— Күрше авылдан ул. Яшьли каз-үрдәк урлап үсте. Аннан ат урлый башлады. Хәзер барысын урлый, якташларының җанын да кызганмый хәтта...

— Хәзер кайларда йөри икән ул? Абый өчен үч аласы иде бит...

— Ашыкма, балам, өлгерерсең. Бераз үсә төш. Тик онытма: бик хәйләкәр, явыз, диләр аны.

Шулчак каты итеп ишек кага башладылар.

— Нәрсә сузасың, тизрәк ач, картлач! Тышта нинди буран икәнен күреп торасың бит!

— Хәзер, хәзер ачам,— диде карт, үзе Госманга мич башына менәргә ишарәләде дә, сөйләнә-сөйләнә ишеккә юнәлде.— Тиз селкенеп булмый шул хәзер, аяклар сызлый, картаелды... Ә-ә-ә Шахмай, син икәнсең әле, әйдә, рәхим ит.

— Мин озакка түгел. Берәрсе сугылмадымы бирегә? Тик дөресен әйт, картлач!

Карт уйга калды. Көндез бер атлы авылдашы кереп чыккан иде аңа, яңалыкларның барысын да шул сөйләде. Нәрсә дияргә соң бу башкисәргә? Дөресен әйтсәң башсыз калуың бар...

— Юк, беркем дә кермәде, Шахмай туган,— диде карт.

— Җирән кашка атны да күрмәдеңме?

— Ә-ә-ә, бер кеше узып киткән иде, кая юл тоткандыр, бер дә игътибар итмәдем.

— Шул,— диде Шахмай, ярсып.— Бездән качып китте ул. Зәйнулла бай яшергән алтынның кайда икәнен күрсәтергә вәгъдә иткән иде. Кайсы якка китте?

— Әнә теге якка,— дия-дия, урман каравылчысы бөтенләй кирс якны күрсәтте.

— Алдасаң, башыңны кисәм, картлач! — дип кычкырды Шахмай, буранга күмелә-күмелә.

Картның эченә җылы урнашты. Госман да мич башыннан шуып төште.

— Ярый әле, күрмәдe үзеңне! Танып, Хафизның энесе икәнеңне белсә, сиңа да, миңа да котылу юк иде.

... Иртә белән буран тынып калган иде. Госман каравылчы бабай белән хушлашты да Буранчыга юл тотты. Өйдә аны сеңлесе үзе генә каршы алды.

— Абыем, — диде Хәмидә, Госманны кочаклап, — әниебез югалды. Төнлә, мин йоклагач, чыгып киткән. Мин уянганда эзе дә юк иде. Андый буранда эз торамыни?! Ары сугылдым, бире сугылдым, тавышым беткәнче кычкырып карадым, бер җавап та килмәде. Инәкәем, бәгърем! Беркайда да юк ул хәзер...

Хәмидә үксеп-үксеп елый башлады. Госман бертын сүзсез торды, бу хәбәрдән башы түнде, әйтер сүз таба алмады. Аннары имән чикләвеген мич башына ыргытты да урамга чыгып йөгерде. Анда бер генә җан иясе дә юк, төнге буран бөтен җирне тигезләп киткән иде. Гәүдәсен булса да табасы иде бит. Ләкин кайдан табасың аны? Башта көрт ера-ера зиратка килде. Монда бер билге дә юк, абыйсының каберен кар тигезләп киткән. Аннары Салкын Чишмәгә сугылды. Сулы Чокырда булды, Озын Куак буйларын әйләнде. Караңгы төшкәч кенә, хәлсезләнеп, өйләренә кайтты. Хәмидә исә, елаган-елаган да, мендәргә капланып йокыга киткән иде. Госман аны уятмаска тырышып кына өстенә япты, коңгырт чәчләреннән сыйпады, аннары үзе дә урынга ятты. Менә хәзер, шулай итеп, бөтенләй икәү генә калдылар...

Иртәгесен имән чикләвеген мичкә салып киптерделәр, әниләреннән калган киледә төйделәр. Ярты чиләк чамасы он чыкты. Бераз көн итәрлек рәт бар иде хәзер.

Тик газиз әнкәсен табу теләге тынгы бирмәде Госманга. Тагын Сулы Чокыр ягына юнәлде ул. Мондый тынлык, иксез-чиксез кар диңгезе берәр кайчан булдымы икән тагын? Җәен җир җиләкләре кызарып пешә торган Кырын Тауны да үтте, Сулы Чокыр да артта калды. Аннары Госман, сулга борылып, Биек Тауга юнәлде. Аның түбәсенә менсәң, тирә-юнь киңәеп, офыклар ерагаеп кала... Менә Госман бу якларның иң биек, иң югары ноктасы — Биек Тауның түбәсендә. Тынлык, тынлык... Хәзер Буранчының бөтен җире күз алдында. Тукта, нинди дер кара нокта кыймылдый түгелме соң Озын Куак буенда? Кеше дисәң, охшамаган... Биек Таудан очып төшкәндәй төште Госман, Озын Куакка таба юнәлде. Кара нокта дигәне төлке булып чыкты. Әле бер куакка, әле икенчесенә сикерә, тәпиләре белән карны тырный. Күрәсең, ул да ашарына эзли. Ул да Госман хәлендә. Мылтыгын алып төзәгән иде дә, ничектер кызганыч булып китте. Аз гына булса да яшәсен әле, эзләсен әле ашарына. Тик өйдә калган ач сеңлесен исенә төшергәч, мылтыгын тагын кулына алды...

Бу авыр язның һәр көне, һәр сәгате елга тиң иде. Урман каравылчысы биргән патроннар булмаса, нәрсә эшләр иде икән Госман? Аларның берсе дә бушка китмәде. Бер төлке, ике куян атты Госман. Менә инде патронның соңгысы. Монысына нәрсә эләгер икән?

Шундый уйлар белән, көннәрнең берендә Госман Озын Куак ягына юл тотты. Яз якынлаша. Урыны-урыны белән тау битләре, ярларның кояшка каршы яклары кардан арынган. Кар басылып тыгызлана төшкән. Кояш утлы авызыннан көчәнебрәк бер җылы бөркесә, бар дөнья су булып агарга әзер тора. Әнә, куак төбенә икс ала карга очып төште. Госман башта гаҗәпләнде: ничек исән калганнар диген? Инде ай чамасы бер кош-корт заты күренгәне юк иде. Буш кул белән кайтканчы, әллә берәрсен атып алыргамы? Шулчак, патроныңны бушка әрәм итмә, дигәндәй куак янындагы чокырда бер җәнлек күренде. Карале, бурсык бит бу!


Татарстан Җөмһүриятенең

Госман, дөньясын онытып, аны күзәтә башлады. Кышкы йокысыннан ачыгып уянгандыр, күрәсең, Ашарына эзли, гүя аның беркемдә дә эше юк. Менә соңгы ядрәләр очты, ала каргалар дәррәү күккә күтәрелде. Госман, карга бата-чума, бурсыкка омтылды. Тик шулчак аның каршында, күз алдында чукылган бармаклар пәйда булды. Нәрсә соң бу? Әнкәем, бу бит синең бармакларың! Ала каргалар менә ни өчен төшкән икән бирегә! Госманның күкрәгендә нәрсәдер өзелгәндәй булды, нидер каты итеп чәнчеп куйды, аннары бөтен тәне, буыннары буйлап кайнарлык йөгерде, күзләренә яшь тулды... Онытылып, кызу-кызу карны чокый башлады Госман. Әнә шәлгә уралган бәрәңге тукмагы да янәшә ята. Гомеренең соңгы минутында да аерылмаган ул аннан, һаман да: «Хафизым, йокла, бәбкәм, йокла!» — дип куенына кыскандыр ул аны...

Озак, бик озак исәнгерәп утырды ул әнисенең гәүдәсе янында. Кояш инде кичкә авышып бара иде. Авылга кайтып килсә, кояш баерга байтак вакыт бар иде әле барын. Тик әнисен бирәдә ялгызын гына калдырасы килмәде Госманның. Юанрак ике талны сындырып алды да, аларны вак тал чыбыклары белән үреп ныгытты. Тора-бара чанага охшаш бер нәрсә килеп чыкты. Кояш баеганда инде ул Буранчыга кайтып җиткән иде.

Әнисен күргәч, Хәмидә башта югалып калды, аннары бөтен көченә:

— Инәкәем! — дип кычкырып җибәрде дә үкереп еларга кереште.

Иртәгесен авылдашлары Сания түтәйне хәл кадәренчә хөрмәтләп улы Хафиз белән янәшә күмделәр. Госман Хәмидә өчен әти дә, әни дә, абый да, бердәнбер таяныч та булып калды.

Буранчы халкының хәлен аңлагандай, ул елны яз иртә килде. Ике-өч көн дигәндә көн шундый җылытып җибәрде, елга ярларыннан ташып чыкты. Бозлар утырып калмагач, тормыш әйбәтләнер, туклык килер, диде авыл картлары. Халык киләчәккә ышанды, шуңа күрә дә ачыкса ачыкты, әмма ачыгучы районнарга ярдәм йөзеннән бирелгән чәчүлек орлыкка беркем дә кул сузмады. Госманнарга да симәнә өчен бер капчык чамасы бәрәңге, өч чиләк бодай биргәннәр иде. Чәчүлек орлыкка тимәсәң дә яшәргә була хәзер. Кар астыннан никадәр алабута җыйдылар, аны һәркем диярлек суктырып, алабута көлчәсе пешерде. Аннары койма буйларында, үрләрнең кояшка караган якларында кычыткан да күренә башлады. Какы, йонлы көпшә, кәҗә сакалы, ат кузгалагы, юа булганда ачлыкка кем бирешсен?!

Булган орлыкны һәркем тизрәк җир куенына күмдерергә ашыкты. Ләкин иртә килгән яз үзенең эссе-җиләс көннәре белән туфракның дымын бик тиз алмады. Туфракта дым әсәре калмады. Таң атты исә, һәркем күккә карап, яңгыр көтте. Тик анда бияләй хәтле генә бер болыт кисәге дә күренмәде. Кырлар һаман каралып ята, шытым юк.

Көннәрдән бер көнне Буранчыда арыган, хәлсезләнгән берничә җәяүле туктады. Үзләре каяндыр Туймазы якларыннан икән. Әстерханнан кайтып килүләре. Бирегә ял итәргә, хәл алырга туктаганнар. Юлаучыларны Габдрахман бабай ачык йөз белән каршы алды. Кулына авыру яшь баласын тоткан хатын, бераз ял иткәч, кулларын болгый-болгый сөйли башлады:

— Әстерханнан алып бөтен Идел яры буйлап үләт дигән яман чир таралган. Кайсы гына авылга барып кермә, бөтен җирдә әллә ничә көн күмелми яткан үле гәүдәләргә тап буласың. Кырыла халык, кырыла...

Кинәт йокымсырап яткан бала ыңгырашып куйды. Күзләрен ачып, тирә-ягына җыелган Буранчы кешеләренә бер карап алды да тагын күзләрен йомды. Тәне уттай яна иде баланың. Хәле авыр, нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә саташа. Күпме генә яшәргә тырышса да, Туймазы якларына кайтып җитә алмады бала. Габдрахман бабай йортында җан бирде, бичара. Туфрагы шушында булган икән.

Юлаучылар, баланы Буранчы зиратына күмгәч, ары киттеләр. Шуннан соң күп тә үтмәде, Габдрахман бабай үзе аяктан егылды. Аннары

Хәлимә тутәй... Аз гына вакыт эчендә Буранчы зираты уннарча жанны үзенең куенына алды.

... Газиз бабайның бер дә үләсе килми иде. Үләт диган хәбәрне ишеткәннән бирле ул өennән чыкмады, кешеләр белән аралашмады. Әгәр дә берәрсе йомыш белән керсә, ишек аркылы гына сөйләште. Янәсе, ишекне ачса, үләтнең кереп калуы бар. Авыл кешеләренең күпләп кырылуы аны да куркуга салды. Саклану чарасын күрергә кирәк, дип, кешеләр уянганчы өennән чыкты да абзар янында яткан иске сукасын алып, үткенләгәндәй итте һәм үзе сукага җигелде. Чирәмне ерттырып бер-ике атлый да:

— Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр! — дип тәкбир әйтә, аннары бераз туктап хәл ала да тагын сукалый башлый: — Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр!

Ничек кенә тырышса да, кешеләр уянганчы йортын әйләнеп чыга алмады ул. Күршесе Бәләкәй әби бу хәлне бертын карап гаҗәпләнгән сыман күзәтеп торды да сүз катты:

— И-и Газиз бабай, болай булгач, синең йортка үләт бөтенләй кермәс инде. Ә минем күк ялгыз карчыкны кем кызганыр соң? Минем йортны да кертеп сукалыйсыңмы әллә, Газиз? Яшәсәк, бергә-бергә яшик, диюем...

Газиз бабай күршесенең сүзен чынга алдымы, юкмы, әмма җавабын шаяртыбрак бирергә тырышты:

— Синдәй җен ташы янына үләт керәмени? Чакрым ярымнан әйләнеп үтә ул сине, кем, Минҗамал... Аллаһе әкбәр!..

* * *

Минзәләдән доктор килгәндә Госман аяктан егылган иде инде. Доктор аңа рәттән ике укол ясады һәм әйтте:

— Син яшәргә тиеш, Госман энекәш. Бүген кич мин сине үзем белән Минзәләгә алып китәм. Сеңлеңне дә.

— Син кем соң? — диде Хәмидә кыяр-кыймас кына.

— Мин доктор булам, Сергей Михайлович. Гади генә итеп, «Сергей абый» диярсез.

Аю урманына кергәндә, көн инде караңгыланып килә иде. Госман арбада ята, аның белән янәшәдә — Хәмидә.

Тынлыкны Сергей Михайлович бозды:

— Абыеңны кемнәр атты, дисең, Госман?

— Аны безнең якларда Шахмай карак дип йөртәләр. Кансыз диләр үзен. Кешене чебен урынына да күрми. Аз гына карышып тордыңмы, тота да ата...

— Алай, кансыз дисең. Кулыңнан килсә, ни эшләтер идең?

— Мин анымы? Мин аны!

— Ә үскәч кем буласың килә, Госман энекәш?

— Нәрсә дим соң? Туйганчы ашыйсы килә. Әпекәй үстерәсе иде.

— Игенче булмакчы, димәк. Ә мин синнән эшче чыкмасмы дигән идем. Теләгеңә каршы килеп булмас алайса...

Кинәт ат өркеп, каршы чигенеп куйды. Шулвакыт куаклыктан ике кеше килеп чыкты. Берсе атның йөгәненнән эләктереп алды, икенчесе, наганын алга таба сузып, Сергей абыйга ташланды.

— Егетләр, — диде доктор, каушамаска тырышып, — ялгышмыйсызмы икән сез, ә? Мин үз гомеремдә берәүне дә кыерсытмадым. Шулай булгач, миңа үчле кеше юктыр дип уйлыйм. Аннан соң, арбада каты авыру бала, аның тормышын саклап калу миңа йөкләтелгән. Мин — доктор.

— Безне синең кем булуың кызыксындырмый. Арбада нинди байлыгың бар? Менә нәрсә кызыксындыра безне, доктор әфәнде,— диде тырпаеп торган калын кашлы, озын борынлысы, кулындагы наганын болгап. Аннары, арбадагы бөтен нәрсәне актарып, андагы әйберләрнең астын өскә китерде.

Госман юлбасарга текәлебрәк караган иде, йөрәге «жу» итеп китте, аздан гына: «Шахмай!» — дип кычкырмыйча калды. Шахмай исә өч-дүрт банка консерва, докторның костюмын эләктереп, арбадан җиргә сикерде:

— Тугар атыңны!

Юлбасарлар ничек кинәт килеп чыккан булсалар, шулай кинәт кенә урманга кереп юк та булдылар. Ә болар өчәүләп, кичкә каршы урман уртасында атсыз арбада утырып калды. Караңгы төшкәнче юлда берәү дә күренмәде. Госманга янә укол ясады доктор, аннары, чыбык-чабык җыеп, учак тергезеп җибәрде. Госманның хәле бераз рәтләнә төшкән кебек иде.

Ара-тирә ул да сүзгә кушылгалап куйды:

— Сергей абый, сез ничек татарча сөйләшергә өйрәндегез?

— Татар булгач, ничек үз телеңне белмисең ди? Үз ана телеңне белмәү тәрбиясезлек булыр иде, Госман энем.

— Ә исемегез? Нигә урысча соң ул? — дип Хәмидә сүзгә кушылды.

— Анысы инде бүтән сүз. Моннан дүрт йөз еллар элек Явыз Иван дигән урыс патшасы Казанны алгач, тирә-юньдәге халыкларны урыслаштырмакчы булган. Бабаларыбызны көчләп чукындырган, исемнәрен үзгәрткән. Ләкин аңа карап кына без татар булудан туктамадык. Телебез, гореф-гадәтләребез сакланган. Керәшеннәр татар теленең сафлыгын әле күбрәк тә саклап калмадылармы икән?

— Бигрәк кызык сөйлисез сез. Минем тизрәк үсәсем, күбрәкне беләсем килә.

— Белерсең, Хәмидә, белерсең. Казан дигән калада зур-зур уку йортлары бар. Аларда барын да өйрәтәләр. Тик моның өчен иң элек укый-яза белергә кирәк. Менә Минзәләдә үзегезне укырга урнаштырырбыз. Үсә төшкәч, барын да аңларсыз...

Сергей Михайлович сискәнеп китте. Куаклар арасыннан кинәт кенә берьюлы ике атлы килеп чыкты.

— Безгә Шахмай кушты, доктор,— диде атлыларның берсе.— Атыгызны бирәбез, әмма син безнең бер кешебезне дәвалыйсың.

— Кулдан килерлек булса, тырышып карарбыз,— диде Сергей Михайлович, бераз тынычлана төшеп.— Авыруны бирегә китерегез.

Атлы юлбасар, иптәшен култык астыннан эләктерде дә, учакка таба сөйрәде.

— Хәле шәптән түгел,— диде доктор.— Шулай да укол биреп карыйк. Кем белә, бәлки, бәхете булып исән калса, кешеләргә үзе дә игелек кылыр...

Авыру аңында иде, Сергей Михайловичның бу сүзләрен тыныч кына тыңлый алмады ул:

— Гомерем булып, исән калсам, кешеләрне түгел, песи баласын да кыерсытмас идем! Терелт мине, доктор, терелт... Бу үләттән кем дә исән калмый, диләр, тик син терелт мине. Хәзинәмнең яртысын бирәм. Зәйнулла байның яшергән алтыннарын табып алдык без. Ал алтыннарымны, тик гомеремне генә саклап кал!

Шулчак авыруны озата килгән юлбасар урыныннан сикереп торды да:

— Әллә үзең белән алдыңмы алтыннарыңны? Үләсе кешегә ниемә ул алтын?! Үземә бир! — дип, кабалана-кабалана авыруның кесәләрен тентергә кереште. Берни дә тапмагач, авыруга ташланды:

— Кая яшердең алтыннарыңны, хәзер үк әйт! Юкса...

— Юкка борчылма, Фалис,— диде авыру тыныч кына.— Алтыннар барысы да Шахмайда. Ул бит үз өлешемне бирергә вәгъдә итте. Шуны әйтүем бу.

Авыру дөресен әйтмәде. Чынында ул, алтынны алып, яшереп куярга өлгергән иде инде. Аның кайда икәнен үзе генә белә ул! Үлә-нитә калса, алтын да аның белән «китеп барачак» ич! Башка беркем дә таба алмас аны.

— Их, исән каласы иде бит! Кадерле доктор, калдырма мине монда, ал үзең белән,— диде ул, ялварып.— Үзең белән ала күр!...

— Юлдашың озата барса, мин каршы түгел,— диде Сергей Михайлович,— күреп торасың ич, арбада урын тар.

Фалис җавап бирергә ашыкмады. Иң элек Шахмайның үзен күреп, алтын турында белешәсе килә иде аның. Аннары кантком, өязком урнашкан төбәкләрдән ераграк йөрергә ярата ул. Ә монда Минзәләнең нәкъ үзенә барырга кирәк. Шулар турында уйлады ул башта. Соңыннан, сыкрап булса да, ризалык бирде:

— Озата барам. Тик Минзәләгә кадәр генә, күпер чыкканчы. Аннары кире борылырга кирәк миңа.

Фалис сүзендә торды. Күпер чыгу белән капыл туктады да:

— Ярый, сәламәтләнә күр, Шәкүр. Докторга ышан син. Ә алтыннарың турында кайгырма, мин аларны Шахмайдан алып яшерү чарасын күрермен. Тик менә шушы ышаныч кәгазенә генә кул куйсаң иде. Так шту, һәммәсе дә тәртиптә булыр,— диде.

Шәкүр башта югалып калды. Аннары, үзен кулга алып, Фалис язган ышаныч кәгазен укып чыкты:

— Мин кул куям, Фалис, тик сак бул.

— Үзеңә ышанган кебек ышана аласың миңа,— диде тегесе һәм кәгазьне түш кесәсенә тыкты да тизрәк урман ягына элдертте.

Минзәләгә килеп җиттеләр. Шәкүр, һәр йортны күздән кичергәндәй, бик озак сүзсез барды. Тик ярминкә була торган мәйданга җиткәч кенә телгә килде:

— Карагыз әле, доктор, миңа, терелсәм дә, Минзәләдә калырга ярамый бит. Шахмай шайкасы төн җиткәч үк эзләп табачак мине. Бигрәк тә Фалис... Мин бит ялган ышаныч кәгазенә кул куйдым. Минем Шахмайдан берни аласым юк. Үземә тигән алтынны кичә үк яшереп куйган идем. Ни эшләргә соң инде миңа хәзер?

— Бер дә кайгырма, Шәкүр! Җаен табарбыз. Ышанычлы җиргә яшерәм мин сине. Шунда дәвалармын.

— Ә үзең? Синнән таптырырлар бит алар...

— Казанга озаттым, диярмен. Шуннан эзләсеннәр. Аннары, бездә Советлар власте юкмы әллә?

Көннәр үтә торды. Әмма Минзәләдә Шахмай шайкасы күренмәде. Шәкүр дә, Госман да сәламәтләнеп аякка бастылар. Озакламый Шәкүр солдатка язылды. Госман белән Хәмидәне исә Алабуга шәһәренә — балалар йортына алдылар.

* * *

Алабугада үткән көннәр ятим балаларның күңелендә мәңге җуелмас хатирә булып калды...

Бер кичне Госман китабын алды да Каманың иң биек ярына чыгып утырды: башта талгын гына аккан Чулманны күзәтте, аннары карашы ерексездән аргы якка — Минзәлә якларына төбәлде. Авылда кемнәр исән калды икән? Мотаһир ни хәлдә икән? Их, ул да бирегә, минем янда булса!.. Аңа да менә шушы икмәк үстерү турындагы китапларны укытыр идем. Нәрсә әйтер иде икән? Китапны язучы галим, бер башак үскән урында ике, өч башак үстерергә мөмкин булыр, дигән иде...

— Госман абый, Госман абый!

Сеңлесе Хәмидәнең кинәт эндәшүеннән Госман сискәнеп китте.

— Нәрсә булды тагын?

— Шахтада эшләгән, әти белән бертуган Гариф абыйны беләсеңме? Шул кайткан, безне авылга алып китәм, ди. Йорт-җирем, сәламәтлегем бар чакта нишләп туганымның балаларын чит җирләрдә йөртим, ди. Син ничек уйлыйсың, абый? Кайтыргамы, юкмы икән безгә? Бәлки, миңа калсам да ярыйдыр.

— Ничек дип әйтим... Монда да начар түгел ич. Ашаталар, эчертәләр, әнә нинди укытучыларның дәресләрен тыңлыйбыз. Китапханә бар, теләгән китабыңны алып укырга була. Ә бит авылда әле боларның берсе дә юк.

Госман үзе сөйли, үзе Хәмидәне күзәтә. Карашы үзгәрмәсме, янәсе. Хәмидә биредә үзе генә каласын сизенә иде. Дөресрәге, абыйсының авылга китәргә ризалык бирүенә һич кенә дә шиге юк иде аның. Шуңа күрә ул җавабын шаярта төшеп, ләкин кистереп әйтте:

— Хуш, Госман абый, исән-имин яшә. Ә мин сиңа һәр җәйдә кунакка кайтырмын, ярыймы?

Балалар йортында Гариф абыйлары аларны ачык йөз белән каршы алды.

— Йә, ничек, сөйләшеп, килешеп өлгердегезме инде? Мин сезне бит авылга алып китәргә дип килдем. Быел мәктәп эшли башлады. Аннары кантонда укырга була. Ашау-эчү ягы да бераз рәтләнеп килә.

— Мин кайтам, Гариф абый,— диде Госман,— ә Хәмидә калсын, биредә укысын, үзенең дә теләге шундый.

... Ак пароход кузгалып киткәч, әллә ни булды Хәмидәгә. Ялгызы гына калды түгелме ул биредә? Хәзер инде бердәнбер абыйсы, якын кешесе, янында булмаячак. Нишләргә соң? Әллә авылга кайтып китәргәме икән?

Хәмидә ашыга-ашыга интернатка кайтты да әйберләрен җыйнаштыра башлады. Үзе китапларын җыя, үзенең күзеннән бертуктаусыз мөлдерәп яшь ага. Калам дигәне генә ансат икән шул. Кала башлагач, бик үк рәхәттән түгел икән. Инде кузгалып чыгам дигәндә генә ишектә Шәкүр абыйсы күренде.

— Исәнме, сеңелкәш?— диде ул, елмаеп.— Госман кайда?

Хәмидә башта аптырап калды. Солдат киемендәге Шәкүрнең әле хәрби киеменә, әле кызыл йолдызына сокланып, ни дип җавап бирергә дә белми торды.

— Ә-ә, Госманмы? Авылга кайтып китте бит ул.

— Син дә авылга җыенгансың түгелме? Юк, беркая да бармыйсың, сеңлем. Моны теге вакытта безне аякка бастырган доктор абыеңның боерыгы дип кабул ит, ярыймы?! Ә менә бу хатны ничек тә Госманга җибәрергә тырыш. Очрашырбыз әле без аның белән. Кабатлап әйтәм, доктор абыеңның сүзен тот. Ярый, хуш, сеңлем!

* * *

Ул елны да яз иртә килде. Көннәр җылы торса да, авыл картлары гәпләштеләр-гәпләштеләр дә, тагын бер атнасыз кырга чыкмаска булдылар.

— Гариф абый,— диде Госман,— минем сиңа бер үтенечем бар иде. Быел чәчәчәк җиреңнең бер өлешен бүлеп миңа бирче, ә?

— Сиңа җир нәрсәгә, энем? Үземнеке бар чакта ач булмассың, бер дә борчылма!

— Аннан түгел, Гариф абый. Минем үз кулларым белән җирдә икмәк үстереп карыйсым килә. Рөхсәт ит инде, ә?

— Юк белән булышма, Госман. Җир эше синең эш түгел ул, әнә, сабагыңны укы, өйрән...

— Укыганымны сынап карыйсы килә дә инде, абый. Җиреннең бераз өлешен генә булса да тырмаларга рөхсәт ит, ә?

— Нәрсә, икмәксез калдырасың киләмени? Әнә кояш ничек кыздыра. Тырмаласаң, бусулар бер көндә корып бетәчәк. Ә болай кабык белән капланган туфрак җилләми, дымсу килеш тора. Ышанмасаң, өй артындагы түтәлне тырмалап күрсәтимме?

Гариф абыйсы бәрәңге бакчасына чыкты да, кул тырмасы алып, ике адым чамасы җирне тырмалады. Икәүләп күзәтә башладылар. Күп тә үтмәде, чынлап та, тырмаланган җир җилли, кибә, аксыл төскә керә барды.

— Күрдеңме инде, энем? Тырмалау файда китерсә, әнә Бәкер ише картлар эшләр иде инде аны...

Госман бирешергә теләмәде. Китапта язылганнарга ышанган иде ул. Тик менә Гариф абыйсын ничекләр генә күндерергә икән соң?

— Абый, үтенеп сорыйм, миңа жиреңнән кәчкенә генә өлеш чыгар инде. Укытучы абый кушты, аңа вәгъдә бирдем...

Гариф энесенең бу сүзләренә колак салмый булдыра алмады.

— Күпме җир кирәк соң сиңа?

— Кызганмасаң, күбрәк тә ярый.

— Эш бит кызгану-кызганмауда түгел, энем. Җирне эштән чыгармыйк, диюем. Ярар, ни язса, шул булыр. Чәчеләчәк кырны өч буй итеп бүл дә, берсен үзеңә ал.

Әй, сөенгәннәре Госманның! Төштән соң ул абыйсы кишәрлегендә иде инде. Тырманы җайлап куйды да атына йомшак кына эндәште:

— Әйдә, бахбай, кузгалып карыйк...

Гарифның йөрәге түзмәде: Госман бер әйләнеш ясаганда, ул кыр башында басып тора иде. Тырмалап төшкән иң беренче эзнең инде җилләп тә өлгергәнен күргәч, аның кәефе кырылды. Шулай да моны Госманга сиздермәскә тырышты:

— Йә, ничек, тырмалап буламы?

— Әйбәт тармалана. Җирнең нәкъ өлгергән чагы, өсте әле кабыкланып та җитмәгән,— дип, абыйсын тынычландырырга ашыкты Госман.— Күрерсең, бу җир әйбәт уңыш бирәчәк.

— Кеше үстергәннең хет яртысын ала алсак, диген. Синең хакка шуңа да канәгать мин, энем.

Үзенә тигән өлешне Госман кояш баеганда тырмалап та бетерде. Берара Гариф аны туктатырга да ымсынып караган иде, әмма баланың күңелен кайтарасы килмәде. Алабугадан үзе барып алып кайтты ич малайны. Аллага тапшырдык, ни булса, шул булыр...

Иртәгесен Госманның тырмага чыгуын бөтен авыл белде. Күпләр моны начарга юрады.

— Теге детдомнан кайткан малай быел Гарифны икмәксез калдыра икән,— диделәр кайберәүләр.

Кояш исә кыздыруын белә. Тырмаланган җир урыны-урыны белән инде ярыла да башлады. Авыл чәчүгә керешкән көнне Госман белән Гариф та кырга юнәлделәр. Моннан бер атна элек тырмаланган кишәрлекне күргәч, Гариф, башын тотып, аптырап калды: җир өстен ямь-яшел үлән баскан иде. Әмма Госман аптырап калмады:

— Үлән өстенә чәчәргә ярамый, абый. Тагын тырмалап чыгарга кирәк, чүп үләнне бетерү өчен.

Гарифның чын-чынлап ачуы чыкты. Кызып китүдән үзен чак-чак кына тыеп калды ул:

— Болай да корып беткән җирне тагын да корытыргамы? Аннары болай түгел, шайтан таягы да үсми анда, энем.

— Әгәр дә җир дымсыз булса, монда үлән үсмәс иде, абый. Күрәсең бит, котырып үскән. Димәк, дым бар. Тырмаларга кирәк, каршы килмә инде, абый җаным!

Хәзер, чынлап та, бүтән чара юк иде инде. Үлән арасына симәнә күмдереп уңыш алып булачак түгел. Кешеләр чәчә, болар үлән тырмалыйлар. Төш җитәрәк, Гариф янына авылның дәрәҗәле карты Бәкер килде:

— Кат-кат тармалап, юрган киптергән кебек киптерәсеңме җирне, Гариф? Кем инде мондый эштә бала-чага сүзенә карый, акылы бармыни аларның? Һич югы, тырмаланган өлешенә чәчеп кал инде бүген, анысы да катып, ярылып бара бит.

Бәкергә кайтарып сүз әйтә алмады Гариф. Авыл аксакалына нәрсә әйтсен ди ул? Шул арада Госман да әйләнеп килеп җитте. Гариф абыйсының йөзе үзгәрә баруын күреп, атын туктатты:

— Тр-р-р, бахбай! Әнә бабай да килгән. Әссәламәгаләйкүм, бабай!

— Вәгаләйкүмәссәлам, улым! Болай үзең тәртипле генә малай күренәсең күренүен. Тик нигә дип әле абзыеңның җирен бозасы иттең?

— Кем әйтә аны, бабай? Без менә үзебезчә, яңача эшләп карарга телибез.

— Җитте, Госман,— диде Гариф усал итеп.— Олы кешегә шулай әйтергә ярыймыни? Йомырка тавыкны өйрәтми бит.

Абыйсының бу сүзләреннән соң Госман алыштырып куйгандай булды. Дилбегәсен бер читкә ыргытты да, өстендәге тузаннарны каккалап, Гариф абыйсы янына килде:

— Җиреңне бозган булсам, кичер мине, абый. Ачуланып калма, хуш!

Аннары яшьле күзләрен җиң очы белән сөртеп алды да авылга таба йөгерде.

— Госман, кая киттең, Госман, дим?..

Госман исә артына да әйләнеп карамады. Бәкер карт, сакалын сыпыра-сыпыра, сүзсез генә үз кишәрлегенә юнәлде.

— Нишләргә соң инде хәзер?— Гариф аптырап калды.— Үләнле басуны тырмалап бетерәсеме, әллә чәчәсеме? Госманны да үпкәләттем. Тукта, яңадан Алабугасына китеп бармасын тагын. Гөнаһлы булырмын.

Гариф кайтып кергәндә, Госман, әйберләрен җыйнап, чемоданын әзерләп куйган иде инде.

— Мин китәм, Гариф абый,— диде ул гаепле бер кыяфәттә.— Ачуланма инде мине.

— Беркая да бармыйсың! Мин әтиең урынына калган кеше. Әгәр дә акыллы малай булсаң, син мине тыңларга тиеш. Ә җир турысына килгәндә, үлән баскан кишәрлек синеке — бөтенләй үзеңә бирәм, теләсәң нишләт. Моннан ары катнашмыйм.

— Рәхмәт, абый! Бу изге эшеңне беркайчан да онытмам.

Ул көнне кичкә кадәр бергәләп тырмаланмаган җирне чәчтеләр. Аннары кырда Госман үзе генә калды: үләнле кишәрлекне тырмалап бетерде, ә иртәгесен бодай чәчте.

Беркөнне Госман түзмәде, кишәрлегенә юнәлде. Килсә, үз күзләренә үзе ышанмады: башкаларга караганда бер көнгә соңрак чәчсә дә, аның бодайлары ямь-яшел булып тишелеп килә иде. Ул, шатлыгын кая куярга белмичә, тишелеп килгән шытымнарны сыйпады. Аннары абыйсы чәчкән кишәрлеккә юнәлде. Тукта, нишләп биредә бөртекләр начар тишелгән соң әле? Үсентенең төбен чокып карады. Бодай урынына аннан солыча килеп чыкты. Ниндидер кара солы...

— Нәрсә соң бу? Абый бит монда солы чәчмәгән иде. Бәлки, узган ел коелып калгандыр? Шулай булырга тиеш, чөнки тирәнрәк туфрактан чыккан...

Ә менә бодай шытымнары күтәрелеп килә! Шатлыгын абыйсына җиткергәндә, Госман солы турында искә алмаска тырышты. Ә менә беркөнне Бәкер карт аны үзе кырга чакырды. Бу вакытта инде бүтәннәрнең дә кишәрлекләре яшәреп килә иде.

— Барыбыз да бодай чәчтек, улым,— диде аңа Бәкер карт.— Синең җирдә бодай гына үсә, ә безнекендә бодае да, солысы да. Сәбәп нәрсәдә соң? Бәлки, аңлатып бирерсең.

Госман уйга калды. Теге китапта бу хакта нәрсә язылган иде соң әле? Тукта, тукта, тырмалаган җирдә нинди дер бер чүп үләне иртәрәк һәм тизрәк шытып чыга, дип язылган иде. Овсюг, ахрысы.

— Солы түгел ул, бабакай, авсюг дигән чүп үләне.

— Ә нигә соң синең кишәрлектә әпсүк юк?

— Нишләп булмасын? Теге көнне син мине тиргәгән чагында нәрсәне тырмаладым соң мин? Шул авсюг иде бит инде ул.

Госман бу сүзләрне шулкадәр ышанып һәм кистереп әйтте, теге көнне солычаны тырмалавына хәтта үзе дә ышанды. Бәкер картны исә мәсьәләнең икенче ягы борчый иде.

— Шулай да булсын ди. Ә нигә синең кишәрлектә, дым беткән булса да, бодай әйбәт тишелгән?

— Дым бетмәгән, тырмалагач, киресенчә, сакланып калган.

Бәкер карт йомшак туфракка бармакларын батырды. Аннары дымлы туфракны учына алгач, хәйран калды:

— Вәт могҗиза!.. Җен эшедер бу. Туфракны киптер-киптер дә, дымлы да булсын, имеш. Гаҗәп, гаҗәп...

Бәкер картның сер бирәсе килми иде. Аннары, борын асты да кипмәгән малай алдында ничек җиңелеп калмак кирәк? Шуңа күрә бу турыда ул кеше-карага әйтеп тормады. Әмма күз алдындагы әйберне яшереп буламыни? Кемдер кичә Госманның кишәрлеген күреп кайткан да хәбәрне бөтен авылга тараткан ич әнә.

Бәкер картка акланудан бүтән чара калмаган иде:

— Җен эшедер бу. Мондый хәлләр булгалый. Кяферләр мәктәбендә укыган бит. Анда малайны тәгаен җен котырткандыр...

Бәкер картның бу сүзләре Госманны рәнҗетте. «Иң яхшысы Алабугага барып, теге китапны тагын да әйбәтрәк өйрәнеп кайтырга кирәк»,— дип уйлады ул бу минутларда.

Иртәгесен Алабугага барып җитте. Сеңлесе Хәмидә аның сөйләгәннәрен тын да алмый тыңлап утырды. Китапны табып, солыча турында язылган битләрен кат-кат укыдылар. Кайбер урыннарын Госман дәфтәренә күчереп тә алды. Бер урында ап-ачык итеп: «Тырмалаган җир алданрак җылына, шунлыктан анда солыча иртәрәк тишелеп чыга»,— дип язылган иде...

Хәмидә, кинәт нәрсәнедер исенә төшергәндәй, сүзне икенче якка алып китте:

— Абый, син теге вакытта Шәкүр абый язган кәгазьне алдыңмы?

— Алдым, Хәмидә. Бер үтенечен язган иде ул анда: «Кем белә, бәлки, сугыштан әйләнеп кайтып булмас,— дигән иде хатында,— иң ышанычлы кешем син. Көрәш кырында ятып калсам, яшергән алтыннарым бер мәгънәсезгә югалмасын. Син аны эзләп тап һәм икебез исеменнән дәүләт органнарына илтеп тапшыр!» Ә бит ул урынны болай гына табып булмый, сеңлем. Нинди дә булса берәр төрле ачкычы булырга тиеш аның.

— Дөрес әйтәсең, абый. Ә беләсеңме, бар иде бит ул. Минем китаплар арасыннан юкка чыкты...

— Нигә аны вакытында хәбәр итмәдең? Алтыннан җилләр искәндер инде хәзер.

— Бездән башка ул урынны беркем дә таба алмастыр. Чөнки Шәкүр абый «ачкыч»ның кереш өлешен телдән генә әйтте. Хәтерлисеңме, теге вакытны, доктор Сергей Михайлович белән авылдан Минзәләгә килгәндә, безне Шахмай туктаткан иде. Күпер төбен әйтәм. Әнә шул күпердән яр читe буйлап туп-туры коньякка таба барырга кирәк. Берәр чакырым чамасы баргач, матур бер аланлыкка килеп чыгасың. «Ачкыч» әнә шул урынны тапкач кына ярдәм итә ала.

— Ә «ачкыч»ны хәтерлисеңме соң?

— Тулысынча хәтерләмим. Шулай да бераз өлеше истә калган.

— Йә, әйтеп кара.

— Шул аланның төньягында бер карт имән үсеп утырыр. Шул имәннең төбенә басып, кичке сәгарь биштә туп-туры кояшка таба йөз адым атласаң, юкә агачына тап булырсың.

Юкә күләгәсе беткән урын яңа ориентир булып тора... Шунда кадәресе истә калган. Башкасын онытканмын. Тукта, тукта... Юкәнең күләгәсе беткән урыннан күпергә таба ничәдер адым атларга кирәк: илleme, кырыкмы... Инде анысын төгәл генә хәтерләмим. Аннары тагын шартлы өч сан бар иде анда. Менә шуның серенә төшенсәк...— диде дә Хәмидә нидер эзли башлады.

— Шартлы саннар, дисең... Хет шулары исеңдә калмаганмы соң?

— Менә таптым, күчереп алган идем,— дип, Хәмидә ниндидер саннар язылган кәгазьне абыйсына сузды. Госман исә озак кына аларның серенә төшә алмый азапланды. Анда «Ш 40-К 50-Т февраль» дигән хикмәтле сүзләр, саннар язылган иде. Бертын утыргач, ул, көлемсерәп, сеңлесе янына килде.

— Катлаулы берни дә юк икән монда, Хәмидә. Шәрыкка кырык адым, аннары көньякка илле адым һәм төрьякка февраль озынлыгы, ягъни 28 адым ясарга кирәк, диелгән. Шәкүрнең байлыгы шунда ятадыр. Бүген минем өчен алтыннан да мөһимрәк, кадерлерәк нәрсә бар. Әгәр күрсәң икән — шундый матур булып тишелде бодайларым! «Алтынны кесәңә салсаң, икмәкне йөрәгеңә кыс»,— ди халык. Бик дөрес әйтелгән сүзләр. Ярый, мин тиздән китәрмен, сеңлем. Хуш хәзергә!

Госман Алабугадан кайтып килгәндә, каланча янына бер төркем картлар җыелган иде. Бәкер карт та, хәтта волком рәисе Вилданов та шунда иде.

Хәмәй абыйсы, аны күргәч, ымлап, үзе янына чакырды:

— Йә, хәлләр ничек, Госман энем?— диде ул елмаеп.— Җен алыштырган кишәрлегеңнең серен аңлатып бирәсеңме әллә безгә.

Аннары ул, картларга таба борылып:

— Йәгез, җәмәгать,— диде.— Бәкер картны тыңладык, инде хәзер Госманны тыңлап карыйк. Икмәксез йортның морҗасыннан төтен чыкмавын да, бер валчык икмәкнең алтыннан кадерлерәк булуын да яхшы беләдер ул.

«Алтын» дигән сүз чыккач, Госман сискәнеп китте. Теге вакыйганы әллә Хәмәй абый да белдеме икән? Серне болай озак тик яткыру ярамас. Эзләп карарга кирәк, бәлки, табылыр да...

Госман, ниһаять, уйларыннан арынып, сүз башламакчы булып авызын ачкан иде, күзләре Бәкер карт күзләре белән очрашты. Тегесе, нидер сөйләнеп, җиргә төкерде. «Җен алыштырган нәрсә», — дип сүгүедер инде...

— Әллә ни шаккатарлык нәрсә юк биредә,— диде Госман.— Солычаны әйтәм, тармалаганны ипләп кенә көтеп ята ул. Ник дисәң, тырмалаганнан соң аңа үсү өчен шартлар яхшыра, җир җылына, «куркыныч» та үтә. Чөнки безнең игенче, гадәттә, тырмалаган көнне чәчкән яисә чәчкән арты тырмалый барган. Башкача җиргә кагылмаган. Ә солычага шул гына кирәк. Үзе рәхәтләнеп үсә, бодайны кысрыклый, аңа үсәргә ирек бирми. Ә без, абый белән иртә тырмалап, аны «алдадык», куркыныч үтте дип белеп, ул ныграк үсә башлады. Шул чакта, тагын тырмаладык һәм юк иттек без аны.

— Әкият сөйләмә син безгә,— диде шулчак Бәкер карт, артык түзә алмыйча.— Ходай яраткан үләнне ничек алдап, хәйләләп булсын ди аны? Халыкка көфер сүз таратма!

— Бәкер ага,— диде Госман тыйнак кына,— безнең кишәрлеккә килеп үзегез күрдегез: дым да бар, солыча да беткән. Дөреслекне танырга туры килә.

— Җен эше бу. Кяферләр детдомында җен алыштырган сине, улым.

— Чынлап та, моның җен эше булуы ихтимал,— дип сүзгә кушылды Салих бай.— Андый икмәкне ашау кемгә дә хәрәм.

— Сезнең сүз закон түгел хәзер, кем, Салих мелла. Авыл картларын тыңлыйк. Алар ни дияр бит әле?

Сүзгә җәһәт кенә дусты Мотаһир кушылды:

— Дөрес әйтәсең, Госман. Теге вакытта шушы Салих мелла таларга килгән иде бит инде сезне, хәтереңдәдер. Имеш, мәрхүмә Сания апаның аңа бирәчәге калган. Менә кем ул хәрәм байлык туплаучы! Салих кебекләр сүзе безгә чүп хәзер. Үз кишәрлекләребезне Госман әйткәнчә эшкәртсәк, дөресрәктер.

— Хак әйттең, Мотаһир,— диде волком рәисе.— Яңалыкка йөз белән борылырга вакыт...

Халык таралырга ашыкмады.

— Рәхмәт, улым, Хафиз абыеңа охшагансың,— диеште картлар.— Тик шунысын әйт, синеңчә эшләсәк, чынлап та икмәкле булырбызмы без?

Госман исә: «Булыр, агайлар, ышана аласыз»,— дигән кебек ипле генә итеп башын какты да волком рәисенә текәлде. Тегесе аны шунда ук төшенеп алды:

— Җирнең кадерен белсәң, аның турында кайгыртсаң, һичшиксез икмәк уңар, агайлар,— диде Хәмәй Вилданов.

Картлар акрынлап тарала башлады. Бу вакытта Госман күңеле белән Аю урманында йөри иде инде. Иртәгә үк шунда булырга кирәк.

... Менә ул Аю урманы. Инде төш вакыты узып барса да, ниндидер сәер бер тынлык. Хәтта кошлар да аваз салмый. Теге таныш күпер янына җиткәч, дусты Мотаһир белән бергә, яр буйлап урман эченә атладылар. Бераз баргач, Госман ау мылтыгын Мотаһирга сузды:

— Син шушында кал. Чит кеше күренсә яисә ул-бу булса, хәбәр салырсың.

— Мин синнән калмыйм, Госман. Ничек инде ялгызыңны Аю урманына җибәрим? Азмыни монда Шахмай шайкасы калдыклары, төрле җилкуарлар, кеше талап йөрүчеләр?

— Тыңла, Мотаһир! Беләсеңме, шулай кирәк. Син шушыннан торып күзәтергә тиеш мине. Үзең сак бул! Ярыймы?..

Госман урман эченнән инде ялгызы гына атлады. Озакламый аның каршында Якты Алан калкып чыкты. Сәгать дүрт җитеп килә. Иң элек ул аланлыкның төньягына күз ташлады. Анда колачлы карт бер имән үсеп утыра иде. Моңа кадәр Госман күргәннәрнең иң мәһабәтенә, иң олкәненә охшаган иде бу. Нинди генә елларны, нинди генә җирләрне, нинди генә яуларны күрмәгәндер бу имән. Әмма үзе, берни дә булмагандай, горур утыра. Бодай тамырлары да имәннекедәй көчле, табигать көйсезлекләренә бирешми торган булсын иде ул. Кешеләр беркайчан да ачлыкны белмәсләр иде...

Госман кинәт айнып киткәндәй булды. Монда хисләргә бирелергә ярамый. Хәмидә югалткан «ачкыч» кем кулына барып эләккәндер бит әле? Шундый уйлар белән ул кояшка таба йөз адым атлады. Әмма каршыда бернинди дә юкә агачы күренми иде. Үңдарак калды, ахрысы. Чөнки әле биш туларга шактый вакыт бар. Биш тулгач кына кояшка таба туп-туры барырга кирәк. Ашыкты шул, котәргә вакыт юк бит. Бераз уң яккарак тайпылып, юкә агачын эзләвен дәвам итте Госман. Ләкин якын-тирәдә бер генә юкә агачы да күренми иде. Янә уңышсызлык... Бәлки, юкә булмагандыр ул? Элмә яисә каендыр? Усаклар да күп монда. Аннары Шәкүр абыйның ялгышуы да бар бит. Тагын теге имән янына барып, кояшка туп-туры йөз адым атлау кирәктер.

Госман янә әлеге мәһабәт имәнгә таба китте. Кояшка карап басты да тагын алга атлады. Тагын йөз адым үтелде. Туктады. Өч метрлар чамасы сулдарак карама агачы утыра, уңда — каен. Ә юкә күренми. Эзләүне каеннан дәвам иттерергәме, карамаданмы? Кайсысын сайларга? Карама тәбәнәк, каен — озын, күләгәсе ерак сузылган...

Каенга таба атлауга, Госманның күзләре үлән арасында яткан юкә ботагына төште. Димәк, ул табарга тиешле юкәне кискәннәр. Төбе шушы тирәдә булырга тиештер... Менә ул! Төптән үк киселгән, өстен иске яфраклар белән каплап куйганнар. Димәк, серненң эзенә төшкәннәр. Әллә Шәкүр абый үзе булдымы икән биредә?

Нишләргә соң? Эзләүне дәвам иттерергәме, әллә кайтып китәргәме? Дәвам итәр өчен иң элек юкәнең биеклеген белергә кирәк ич. Ә ничек? Госман киселгән юкә төбенә иелде, юанлыгын үлчәп маташты. Тукта, киселгән теге юкә агачын әллә ни ерак ташламаганнардыр әле. Шуны эзләргә кирәк... Әнә ич, чокыр төбендә ята икән.

Госман юкә агачын күтәрим дип иелгән иде, урманны тутырып мылтык тавышы яңгырады. Аңа җавап төсендә ату тагын кабатланды. Монысын Мотаһир атты, ахры... Ату тавышына аның: «Авылдаш, сак бул!» — дигән сүзләре кайтаваз булып кушылды.

* * *

Ул вакыйгалардан соң байтак сулар акты.

Язмыш диген... Ничә еллар үткәч кенә изолятор шифаханәсендә кабат очрашты алар. Госманның хәле шәптән түгел иде. Шуңа күрә Мотаһирны башта аның янына кертмәскә булдылар. Әмма Мотаһир исеме колагына кергәч, Госман айнып киткәндәй булды. Рөхсәт итмәүгә карамастан, урыныннан ук торып утырды:

— Яшьлек дустым Мотаһирмы ул? Кертегез үзен, үтенеп сорыйм, кертегез,— диде һәм койкасыннан ук төшә башлады.

— Кертегез, алайса,— диде күзәтүче врач.— Монда икенең берсе: йә хәле яхшырып китәчәк, яисә...— Докторның калтырап киткән тавышына игътибар иткәндә, ул үзе дә, Госманның күрешүгә булган омтылышын күреп, нык дулкынланган иде.

Ишектә Мотаһир күренүгә, Госман дустына таба омтылды, күзләрендә бу очрашуның никадәр әһәмиятле булуын сөйләүче очкыннар пәйда булды. Мотаһир доктор белән баш кагып исәнләште дә, авылдашына кулларын сузды:

— Исәнме, Госман! Хәлләрең ничек? Нәрсә булды сиңа, дускай?

— Булды инде, Мотаһир. Без күргәнне бүтәннәр күрмәсен. Синең тавышны ишеткәч, яшьлек елларыма кайткандай булдым. Их, яңадан башлыйсы иде гомер юлын, Мотаһир!.. Кешеләрне танырга өйрәнәсе иде... Шуның аркасында күпме ялгыш ясалды.

Сөйләшүнең мондый юнәлеш алуын күргәч, доктор чыгарга булды. Әмма ишекне кабат ачып:

— Озак тормаска тырышыгыз, авыруны борчырга ярамый,— диде.

Сүзне Мотаһир дәвам итте:

— Мин синең баштан ниләр үткәнлеген шактый яхшы беләм. Шуңа күрә бүген алар хакында сөйләшеп, сине борчыйсым килми. Шулай да синең өчен бер яңалык әйтмичә булдыра алмыйм. Хәтерлисеңме Аю урманында булган вакыйганы?

— Хәтерлим, Мотаһир, хәтерлим. Әле бүген дә күз алдымнан бер-бер артлы тезелеп үтте ул көннәр...

— Хәтерләсәң, әйт әле, ул чакта безгә кем атты дип уйлыйсың?

— Белә алмадык без моны, Мотаһир. Мәңге ачылмас сер йомгагы бу хәлләр... Шәкүр көрәш кырында һәлак булды. Алтынны да таба алмадык. Аткан кеше дә билгесез калды.

— Калмады, Госман, калмады,— диде Мотаһир, пышылдауга күчеп.— Ул кешене кичә кич Казанда очраттым. Күргәч, артыннан калмыйча күзәттем моны... Мунчага керде бу. Мин — аның артыннан. Беләсем килә: улмы, түгелме? Шунда бүре ядрәсеннән чәрдәкләнгән иңсәсен күрдем. Теге чакта шәп эләккән икән үзенә!

— Ул, дисең, алайса? Шулай да бу хакта ныклап уйларга кирәктер. Хәзергә ашыкмыйк, Мотаһир. Менә миннән сорау алган тикшерүче дә бик таныш кебек. Шәкүр абыйны озата килгән Фалиска бик охшаган. Ләкин шикләнәм. Ялгышып куюыбыз бар.

— Бәлки, бер үк кешедер болар?

Госман уйга калды. Шулчак ишектә доктор күренде:

— Хөрмәтле иптәш, бүгенгә җитеп торыр. Авыруны тынычлыкта калдырыгыз.

— Кайтыр җирем ерак шул, доктор. Бер киткәч тиз генә килеп булмый. Ә Госман минем яшьлек дустым, авылдашым. Бер бәрәңгене урталай бүлеп ашый идек...

Аннары, саубуллашып, болай диде:

— Нык бул, Госман, бирешмә! Тизрәк аякка бас!

— Рәхмәт, Мотаһир! Онытмавың, якын итеп килүең өчен рәхмәт!

Мотаһир урамга чыкты. Көнбатыштын күе кара болытлар күтәрелеп килә иде. Давыл алдыннан була торган тынлык. Черек күл буенда кайнашкан биш-алты бала-чаганы исәпләмәгәндә, якын-тирәдә берәү дә күренми. Кешеләр Черек күл буена урнашкан бу дәһшәтле биналар тирәсеннән үтәргә куркалар иде, ахрысы... Мотаһир, Госман яныннан чыккач, үзен-үзе битәрләп алды: «Берәр ничек ярдәм итеп булмыймы икәнни соң? Гаепсез кешене ничек инде гаепле дияргә мөмкин? Нинди заманда яшибез? Үз күләгәңнән үзең куркып йөр инде!..»

Шулчак урам почмагында өстенә гимнастерка, галифе чалбар, башына ак фуражка кигән берәү күренде. Ул, бераз уң аягына аксый-аксый, «кыямәт» бинасына таба борылды. Мотаһир утырган эскәмия янына җиткәч, алар күзгә-күз очраштылар. Мотаһир тыелып кала алмады:

— Фалис иптәш! — дип дәште.

Тикшерүче сискәнеп китте. Әмма шундук үзен кулга алып, юлын дәвам итте.

— Фалис иптәш,— диде кабат Мотаһир, урыныннан торып.— Сезне бер генә минутка мөмкинме?

— Ялгышасыз, мин Фалис түгел. Кем беләндер бутадыгыз, ахры...

— Аю урманын искә төшерегез... Бүре ядрәсен...

— Берни дә аңламыйм...— Тикшерүче бирешмәскә тырышса да, аның каушап калганы сизелә иде: йөзе, күзләре үзгәреп китте. Аңлатып сөйләгез: нинди Аю урманы? Нинди ядрә ул?

Мотаһир, һөҗүмгә күчеп, турыдан кистерде:

— Хамелеон! Кеше талаучы, ат карагы син! Беренче генә көн күзәтмим мин сине. Менә нәрсә: күп сүз — юк сүз. Кыска тотам. Әгәр дә бер гаепсез Госман Закировны иреккә чыгармасаң, башың Себер киткән дип исәплә! Бүре ядрәсен онытма! — Мотаһир башка бер сүз дә эндәшмәде. Кызу-кызу атлап Черек күл аша чыкты да Университет урамына күтәрелде. Яңгыр коя башлагач, юлаучы машинага утырып, вокзалга килде. Аның Мәскәүгә китеп барышы иде.

...Тикшерүче Фалис эш урынына кереп утырырга да өлгермәде, аны дежур офицер дәште:

— Сезне телефонга чакыралар. Министрлыктан, диме?..

Трубкада Мотаһирның таныш тавышы ишетелде:

— Йә, ничек, уйладыңмы?

Тикшерүче як-ягына каранып алды: шикләнә иде ул. Үч иткәндәй, бүлек начальнигы да биредә. Аннары бу сөйләшүне тыңлап тормаслар дип кем әйтә ала? Шуңа күрә ул кыска тотты:

— Борчылмагыз, сез әйткәнчә булыр,— диде дә трубканы куйды.

Мотаһир шул сөйләшүдән Мәскәүгә китеп барды. Госманны исә, ни гаҗәп, сорау алырга бүтән чакырмадылар. Нигә, ни өчен? Сәбәбе аңа билгесез иде. Дөресрәге, гаебе булмагач, аклаганнардыр дип уйлады.

Госман тулай торакка — гаиләсе янына кайтып кергәндә, хатыны Гөлфия Черек күлгә барырга җыенып йөри иде. Ирен күргәч, куанычыннан яшьле күзләрен сөртә-сөртә, аңа ташланды. Уллары Алик исә берни белми йоклап ята иде.

* * *

Гаҗәеп бер матур иртә. Урман өстеннән кояш күтәрелеп килә. Бөтен җир яшеллеккә чумган. Өстә, биектә тургайлар сайрый, чәчәктән чәчәккә кунып күбәләкләр уйный, бал кортлары тырышып-тырышып бал җыя. Нинди генә җан иясе юк биредә... Әнә шулай бөтен табигатькә, серкә очырып утырган арышларга, баш чыгарып килгән бодай кырларына соклана-соклана Госман тәҗрибә кырына килде. Кишәрлекләр янында беркем дә күренми. Хәер, бүген бит ял көне — сабан туе.

Госман ап-ак чәчәккә күмелгән борчак кишәрлекләре янында тукталды. Нинди генә сорт, нинди генә гибрид юк биредә. Аны бигрәк тә утыз сигезенче номерлы кишәрлек кызыксындыра иде. Ышанычы ул Госманның. Узган ел да сынатмады: кузаклары эре, һәр кузакта сигезәр-тугызар борчак булды. Кузаклар саны да күбрәк булды. Быел көзгә сортларны сынау комиссиясенә тапшырасы булыр...

Госман кайтыр якка борылды. Онытып язган икән, Гөлфия бүген Каенлыкка — сабантуйга чыгабыз, дигән иде бит.

Ул кайтканда, Гөлфия дә, Алик та җыенып беткәннәр иде инде.

— Ашарга әзер, Госман, капкалап ал да, киттек.

Шулчак телефон шылтырады. Трубкада Мотаһирның дулкынланган тавышы ишетелде:

— Бөтен планнар җимерелде, Госман. Сугыш... Инде Киевны бомбага тоталар, кабахәтләр. Тиздән фронтка китәм. Күрешә алмасак, хуш, авылдаш... Гөлфиягә күп сәлам...

Бу хәбәрне ишеткәч, Гөлфия, өнсез калып, диванга утырды. Алик мөлдерәмә тулы күзләрен әле әнисенә, әле әтисенә төбәде...

Госман бу сугышның котылгысыз икәнен абайлый иде. Әмма Мотаһир җиткергән хәбәр аның өчен көтелмәгәнрәк булды. Нәрсә эшләргә соң инде? Әллә хәрби комиссариатка барып караргамы? Сугышка үз теләгең белән китү начармыни? Ә гаилә, фәнни эш, дуслар?.. Алик та әле бик кечкенә. Гөлфия? Ул моны ничек кичерер?

Хәрби комиссариат бинасы янында халык гөж килә. Ничек кенә тырышса да, Госман хәрби комиссар янына үтә алмады. Гаризасын дежурныйга тапшырды. «Мине хәрәкәттәге армиягә җибәрүегезне үтенәм. Трактор йөртә беләм. Винтовкадан атам. Теләсә нинди приказны үтәргә әзер» — дип язды ул.

Хәрби комиссариатка Госманны өч көннән генә чакырдылар.

— Гаризагызда сез кайда, кем булып эшләвегезне, белгечлегегезне күрсәтмәгәнсез,— диделәр аңа.— Хәзерге көндә кайда эшлисез?

— Мин фәнни хезмәткәр. Селекционер. Быел республикабыз кырларына яңа сорт бирергә исәплибез. Хәер, анысын миннән башка да ахырына кадәр җиткерерләр дип ышанам.

Комиссар тиз генә каядыр шалтыратты да:

— Теләгегезне канәгатьләндерә алмыйм. Югарырак мөрәҗәгать итегез,— диде һәм өстәп куйды:— Сез монда фронттагыдан күп өлеш артыграк файда китерә алыр идегез, иптәш Закиров. Уйлагыз...

* * *

**1941** елның августында Госман хезмәт иткән укчылар дивизиясе Вязьма районына килеп тукталды. Тиздән алар беренче сугышчан чирканчык та алдылар.

Ул көнне Госманнар ротасына яуланган биеклекне ничек тә фашистларга бирмәскә дигән бурыч куелган иде. Пулемет взводын алгарак күчереп тә өлгермәделәр, немецлар, дивизиянең елга ярына сыенган алгы подразделениеләрен туктатырга теләп, еракка ата торган туплардан давыллы ут ачтылар.

Рота командиры, яңа гына училище тәмамлап килгән яшь кенә лейтенант, бер ут ноктасыннан икенчесенә күчеп, солдатларның рухын күтәрергә тырышты:

— Әйдә, интеллигенция, дөмектер фашистларны!

Лейтенант ополченецларга үзенә бертөрле ихтирам белән карый иде. Чөнки аларның күбесе — лейтенантның әтисе яисә бабасы яшендәгеләр. Батальон командиры аңа ополченецлардан торган өстәмә көчне тапшырганда кистереп әйтте:

— Син, лейтенант, кара аны, кеше бул! Монда синең ротада хәзер биш кандидат, өч доктор, бер профессор. Әнә теге чандыр гына, мыеклы абзыйны күрәсеңме? Мәскәү университеты профессор Василенко ул. Ә менә бу төп кебек таза, нык абыең Казаннан, кандидат Госман Закиров. Окоп янында тәмәке көйрәтеп торганы шулай ук фән докторы, танылган галим...

— Нигә кирәк миңа бу кадәр доктор?— диде лейтенант, сөйләп бетергәнне дә көтмичә.— Хәзергә берсе дә житкән. Санинструктор бармы? Бар. Менә дигән кыз. Ут кебек. Берүзе дә өлгерәчәк ул. Ә бу докторларны бүтән роталарга җибәрсеннәр.

— Их син, лейтенант! Болар дәвалый торган докторлар түгел, ә галимнәр. Төшендеңме?

Бу сөйләшүдән соң лейтенант Госманны күздән ычкындырмады.

— Молодец, әйбәт сылыйсың, иптәш Закиров. Әллә Гражданнар сугышында да катнашырга туры килдеме үзенә?

— Әләкмәдә диярлек. Ә менә җәнлек ауларга йөрата идем. Бушка киткән патроннарым булмады шикелле. Ә монда, үзегез беләсез, лейтенант, аерата сакчыл булырга кирәк.

Госманның бу ротага эләгүе очраклы гына килеп чыкты. Мәскәүдә чакта университетка йомыш белән кергән иде. Анда халык ополченецларыннан торачак махсус дивизиягә язылу бара икән. Госман да, озын-озак уйлап тормыйча, шуларга кушылды.

Мәскәү ополченецлары, нигездә, интеллигенция вәкилләре иде. Үзләренең институтларын, кафедраларын, лабораторияләрен, ачылып җитмәгән ачышларын калдырып, өсләренә шинель киделәр дә Мәскәү каласын фашисттан сакларга күтәрелделәр. Үзләрен бимазалаган төрле-төрле чирләрен онытып торып, хәзер менә дошман белән көрәшәләр, аның алга баруын азга гына булса да тоткарлап торалар. Винтовка һәм автоматлардан аталар, яндыргыч шешәләр ыргытып, «тигр»ларны шартлаталар, атакага күтәреләләр, пулемет утына эләгеп егылалар...

Атышлар тынган арада сугыш бөтенләй онытылып киткәндәй була. Алар, бәхәсләшә-бәхәсләшә, йә фән дөньясына кереп чумалар,

йә Пушкин, Блок шигырьләрен укый башлыйлар, яисә Декарт һәм Монтескье философиясен, Эйнштейн теориясен тикшерәләр.

Ул көнне тынлык озаккарак сузылды. Гәпләшергә генә түгел, улы белән хатынына хат язып салырга да вакыты табылды Госманның.

**«Кадерлеләрем минем Алик, Гөлфия! Менә сезгә хат язам. Кайда диген, кайчандыр безнең Буранчы кебек шау-гөр килеп торган бер авыл читендә. Тик инде биредә җан әсәре юк, йортлар урынында янып бетмәгән кисәүләр генә көйрәп ята. Җан әсәре юк диюем бик үк дөрес булып бетмәс, әнә, урман ягыннан бер мәче кайтып килә. Хуҗасын күрергә теләгәндер, мөгаен. Ләкин ул аны инде беркайчан да күрә алмас...**

**Үзегез ничек яшисез? Хатларымны ешрак язарга тырышырмын. Кызу сугыш әле монда.**

**Кичә генә командирыбызга унтугыз яшь тулды. Дамирдан нибары өч яшькә генә олы. Күрше Дамирны әйтүем. Аның кебек, кыюлыкны Казан урамында хулиганлык кылып түгел, ә эш белән, көрәш белән исбат итәргә кирәк. Моны онытма син, Алик. Болар матур сүзләр түгел, ә сугыш тынган арада башка килгән уйлар. Борыныңны салындырма, әниеңә булыш, ярыймы?**

**Минем өчен борчылмагыз. Әтиегез сугышырга өйрәнеп килә инде. Ашыгам, почтаны алып китәргә җыеналар. Хуш, Гөлфия! Хуш, улым! Әтиегез».**

Бу хат, озын-урау юллар үтеп, Казанга бик соңарып кына барып җитте.

Көттереп килгән хатны ачканда Гөлфиянең куллары калтырады. Хатны кат-кат укыдылар, туганнарына, Госманның сеңлесе Хәмидәгә шылтыраттылар: «Аллага шөкер, исән-таза, барыгызга да сәлам юллый»,— диделәр. Шул ук көнне иске дәфтәр битенә Гөлфиянең саф йөрәктән чыккан сүзләре тезелде:

**«Кадерлем минем! Менә зарыгып көткән хат минем кулымда. Сине ничек сагынганымны белсә идең, Госман! Үзең дә беләсең, синнән башка минем тормышымның мәгънәсе юк. Үтенәм, сак бул! Үзеңне безнең өчен, киләчәк өчен сакла. Бу сүзләр, бәлки, сәеррәк яңгырар. Гафу ит. Мин бит гомеремдә беренче тапкыр ялгыз калдым...**

**Барысын да син өйрәткәнчә эшләргә тырышам: артык нәрсәләрне оборона фондына бирдем. Тик син бүләк иткән йөзекне калдырдым: бик тә кадерле ул миңа.**

**Ә хәзер хатны Аликка бирәм, ул дәвам итә:**

**Исәнме, әтием! Кичә көне буе дежур тордым. Караучысыз калган апаларга, абыйларга су китердек, утын кисештек.**

**Әтием, күршебез Дамир турында башкача алай уйлама. Ул бик үзгәрде хәзер, кыерсытылган һәркемне яклый. Әгәр дә мөмкин булса, иң элек Гитлерның үзен дөмектерер идем, ди. Кичә генә әле күрше Галләм бабайның ишеген төзәтеп бирде. Хәзер инде фронтка китәргә ашкына, тик алмыйлар гына...**

**Ешрак яз, әтием. Кайнар сәлам белән, улың Алик».**

Бу хатны Госман сентябрь башларында алды. Һәр карыш җир өчен каты сугышлар бара иде. Ул көнне алар Вязьма якларындагы урман авызына урнашкан икенче бер авылның яшелчә саклау складлары янында тукталдылар. Атларны исә окоплардан көньяк-көнбатыштарак урнашкан таш сарайга яптылар.

Ул көнне Госман озак кына йокыга китә алмады. Йокымсырауга, улы күз алдына килеп аптыратты. Менә инде ул яп-якын, каршыда гына. «Әтием, мин сине бик тә сагындым»,— дип аның муенына сарыла кебек. Җылы сулышы йөзгә кагылгандай була. Госман, күзләрен киң ачып,

караңгылыкка текәлә. Алик исә, эрегән кебек, кинәт күздән югала. Күзләре йомылырга да өлгерми, тагын улы күз алдына килеп баса...

«Әллә бер-бер хәл булдымы Алигыма?» — дигән шомлы уй килде Госманның башына. Әллә авырып киттеме? Нәрсәдер әйтергә, ниндидер хәбәр җиткерергә тели бит, балакаем. Юкса, бу кадәр дә йокымны бүлмәс иде...

Инде таң беленеп килә иде. Кинәт якында гына ату тавышлары яңгырады. Кемдер: «Тревога! Фашистлар безне камарга омтыла!» — дип кычкырды. Госман, йөгерә-киенә, бу хәбәрне бүтәннәргә җиткерде.

Таш сарай янында пулемет тыкылдый башлады. Ике ополченец шундук җиргә егылды. Пулеметның кайдан атканын абайлагач, башкалар иске канау буйлап урманга таба чигенә башладылар. Урман авызына кергәндә, тагын икәү яраланды. Берсе — галим Василенко әле исән иде. Аның янына тагын бер яралыны алып килделәр.

— Закиров, Шәрәпов! — диде лейтенант.— Сезгә менә бу ике яралыны Упкын сазлыгы аша үзебезнекеләр ягына чыгару бурычы йөкләнә!

Сазлык янына төш алдыннан гына килеп җитте алар. Менә нинди икән ул Упкын! Моның аркылы яралы белән түгел, ялгыз гына үтә алуың да бик шикле. Әйтүләре буенча, монда кайдадыр тар гына түмгәкле бер сукмак бар икән барын...

Сукмакны эзләп тапканчы шактый гомер үтте. Аннары яралыларны шунда күчерергә булдылар.

— Мин бик арыдым,— диде Шәрәпов Госманга.— Сез атлый торыгыз, без соңрак кузгалырбыз.

— Тик озаклама, бергә-бергә юл җиңелрәк була ул,— диде дә Госман, яралыны алып, Упкын сукмагына атлады.

Аяк астындагы түмгәкләр дерелдәп тора. Һәр адым зур кыенлык белән үтелә. Өч йөз метр чамасы ара үтүгә, яралы аңына килде.

— Су! — диде ул.— Су бир, янам...

Фляга төбендә калган соңгы йотым суны яралыга сузды да Госман сорап куйды:

— Сугышка кадәр кайда эшләгән идең, Николай Сергеевич?

— Доктор Василенко лабораториясендә. Әйбәт кеше, кешелекле кеше. Сезнең Казан галимнәренә дә күп булышты ул...

— Доктор үзе дә синең хәлдә — яралы. Шәрәпов белән Упкын читендә калды.

Николай Сергеевич нәрсәдер сорамакчы булган иде, күктә немец самолетлары күренде. Ополченецлар позициясен бомбага тота башладылар. Тирә-юнь гөрелтегә, шартлап сынган агачлар тавышына күмелде, дөньяны караңгылык басты. Бер «Юнкерс», сазлык өстеннән генә очып, Упкын сукмагыннан читкәрәк бомба ташлап китте. Алда саз былчырагы, кечкенә бер вулканны хәтерләтеп, һавага күтәрелде. Димәк, сукмак өзелде!

— Күрделәр, ахры, бәдбәхетләр,— диде Госман, тешен кысып.— Тагын бер әйләнеп узса, саз төбенә китәчәкбез.

Шунда Николай Сергеевичка хәл кереп киткәндәй булды. Ул аягына басты:

— Әйдә, соңарганчы, үзебезнекеләр янына шуыша торыйк. Аякларым аз-маз кыймылдаганда, сиңа йөк буласым килми, Госман.

Сукмакның өзелгән турына җиткәч, алар тагын туктап калдылар. Ә нигә Шәрәповлар күренми? Василенкога бер-бер хәл булдымы икән әллә? Ул тирәдә бомба да шартламады. Докторны калдырып китәр микәнни? Куак арасына кереп поскан кеше Шәрәпов булды микәнни? Ничек белергә моны?

Госманның уйларын абайлагандай, Николай Сергеевич сүз катты:

— Докторны Шәрәпов белән калды, дисезме? Нигәдер ул кешене мин өнәп бетермим. Ә ни өчен, үзем дә белмим. Ихлас кеше түгел ул.

Шулвакыт Упкын читендәге куаклар арасыннан Шәрәпов кычкырды:

— Доктор Василенко үлде. Мине көтмәгез. Аны бергә җирлим дә үзебезнекеләр янына китәм. Аңладыгызмы?

— Аңладык. Тик документларын алырга онытмагыз!

Николай Сергеевич, нәрсәдер исенә төшкәндәй, Госманның шинеленнән тартып куйды:

— Итек кунычында блокноты бар. Көмеш портсигарда. Галимнең бөтен хыяллары, яңа ачышның планнары шунда иде. Әйт, алырга онытмасын.

— Иптәш Шәрәпов, докторның блокнотын алырга онытма. Итек кунычында... Иптәш Шәрәпов!

Әмма Госманга җавап бирүче булмады. Урман кабат автоматлар тыкылдавына күмелде. Немецлар, яңа көч туплап, урманны тарарга керештеләр.

— Ашыгырга кирәк,— диде Госман һәм, Николай Сергеевичны сукмакта калдырып, өзелгән урынны карарга китте. Бомба ярылганнан соң сазлык юл ничектер сыегаеп калган кебек. Аякларны төпкә суыра башлады. Госман кызу-кызу атларга, ничек тә төпкә чуммаска тырышты. Түмгәккә ябышып үскән куак ботагына тотынырга була. Талпынды... Ботак аның кулында. Хәзер инде Николай Сергеевичка булышып, аны ничек тә бердән чыгарырга кирәк. Госман, бер кулы белән ботакка тотынган килеш, икенче кулын Николай Сергеевичка сузды. Бер-берсенә тотынышып өзеклекне үткәндә, автомат тавышлары Упкын сазлыгына ук якынлашты.

Өзеклекне үтеп, теге якка күтәрелгәч, Николай Сергеевич та җәһәтрәк кыймылдарга тырышты. Һәр адым осталык, тәвәккәллек таләп итә иде. Яралы кеше түгел, сау-сәламәт кеше өчен дә мондый сират күперен үтү җиңелдән түгел иде, билгеле.

Ничек кенә тырышсалар да, немец автоматчылары Упкын сазлыгына килеп җиткәнче алар сукмакны чыгып өлгермәделәр. Шәрәпов белән доктор Василенко калган төбәктә: «Хальт! Рус, сдавайся!» — дигән тавышлар яңгырады. Берсе, Упкындагы сукмакны табып, Госманнар ягына таба атлады. Ә болар исә, түмгәкләргә елыша-елыша, һаман алга үрмәләделәр. Шулчак фашист автоматтан атарга кереште. Ләкин ара шактый ерак булганлыктан, бу Госманнар өчен куркыныч түгел иде. Шунда тагын ике немец Упкын сукмагына керде. Госманның ачуы чыктымы, әллә башына бер-бер уй килдеме, Аверьяновның кулыннан тотты да:

— Аз гына көчең калган булса, син бу фашист актыгына күренеп-күренеп алга таба шуыш. Ә мин, яшеренеп, аларга каршы барам. Хәйләләп карарга кирәк. Без исән калырга тиеш, Николай Сергеевич.

— Мин каршы түгел, тик син сак була күр, Госман Айдарович!

Госман, сазлык түмгәгенә таба шуышып, үзенә җайлы урын сайлады. Аларга таба килгән фашист һаман да Аверьянов шуышкан якка төбәп ата иде. Ул Госманны күздән ычкындырды. Сукмакка тагын берничә немец керде. Инде алдагысын сазлыкка әйләндереп төшерергә дә була иде, ләкин Госман атарга ашыкмады. Алдагысы сукмакның өзелгән турына җиткәч, туктап калды: күрәсең, сазга төшәргә шүрли иде. Аның янына тагын икәү килеп туктады. Болары да сазга керергә батырчылык итмәде. Соңгы төркем белән килүче өч фрицның берсе нәрсәдер боерып кычкырды. Тик шуннан соң гына алдан килгәне сазга керде һәм бата да башлады. Икенчесе, аны коткарырга теләп, кулын сузган иде, куак арасыннан Госманның автоматы телгә килде. Кулын сузган фриц башы белән сазга мәтәлде. Аннан икенчесе... Калганнары тар сукмакта этешә-төртешә качарга тотындылар. Әле генә нидер боерып кычкырган офицер да саз эченә мәтәлде. Калганнары да Госманның ауда йөреп чарланган үткен күзеннән ычкына алмадылар.

Шулчак Упкын сукмагы башында старшина күренде.

— Молодец, егетләр! Булдырдыгыз! — диде ул.— Фрицлар ягына чыккан солдатны Шәрәповка охшаткач, бик борчылган идем. Сез монда орденга лаек батырлык күрсәтәсез икән,— дип сөйләнә-сөйләнә, Упкын сукмагы буйлап Госманга каршы атлады.

Шулчак автоматтан очередь бирделәр. Старшина елмайган килеш Упкын сукмагына егылды.

Кайдан аталар икән моны? Әллә яңа төркем фрицлар килеп чыктымы? Юк, беркем дә күренми. Кинәт сукмактагы бер түмгәк селкенеп куйды. Әле генә сазлыкка мәтәлгән немец офицеры сукмакка менмәкче булып тырмаша иде. Менә кем икән ул безне старшинасыз калдыручы! Мә, ал, бәдбәхет!

* * *

Көтеп-көтеп тә хат килмәгәч, Гөлфия, Аликны алып, бөтенләйгә Буранчыга күчеп кайтты. Гомер итү өчен авылда әйбәтрәк булыр, дип уйлады ул. Сыер-фәлән дә алып җибәрсә, катык-сөтеннән өзелмәс. Аннары, туган-үскән җирләргә ни җитә?! Алик та табигатьне, болын-кырларны яратып үсәр.

...Ул елны яз кинәт кенә килде. Кояш, бөтен җылысын өреп, кышкы юлларга су тутырды. Гөлфия, Җирән бияне җигеп, Чаллыга орлыкка дип килде. Кайтканда, җене өзелеп, Җирән бия юлда җан бирде. Ә Гөлфия өенә билдән суга батып кайтып керде. Кулында ярты капчык бодай иде.

Ашап та тормыйча, урынга егылды Гөлфия. Алик эчтән генә: «Бирештең бит, әнкәй»,— дип куйды. Ә иртән йокысыннан уянса, әнисе инде күптән эшкә киткән иде.

Госманнан хат юк та юк. Шул көннәрдә көтмәгәндә генә авылга Гыйлаҗ кайтып төште. Авыр хәбәр алып кайтты ул Гөлфия белән Аликка. Нindidер Упкын сазламыгында ополченецлар ротасын немецлар чолгап алып юк иткәннәр, имеш. Нindidер могҗиза белән Шәрәпов дигән кеше генә исән калган икән. Ул аның белән госпитальдә танышкан, шунда сөйләшкәннәр.

— Адресын алмадыгызмы соң ул Шәрәпов дигән кешенең? — дип сорады Гөлфия, күз яшьләренә буылып.— Каян табарга икән аны?

— Анысын сорарга башка да килмәгән, Гөлфия. Тик син үз-үзеңне бетермә, үлгән артыннан үлеп булмый.

— Шулаен шулайдыр, Гыйлаҗ абый... Тик минем Госманым үлгән булырга тиеш түгел.

— Гафу ит, сеңелем! Мин сезгә кеше авызыннан ишеткәнне генә җиткердем.

Гөлфия уйга калды. Нигә соң әле Гыйлаҗ үзенекен генә расларга маташа? Госманның үлеменә ничектер куанган сыманрак сөйләшә. Күзләрен генә күр әле син аның?! Шулай да үзе сөйкемле, ягымлы күренмәкче булып кылана.

— Борчылма, Гөлфия,— диде ул, тагын да якынрак килеп.— Синең мәче тырнагына эләккән тычканның хәлен күргәнең бармы? Бар көчен бетергәнче, үтермичә, озак уйнатып йөри ул аны. Моннан да коточкычрак язмышның булуы мөмкин түгел. Кешенең дә бер тотам гомере әнә шул тычкан хәленә охшаган бит. Язмыш туктаусыз куа, ашыктыра. Кеше моны көче сызгач кына абайлый, әмма инде соң була. Бу мин уйлап чыгарган уй түгел, бу — хакыйкать, Гөлфия, ачы дөреслек. Шуңа күрә, гомереңбушка узмасын, әйдә, болыннарны әйләнеп кайтыйк булмаса...

Гыйлаҗның бу сүзләреннән Гөлфиянең тәмам ачуы кабынды һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, «солдат»ның күзеннән утлар сибелде...

Кәзләр җиткәч, Буранчының хатын-кызлар тирә тамган кырларында тук башаклар өлгерде. Алик басу буйлап атлый, башакларны уып, өреп карый. Нinди эре, тук башаклар!

Басу почмагында шулай игеннәргә сокланып торган чагында кинәт кенә аның биленә китереп типтеләр. Бу — Гыйлаҗ иде.

— Шакшы малай,— диде ул,— ник урлыйсың колхоз икмәген? Яшең җиткән булса, моның өчен башың Себер китәчәген беләсеңме син?

Елады бала, сабыйларча үксе-үксе елады...

Авылны пошаманга салып, яңгыр болытлары күкрәп үтте. Игеннәр җиргә тагын да ныграк сәрлектеләр. Бөтен авылга бер лобогрейка, ул да яткан игенне юньләп урдыра алмый. Бөтен өмет, бөтен ышаныч хатыннарның тамырлары бүрткән кулларда. Аз гына булса да йөри алган һәр кеше кырга кучте. Икенче ай инде менә Аликның үз әнисен көндез өйдә күргәне юк. Иртән кояш белән торып эшкә китә, кичен караңгы төшкәч кенә кайта.

Календарьда инде октябрь булса да, кырда эшнең кызган чагы. Шундый көннәрнең берсендә авылга Мотаһир кайтып төште. Шул көнне үк Гөлфияләргә килде ул. Алик, аңа сокланып, күкрәгендәге медальләрен санап утырды. Мотаһир иң әүвәл фронт юлларын, кайда яралануын, нинди госпитальдә ятуын искә алды.

— Госман ниләр яза?— дип сорады аннары.

— Аннан инде күптән хат-хәбәр алганым юк,— диде Гөлфия, сагышланып.— Гыйлаҗ, үлгән, дигән хәбәр таратты. Ә мин ышанмыйм, күңелем ышанмый, Мотаһир.

— Мин дә ышанмыйм. Нигә кирәк булды икән аңа Госманның үлеме? Тукта, алар госпитальдә бергә ятмадылар микән? Соңгы хатында Госман миңа шулай дип язган иде.

— Госпитальдә? Госман анда ничек эләккән соң?

— Сезгә хаты килмәдемени?

— Юк, бу хакта язмады.

— Менә болай була ул. Вязьма тирәсендәге сазлыкларда алар чолганышта калалар. Чолганыштан берничә кеше генә чыга. Алар арасында яралы бер Мәскәү галиме дә була. Аны чолганыштан алып чыкканда Госман үзе дә яралана, госпитальгә эләгәләр. Шул ук госпитальдә Госман Гыйлаҗны күргән кешене очрата. Тик ул Гыйлаҗны, терелеп кабат фронтка китте, дип язган иде. Ә ул әнә бередә икән!

— Хат килмәве аптырата мине. Сезгә язган, ә миңа юк. Һаман да Казанга язып ятмыйммы икән ул? Анда язса, җиткерерләр иде. Бернәрсә дә аңламыйм мин, Мотаһир...

— Әйе, уйланырлык нәрсәләр бар монда. Әмма барысы да ачыкланыр. Бераз сабыр итәргә кирәк.

Ул елны авыл халкы күпме генә тырышмасын, кар төшкәнче урак бетмәде. Урылмаган бодай кыры ятып калды, кибән төпләрен кар каплады. Әмма хатын-кызлар суык дип тормады, урагын да урды, ашлыгын да сукты. Фронт өчен дип җан тырмашты...

* * *

Карлары һәм бураннары белән тагын бер кыш сынды. Басулар кардан арчыла башлау белән, хатын-кызлар, кыр казлары кебек тезелеп, кар астыннан чыккан башакларны җыярга ашыкты. Әнә капчык-капчык башак җыеп кайтып киләләр. Үзләренең түбәләре күккә тигән. Әмма беркайчан да, беркем дә күрмәсен иде мондый куанычны.

Бодай оныннан пешкән икмәкне бик тә ашыйсы килә иде Аликның. Дусты Хәкимҗан кулында бер бөтен бәләкәй күмәч күргәч, авызы ерылды:

— Әйдә, яртысын майга алыштырам!

— Дуслар өчен берни дә җәл түгел, Алик, мә, ал яртысын.

Аннан алар, кеше күзенә чалынмас өчен, иске бура эченә кереп яшеренделәр. Яңа пешкән күмәчкә май ягып, туйганчы ашадылар. Телләрне йотмалы иде күмәч, тәмле, баллы иде...

Кинәт шунда бөтен дөньяны караңгылык басты.

— Алик, карале, кояш тотыла бит,— диде Хәкимҗан.

— Кояш тотыла?

Хәкимҗан, ашалып бетмәгән күмәчен бер читкә куйды да, дустына таба омтылды. Бер почмакка барып сыендылар. Хәзер көн уртасы бит, нигә шулай караңгы соң әле?

Ике араны шушы караңгылык өзәр дип кем уйлаган?! Көтмәгәндә кайсыдыр, азан әйтеп: «Үләт килә!» — дип кычкырды. Ә Хәкимҗан, дустын калдырып, өйләренә таба йөгерде. Аларның соңгы тапкыр күрешүләре, ә Хәкимҗанның кояшны соңгы тапкыр күрүе булды бу.

Үләт... Бу сүзне Аликның беренче ишетүе иде. Аның дусты Хәкимҗанның, тагын бик күпләрнең гомерен шушы нәләт төшкән афәт чикләде.

Үләт дигәннәре Аликка да килде: тел очлары кабарып чыкты, әҗәл белән көн-төн якалашты ул, йөзе көлдәй агарып калды. Ләкин бирешмәде, үлем белән бар көченә көрәште. Үләт Аликтан качты. Дәресрәге, сыер сөте коткарды.

Бу хәлләрнең нindидер явыз рух эше икәнен аңламый-нитми, яз айларында гына да Буранчының җитмештән артык сылу кызлары, балалары, апалары дөнья куйды. Үләт чире нинди сукмаклардан килеп тапты соң бу авылны?! Кырларда тау хәтле иген үстереп тә, буранда бер уч икмәк булмасын әле... Мондый хәлнең кайда булганы бар? Уйлап карасаң, колларның да тамагын туйдырганнар... Ә монда үзе үстергән икмәкне бер уч алса да, кеше себер китте. Буранчылар үз җирләрендә, үз куллары белән үстергән икмәкне кабып карарга зар булып, ачтан һәм агулы бөртекләр ашап харап булды. Соңлап, бик соңлап авыл халкы җыйган агулы бөртекләрне алыштырып бирделәр. Кайдандыр киемнәр дә кайтардылар. Аликка пуля тишкән фуражка эләкте...

Янында Хәкимҗанның булмавы — аның өчен фаҗига иде. Үз-үзенә урын таба алмады Алик. Беркөнне шулай ялгызы гына йөреп кайтты да үксе-үксе еларга кереште. Әнисенең эштән кайтканын да сизми калды ул. Гөлфия аптырашта иде.

— Ни булды, улым, ник елыйсың? — дип сораштыра башлады.

— Хәкимҗанны күрәсем килә. Ансыз бик күңелсез миңа, әни...

— Ниишлисең инде, улым... Үлгән кешене кире кайтарып булмый бит. Йә, ярый, елама, югыйсә, минем дә елыйсым килә башлады.

Шул көнне Госманнан хат килеп төште. Ут эченнән, көрәш кырыннан язган иде ул хатны. «Көрәштәшне, дусны җирләдем, дигән. Бик күп көннәр саклап йөрткән серен үләр алдыннан миңа чишти. «Гыйлаҗ тугры бәндә түгел,— диде...— Теге чакны госпитальдә бергә яткан адашының кәгазьләрен үзенә алган. Бичара солдат юлда җан биргән, ә Гыйлаҗ шул кәгазьләр белән өенә кайтып киткән. Чынлап та, аның ярасы куркыныч түгел иде. Шуңа күрә, туган анасын кайтып күрер дә килер, дидем. Юк, килмәде. Белеш әле шуны, Госман. Авыл картлары, аксакаллар, көрәшче дип, алдында баш ия күрмәсеннәр тагын. Шуны ачыкла, Госман, бу — минем сиңа васыятем». Шулай диде дә күзен йомды көрәштәшем.

Гөлфия! Бу турыда мин инде алда язган хатымда әйткән идем бит. Тик Гыйлаҗ хакындагы усгызны әйтеп язмадыгыз. Әллә минем хатлар сезгә барып җитмиме?»

Гөлфия кинәт иреннәрен кысты. Менә нигә бу хатны ире район комиссариаты исеменә җибәргән икән. Менә ни өчен Гыйлаҗ Госманның тизрәк үлүен теләп торган икән. Хат ташучы Зифа апага да юкка гына елышмаган ул. Әйе, бик күп хатлар килгән безгә, тик кулга гына кермәгән...

Мотаһир да шундый ук хат алган икән. Гөлфияләргә килеп, ул да киңәште.

— Иртәгә үк районга барырга, барысын да, хәбәр итәргә кирәк,— диде ул.

— Тик моны сиздермичә, тыныч кына эшлик, Мотаһир,— диде Гөлфия.— Монда да, районда да аның дуслары аз түгел.

— Килештек, алайса, Гөлфия. Бүгенгә хуш! Тыныч йокы!

— Тыныч йокы, Мотаһир!

Ләкин Мотаһирга тыныч йокларга насыйп булмады. Шундый да тын кич иде. Хәтта Баҗанадагы бакалар да тынып калган. Мотаһир, үзләренә кайтып җиткәч, өенә керергә ашыкмады. Авылның кичке һавасын сулап, капка төбендә утырды. Шулвакыт авыл башыннан, фараларын яктыртып, бер машина килеп чыкты. Мотаһирлар турысына җиткәч, кинәт кенә туктап калды. Машинадан җәһәт кенә ике кеше төштеләр дә туп-туры Мотаһирга таба атладылар. Аларның берсе Гыйлаҗ иде.

— Нәкъ үзе,— диде ул, Мотаһирны күрсәтеп.— Гаепленең күзенә йокы кермәве дөрес икән!

— Сез кулга алынасыз, менә рөхсәт кәгазе. Машинага утырыгыз,— диде икенчесе.

— Минем бер гаебем дә юк. Шуңа күрә беркая да барырга уйламыйм. Провокация бу...

— Әһә, провокацияме? Уйлабрак сөйлә, сатлык җан! Кырык бердә пленда булдыңмы? Булдың. Провокация, имеш...

Күн тужурка кигән кеше наганын тартып чыгарды:

— Атлагыз. Районда аңлашырбыз...

— Дөрес. Әсирлектә булдым. Ләкин озак түгел. Без аннан качтык. Мине акладылар. Аннан соң инде ничәмә-ничә каты сугышларда катнаштым. Ике орден белән бүләкләндем. Гайбәт, яла ягу бу!

Әмма күн тужурка кигән кеше аны тыңларга да теләмәде:

— Утырыгыз машинага, соңгы тапкыр боерам.

— Документларыгызны күрсәтегез, сез кем буласыз?— диде Мотаһир, аягүрә басып.

Тегесе исә, тагын да зәһәрләнә төшеп, Гыйлаҗга төртеп күрсәтте:

— Каршыңда авылның хуҗасы басып тора. Бу сиңа документ түгелмени?

Мотаһир Гыйлаҗ турында нәрсәдер әйтергә теләгән иде, ничектер үзен кулга алып, тыелып калды. Ирексездән машинага таба атлады.

Шул китүдән ул суга төшкәндәй юкка чыкты. Хаты да, хәбәре дә килмәде. Гөлфия, район үзәгенә барып, белешеп тә караган иде, ләкин әллә ни ачыклый алмады. Бары тик: «Казанга чакырып алдылар»,— дип кенә җавап бирделәр.

* * *

Гөлфия тәмам аптырашта калды. Мотаһирны да алып киттеләр, бер хәбәрсез югалды. Хатыны Майҗанга да инде бер атна эшкә әйткәннәре юк икән. Әле күптән түгел генә Гыйлаҗ аларның өендә тентү оештырган. Мотаһирдан элек килгән хатларны таләп иткән. Сакланган хатларында яла ягардай нәрсә таба алмагач, абзар-кура тирәләрен актарган, ломнар белән төрткәләп ниндидер урланган ашлык эзләгәннәр. Тик берни дә таба алмаганнар. Шуңа күрә хатынның үзенә тияргә батырчылык итмәгәннәр. Авыл халкы бөтәнрәк шул хәзер. Әлегә йөзенә бәреп әйтә генә алмыйлар Гыйлаҗның...

Авыл картларына эч серләрен җиткерергә, Госман язганнар турында сөйләргә әллә ничә талпынып карады Гөлфия, әмма кыюлыгы җитмәде.

Бу Гыйлажның тагын ниләр уйлап чыгарасын кем белә? Госман белән киңәшер иде, аннан да хат килми ичмасам.

Шундый уйларга бирелеп утырганда, беркөнне ишектә Гыйлаж күренде:

— Керергә ярый микән?

— Ниятегез изге булса, кереп карагыз.

— Минем кайчан начар ният белән йөргәнем бар?

— Мотаһирның югалуы синнән башка эшләнмәгәндер дип беләм.

— Май кап, Гөлфия. Аның исемен дә телгә алырга ярамый. Пленда вакытта фашистларга хезмәт иткән ул. Гаебе зур. Аңа башкача туган авылы Буранчыны күрү насыйп булмастыр. Синең Госманың турында да әйбәт сөйләмиләр хәрби комиссариатта. Соратканнар икән дә, тегеләр ягында калган, дигән хәбәр килгән. Сиңа хатлары килмидер ич?

Гөлфия тәмам коелып төште. Үзе дә сизмәстән:

— Күптәннән килгәне юк, тикмәгә генә түгел икән шул,— дип, битен куллары белән каплады.

Гыйлаж исә, юаткан булып, кулын аның иңнәренә куйды. Үзенә табарак тартып:

— Борчылма, Гөлфия, без бар чакта югалмассың. Әйттем бит мин сиңа теге чакны... Яшьлекнең кадерен белергә кирәк. Үкенмәслек булсын,— диде дә Гөлфиянең иреннәренә үрелде.— Яшь бит әле син, без кирәк сиңа...

Кинәт Гөлфиягә әллә кайдан гына көч килгәндәй булды, әйләндереп торып Гыйлажның яңагына чабып җибәрде:

— Әйе, безгә ирләр кирәк, тик үз ирләребез, синең ише дезертир түгел!..

Гыйлажны яшен суккандай булды: «Каян белгән ул? Юк ла, болай гына әйтелгән сүзләр, ачуы чыкканга кына...»

Гыйлажның ничек чыгып киткәнен дә сизмәде Гөлфия, битен кулы белән каплаган килеш, тавышсыз гына елый бирде. Шулчак күз алдына Госманы килеп басты: «Нишләп болай жебеп төштең әле, акыллым? Башыңны юк-бар белән тутырма, ышанма бу сүзләргә! Әйдә, иң яхшысы, болынга киттек. Хәтерлисеңме, институтны бетереп кайткач, көне буе болында йөргән идек. Чәчәкләргә күмелгән болында...»

* * *

Госпитальдән чыккач, Госман Воронеж тирәсендә барган каты бәрелешләрдә катнашты. Беркөнне тел алырга киткән төркемнән беркем дә кире әйләнеп кайтмады. Яңа группа җибәреп карарга булдылар.

— Дүртенче булып кем барырга тели? — диде лейтенант.

— Мөмкин булса, миңа рөхсәт итегез,— диде Госман.

— Госпитальдән генә бит әле сез...

— Зыян юк, иптәш лейтенант, ярам төзәлде инде.

Күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгы төн. Разведчиклар куаклыкка кергәч, тын гына шуышып, фронт сызыгын кичтеләр. Урман читенә килеп җиткәндә, немецча сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады. Госманны юкка гына «Төнге ярканат» дип йөртмиләр иде. Ул шундук хәлне абайлап алды.

— Өчәү, яннарында мотоцикл. Каядыр китәргә җыеналар, ахры,— диде.

Ул арада немецларның икесе мотоциклга утырып китеп тә барды. Ә өченчесе калды. Мөгаен, өстәмә сакчы итеп калдырганнардыр аны-сын... Шулай булып чыкты да, фриц арлы-бирле акрын гына йөрергә кереште. Егетләр аны «эләктерергә» булдылар. Госман уңайлы урынга урнашты. Шулчак немец, сукмак буйлап эчкәрерәк үтте дә, як-ягына

карана башлады. «Әллә сизенде инде? — дип уйлады Госман. — Нәрсә эшләргә соң хәзер?»

Разведчиклар немец солдаты артыннан үрмәләделәр. Ул арада борынга төтен исе килеп бәрелде. Алда землянкалар икән. Сакчы фриц тагын як-ягына карап алды да землянкаларның берсенә кереп китте.

Госман землянка янына ук килде, уңайлы урын сайлап, фрицның чыкканын көтә башлады. Әмма землянкага бүтән керүче дә, чыгучы да булмады. Госманның сабырлыгы төкәнде, землянкага тагын да якынрак шуышты да, төтен чыга торган торба янына ук килеп, аның авызын бүреге белән томалап куйды.

— Хәзер инде чыкмый хәлләре юк. Әзер торыгыз,— диде ул иптәшләренә.

Землянка ишегеннән бер фрицның башы күренде. Анысын, тавыш-тынсыз гына авызын томалап, бер читкә сөйрәделәр. Икенчесен дә җайлы гына алдылар. Әмма өченчесе эшне сизеп алды, землянка ишеген чак кына ачты да автоматтан сиптерә башлады. Землянка өстендә торган Госман, немец офицеры өстенә бөркеттәй атылып, аны аяктан екты. Лейтенант Васильев ярдәмгә ашыкты.

— Монысы эрерәк кош. Штабка ничек кенә булса да шушысын илтеп җиткерергә кирәк,— диде ул.

Шулчак күккә яктырткыч ракеталар очты. Тирә-юнь яп-якты булып балкып китте. Якында гына автоматтан аткан тавышлар ишетелде.

— Сизенделәр, бәдбәхетләр... Болай булгач, барысын да алып булмый. Самойлов, сез Ибраһимов белән менә бу кошны эләктерегез дә, килгән сукмактан туп-туры элдертегез. Тиз булыгыз. Ул-бу була калса, юлны каплап торырбыз,— диде лейтенант.

«Тел» алучылар куаклар артына күмелергә дә өлгермәде, блиндаж артында бер төркем немецларның йөгергәне күренде. Юлның уң ягында мотоцикл тырылдаганы ишетелде. Фараларын яндырмыйча гына киләләр иде. Ракеталар сүнгәч, тирә-юнь караңгылыкка чумды. Шуннан файдаланып, Госман имән артындагы чокырга барып ятты һәм үзен чыршы ботаклары белән каплады. Янәшәдә лейтенант урын алды. Болар яныннан гына өч немец йөгереп үтте.

— Иптәш лейтенант, болар безнең «тел»не күреп чабалар булса кирәк, атыйм! — диде Госман, һәм автомат телгә килде. Караңгы булса да, берсенә эләкте, юл өстенә тәгәрәп төште. Калганнары җиргә ятты. Шул арада уң яктан мотоциклдан төшкән немецлар килеп чыкты. Җиргә ятып калган теге немецлар, үзләренеке икәнен абайламыйча, боларга автоматтан ут ачты. Землянка янына килгән немецлар да атышка кушылдылар.

— Безнең егетләр куркыныч зонаны үттеләр инде. Хәзер болар белән бәйләнмәсәк тә була. Тик атышсыннар шунда үзара,— диде лейтенант Васильев һәм, тирә-юнь тагын караңгылыкка чумгач, өстәп куйды:

— Килгән юлдан үзебезнекеләр ягына чыгарга маташу хәзер мәгънәсезлек. Әйдә мотоциклга! Йөртә беләсеңме?

Госманны, әйтерсең, урыныннан күккә чөйделәр, лейтенантның сүзләрен ишетү белән, ул мотоциклга ташланды. Тик ашыгып чак кына хата ясап куймады. Мотоцикл янында сакчы калдырганнар икән. Әмма, ул Госманны «үзенеке»ләрдән дип белде, ахры, немецча аңа нәрсәдер дәште. Әмма җавап урынына Госманның автоматы тырылдады. Ул арада лейтенант та килеп җитте һәм мотоциклның берсен кабызып җибәрде. Госман исә янәшәдәге мотоциклның электр чыбыкларын суырып алды да лейтенантның артына килеп утырды.

Берничә немец мотоцикл янына йөгерә башлады. Берсе, йөгергән шәпкә: «Партизан!» — дип акыра иде. Алар килеп җиткәнче мотоцикл инде борылышка кереп күздән дә югалды.

Лейтенант Васильев бу тирәләрне яхшы белә булып чыкты.

— Бу юлдан бүтән барырга ярамый. Юкса, менә-менә каршыга килеп чыгачаклар,— диде ул Госманга һәм сул яктагы ташландык юлга борылды. Биредән бернинди дә машина-фәлән үтмәгән иде. Унбиш минутлап баргач, җимерек күпергә килеп җиттеләр. Мотоцикл белән үтмәле түгел. Лейтенант мотоциклны яр буенда туктатты да:

— Килеп җиттек, иптәш Закиров, төшегез,— диде һәм, Госман төшүгә, мотоциклны туп-туры ярдан аска этеп җибәрде.

— Тиздән безне эзләп киләчәкләр. Мотоциклның суга төшүе аларда төрле уй кузгатуы ихтимал. Кем белә, безне караңгыда җимерек күпердән чыкканда суга төшеп үлгәннәр, дип уйлаулары да бар. Ничек кенә булса да, алар биредә шактый вакытка тоткарланачак. Ә без инде аңарчы шактый еракта булырбыз. Хәерле сәфәр, иптәш Закиров,— диде дә лейтенант, беренче булып җимерек күпернең исән калган тактасына сикерде. Госман да аңардан калышмады. Тик, алдагы тактага басыйм гына дигәндә, такта урталай сынды да, аягы ярыкка төшеп китте, үзе янәшәдәге өрлеккә чак тотынып калды. Лейтенант аңа аягын күтәрергә, өскә менәргә булышты. Ничек кирәк алай күперне чыгып ярты сәгать чамасы баргач, урман читенә килеп чыктылар.

Госман уйга калды. «Тел»не алып кайта алдылар микән? Безнең турыда нәрсә уйлыйлар икән хәзер частьта? Ул, үзе дә сизмәстән, уң кулы белән гимнастерка кесәсенә тыгылды. Хат... Гөлфиягә, Алигына язган хаты. Салырга өлгермәгән хат...

* * *

Аларга үз частьларына кайтып җитү насыйп булмады. Сугышның мең афәтеннән берсе юлларын кисте, күперләрен җимерде, упкынга атып бәрде...

Ул көннәрдән соң инде шактый вакыт үтте. Партизаннар отрядында озак сугышырга туры килмәде Госманга. Тигезсез, рәхимсез бәрелешләрнең берсендә каты яраланып, уң кулын өздерде. Шуннан соң аны чираттагы самолет белән тылга озаттылар.

Алты айдан артык госпитальдә ятканнан соң, Госман туган якларына кайтты. Менә ул төшләрдә күреп сагынган Буранчы! Госманның кайтуын ишетү белән, Гыйлаҗ районга дип чыгып китте. Һәм шул китүдән авылга әйләнеп кайтмады. Суга төшкәндәй юкка чыкты.

Туган авылында бераз хәл алганнан соң, Госман гаиләсе белән Казанга күчте, селекция үзәгендә сугышка кадәр башлаган эзләнүләрен дәвам итте. Гөлфия дә шунда урнашты. Бергә-бергә эшләп, яңа сорт һәм гибрид үстерделәр, иген игү технологиясен камилләштерү юнәлешендә эзләнү алып бардылар...

Ә менә селекция үзәгенә директор булып Нәхитов килгәч, хәлләр катлауланып китте. Хикмәт шунда иде: көннәрдән беркөнне танылган галим, профессор Закиров эшсез калды.

... Селекция үзәгендә инде айдан артык булганы юк Госманның. Килмәскә, онытырга теләгән иде. Шулай да йөрәге түзмәде. Ничек түзсен, туган йорты кебек якын иде бит селекция үзәге. Күпме йокысыз төннәр, күпме җәй һәм көз, кыш һәм язлар уздырды биредә. Шуңадырмы, тагын бер генә кат булса да коридорлары буйлап үтәсе, галимнәр Советы җыела торган залларына сугыласы, өске катына менеп, ерак-еракларга җәелгән тәҗрибә кырларын күзәтәсе, якын хезмәттәшләрен сәламлисе килде аның.

Шуларны уйлап, ул тауга таба атлады. Элекке кебек түгел хәзер, үргә менүләре авыр икән. Хәер, соңгы вакытта җәяүләп бик сирәк йөрелде шул. Машина дигәненә кирәгеннән артык күнегеп кителде. Шофер егет Мәхмүт иртән өйгә килеп ала, эш беткәч, кире кайтарып куя иде. Ялгышрак булган монысы. Ара-тирә җәяүләп килгәндә, тавыннан меңгәләгәндә, болай ук читен тоелмас иде.

Тауны менеп җиттем дигәндә генә капкадан җилдереп таныш кара «Волга» килеп чыкты. Машинаны әле һаман да шул Мәхмүт йөртә икән. Янындагы хуҗасыннан тартыныбрак кына Госман абыйсы белән баш кагып исәнләште егет. Нәхитов исә, Госман Айдаровичны күрмәмешкә салышып, читкә борылды.

Кинәт шунда әллә нәрсә булды. Машина артыннан күтәрелгән тузан торган саен куера, карала барды. Кичке якка авышып барган кояш та әллә кайда, тузан артында калды. Нәрсә соң бу? Өнме, әллә төшме? Госман, күзләрен киң итеп ачып, кояшны кабат күрмәкче булды. Әмма тез буыннары йомшарып, хәле китте. Һәммәсе караңгылыкка кереп чумды...

Бу хәлне тәрәзәдән күреп торган лаборант кызлар шундук йөгерешеп килеп җиттеләр:

— Госман Айдарович, нәрсә булды сезгә?

Закиров җавап бирмәде. Арадан берсе, Госманның кулын алып пульсын карады. Акрын гына, менә туктыйм, менә туктыйм дип кенә тибә иде йөрәк.

Тиздән ашыгыч ярдәм машинасы килеп җитте. Госманны махсус клиникага алып киттеләр. Йөрәк ярасы хәтәр иде шул. Ни эшләсен, аңа кадалган уклар аз булдымыни?!

* * *

Махсус клиникада барысы да көйле, тәртиптә. Аны башка клиникалар белән чагыштырып булмый, билгеле. Ни әйтсәң дә, элита өчен эшләнгән һәм ул мәгълүм катлам кешеләргә хезмәт итә. Госман бирегә эләгүенә бер яктан канәгать булса, икенче яктан уйланды да: «Эштән куылган кешене ничек бирегә салдылар икән?.. Димәк, ул да номенклатура кешесе, әле сызып ук ташламаганнар...»

Селекция үзәге — изге йортта булган вакыйгаларны күз алдыннан кичереп яткан вакытта, ишек шакыдылар. Ишек артында лаборатория мөдире Каргинаның йөзе күренде.

— Керергә мөмкинме?

— Рәхим итегез,— диде Госман, күңелендәген сиздермәскә тырышып.— Нинди җилләр ташлады?

— Разве сезне онытырга мөмкин? Юк дигәндә дистә елдан артык бергә эшләдек бит, Госман Айдарович. Шулай да мин сезне аңлап җиткермәгәнмен икән. Игътибарсыз булуым өчен кичерегез мине!

— Нәрсә сез тагын? Болай үзегезне кимсетмәгез, Мәсхудә Хәйрулловна! Яхшы урнаштыгыз, яна директор башта ук үз итте. Сезгә үсәргә дә үсәргә хәзер...

— Үсәрсең менә, үсми ни! Беркөнне үзенең бүлмәсенә чакырып алды да: «Йә телеңне тый, йә хушлашырга туры килер синең белән»,— ди. Кара син аны, ә! Башка кеше әйтсә, ачуың да килмәс иде. Айлар буе диссертациясен карап, төзәтеп утырдым. Николай Алексеевич вафат булгач, аерата батырайды. Тәп шаһит юк хәзер. Аңа өч бүлмәле квартир вәгъдә иткән булган. Коршун берничә тапкыр профкомга да килеп караган. Беренче чиратка куеп, алдан бирүләрен таләп иткән, ди. Хәзер менә квартир да кирәкми үзенә, диссертация дә, акчасы да... Коршун үзе үлгәннән соң мәрхүмнең хатыны килгән икән түрәгә, «вәгъдә ителгән»

квартирны сорап. Тегесе сүзеннән кире кайткан, вәгъдә итмәдем, дигән. Алырсың квартир хәзер, алмый ни...

— Мәсхудә Хәйрулловна, болай утыру бер дә матур түгел. Кеше гайбәтен сатмыйк әле, әйдәгез. Эшлекле фикерләрегез, теләкләрегез булса, сөйләшергә мөмкин. Ничек соң, докторлык диссертациясе өстендә эшлисезме? Нинди кыенлыклар бар?

— Шул кыенлыклар турында сөйли башлаган идем ич, Госман Айдарович. Озаклап сөйләргә яратам шул, туйдырып бетерәм. Турысын әйтәм, мин аның өстеннән Бөтенсоюз Авыл хуҗалыгы академиясенә хат язган идем. Түзәр хәл калмады хәзер. Чарасын күрмәсәләр, тагын да югарырак язам. Хатка инде берничә кеше кул куйды. Сез дә укып чыксагыз иде, бәлки, кулыгызны да куярсыз...

— Мәсхудә Хәйрулловна, гафу итегез, кәефем начарланды. Медсестраны чакырсагыз иде. Ә хатыгызны калдырып торыгыз. Бераз хәлләнгәч, карап чыгармын.

Мәсхудә Хәйрулловна, кызулык белән, медсестраны чакырырга да онытып, урамга ук чыгып китте. Чыккач, ялгыз каен агачы төбендә бер тын уйланып басып торды. «Нигә хатны калдырдым соң әле мин аңа? Кара син аның кылануын! Югыйсә бит Нөхитов үзе белән ничек кенә уйнамады. Кермәсә керми икән бу кешегә...»

— Каргина, ни эш бетереп йөрисез бирелә?

Нөхитовның таныш тавышын ишеткәч, Мәсхудә Хәйрулловна тәмам бөрешеп төште. Башта ни дип җавап бирергә дә белмәде. Аннары, үз-үзен кулга алырга тырышып, нәрсәдер әйтмәкче булган иде. Нөхитов аңа авыз ачарга ирек бирмәде:

— Сез дә авырып китмәгез тагын... Югыйсә, безгә читенгә туры килер... Ярый, хушыгыз!

Нөхитов китә башлагач, Каргина ялвара ук башлады:

— Бер генә минутка мөмкинме, Харис Сәлимович? Сез ялгыш уйлый күрмәгез тагын... Бирегә килүемнең сәбәбе бөтенләй бүтән...

— Шулай була күрсен, Мәсхудә Хәйрулловна, шулай була күрсен...

Нөхитов җәһәт кенә борылды да клиникага кереп китте. Каргина авызын ачкан килеш басып калды.

— Әллә чынлап та Закиров янына килүеме икән? Әгәр дә минем кәгазьне күрсә, тегесе укытса?..— Каргина, нәрсә эшләргә дә белмичә, бик озак басып торды. Хәтта Нөхитовның әйләнеп чыкканын да абайламый калды.

— Нәрсә, мылтыгы суга төшкән сунарчы кебек катып калдыгыз?

Каргина сискәнеп китте. Үзен кулга алып:

— Сезнең чыкканны көттем, Харис Сәлимович, ни өчендер бик тиз әйләндегез,— диде.

Нөхитов хәлнең ничек булганын аңлатуны кирәк дип тапмады.

— Озаклап сөйләшергә вакытым тар, Мәсхудә Хәйрулловна. Кайтырга уйласагыз, әйдәгез, мин фәнни үзәккә кадәр.

Нөхитовның клиникага килүе очраклы түгел иде, әлбәттә. Госман нәкъ шулай уйлады, әмма кабул итмәде.

— Кәефем шәптән түгел бүген, Харис Сәлимович. Бу очрашуны бераз кичектерик. Авырсынмасагыз, алдан шалтыратыгыз,— диде.

Госман Айдаровичның хәле, чыннан да, шәптән түгел иде. Бигрәк тә, Нөхитовны күргәч, күз аллары караңгыланып китте. «Шундый хәлләрдән соң ничек килгән дә, ничек керә алган минем янга?» — дип уйлады ул.

Госман Айдарович һәрчак турысын әйтергә ярата. Нөхитовны селекция үзәгенә директор итеп билгеләү алдыннан аның да фикерен сорадылар.

— Бармый. Фәннән ерак кеше ул,— диде Госман турыдан-туры.— Әгәр дә без селекция үзәгенең житештерүче көчкә әверелүен телибез икән, аның башында фәнне, фән кешеләрен аңлый белә торган һәм

шул фәнгә үзеннән дә өлеш кертә алырдай кеше торырга тиеш. Ә фән кандидаты да булмаган, «урамнан тотып куйган» директор бүгенге бурычларны хәл итә алырмы, белмим...

Шул сөйләшүдән соң атна-ун көн Нөхитов хакында сүз кузгатучы булмады. Закировның фикерен булачак директорга җиткерделәрме, юкмы — анысы билгесез.

Икенче чакыруда Госман Айдаровичны инде тыңлап тормадылар.

— Нөхитовтан да кулай кандидатура юк,— диделәр өлкә комитетында.— Хуҗалык эшен яхшы белә, оста оештыручы. Аннан соң Мәскәүдә дә үзен кулай таптылар...

— Мин үз фикеремне генә әйттем. Ялгышкан булуым да ихтимал. Шуңа күрә үзегезгә карыйсыз...

— Бергәләп, ярдәмләшеп эшләргә туры киләчәк, иптәш Закиров. Нөхитов бигрәк тә оештыру ягыннан җавап бирсә, сез, аның урынбасары буларак, фән өчен җавап бирәсез. Килештекме? Уңышлар телибез сезгә.

Яңа директор белән селекция үзәгендә тәүге очрашу Госман өчен эзсез калмады. Менә ул эре генә кыяфәттә кафедра янындагы өстәл артына кереп утырды. Күзлеген киде, түшенә кунган мамыкны өреп төшерде, аннан горур гына сакалын сыпырып алды... Түгәрәк сакалга тар кара мыек килешеп тора. Килеш-килбәте академиктан ким түгел. Госман шунда аны кемгәдер охшатып та куйды, тик исенә төшерә алмады. Үзе белгән фән дөньясында моңа охшаган кешене таба алмады. Еш кына кешенең тышкы кыяфәте алдаучан була шул... Бигрәк тә Нөхитовның уйлап әйтелмәгән сүзләре хафага салды.

— Бүгеннән барыбызга да,— диде директор,— яңача эшли башларга туры киләчәк. Йокыдан айнырга вакыт. Фәнни хезмәткәрләргә генә хөкүмәтебез ай саен ярты миллион сумнан артык хезмәт хакы түли. Без моны акларга тиеш, шулай бит, Госман Айдарович?!

— Гафу итегез,— диде селекционер Шәрәф, урыныннан кузгалып,— сезне вакытында төзәтмәсәң, гомерегез буе ялгыш фикердә калуыгыз бар. Безнең селекция үзәгендә иллегә якын сорт кына чыгарылган. СССР Дәүләт премиясе лауреаты Мәдинә Зәйнурова чыгарган сортлар үзләре генә дә безнең кебек өч үзәк тоталрлык табыш китерә. Аның янына борчакның, карабодайның, тары, җиләк-җимеш культураларының да безнең галимнәр, селекционерлар чыгарган сортларын өстәсәң... Аннары никадәр яңа технологик алымнар, ысуллар тәкъдим ителде.

— Шулай да булсын,— диде Нөхитов.— Сез мәсьәләнең икенче ягына игътибар итегез. Әнә шул бармак белән санарлык галимнәрнең күләгәсендә тагын никадәр кеше туена...

— Хәзер ялгыз галимнәр юк, иптәш Нөхитов,— диде Шәрәф, кызып ук китеп.— Ачышларны коллектив ясый, сортлар да коллектив көче белән туа. Аерым җилкуарларның булуы ихтимал, билгеле. Гаиләгарип-горәбәсез булмый, диләр. Аларны күз алдында тотып, бөтен коллективка пычрак атарга ярамый.

— Тәүге очрашуны үзегезгә кадәр эшләгән кешеләргә, гомумән, коллективка гаеп ташлауга кайтарып калдыру матур күренеш түгел,— диде Госман, урыныннан күтәрелеп. Әмма Нөхитов аңа утырырга ишарәләде.

— Бүгенгә шушының белән төгәлләргә туры килә,— диде Нөхитов, урыныннан торып.— Так что, мине срочно өлкә комитетына чакыралар. Хушыгыз!

Барысы да теләр-теләмәс кенә урыннарыннан кузгалдылар. Күпчелек хезмәткәрләр аптырашка калган иде: нәрсә булды соң инде бу? Очрашу-танышу дисәң, үзе турында берни дә әйтмәде. Җыелыш дисәң, президиум сайланмады. Галимнәр Советы утырышы дисәң, бернинди анализ булмады, бурычлар куелмады...

— Болай булса, эшләр барачак,— диде фәнни-техник информация бүлегенең өлкән гыйльми хезмәткәре Мария Яковлевна.— Башлы күренә, тач ЭВМ инде менә...

Янында гына җыелышып торган хатын-кызлар шаркылдап көлешеләр. Алар янынннан тек-тек басып кына Каргина узып китте.

— Эш вакытында тапканнар кәефләнер урын,— диде ул.— Иптәш Нөхитовның сүзләрендә хаклык юк дип кем әйтә алыр?

— Бар, принцесса, юлыңда бул,— диде Мария Яковлевна.— Юкса, өлгерә алмассың, эш артты сиңа хәзер...

Иртәгесен Мария Яковлевнаны директор үзенә чакыртып алды.

— Сезнең гариза буенча сөйләшергә теләгән идем,— диде Нөхитов. Мария Яковлевнага урын тәкъдим итеп.— Фәнни-техник информация бүлеген нигытуны сорап сез мәсьәләне дөрес күтәрәсез.

— Күптән язылган гариза инде ул,— диде Мария Яковлевна.— Анда күтәрелгән мәсьәләләр өлешчә хәл ителде инде.

— Өлешчә генә хәл ителергә тиеш түгел алар. Менә сез елдан артык инде бүлек мөдире вазифасын башкарасыз. Аңлыйм, бу сезнең өчен җиңел түгел. Шуңа күрә төп эшегезне башкарырга вакыт та аз кала. Бүлек һәм лабораторияләргә кирәкле фәнни-техник информация вакытында барып җитми. Димәк, фәнни эзләнүләр алып баручы галимнәр «сукыр килеш» эшлиләр дигән сүз. Шуңа күрә сезнең бүлеккә мөдир итеп Каргинаны билгеләргә дигән тәкъдим бар. Так что, гаризагыз уңай хәл ителгән, дип исәпли аласыз.

Сүзгә үткен, телгә тапкыр Мария Яковлевна бертын өнсез калды, нәрсә әйтергә дә белмәде. Тик чыгып киткәндә генә:

— Һәр киек кош ояны үзенчә кора инде ул, Харис Сәлимович,— дип куйды.— Холкына, гадәтенә карап... Шулай да баш белән эшләгәндә әйбәтрәк чыгар иде.

— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз?

— Ничек теләсәгез, шулай аңлагыз, Харис Сәлимович. Итекче пешекче булса, пешекче итекче булса, хәйран гына хәлләр булгалый бу дөньяда. Минем сезгә бүтән әйтер сүзем юк.

Әлегә кадәр үзен ярыйсы гына тыныч тоткан директор кинәт кызып китте:

— Җитәр фәлсәфә сатарга! Так что, эш белән шөгыльләнергә кирәк. Барыгыз, эшегездә булыгыз.

Мария Яковлевна чыгып киткәч, Нөхитов чын-чынлап уйга калды. Авыр бу галим халкы белән эшләү. Юкка гына кузгалдым үземнең Себеремнән. Хуҗалык эшләре буенча директор урынбасары булу җитмәгән идемени?! Барысына да шул доктор Шариков гаепле. Директор булып бар, тиешле кешеләр белән үзем сөйләшермен, ди. Аннары тиз арада кандидатлык диссертациясе якларга кирәк булыр, диде. Әйе, монысы — иң мөһиме. Кандидат булмый торып, минем белән бик исәпләшмәсләр... Ә ничек язарга соң аны? Кемне җигәргә бу эшкә? Госман Айдарович белән беренче көннән үк телгә килеп ялгыш эшләдем. Хәер, миңа каршы бер сүз дә әйтмәде бит ул... Аңлашасы булыр, әлегә ул минем өчен кирәкле кеше.

Урынбасары янына үзе керергә булды Нөхитов.

— Мөмкиндер бит, Госман Айдарович? Ни эшләр бетереп ятасыз?

— Регионда авыл хуҗалыгы алып бару системасын тәгәлләп киләбез. Кайбер мәсьәләләрне авторлары белән ачыклыйсы гына калды...

— Быел чыгарга тиешме ул?

— Әйе, быел, дүртенче кварталда. Ә эше әле шактый.

— Аңлыйм, Госман Айдарович, бу җаваплы эш, так что, мактаулы эш. Вакытыгыз югын да беләм, шулай да сезнең белән бер мәсьәләне хәл итәсе иде...

— Тыңлыйм, Харис Сәлимович.

— Үзегез дә аңлыйсыз, мине, директор буларак, фән кандидатлары, докторлар арасында дәрәҗәле булмавым борчый. Ким дигәндә бер-ике ел эчендә эшлисе иде шуны...

— Бик хуп күрәм мин моны, Харис Сәлимович. Никадәр кыскарак тотсагыз, шулкадәр яхшырак булыр. Берәр ел эшләгәч, диссертацияне тәгәлләү өчен иҗади ял да ала аласыз. Тәвәккәлләгез!

— Моны сезнең ярдәмнән башка очлап чыгып булмас, Госман Айдарович.

— Булышырбыз. Иң элек материалын туплагыз, караламасын эшләгез. Ә без карап чыгарбыз, кирәк икән, ярдәм итәрбез.

Директорны Госман Айдаровичның киңәше һич тә канәгатьләндермәде. Башкачарак кабул итәр дип көткән иде ул. Ни эшлисең, бу очракта таләп итеп булмый. Шуңа күрә ул сөйләшүне куертып тормаска булды.

— Ярый, рәхмәт киңәшегез өчен,— дию белән чикләнде.

Директор чыгып киткәч, Закиров уйга калды. Кайчанга кадәр дәвам итәр шушы начар гадәт? Югары постларда утыралар. Тотып селкесәң, бернәрсә төшми. Үзләре эшлисе эшне бүтәннәрдән эшләтәләр. Әнә, Валерий Васильевичны гына кара. Өченче ел бездә бүлек мөдире булып утыра, әле һаман фәнгә керә алганы юк. Узган атнада министрга доклад язды, монысында инде министрның урынбасары чакырды, алдагы атнада бүлек мөдире исеменнән өлкә комитетында ниндидер журналга мәкалә язарга кирәк икән. Ә үз эше, төп эше тора... Кайчанга кадәр дәвам итәр икән мондый хәл? Кайда гына утыруы, кайда гына эшләвенә карамастан, кайчан кеше үз вазифасын үзе башкарырга өйрәнер? Менә Нәхитовны китереп утырттылар бирегә. Фәннән ерак кеше. Аны директор итеп куеп, кем нәрсә отты? Минемчә, беркем дә: селекция үзәге дә, фәнни хезмәткәрләр дә, дәүләтебез дә. Соңгы елларда тагын да куркынычрагы: «блат» дигәне борын төртте, хәзер ул тамырларын тагын да тирәнгәрәк җибәрә. Җәмгыятьтәге бу йогышлы чир хаклык, намус үсентеләрен сугара торган дымны суыра, аларга кояшны каплый...

Кинәт ишек шакыдылар. Киң елмаеп, кош тоткан төсле сөенеп, Галина Рязанова килеп керде.

— Нәрсә булды, Галина Федоровна? Нинди куанычыгыз бар? — диде Госман, әлеге авыр уйларыннан арынып.

— Әле генә академик Ремеслодан хат алдым. Карабодайның без чыгарган сорты Украина шартларында уңышлы стандарт сортка караганда биш центнерга күбрәк биргән. Гаҗәп бит бу, Госман Айдарович! Димәк, безнең сортлар белән бергә, селекция үзәгенең дә даны еракларак тарала диган сүз...

— Әйе, бу безнең уртак куаныч, Галина Федоровна. Котлыйм үзегезне, ихлас күңелдән. Тик менә Шаламова группасының гына соңгы ун елда бернәрсә белән дә куандыра алганы юк.

— Аңардан нәрсә дә булса көтү, өмет итү мәгънәсезлек булыр иде, Госман Айдарович. Селекция эше ул үзенә чын мәгънәсендә бирелгән, гашыйк кешеләрне генә бүләкли. Ә бит Шаламова, әйтергә кирәк, җирдән ерак кеше. Селекция питомниклары янына атнага бер килеп, хезмәткәрләргә күренеп китеп кенә эш чыкмый ул. Безнең кызлар әнә көннәр буе басуда, хәтта куна да калгалыйбыз...

— Дөрес әйтәсез, Галина Федоровна. Яңа сортлар чын селекционерлар күңеле аша гына дөнья күрә. Әнә, Зариф аганы гына алыйк. Борчак кузаклана башлаганнан алып, кишәрлекләрне җыеп алганчы кырдан кайтмый. Шунда шалаш корып, шунда ашарга әзерләп, кунып ята. «Нигә бер дә кайтып килмисең?» — дип сорыйм үзеннән. Көлә генә. «Моннан хәзер бер минутка да аерылырга ярамый, көтүе белән каргалар төшә, кача-поса «кузак җыярга» малай-шалай килеп җитә. Ташлап китсәң, кишәрлекне танымассың да»,— ди.

— Ә Шаламованың сорт бирәсенә мин ышанмыйм. Тел белән борчак атып кына сорт чыгарып булмый, Госман Айдарович. Ә ул үзе соңгы вакытта һаман Нөхитов янында кайнаша әле.

— Аларны искә алып, кәефне бозмыйк, Галина Федоровна. Якын-тирәбездә яхшы кешеләр күп бит. Ничек, академик Ремеслога хат җибәрәбезме?

— Хат кына түгел, орлык җибәрергә кирәк. Яңа сортларны җибәрүемне үтенгән. Сез ничек карыйсыз?

— Җибәрегез... Аннан соң күп кенә хуҗалыкларда бик яхшы уңыш биргән Казан сорты да өметле күренә.

— Мин үзем дә уйлаган идем аны. Киңәшегез өчен рәхмәт, Госман Айдарович.

* * *

Эссе көн көчле яңгыр белән тәмамланды. Прокурор Минһаж Бауман урамы буйлап Кремль ягына атлый, танырга теләгәндәй, үзенә каршы очраган кешеләрнең йөзләренә карап-карап ала. Ә кешеләрнең күнеле шат: көлешәләр, шаярышалар, җыелып торган яңгыр суларын сикереп-сикереп чыгалар, һәркайсы үз эше белән ашыга. Ә янәшәдәге скверда бер бәләкәй генә малай, сул кулына печеньесен кысып тоткан да күгәрченнәр туйдыра, уң кулы белән ак күгәрченне койрыгыннан эләктермәкче була...

Шул күренешне күзәтеп, Минһаж бер мизгелгә онытылып киткәндәй булды. Тормыш гүзәл генә түгел, тәгәл дә икән дип уйлап алды, авыр сулап куйды. Тагын бер сәгатьтән аңа, прокурор буларак, хәтәр, авыр бурычны башкарырга, ягъни үзен кеше дип санаучы бер имгәкне гомереннән мәхрүм итүдә катнашырга кирәк иде.

... Ул кичне Васильевоның тыныч тормышын шомлы хәбәр бозды: читтән килгән бер хатынны үтереп, наратлык тирәсенә ташлаганнар. Ул хатын турында баштарак әллә ни белеп булмады. Кәгазьләре белән танышкач, күпне күргән тикшерүче дә: «Шундый кешене әрәм иткәннәр бит, ә?!» — дип уфтанып куйды.

Үтерелгән хатын Бөек Ватан сугышы вакытында партизаннарда элемтәче булган. Концлагерьга эләккән, тәмугның бөтен мәхшәрләрен кичкән, әмма нинди дер могҗиза белән исән калган. Аннары тыныч хезмәттә дан алган, кызлар үстергән. Ә менә бүредә, тыныч көннәрдә, үзебезнең тыныч күк астында гомере киселгән...

Тикшерү эше башланды. Күренеп тора: үтерүче шактый тәҗрибәле, үзеннән соң тирә-юньдә бернинди дә эз калдырмаган. Бармак эзе калмасын өчен, хатынның башына бәргән тимер бощраны да кәгазь белән тоткан. Хатын белән янәшә генә кечкенә сумка ята. Анда хатын-кыз кирәк-яраклары, паспорт... Әмма акча юк иде.

Санаторий директоры бу ханымның дәвалау курсын үтүе һәм Каменец-Подольск шәһәренә кадәр билет алуы турында хәбәр итте. Әгәр дә шушы хәл булмаса, ул инде Украинасына китеп барган булыр иде. Ә билеты кайда соң әле аның?

Барлык читтән килгән кешеләрне, үз йортларында торучыларны тикшерергә, срогын тутырып кайткан җинаятьчеләрне, мәрхүмәнең танып-белешләрен ачыкларга булдылар.

Икенче көнне санаторийга якын гына бер йортта нинди дер бер сәер кешенең бүлмә алып яши башлавын хәбәр иттеләр. Николай Нузитов дигән кеше икән. Моннан бер ай элек кенә срогын тутырып кайткан, әлегә беркайда да эшләми.

Тәп кебек нык, утыз яшьләр тирәсендәге Нузитов үзен тикшерүче янында бик тыныч тотты, сорауларга ышанырлык итеп җавап бирде.

Хәтта ачыктан-ачык сорау биргәндә дә кыенсынмады. Әмма тикшерү вакытында Нузитовның кесәсеннән тимер юл билеты килеп чыкты.

— Сез, Нузитов, әле генә бу якларда төпләнеп калырга ниятләвегезне әйткән идегез. Ә үзегез әнә кая — Каменец-Подольскига билет алгансыз?

— Алмадым һәм алырга уйлаганым да юк.— Нузитов мыскыллы елмайды.— Мин аны таптым, беләсегез килсә.

— Ә нигә милициягә яисә кассага тапшырмадыгыз?

— Тапшырырга теләгән идем. Хәтта кассага бардым да... Кассиры туры килмәде. Аннары онытканмын.

Тикшерүче күрше бүлмәгә чыкты һәм вокзал начальнигына шалтыратты:

— Сезгә берәрсе билетын югалтуын әйтеп мөрәҗәгать итмәдеме? Каменец-Подольскига кадәр?..

— Бер кеше булды,— диде начальник,— билетын тапшырырга теләгән иде. Ниндидер эше килеп чыккан, хәзер бара алмый икән. Ләкин ул билетын тапшыра алмады — кассир юк иде. Шуңа күрә, соңрак килермен әле, дип китеп барды.

Экспертиза Нузитов җиңендәге тапның буяу түгел, ә кан булуын, әйе, күптән түгел үтерелгән ханымның группасына туры килә торган кан булуын раслады.

Менә егетебез прокурор алдында аз гына елмаеп, зәңгәрсу күзләрен кыса төшеп утыра. Ул күзләрдә үкенүнең әсәре дә юк.

— Сөйләгез, ничек мондый җинаятьне эшли алдыгыз?

— Бернәрсәсе дә юк аның. Беләсегез килсә, акчам беткән иде. Карыйм, миңа таба бер хатын килә. Якын-тирәдә беркем юк. Мине үтеп китте бу. Мин аның артыннан... Һәм сез тапкан тимер бөҗра белән... Менә шул гына. Билгеле, акчасын алдым.

— Күпме?

— Илле биш сум.

Шулчак телефон шалтырады. Санаторий директоры үтерелгән ханымның туганы килүен хәбәр итте. Минһаҗ башын тотып катып калды. Аннары урыныннан сикереп торды да Нузитовка ташланды:

— Неужели Хәмидәне үтердең син, бәдбәхет?

Сугыйм гына дигәндә, эш урынында икәнен искә төшереп, бу адымыннан, тыелып калды. Кабинетта хәтәр тынлык урнашты. Прокурор, инде ни әйтергә белмичәме:

— Тагын ниләр эшләдең, эт жан? — диде.

Тегесенең исә бер дә исе китмәде:

— Билетын алдым. Акчага әйләндерергә теләп, кассага килгән идем. Барып чыкмады, кассир юк иде.

— Кеше үтердем, дип, ничек шулай тыныч кына сөйли аласың? Кем тудырды сине? Кайда үстең син?.. Алып чыгыгыз үзен!

Бүлмәдә үзе генә калгач та Минһаҗ Салихов бик озак уйланып утырды. Буранчыда үткән яшьлек елларын күздән кичерде. Хәмидәнең Алабугадан кайткан чаклары онытылмас хатирә булып истә калган.

... Шундый җылы бер кич иде. Яшьләр авыл янындагы аланга уенга җыелдылар. Минһаҗның күзе Хәмидәдә. Башкалар өлгергәнче дип, беренче булып аны биергә чакырды. Озак биеделәр ул кичне. Аннан ул аны Мотаһирларга кадәр озата кайтты.

— Бик тә ошыйсың син миңа, Хәмидә...

— Чынлапмы?

— Чынлап. Тагын кайчан күрешербез икән?

— Исән булсак, күрешербез әле. Дөньялар гына тыныч булсын.

— Ә син бүтән Алабугага китмисеңме инде?

— Юк, Минһаҗ, Мәскәүгә укырга барам.

— Тагын кайчан кайтырсың икән?

— Киләсе елга, җәйге каникуллар җиткәч. Син дә авылда булырга тырыш, яме? Бергә-бергә күңелле булыр...

Икенче җәйне Хәмидә чынлап та Буранчыга кайтты. Тик Минһаҗ авылда юк иде инде. Барысы да әтисе аркасында. Колхозга каршы сүз әйткән өчен, ул, әтисе белән килешә алмыйча, авылдан чыгып китте. Шуннан соң Хәмидәне бер тапкыр да очратырга туры килмәде. Язмыш, диген, үле гәүдәсен генә күрергә насыйп булган икән...

Тикшерү инде ахырына якынлашып килә иде. Шул көнне кич белән район прокуроры Салихов һәм тикшерүче Зеленодольск шәһәренә кайттылар.

— Хәзер йомгак ясарга да мөмкин. Свияжск һәм Әгерҗедә квартира баскан. Пермьгә дә сугылган. Андагы прокуратурага запрос ясалган иде, әмма әлегә кадәр җавап алынганы юк.

Салихов телефон трубкасын алды:

— Мине Пермь өлкәсенең прокуроры белән тоташтырыгыз әле!

Озак көтәргә туры килмәде. Линиядә прокурор үзе иде.

— Тыңлыйм сезне.

— Менә нәрсә. Сезнең Пермь шәһәрендә ачылмый калган олы җинаять очраклары юкмы?

— Бар,— диде коллегасы.— Моннан бер ай чамасы элек өлкән яшьләрдәге бер хатын үзенең квартирасында үтерелгән иде.

— Нинди ысул белән?

— Башы яньчелгән. Җинаятьче кыйммәтле әйберләрен алып качкан. Утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге ир кеше. Ул берничә көн шул хатында фатирда торган.

Әйе, Пермьдәге үтерүнең дә Нузитов кулы икәнлегенә шик калмады. Сорау алу вакытында Нузитов бары тик бераз ачынган, гаҗәпләнгән сыман, ике генә сүз әйтте:

— Тәки казынганнар...

Башкача вакыт уздыруның кирәген тапмады прокурор: ике айда ике йортны баскан, ике кеше үтергән Нузитов.

Судта ул бөтен гаепне гаиләсенә аударды, әти-әнисен хурлады. Имеш, аны ата-анасы тәрбияли белмәгән.

Гаепләнүче аз гына булса да шәфкать күрсәтүне, хөкем карарын йомшартуны сорый. Үкереп елый:

— Мин яшәргә телим! Яшисем килә!..

Дежурный, авыр сулап, ишекне бикләп куя.

Кич җитте. Салихов хөкем ителүче белән соңгы очрашуга килде. Прокурорның вазифасы шундый.

— Тиздән хөкем карары җиренә җиткереләчәк,— диде ул Нузитовка әкрен генә.

Җинаятьченең күзләрендә нәфрәт катыш ялвару кайный:

— Мин яшәргә телим! Яшисем килә!

— Соң инде, Нузитов, соң. Син үтергән теге ике хатынның яшисе килмәгәндер дип уйлыйсыңмы әллә?..

Салихов бу сүзләрне пышылдап кына диярлек әйтсә дә, алар коридорда кайтаваз булып яңгырады сыман.

* * *

Хәмидә үтерелгән көннәрдә күктә кара болытлар асылынып торды. Алар хәзер дә таралмаган килеш. Тик күңелләр күгенә генә күченгәннәр.

— Хәмидә, нәрсә эшләттеләр сине?! Киткәнче безгә керәм дигән идең бит. Бүтән күрергә насыйп булмаган икән үзеңне. Ә бит киләсе елда бергә-бергә Буранчыга кайтырбыз, дип сөйләшкән идек. Нәрсә соң бу?

Кайсы явызның эше? Юлыңда очраган ерткыч хайваннар да сине күреп, йомшак тавышыңны ишетеп, юашланып калалар иде бит. Ә сиңа кул күтәргән адәм ерткыч хайваннан да ерткычрак булып чыккан түгелме соң? — дип, тезләнгән җиреннән күтәрелмәкче булган иде, йөрәген тотып, янә сеңлесенең күкрәгенә капланды. Гөлфия ярдәмгә ашыкты...

Бердәнбер сеңлесен югалтуны бик авыр кичерде Госман. Хәмидәнең кызлары, оныклары килеп чыккач, күңеле кат-кат тулды, кабат йөрәгенә ябышты... Кызлары әниләренең гәүдәсен Украинага алып китәргә теләгәннәр иде. Тик Госман аларга:

— Буранчыда, туган авылында күмәбез әниегезне, сеңелләрем,— диде.— Үзенең васыяте шундый иде. Кайсыбыз исән калсак та, васыятебезне үтәргә сүз куештык. Соңгы юлга озатканда, аның теләгенә каршы килә алмыйм...

— Әгәр дә әниемнең гәүдәсе бу якларда кала икән, мин дә биредән китмим,— диде Хәмидәнең кече кызы Халидә.

Госман, аңышып җитмичә, башта ни әйтергә белми торды. Аннары исенә килде, күзләрендә өмет очкыннары кабынган сыман булды:

— Калырсың, сеңлем, бергәләп селекция үзәгендә эшләрбез.

...Госман Буранчыдан өч көн үткәч кенә әйләнеп килде. Бүлмәсенә кереп утырды, әмма эшкә кулы бармый иде.

Әйе, үскәндә әнә шулай олы хыяллар белән янып йөрисең дә, шул хыяллар тәмам чынга аша дигәндә генә, нindидер бер адәм аламасы һәммәсен дә чәлпәрәмә китерә.

Тарих фәннәре кандидаты Хәмидә Закирова инде докторлык диссертациясен төгәлләп килә иде. Ә яклагач, Казанга эшкә кайтуда иде исәбе. Тарихны ярата иде шул. Сугыш булмаса, концлагерьларда газап чикмәсә, кем белә, инде күптән доктор булыр иде, бәлки...

Теге ачлык елларында, бер бәрәңгене икегә бүлеп ашарга туры килгән елларда, бер туйганчы ипи ашау турында хыялланган минутларда туган олы хисләр аларның барыр юлында якты маяк булды. Фән өлкәсендәге һәр яңалык, Госман катнашында чыгарылган һәр яңа сорт, гибридлар белән һәрчак кызыксынып тора иде, мәрхүмә. Кече кызы Халидәнең селекционер һөнәрен сайлавы очраклы хәл түгел иде, билгеле. Буранчыда үткән көннәрен, аның кырларында ничек итеп бөтен Буранчы туярлык икмәк үстерү хыялы белән яшәүләрен, ничек итеп Госманның бодай үстерергә өйрәнүен һәм башка хәлләрне ул кызына бер генә тапкыр сөйләмәгәндер. Шуңадырмы, унынчы классны бетергәч, Халидә әнисенә:

— Госман абыем юлыннан китәм,— диде.— Бүген бер башак үскән урында икене, өчне үстерү юлларын эзләп табасым килә...

Институтны тәмамлагач, Халидә берничә ел академик Ремесло белән бер институтта эшләде. Илебезгә, башка илләргә танылган сортларны чыгаруда, генетик буларак, Халидә дә үз өлешен кертте.

Ә хәзер ул биредә, Казанда.

— Алдан сөйләшкәнчә, мин монда калырга булдым, абый,— диде ул.

— Ярый, гаризаңны язарсың да...

— Минем әзер инде, язылган.

Госман эчке телефоннан шылтыратты:

— Иптәш Шаламова, бер генә минутка кереп чыгыгыз әле минем янга.

Күп тә үтмәде, ишектә лаборатория мөдире Шаламова күренде.

— Утырыгыз, Ольга Давыдовна. Ялгышмасам, сезнең лабораториягә генетика буенча белгеч кирәк иде бугай?

— Әйе, әйе, Госман Айдарович, бик кирәк. Мин бу хакта галимнәр советында да әйткән идем инде.

— Ул чагында менә Халидә белән сөйләшеп карагыз. Ул — селекционер-генетик. Моңарчы академик Ремесло белән бергә эшләгән. Теләге — Казанга кайту.

Шаламова сүзен, гадәттәгечә, төпченүдән башлады:

— Нәрсә, танылган селекционер янында ошамадымыни? Әллә...

— Әйтеп бетерегез, нәрсә әйтергә теләгән идегез? — диде Халидә, Шаламовага туры карап.

— Әллә китәргә куштылармы, дип әйтүем... Хезмәт кенәгәгезне күрсәтегез әле, мөмкин булса?!

— Башка вакытны,— диде Халидә һәм, Госман абыйсына борылып: — Ольга Давыдовна белән уртак тел таба алмабыз, ахры, көнелем шулай сизә,— диде.

— Теләмәсәгез, ихтыярыгыз. Китәргә мөмкинме миңа, Госман Айдарович?

— Әйе, әйе. Борчуым өчен гафу итегез.

Шаламова чыгып киткәч, Халидә абыйсы янынарак килеп утырды да:

— Мондый кешеләр белән ничек эшлисең син, абый? Әллә бик танылган селекционермы үзе? — дип сорады.

Госман җавап бирмәде. Ул нәрсәдер уйлый иде. Дөресрәге, аңа сеңлесенең кызы алдында уңайсыз иде. Ник соң әле без «яхшы мөгамәлә», «кешелеклелек» дигән нәрсәләрне онытабыз? Тәрбия дигәнең җитми, күрәсең.

— Нигә уйга калдың әле, Госман абый? Мин килеп борчыдым бугай инде үзеңне...

— Юк, юк, Халидә, алай уйлый күрмә. Мин болай гына...

Госман Айдарович тагын телефон трубкасына үрелде:

— Зариф Хәкимович, бер генә минутка кереп чыга алмассызмы икән?

Кузаклы культуралар селекциясе буенча бүлек мөдире Хәмитов бик ачык йөзле кеше булып чыкты.

— Керергә мөмкинме? — диде ул, елмаеп.— А, кунаклар да бар икән!

— Кунак дисәң дә ярый. Әмма, Зариф Хәкимович, кызның биредә эшләргә теләге бар.

— Белгечлеге буенча кем?

— Селекционер-генетик булам, Зариф ага,— диде Халидә.— Ерактан килдем. Моңарчы Украинада эшли идем. Үзебезнең якларга тарта.

— Бик хуп,— диде Хәмитов.— Белгечлегең дә бик әйбәт. Шәт, уртак тел табарбыз.

— Әгәр дә үзегезгә алырга риза икәнсез, мин шуны әйтергә бурычлымын: бу — минем сеңлемнең кызы. Ә сеңлемне, инде ишеткәнегезчә, авылда җирләп килдек. Әнисе туган төбәктән кире китәсе килми Халидәнең. Ләкин безнең мөнәсәбәтләр эшкә зыян китерергә тиеш түгел. Ничек кулай күрәсез, шулай таләп итегез, шулай эшләгез...

— Борчылмагыз, Госман Айдарович, әйткәнне көтеп тора торган кызга охшамаган Халидә.

— Әгәр килешсәгез, бергәләп Нәхитов янына кереп чыгыгыз. Гыйльми хезмәткәрләрне эшкә кабул иткәндә аның визасы кирәк. Гомумән, ул белеп торырга тиеш.

Халидә директорда озак булмады. Зариф ага таныштыргач, бүтән бернәрсә дә өстәп сорамады Нәхитов. Кәефе юк идеме, кая да булса ашыга идеме шунда...

* * *

Нәхитов бүлмәсендә кабат телефон шылтырады:

— Тагын прокуратурадан борчуыбыз әле сезне, Харис Сәлимович. Улыгыз сезнең белән күрешергә тели. Тиешле кешеләр

белән килешенгән. Әгәр дә очрашмасагыз, күңелсезлек килеп чыгуы бар.

— Минем бернинди дә улым юк. Минеке түгел ул. Киттем бит мин ул гаиләдән...

— Анысын ачыкладык. Ничә еллар бергә яшәгәнсез. Ул сезне үз әтисе дип белә. Хөкем алдыннан сезне күрәсе килә. Иң соңгы теләге шул аның.

— Ярый, алайса...

...Нөхитовка күрешү бүлмәсендә озак көтәргә туры килмәде. Менә аның янына елаудан шешенеп беткән улы Николай Нузитовны алып керделәр.

— Әти, әтием,— диде ул, Нөхитовны күргәч,— мин бит сине Себердә яши дип уйлаган идем. Әгәр дә Казанда икәнеңне белсәм, бу көнгә калыр идеммени мин?..

Нөхитов башта үзе дә каушап калды, аннары үзен кулга алып:

— Мин сиңа әти түгел, Наил...— диде.— Дөрес, берничә ел бергә яшәдек, ул чакта син миңа үги ул идең. Так что, син мин әйткәннәргә колак салмадың. Ә әниең мәрхүмә үзеңне артык иркәләде, азындырды, һәм мин сездән китәргә мәҗбүр булдым.

— Ә бит әни башкача сөйли иде.

— Бала кешегә барысын да сөйләп бетереп буламыни ул, Наил?

— Шулай булсын да ди... Барыбер җирдә иң ышанычлы, иң якын кешем син генә. Син генә коткара аласың мине үлем тырнагыннан. Ялысем килә, әти...

— Аңла, Наил, сине йолып калу беркемнең дә кулыннан килми хәзер. Хөкем карары бар. Так что, ул, һичшиксез, үтәлергә тиеш.

— Миннән дә явыз түгелдерсең бит, әти? Мин арттан гына, сездермичә генә үтердем, ә син күзләремә карап, ачыктан-ачык үлем тырнагына ташлыйсың. Коткар мине... Синең танышларың бар. Теләсәң, коткара аласың...

— Юк, Наил, мондый эш минем кулдан килми. Син бала түгел, үзең җинаять кылгансың, үзең җавабын да бир...

— Син дә гаепле монда. Хәтерлисеңме, ничек җәберли идең әнине? Кешегә кул күтәрергә иң элек мин синнән өйрәндем...

Нөхитовның күңеле тәмам ташка әйләнде. Бу сүзләрдән соң аңарда Наилгә карата бер тамчы да кызгану хисе калмады.

— Шантажга барма, сиңа аның файдасы булмаячак. Кеше гомерен өзгән өчен үз гомереӊ белән җавап бирергә туры килә. Кануннар шулай куша. Ярый, хуш!

— Әти! Китмә, ташлама мине! Яшисем килә, коткар!—дип, Нузитов кычкырып еларга ук кереште.

...Нөхитовның башы түнде, аяклары алга атлый, колагында Наил тавышы. Һәм ул тавыш һаман ерагая, ерагая бара...

Чыгуына аны ишек төбендә кара «Волга» көтеп тора иде.

— Селекция үзәгенәме?—диде шофер егет Мәхмүт.

— Юк, өйгә. Көтмәгәндә генә әллә нишләп киттем әле...

Бу очрашу турында өч кенә кеше белә иде. Нөхитов үткәннәрне тагын бер кат күздән кичерде. Ышанычлы кешеләр. Шәт, мондый яман хәл селекция үзәгендә эшләүчеләргә дә, өйдәгеләргә дә ишетелмәс...

Өйдә аны улы Өлфәт каршы алды:

— Нигә бүген бик иртә, әти?

— Нишләптер авыргандай иттем әле. Кәеф китеп тора. Ә син үзең нигә өйдә?

— Балалар белән экскурсия оештырган идем, иртәрәк бетте.

— Экскурсия, икенче төрле әйткәндә, шул ук дәрес инде ул. Ә дәрес үз вакытында бетәргә тиеш. Так что, балаларны алай гадәтсезлеккә өйрәтергә ярамый.

— Нәрсә булды бүген сиңа, әти? Гомердә булмаганны, нигә болай бәйләнәсең әле?

— Бәйләнергә вакыт, Өлфәт. Буйдак булып күпме йөрергә мөмкин? Синең яшьтәгеләр инде күптән гаилә кордылар, так что үзләре бала атасы.

— Анысына өлгерербез, әти. Бездән генә калмас. Ә менә мине шелтәли башларга соңармадың микән, дим. Югыйсә, минем һәр адымга алсу күзлек аша карарга ярата идең.

— Ниткән фәлсәфә сату бу тагын? Яхшылыкка өндәү беркайчан да соң түгел, хәтта үлем янаган...— Нөхитов, сүзен әйтеп бетермичә, тотлыгып калды.

— Ул чагында бөтенләй соң була инде ул, әти. Ярый, борчылма, һәммәсе дә син дигәнчә булыр. Мин кинога киттем. Пока!

Нөхитовка һаман да Наилнең: «Яшисем килә!» дигән сүзләре тынгылык бирми иде. Сәер, бик сәер... Күз карашлары, борыны, кашлары үземә охшаган. Теге вакытта чынлап та ялгыштыммы икәнни? Ярый, үткән эшкә салават. Хәзер беркемгә дә кирәге юк инде аның. Әнисе инде күптән вафат булды. Соңгы шаһит — Наилнең дә соңгы минутлары. Болар белән беркем дә кызыксынмаячак.

Һәммәсен дә башыннан чыгарып ташлыйсы килеп, Нөхитов телефон трубкасына үрелде.

— Алексей Иванович, сез өйдәмени, институтка бармадыгызмыни? Бүген килеп йөрмәгез инде. Мин дә була алмыйм. Иртәгә иртә белән килерсез. Әйе, әйе, сәгать тугызларга, ярый, хушыгыз!

* * *

Алексей Коршун билгеләнгән вакытка килеп җитәргә ашыкты. Кирәк бит, баскычтан менеп җиткәндә генә Мария Яковлевна каршы очрады.

— О, Алексей Иванович! Безнең академик! Исәнмесез! — диде ул.— Нәрсә, өйдә утыру ялкыттымы әллә?

— Үзең пенсиягә чыккач, аңларсың әле минем хәлне, Мария Яковлевна. Яраткан эшеңнән аерылып, өйдә утыру бер дә җиңел түгел икән шул...

— Дөресрәге, «яраткан зарплата»дан диегез инде, Алексей Иванович! Күпме өйрәттем үзегезне турысын сөйләргә, барыбер читкә каерасыз.

— Ярый, Мария Яковлевна, шаяртырга вакыт юк хәзергә. Директор чакырткан иде.

— Сезнең шулай инде, һәрчак вакыт юк. Атнага ике көн эштә күренәсез. Аның да бер көне — зарплата ала торган көн. Өйдә, биргәндә алыгыз... Нигә алдың, дип кайный башласалар, алмадым, диярсез.

Нөхитов Алексей Коршунны җылы каршы алды. Тик тегесенең генә кәефе кырылган иде.

— Нәрсә булды, Алексей Иванович?

— Монда кергәндә теге Мария Яковлевнага эләктем. Әллә берәр нәрсә сизенгән инде? Фәлән, ди, академик, ди... Атнага ике көн эшкә киләсез, аның да берсе зарплата алырга, ди...

— Ну бу хатынның телен! Моңарчы әле бүлек мөдире вазифасын үти иде. Аннан да бушаттым инде. Так что, хәзер хезмәт хакын алтмыш сумга кимрәк ала. Мөдир итеп Каргинаны билгеләдем. Анысын нык кисәттем: «Эш белән күм, мин әйтәм, ул хатынның исәнеп йөрергә вакыты калмасын»,— дидем. Таба бит вакыт. Алып кына ташлар идең, эшендә бәйләнер нәрсә юк, ди Каргина. Төгәл, пөхтә, вакытында эшли икән. Район, хуҗалык белгечләре үзен мактап бетерә алмыйлар.

— Бәлки, яхшылык белән алдырып булыр, Харис Сәлимович? Яхшылык эшләп карагыз сез аңа, премиясен кызганмагыз. Бу көчле хатынны үз файдаңа эшләтү кирәк...

— Чынлап та, хак әйтәсез бит сез, Алексей Иванович. Уйларга кирәк булыр. Үзегезнең хәлләр ничек соң?

— Хәлләр ярыйсы. Мәнә «роман»ны тәгәлләдем. Хәзер машинкага бирергә кирәк. Аннары тагын бер кат карап чыгармын да, Госман Айдаровичка күрсәтеп карарсыз. Нигездә аның материалларына таянып язылды, ул нәрсә әйтер?

— Монысы читенрәк мәсьәлә. Башкача мөмкин түгелме?

— Ничек инде директор урынбасары диссертациянең эчтәлеге белән таныш булмаска тиеш? Фән өчен, нигездә, ул җавап бирә бит.

— Әгәр дә каршы килсә? Монда бар ягын уйларга кирәк.

— Анысы сезнең эш, Харис Сәлимович. Ничек телисез, шулай эшлисез... Ә менә квартир мәсьәләсе белән ничек булыр икән? Җәфаландым бу иске квартирада: кышка керсәң, җылысы юк, күп вакыт суы булмый. Якын көннәрдә хәл итәсе иде, Харис Сәлимович.

— Кайгырмагыз. Әйттем бит инде мин сезгә, бу ел фондыннан була, дип. Озакламый биш квартир бирәчәкләр. Так что, берсе — синеке. Тик нигә ул сезгә өч бүлмәле фатир? Өч кешегә ике бүлмәле җитмимени?

— Кысанрак шул. Кайвакыт миңа шулай өйдә эшләргә туры килә. Аннары, дөнья хәлен белеп булмый, кызның да кияүгә чыгып куюы ихтимал. Үзебезнең яннан җибәрәсе килми.

— Ярар, аңлашылды, Алексей Иванович. Сез дигәнчә эшләрбез. Тик бу хакта безнең икебездән башка беркем дә белергә тиеш түгел. Югыйсә, үзең беләсең бирелә эшләүчеләрне... Күбесе энәдән дөя ясарга ярата.

— Борчылмагыз, Харис Сәлимович, барысы да сез дигәнчә булыр. Миңа тагын бер-ике ай эшләргә рөхсәт итәрсез бит?

— Эшләрсез. Сезнең кебек ветераннарга мөмкин.

Коршун чыгып киткәч, Нәхитов кульязманы караштырып утырды, аннан кыңгырау төймәсенә басты. Бераздан ишек төбендә секретарь-машинистка Гүзәл елмаеп тора иде:

— Тыңлыйм, Харис Сәлимович.

— Беләсеңме, Гүзәл, нәрсә... Сиңа бер атна-ун көнгә минем ял бүлмәсенә күчеп утырырга туры килер. Срочный эш бар. Югыйсә, сиңа приемныйда комачаулыйлар. Әле бер йомыш, әле икенче йомыш табып, эшеңнән бүләләр. Килештекме?

— Бик яхшы булыр. Тынычлап эшләрмен, ичмасам.

Сылу кыз Гүзәлне эчке бүлмәгә урнаштыргач, директор аңа кульязманы тапшырды да, озаклап кызның күзләренә карап торды:

— Их, яшьрәк чагым булса...

— Нәрсә эшләр идегез, Харис Сәлимович?

— Яратыр идем...

Гүзәл, кызарып, башын түбән иде. Шулчак эш бүлмәсендә телефон шалтырады. Нәхитов йомшак кына итеп Гүзәлнең иңнәреннән какты да, «Башлый тор, булмаса»,— дип, телефонга таба ашыкты.

— Мәскәүдән? Ә, Ольга Ивановна! Исәнмесез! Нинди яңалыклар бар ВАСХНИЛда?

— Куандыра алам, сезнең селекция үзәге фән өлкәсендәге ачышлары һәм аларны гамәлгә кертүдәге уңышлары өчен СССР Халык Хуҗалыгы Казанышлары Күргәзмәсенең беренче дәрәҗә дипломына лаек. Ә үзләреннән аеруча зур өлеш керткән галимнәрдән Зариф Хәмитов, Госман Закиров, Галина Рязанова алтын һәм тагын биш гыйльми хезмәткәр көмеш һәм бронза медальләр белән бүләкләнә. Якын арада вәкил җибәрегез һәм медальләрне тантаналы шартларда тапшыруны оештырыгыз.

— Рәхмәт сезгә, Ольга Ивановна! Хушыгыз!

Нөхитов трубканы эчке бер канәгатьсезлек белән урынына куйды: «Үткән көннәр, үткәндәге уңышлар... Болар минем өчен плюс түгел».

Шулчак ишек ачылды. Урынбасары Госман Закиров күренде.

— Мөмкин булса, бер мөһим мәсьәлә турында сөйләшеп алырга теләгән идем.

— Рәхим итегез, Госман Айдарович.

— Үзегез дә беләсез, гомуми игенчелек лабораториясендә өлкән гыйльми хезмәткәргә вакантлы урын бар. Әгәр дә шул урын өчен Алик Закиров документларын конкурска бирсә, сез ничек карарсыз икән? Күптән түгел ул кандидатлык диссертациясе яклады. ВАКта инде расланды. Хәзер шул теманы тирәнрәк дәвам итәргә уйлый...

— Кайда эшли соң ул хәзерге вакытта?

— Авыл хуҗалыгы министрлыгында.

— Мин үзем каршы түгел. Әмма министрлыкның кадрларын алган өчен безгә беркем дә рәхмәт әйтмәс, Госман Айдарович. Икенчедән, хатыныгыз Гөлфия бирелә эшләгәнгә дә үз тирелэренә сыеша алмый йөрүчеләр шактый. Тәк што, шулай булгач, уйлап карагыз инде.

— Аңлашылды, Харис Сәлимович. Дөресрәге, тел төбегезне аңладым. Ул бит турыдан-туры минем кул астында эшләмәячәк. Бүлекнең мөдире бар, анда тулы бер коллектив бар. Монда туган-тумачалыкка бернинди дә җирлек юк.

— Госман Айдарович, мәсьәләгә аек карасагыз иде. Әле кичә генә бүлек мөдире Шамкаев та шушы мәсьәләне күтәрде. Так что, хатыныгыз Гөлфия Афзаловна үз вазифаларын башкарып җиткерми икән. Бигрәк тә хуҗалык килешүен үтәү буенча эш начар тора...

— Сез, Харис Сәлимович, миңа Шамкаев сүзен сөйләмәгез. Аннары, уңайсыз хәлдә калмас өчен, үзегезгә дә бухгалтериягә шалтыратып сорарга була иде бит. Әйе, әйе, Гөлфия Закирова исәбенә хуҗалык килешүе буенча күпме акча кергән, дип... Бүгенге көнгә ул тулысынча үтәлгән. Димәк, Алик Закировка документларын конкурска бирмәскә киңәш итәсез?

— Аннан соң бит, әлегәчә ул урында авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Коршун эшли, Алексей Иванович. Вакытлыча алган идек...

— Ишеткән идем. Һаман да эшлимени әле ул? Дүрт кенә айга дигәннәр иде бит.

— Тагын ике айга озайтуны сорады. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Бик үтенгәч, ничек каршы киләсең?

— Анысы шулай... Тик миңа бер нәрсә аңлашылмый...

— Нәрсә тагын? — Нөхитов шикләнә калды. Башыннан: «Кем җиткерде икән?» — дигән уй йөгереп үтте. — Диссертация турындадыр. Каргина түгелме икән? Юк, юк, ул әйтмәс. Әллә Алексей Иванович үзе ялгыш ычкындырдымы?»

— Беләсездер, Харис Сәлимович, киңәшле эш таркалмас, дигән халык. Ә сез киңәшләшүне үзегез өчен түбәнлек саныйсыз, ахры...

— Юктан проблема ясамагыз. Мин сездән башка эшкә дә кабул итә алмыйммыни инде? Үз остегезгә күбрәк аласыз түгелме? Тәк шту, авырга туры килмәсен. Кстати, мин сезне болай да икенче бер мәсьәлә буенча чакыртырга уйлап тора идем. ВАСХНИЛдан хат бар. Сезне, зам булarak, өч айлык курсларга чакыралар.

— Вакыты ул түгел бит, Харис Сәлимович. Ялга китәрмен дип тора идем.

— Курслардан соң чыгарсыз ялга. Килештек. Әзерләнегез. Тәк шту, квалификацияне даими рәвештә күтәреп тору — заман таләбе икәнен онытмагыз, Госман Айдарович.

Закиров, үз бүлмәсенә чыккач та, директорда сөйләшкәннәрне тагын бер кат күңеленнән кичерде. Нигә соң әле ул мине курсларга озатырга тырыша? Нидер аңлашылып җитми монда. Бәлки, киңәшеп эшлисе

килмидер. Вакытлыча тынычлап калырга уйлавымы? Ярый, ни булса да булыр, тәвәккәлләп карарга кирәктер...

* * *

Мәскәүгә белемнәрен күтәрергә килгән галимнәрне Тимирязев исемендәге академиянең тулай торагына урнаштырдылар. Дәресләр көн саен иртән сигездә башлана, алтышар сәгать дәвам итә. Дәресләрдән соң Госман шәһәр урамы буйлап җәяүләп үтәргә ярата, саф һава сулый. Аннары почта тартмасына хат салып килә.

Беркөнне шулай Гөлфиядән хат килеп төште.

***«Әтисе, син юкта биредә безнең өчен аңлашылып бетмәгән шактый гына сораулар туды. Беркөнне Нөхитов Халидәне үзенә чакырып алган да төпченә башлаган. «Син, имеш, Закировка кем буласың? Ничек бирегә килеп эләктең?» — дип аптыратып бетергән. Ә Халидә югалып кала торганнардан түгел икән. «Беренчедән, мин Закиров кул астында түгел, ә Зариф ага белән эшлим. Икенчедән, сезнең болай сорау алырга, дискриминация белән шөгыльләнергә ни хакыгыз бар? Үз эшегез белән ыграк кызыксыныгыз!»,— дигән.***

***Аннары тегесе шушы ук мәсьәлә буенча Зариф аганы чакырткан. Аның белән сөйләшү нинди тәртиптә булгандыр, белмим. Тик, чыккач, Халидәгә: «Шулай, ыграк бул, кызым!» — дигән.***

***Мондагы юк-бар нәрсәләр турында язып борчуым өчен гаепләмә. Болар турында синең дә белеп торуың кирәктер дип уйлыйм.***

***Хәзергә хуш, әтисе. Синең Гөлфияң».***

Госман хатны папкасына салды да авыр сулап куйды. Ни өчендер Нөхитов ике арадагы мөнәсәбәтләрне катлауландырырга уйлый. Нәрсә җитми моңа? Нәрсә тели ул миннән? Әллә беренче очрашуда әйткән сүзләрем ошап җитмәдеме? Әллә өлкә комитетындагы сөйләшүнең эчтәлеген җиткерделәрме? Дөресрәге, шулайдыр. Димәк, аның анда ышанычлы таянычы бар. Югыйсә, бу кадәр дорфа кыланмас иде. Әллә үзем тормыштан артта калдым, әллә заман үзгәрде... Безнең бит атилар, абыйлар хаклык өчен, дөреслек өчен, якты киләчәк өчен көрәштеләр, гомерләрен бирделәр. Ә менә бүген хак сүз әйткән кешегә ихтирам сизелми, киресенчә, кайберәүләр аны эзәрлекләү җаен карыйлар. Бу гадәткә кереп бара. Ничек көрәшергә моңа каршы, ничек корытырга моның тамырын?

Аннары күп нәрсәләрне аек акыл түгел, ә шәраб хәл итә. Шәраб парыннан томаланган акыл зәгыйфь уйлый, зәгыйфь фикергә килә, зәгыйфь карар кабул итә. Ә моннан намуслы кешеләр, җәмгыятебез зыян күрә...

Ул көнне беренче дәрес генетикадан иде. Лекцияне ниндидер профессор Шариков укырга тиеш икән. Ун минут үтте, әмма Шариков һаман күренми. Госман, шушы «тәрәзә»дән файдаланып, ВАСХНИЛга китәргә генә җыенган иде, ишектә профессор үзе күренде. Сакал-мыектан. Сакалы инде агара да башлаган. Дәрескә соңарудан ашыккангамы, пеләшендә вак кына тир бөртекләре дә ялтырый...

— Хәерле иртә, хөрмәтле курсантлар,— диде ул.— Азрак соңарырга туры килде: сезнең алда гафу үтенәм.

Бу тавыш Госманны тетрәндереп җибәрде. «Таныш тавыш... Кайда гына очраштык соң без бу профессор белән? Күзләре дә кемнедер хәтерләтә. Шариков? Ләкин мондый фамилияле кешене хәтерләмим. Бәлки, кемгә дә булса охшаган гынадыр?..»

Менә тәнәфес җитте. Госман, нык.лы фикергә килеп, туп-туры профессор янына юнәлде. Турысын әйтеп сөйләшергә булды.

— Иптәш Шәрәпов, сезне бер генә минутка мөмкинме?

Профессор кинәт үзгәреп китте. Аннары, тиз генә үзен кулга алып:

— Шариков тыңлый сезне, рәхим итегез,— диде Госманның протез кулына текәлеп.

— Ополченецлар батальонында көрәшкән Шәрәпов сез бит ул, ялгышмасам...

Профессор баштарак аптырап калды. Башыннан: «Танытмаскамы, әллә дөресен әйтергәме?» — дигән уй йөгереп узды булса кирәк. Танытмаска маташуның мәгънәсезлек икәнен профессор бик тиз абайлап алды һәм фронтташына ташланды:

— Ялгышмасам, Закиров буласыз бит, шулаймы? Йә, сөйләгез, ничек исән калдыгыз? Ул мәхшәр көнне искә төшерсәм, хәзер дә исем китә. Безнең батальоннан исән калган беренче кешене очратам. Ничә еллар үткәч... Менә нәрсә, бүген эшләр тәмамлангач безгә кайтабыз. Иркенләп сөйләшеп утырырбыз. Минем әле тагын бер лекция укыйсым бар. Деканатта очрашырбыз. Килештекме?

— Мин рәхәтләнеп риза,— диде Госман.— Шундый очрашудан ничек баш тартасың? Чынлап та, көрәш кырында аз гына вакыт бергә булсак та, сөйләшер сүзләр, уртак хатирәләр күп безнең.

Деканаттан автобус тукталышына кадәр ерак түгел иде: җәяүләп кенә чыктылар. Госман, тукталышта Башкортстаннан килгән бүлмәдәш егетне очраткач, аны читкәрәк чакырып алды:

— Бүген миңа соңарып кайтырга туры килер. Профессор Шариковларда кунакта булам. Кайсы профессор дисеңме? Генетикадан лекция укый... Фронтта бергә булган идек. Мине югалтма, ярыймы?

— Бик соңарсаң, кайтып йөрмә. Дәресләргә ничек тә өлгерерсең. Ярый, хәерле юл үзеңә...

Менә сиксәненче номерлы автобус килеп тә туктады. Профессорның кинәт кәефе кырылды. Нәрсә турындадыр бик бирелеп уйлый иде ул. Аннары, уйларыннан арынып:

— Рәхим итегез, безгә кадәр шушы автобус кайта,— диде профессор һәм сорап куйды: — Әлеге егет кайдан була ул?

— Ә-ә-ә, таныштырмадым, гафу итегез. Ул минем белән бергә укый. Башкортстаннан...

— Ничек соң, курсларның файдасы бармы?

— Булмыйча, бар, билгеле. Һәр лектор нинди дә булса яңалыкны, яңа алымны җиткерергә тырыша. Гафу итегез, исемегез истән чыккан...

— Михаил Яковлевич.

— Миңа Госман Айдарович диярсез,— диде Закиров һәм, исенә төшерергә теләгәндәй, кайдадыр еракта калган хәвефле елларга әйләнеп кайтты: әтисенең исеме ничектер бүтәнчәрәк, дөресрәге, безнеңчәрәк кебек иде. Нигә үзгәртте икән соң ул аны? Хәер, андый кешеләр азмыни бу заманда?

Профессор Шариковның квартирасы иркен: өч бүлмәле, биек түшәмле, зур кухнялы... Әмма өйдә берәү дә юк иде.

— Бер дә аптырамагыз өйдәге тәртипсезлеккә,— дип аңлатты профессор.— Марияне узган атнада больниска салган идем. Ашказаны белән җәфалана. Хатын булмагач, уңайсыз шул. Сез миңа игътибар итмәгез. Әнә бу бүлмәдә китаплар караштыра торыгыз. Ә мин капкаларга берәр нәрсә әмәлләп алыйм...

— Борчылмагыз, Михаил Яковлевич, минем тамак тук.

— Сез үз бизмәнегез белән генә үлчәмәгез, мин дә бар әле бу дөньяда,— дип, профессор кухняга кереп китте.

Кунак бүлмәсе китап белән тулган. Идәннән алып түшәмгә кадәр китап киштәләре. Һәркайсы шыплап тутырылган. Госман, кызыксынып,

әле берсенә, әле икенчесенә үрелә. Болары таныш. Күрче, менә революциягә чаклы басылган иске китаплар. Менә монысы аеруча таныш. Кайдадыр укыган иде бугай ул аны. Тукта, тукта... Госман китапка үрелде. Беренче битен ачкан иде, үз күзләренә үзе ышанмыйча, нәрсә эшләргә белми торды. Анда «Алабуга интернат мәктәбе» дигән мөһер сугылган иде. Хәмидә укыган мәктәп... Ничек бирегә эләкте икән соң бу? Шуны профессордан сорамакчы булып бүлмәдән чыгып бара иде, баскан җирендә катып калды. Теге вакытта Хәмидә югалткан «ачкыч»... Әйе, әйе, Шәкүр калдырган «ачкыч»... Ни эшләргә соң хәзер? Ничек тә алып чыгарга кирәк бу китапны... Ә ничек? Папкасын да калдырып килде бит. «Юк, моны һич тә алырга ярамый»,— диде ул үз-үзенә. Өстәл янына утырып, «ачкыч»ны тиз генә кәгазьгә күчереп алды да китапны урынына куйды. Аннары икенче бер китапка үрелде. Шулчак алгы бүлмәдә карлыккан тавыш ишетелде:

— Кунак бар икән, исәнмесез!

Госман янына таза гәүдәле бер пәһлеван килеп утырды.

— Исәнмесез,— диде Госман,— менә бер кызыклы цитата очрады да, шуны күчереп алмакчы идем, ручка язмый. Әнә шул ручканы гына алып бирегезче!

Госманның кулында профессор Шариковның китабын күргәч, пәһлеван күзләрен уып куйды. Шул арада кухнядан профессор үзе дә килеп чыкты.

— Кичке аш әзер, Госман Айдарович,— диде ул, әмма, пәһлеванны күргәч, аптырап калды.— Ничек, син өйдәмени, улым?

— Үзең өйдә булырга куштың ич. Нәрсә, әллә теге таныш фронтовигың килмәдеме?

— Ул бүген килмәде, менә Госман Айдарович белән очраштык бит,— диде профессор, сүзне икенчегә борып.— Әгәр дә безгә соравың булмаса, безнең икебезне генә калдырсаң икән...

— Ярый, мин озак йөрмәм, тиздән әйләнеп кайтырмын...

Икәүдән-икәү генә калгач та, Госман сүзне нәрсәдән башларга белми аптырады. Иң мөһиме — хәлне катлауландырырга ярамый. Бераз үткәннәрне искә төшерергә дә, үзен Казанга кунакка чакырып, тулай торакка кайту ягын карарга кирәктер.

— Хәтерлисезме, Михаил Яковлевич, безнең командирны, яшь-яшь кенә бер лейтенант иде...— дип сүз башлады Госман.

— Хәтерләмичә, андый кеше гомергә истә кала ул. Әйдә, сез капкалап утырыгыз әле... Лейтенантны әйтәм, докторлардан ничек итеп баш тартканы әле дә исемдә. Бер доктор миңа бик җиткән, калганнарын теләсә кая җибәрегез, дигән иде...

— Менә нәрсә, Михаил Яковлевич, безгә, бер вакыт табып, батальон соңгы бәрелешкә кергән җирләрдә буласы иде. Сез анда кемне коткардыгыз әле?

— Юк шул, коткара алмадым мин аны... Кулымда җан бирде, шунда, куаклар төбендә, җирләдем. Үз кулларым белән...

— Тукта, тукта, исеме ничек иде соң әле аның? «В»га башлана иде бугай...

Шариков нәрсәдәндер шикләнә төсле тоелды Госманга. Һәм ул сүзне икенчегә борырга тырышты:

— Онытсак та гаҗәп түгел, шактый еллар үтте бит инде.

— Исемә төште, Госман Айдарович. Аның фамилиясе, минемчә... Тукта, тел очымда гына тора бит...

— Фән докторы иде, шулаймы?

— Анысын белмим. Ә фамилиясе Васильев булырга тиеш.

— Василенко түгелме?— диде Госман һәм ник әйткәненә шундук үкенеп тә куйды. Профессорның кинәт кенә йөзе каралып китте, тавышы үзгәрде:

— Ну, хәтер дә инде үзегездә, Госман Айдарович... Дөрес әйттегез, чынлап та Василенко шул.

— Үзе, Василенконы әйтәм, Мәскәүдән иде бугай, гаиләсе белән элемтәгез юктыр?

— Юк, Госман Айдарович. Документларын тиешле урынга тапшырдым. Ә менә гаиләсен эзләү турында уйламаганмын...

— Хәзер эзләп карасак?

— Үткәннәрне нигә кат-кат әйләндерергә, Госман Айдарович? Гаиләсеннән кем дә булса исән калган булса, йомылып килгән яраны нигә кузгатырга?

— Сез хаклы, Михаил Яковлевич,— диде Госман һәм, хәлне кискенләштермәс өчен, бөтен кич буе Шариков әйткәннәр белән килешкән кешедәй ваемсыз булырга тырышты.

— Мин доктор Аверьяновны Упкын сазлыгы аша алып чыгып җиткердем. Госпитальдә дәваланганнан соң тагын фронтка киткән. Ә менә сугыш беткәндә исән калганмы ул, юкмы, анысы мәгълүм түгел...

Михаил Яковлевич, кинәт кенә башына куанычлы бер фикер килгәндәй, елмаеп куйды. «Шушы профаннан куркып яшәдем бит гомерем буе,— дип уйлады ул эченнән.— Ә ул, баксаң, берни дә белми икән. Аверьяновың кайтты, тик ул бүтәнрәк кеше иде, шуңа гомере кыска булды...»

— Капкалап утырыгыз әле, Госман Айдарович. Бу тостны без җиңү хакына тотабыз.

— Әйе, безнең җиңү хакына. Тик соңгысы... Бүтән ярамый.

Бераздан Закиров китәргә җыенды.

— Сыегыз өчен рәхмәт сезгә, Михаил Яковлевич. Кунакчыл, ачык кеше икәнсез. Үзегез Казанга кунакка килегез. Сезнең белән очрашу үзе бер гомер. Ярый, хушыгыз!

— Тукталышка кадәр озата барам. Таныш түгел җирдә уңайсыз була ул.

Фронтовиклар тукталышка якынлашуга, автобус та килеп җитте.

— Ярый, зур рәхмәт сезгә, Михаил Яковлевич. Казанда очрашырбыз дип өметләнәм.

Шариков куаклар янына житүгә, аның каршысына теге пәһлеван улы килеп чыкты.

— Планнар ни эшләп үзгәрде?—диде ул әтисенә.— Бер төрле сөйлисең, икенче төрле эшлисең...

— Ярамый иде, беләсеңме, ярамый... Тимирязевкадан без киткәндә якташы озатып калды. Ә ул мине яхшы таный. Аннары, мәшәкатьләнүнең кирәге дә булмаган. Үткәннәр хакында Закиров бернәрсә дә белми.

— Алайса, үзегезгә карагыз. Миннән эш калмады... Турысын әйтим, бу кеше миңа бик серле күренде. Аверьянов ише генә түгел бу.

— Соң, мин каршы түгел, артыннан күзәт алайса. Тимирязевканың тулай торагында яши ул. Аны табуы сиңа читен булмас. Ул-бу сизелсә, шунда ук миңа хәбәр ит. Аннары Казан белән элемтәгә керергә кирәк...

* * *

Кайчандыр разведчик булып хезмәт иткән Госманның күзләре үткенрәк булып чыкты. Әнә, әле генә салына башлаган тулай торак почмагында Шариковның улы кем беләндер сөйләшеп тора иде. Госман ни уйларга да белмәде баштарак.

«Әллә берәр нәрсә сизенделәрме? Аның монда аяк басуы юкка гына түгел. Теге китапны эзләп тапканнардыр, бәлки. Тукта, безнең курсташ белән сөйләшә түгелме соң бу?» Ниһаять, Пәһлеван тулай торакка кулы белән төртеп күрсәтте дә ашыгып китеп барды.

— Менә үзе дә биредә икән,— диде курсташы, Госманны күргәч.— Сине берәү эзләп килгән иде, сукса тимер өзәрлек...

— Нигә кирәк булдым икән мин аңа?

— Танышым, ди, очрашасы бар иде, ди. Шуңа синең кайда торганыңны әйттем. Аннары ул дәресләрнең кайчан бетүе белән кызыксынды. Гомумән, иртәгәләргә кереп чыгар ул синең янга. Күчтәнәчеңне әзерләп куярга онытма...

«Күчтәнәч, имеш... Кем икәнен белми торып, нигә адресны әйтергә иде аңа?» — Госманның курсташын ачуланып ташлыйсы килгән иде дә, яхшысынмады.

Әмма кунак башкача күренмәде. Тик беркөнне Гөлфиядән килгән хатның ачып ябыштырылган булуы гына Госманда шик уятты. Шул иснәнеп йөрми микән? Хат аша нинди дә булса яңалык эләктерергә тырыша, ахрысы...

Икенче көнне почта килгән вакытта Госман лекциягә кермәде. Чит күзләр күрми торганрак урынга утырды да, газетка күмелеп, укырга керешге. «Кунак» үзен озак көттермәде. Килгән хатларны карап чыкты да тыныч кына китеп барды.

Бу хакта Госман телефон аша Гөлфиягә шылтыратып өлгергән иде инде. Шунда ул чит күзләр укырга тиеш булмаган хат язып җибәрүен әйтте.

Бу көнне Госман почтаны үзе көтеп алды. «Кунак», вестибюльгә кергәч, Госманны күрде дә, тиз генә икенче катка күтәрелде. Госман исә, хатны алып, уку корпусына юнәлде.

Әлеге хаттагы хәбәр, чынлап та, уйландырырлык иде. Гөлфия анда институтның Гыйльми Советында Нөхитовның диссертациясен тыңлауларын хәбәр итә.

*«Галимнәр советына түгел, ниндидер ашык-пошык оештырылган җыелышка охшый иде ул. Беренчедән, кворумы юк иде, барыбер башладылар. Тирәнтен анализлап чыгып ясаучы булмады. Нөхитов әзер таблицалар буенча аңлаткандай итеп чыкты. Әмма сорауларга юньләп җавап бирмәде. Мин куйган өч сорауның берсенә дә җавап бирә алмады. Ярый, болар турында, үзең кайткач, иркенләп сөйләшербез. Диссертациясе белән танышкан кешеләрдән Каргина, аннары Букреев чыгыш ясады. Төпле анализ булмады. Бары тик мактадылар гына. Шәрәф тә, Зариф ага да, Галина Федоровна да укымаганнар. Имеш, җитмәгән, өч кенә нөсхәдә булган. Без дә күз төшерә алмадык. Шулай итеп, урыс әйтмешли, «капчыктагы мәче»не якларга туры килде.*

*Госман, бүген менә үзебезнең үткән тормыш юлын бер кат күздән кичердем. Хаклык дип, хыялларны тормышка ашырыйк дип күпме каршылыкка очрадык, күпме сыналдык, күпме мәшәкать, күпме кыенлыклар күрдек, әмма сынмадык, үзебезнең өскә төшкән авырлыкны намус белән илтәбез.*

*Госман, гомеребезнең шактый өлешен яшәдек инде. Киләчәктә дә, ничек кенә булса да, мәңге тынмас кешеләр булып калыйк. Хуш! Синең Гөлфияң!»*

* * *

Мәскәүдән китәр вакыт җитте. Иртәгәге көнгә Казанга билет алынган. Бүген исә Госманның буш көне. Ул ВАСХНИЛга юнәлде. Алай артык зур йомыш юк иде югын, шулай да сугылып чыгарга булды. Белеп килгән диярсең. Ул кергәндә, Авыл хуҗалыгын алып бару системасы буенча Совет утырышы башланырга тора иде. Бернича академик һәм күп кенә фән докторлары җыелган. Академик Грязнов та шунда.

Ул Идел һәм Урал буендагы фәнни-тикшеренү учреждениеләренә курьерлык итә: кирәк чакта булыша да, таләп тә куя...

Утырыш озакка сузылмады. Бары тик Белорусиянең бер өлкәсе өчен эшләнгән системаны җентекләп анализладылар һәм, күрсәтелгән кимчелекләрне төзәткәннән соң кабат тыңларга, дигән карар чыгардылар да таралыштылар.

Академик Грязнов әллә игътибар итмәде, әллә танымады, Госманның эндәшүенә башта җавап бирмәде.

— Бер генә минутка мөмкинме сезне? — диде Госман, аны куып җитеп.

— Ә, исәнмесез, иптәш Закиров! Утырышка сезне дә чакырганнар идеме?

— Юк, үзем килдем. Мин Мәскәүдә курсларда идем. Хәзер укулар бетте, иртәгә — Казанга...

— Бик яхшы. Сезнең зона системасы да әзер булырга тиеш инде хәзер. Аны ике-өч айдан да соңармыйча тыңлаячакбыз. Бу турыда сезгә хәбәр иткәннәрдер инде. Сынатырлык булмасын, яхшылап әзерләнегез...

— Датасын әле төгәл генә әйтмәгәннәр иде. Менә курсларда иң кирәкле вакытлар үтте.

— Әле вакыт бар. Кат-кат карап чыгыгыз, бөтен система ресурсларга нигезләнгән булсын. Алай булмаганда, система эшләмәячәк, ягъни аның кәгазьдә генә калуы ихтимал.

— Моны без истә тоттык, иптәш Грязнов. Шулай да әле конкретлаштырасы урыннары бар.

— Тагын бер нәрсәне исегезгә төшерәм. Сезнең бит инде яңа директор. Харис Сәлимович белән килешеп, бер-берегезгә ярдәм итешеп эшләгез. Аңа хәзер сезнең ярдәмегезнең бик кирәк чагы,— диде академик, Госманга кулын сузып.— Ярый, хушыгыз!

Госман академикның соңгы сүзләренә җавап бирмичә генә саубуллашты:

— Хушыгыз!

Госманның әле беркайчан да бүгенге кебек аптырашта калганы юк иде. Нәрсә соң бу? Грязновны — танылган галим, академик, дибез. Алай зур ачышларын белмәсәк тә, безнең өчен олы авторитет. Ә ул әнә моңарчы фәнгә якын да килмәгән, фән кешесе була да алмаячак Нәхитовны яклый, аның турында кайгырта. Әллә үзем артта калдым инде бу тормыштан, әллә?.. Аңлашылмый. Күпләргә үткәннәр дә, киләчәк тә кирәк түгел. Тик көн үтсен, дип, бүгенге көн белән яшиләр, үзләрен генә кайгырталар, күбрәк каерып калырга тырышалар. Әйе, уртак байлыкны, халык байлыгын. Күрсәткән эше булмаса да, нәфесе зур хәзер кайберәүләрнең. Турыдан-туры кул суза алмаса, читләтеп урлый, әйләнгеч юллар таба. Берсе дуслар ярдәмендә күбрәк түләнә торган урынга үрмәли, ә Нәхитов кебекләр, кандидатлык диссертациясен әвәләп, хезмәт хакын бер ярым тапкыр арттыру җаен карый. Ә андый галимнәрдән фәнгә дә, илебезгә дә бер тиенлек файда юк. Ә Грязнов ишеләр шундыйларга булышалар. Әйе, халык байлыгын «законлы» рәвештә каерырга ярдәм итәләр. Мондый хәлгә кем чик куяр, кайчан чик куелыр? Әлегә бу сорауга җавап юк... Дилбегәне кирәгеннән артык бушаттык, ахры. Мин дә читтә калсам, ул да кул селтәсә, нәрсә килеп чыгар?

Соңгы төндә Госманның күзенә бик озак йокы кермәде.

* * *

Госман Казанга кайтып төшкәндә, Халидә тулай торакка күчәргә йөри иде.

— Абый, кайтасыңны алдан хәбәр итмәдең. Өлфәт белән барып алган булыр идек үзеңне. Бүген минем ял көне бит,— диде Халидә.

— Нинди Өлфәт белән ул?
— Менә ич, таныш булыгыз.
— Исәнмесез, Госман Айдарович,— диде егет, башын кагып.— Өлфәт дигәне мин булам инде.
— Исәнмесез, Өлфәт! Сезнең дә ял көнеме бүген?
— Безнең дәресләр тәмамланды инде. Бүген икегә кадәр генә. Мин бит мәктәптә укытам.
— Мактаулы эш. Яратасызмы соң үз һөнәрегезне?
— Турысын әйтим, Госман Айдарович, башта бер дә ошамый иде. Чөнки мин биолог булырга хыялландым. Ә менә укытучы булып эшли башлагач, моңарчы уема да килмәгән ачыш ясадым — балаларны бик тә яратам икән. Хәзер инде алардан башка яши дә алмам кебек.
— Дөрес фикерлисең, Өлфәт энем... Ә кая җыендыгыз соң әле сез болай?
— Менә Халидәгә булышырга килдем, тулай торакка күченергә.
— Нәрсә син, сеңлем, безне ташлап китәргә булдыңмыни? — диде Госман, ачуланып ук.— Әллә бездә урын җитмиме? Алай-болай Гөлфия апаң берәр нәрсә әйтмәгәндер бит?
— Госман абый, булмаганны сөйләмә инде...— Аннары, Өлфәткә борылып: — Әйттем бит ачуланыр дип,— диде Халидә, турсаеп.
— Госман Айдарович,— диде Өлфәт, аңа якынрак килеп,— исегезгә төшерегез, үзегезнең дә яшь чакларыгыз булгандыр...
— Дөрес әйтәсең, Өлфәт энем,— диде Госман, киң елмаеп.— Безнең дә булды ул яшь чаклар. Кадерен белдек, матур яшәдек. Әмма яшьлек еллары онытылмаслык булып калсын өчен тулай торакка китү кирәкме икән?
— Бернинди дә гаеп юк монда, Госман абый,— диде Халидә,— бары тик сезне борчыйсым гына килмәгән иде. Чөнки соңарып кайткан чаклар да, походларга китеп, кайтмый калган көннәр дә була...
— Ярый, килештек, ышандырдыгыз. Тик минем сүзләргә колак сал.
— Аңладым, абый. Сеңлең өчен борчылма. Барысы да син дигәнчә булыр.
Госман яшьләрне урамга озата чыкты. Өлфәт зур чемоданны үзенә алды. Алар бакча буйлап акрын гына троллейбус тукталышына юнәлделәр. Тукталыш турысына җиткәч, юлны аркылы чыгарга уйлаганнар гына иде, кара «Волга» килеп чыкты. Яшьләр артка чигенделәр. Руль артында — Мәхмүт, ә янәшәсендә Өлфәтнең әтисе иде...

Өлфәт Халидәгә тулай торакка урнашырга булышты да, бер җирдә дә тукталмыйча, өенә юнәлде. Ул кайтканда, әтисе инде өйдә иде. Нөхитов улын караңгы чырай белән каршы алды.
— Кайчаннан бирле носильщик булып ялландың? Укытучы, тәрбияче кешегә бер дә килешми. Так что, алдан ук кисәтеп куям: усал кыз ул, аның белән бүтән чуаласы булма...
— Әти, әйдә, вакланмыйк, ә? Синең бит болай да эшең күп, үз мәшәкатьләрең шактый.
— Тормышта вак нәрсәләр юк, улым. Син инде бала түгел. Өлкәннәр сүзенә колак салырга вакыт, югыйсә, соң булуы бар.
— Әйе, мин сабый түгел. Шуңа күрә бу мәсьәләне ничек хәл итүне үз ихтыярыма калдыр!
— Шул кыз белән чуалуыңны инде миңа җиткергәннәр иде, хак икән. Безнең ике арадагы мөнәсәбәтләрне катлауландырма, Өлфәт, гадәтемне яхшы беләсең.
Өлфәт әтисенә бүтән бер генә сүз дә дәшмәде. Үз бүлмәсенә кереп китте.
Нөхитов бу хәлне авыр кичерде. Нәрсә эшләргә бу малай белән? Әллә башка берәр шәһәргә аспирантурага җибәреп карыйсымы? Әйе, шулай итәргә кирәк. Аерым яшәү һәм вакыт үз эшен эшләячәк...

Бу хакта ул сүзне бераз тынычлана төшкәч кузгатты:

— Өлфәт, бер генә минутка минем янга кереп чык әле.

— Нәрсә булды, әти?

— Әле бүген генә теге таныш академик Грязнов белән сөйләштем. Сине аспирантурага чакыра. Үзе үк синең җитәкчең булачак. Бик яхшы килеп чыга бит әле бу. Өч ел да үтмәс, фәннәр кандидаты буларсың. Аннары, кирәк икән, Казанга кайтырсың, кирәк икән, Мәскәүдә калырсың...

— Юкка борчыласың син, әти. Мин үз урынымны таптым тормышта. Хәзер балалардан башка яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм.

— Нәрсә, гомер буе мәктәптә калырга уйлыйсыңмыни? Шундый мөмкинлек барында?..

— Ярдәмгә мохтаҗ түгел мин, әти. Нәрсә эшләсәм дә, үз көчем белән эшләргә телим. Ә бүген исә мин аспирантурага керергә әзер түгел әле.

— Әзер булмасаң, әзерлән. Үз көчең белән кер, ул вакытта...

— Юкка борчылма, әти. Безгә синең кандидат булу да бик җиткән. Бәлки, анысы да кирәк булмагандыр әле...

— Йә, тагын нәрсә?— Нөхитов урыныннан торды.— Йомырка тавыкны өйрәткәнне кайда күргәнең бар? Каян алдың син бу киреләкне? Нигә миңа гел кырын торасың син? Нәрсәм ошамый? Нигә синең белән уртак тел таба алмыйбыз без, яле, әйт әле?

— Икебез ике төрле уйлыйбыз, әти. Тормышка икебез ике биеклектән карыйбыз. Әти буларак син миңа якын, ә менә яшәү рәвешең...

— Яшәү рәвешең...— Нөхитов үзенең тормыш юлын күз алдыннан кичерде. «Ул бит әле минем тормышның бик аз өлешен генә белә. Әгәр дә барысын да белсә... Наил турында да, яшерен алтын турында да, бирегә ничек эшкә урнашуым турында да...»

Уйласаң, уелып китмәле. Һәм ул уйга чумды... Дуамал яшьлеге белән очраклы рәвештә килеп эләккән Шахмай өерен ул чын-чынлап күралмый иде. Байлык кулга төшү белән, шактый өлешен ышанычлы урынга яшерде дә, бу яклардан бөтенләйгә таю ягын хуп күрде. Шуннан соң Мәскәүдә аны әтисенең якын танышы Шәрәпов үз канаты астына алды:

— Укы, Фалис, укы,— диде ул,— укыган кеше югалмас!

Менә шул көннәрдән соң ул Шәрәповның сүзеннән чыкмады. Кыска сроклы курсларда укыды, аннан рабфакта... Шәрәпов ярдәме белән, билгеле. Казанга кайтып, милициянең район бүлегенә эшкә урнашты. Җайлап кына эшләп ятасы иде дә бит, ялгышып куйды. Партия кушуы буенча, диген булып, халык дошманнарына каршы көрәшү өчен, «Черек күл»гә күчте. Гаилә корып җибәрде, малайлары туды, әмма гаилә таркалды... Моңа Черек күл буендагы конфликт та сәбәпче булды. Хәер, шуннан соң аның бөтен планнары җимерелде. Ашыгыч рәвештә китәргә мәҗбүр булды. Үткәннәрнең кабат калкып чыгуын һич тә теләми иде ул.

Их, гомер диген!.. Казаннан киткәч, ул шактый гына вакыт тагын Мәскәүдә, Шәрәпов фатирында яшәде. Зур мәшәкатьләр белән исемен үзгәртте. Ни әйтсәң дә, беркем дә, бернине дә бушка гына эшләми шул. Аннары сугыш... Ярый әле, Шәрәпов тиз әйләнеп кайтты. Менә шунда ул күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга китәргә булды. Шәрәпов аңа Себер якларында жылы, тыныч урын тапты. Себердә ул кабат өйләнеп җибәрде. Өлфәте туды. Һәммәсе дә тәртиптә иде сыман. Нигә дип шушы Казанга кайтасы итте әле ул?! Һаман да шул нәфес гаепле...

Нөхитов йөрәген тотты. Өлфәткә шикләнеп күз ташлады.

— Бар, чык, үземне генә калдыр,— диде ул, өстәл читенә тотынып.

* * *

Хәзер артка чигенер урын юк. Артта — упкын. Ә алда — билгесезлек. Әллә нинди кешеләр бу коллективта. Бигрәк тә Закиров мәкерле. Җиде бабаңа кадәр җитәр. Юк, эшләп булмас аның белән. Ахыргача көрәшергә кирәк...

Закиров кергәндә директорның кәефе юк иде, ул аны салкын каршылады:

— Курслар беттедәмени инде, Госман Айдарович?

— Вакыт тиз үтә ул, Харис Сәлимович, ә шул арада институтта никадәр үзгәреш. Диссертацияне төгәлләвегез белән котлыйм. Мин уйлаганнан да тизрәк тоткансыз сез аны.

— Шулай да, авыр язылды. Ярый әле, булыштылар. Мәсхүдә Хәйрулловна карап чыкты, киңәшләре белән ярдәм итте. Сезне борчып тормадык инде...

— Хәзер дә соң түгел әле, Харис Сәлимович. Мәскәүдә дип ишеткән идем, кайчанрак якларга уйлыйсыз соң?

Нәхитов диссертацияне кайда һәм кайчан яклаячагын үзенә күрә сер итеп саклый иде, шуңа күрә Закировның соравына да:

— Әлегә төгәл генә билгеле түгел,— дип теләр-теләмәс кенә җавап бирде.

— Мөмкин булса, карап чыгыйм дигән идем диссертациягезне, бәлки, бирәр файдалы фикерем дә булыр...

— Борчылмагыз, Госман Айдарович. Хәзер инде сезнең фикерләрне исәпкә алырга, төзәтеп торырга вакыты да юк. Аннары, сезнең алда бик җаваплы эш тора. Системаны бик җентекләп карап чыгып, бер айдан да соңга калмыйча, ВАСХНИЛга тапшырырга кирәк.

— Беләм,— диде Госман,— бу хакта академик Грязнов миңа әйткән иде инде. Аннары ул минем сезгә булышуымны да сораган иде.

— Кирәкмәстер, Госман Айдарович. Ә болай эчкерсез булышырга йөрүегез өчен рәхмәт. Так что, диссертацияне академик Грязнов инде үзе карап чыкты, нигездә уңай фикердә тора.

— Академиктан соң докторга анда ни калган? дип уйлыйсыздыр, бәлки,— диде Закиров, ярым шаяртып...— Ә шулай да мин аны карап чыгарга тиеш, вазифам буенча...

— Карарсыз, Госман Айдарович. Тик басылган артык нөсхәләре калмады шул. Үземдә дә юк. Кулъязманы биреп булмый бит инде.

— Бирсәгез дә ярый,— диде Закиров.— Миңа сезнең почерк яхшы таныш. Озак тотмам мин аны.

Нәхитов кинәт кенә йөрәгенә тотынды:

— Әллә нәрсә булды... Диссертация дип йокысыз үткән төннәр нәтиҗәсе бу. Ә сез, кулъязма, дисез... Каян табыйм мин аны сезгә хәзер?!

Закиров 03 номерын җыйды, ләкин трубканы алдылар да нигәдер җавап бирмәделәр. Тагын җыярга туры килде.

— Кирәкми, Госман Айдарович, чакырмагыз, үтә бугай, хәзер миңа бераз җиңелрәк...

— Кәефегез начар вакытка туры килдем, борчуым өчен гафу итегез. Сөйләшүне бүтән вакытка калдырыйк, булмаса.

— Шулай әйбәтрәк булыр, Госман Айдарович. Аннары, өйдә дә бераз күңелсезлек булып алды...

— Чыкканчы шуны гына әйтим дигән идем: безнең бер төркем фәнни хезмәткәрләр СССР Халык Хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең медальләренә лаек булды, дип әйткәннәр иде. Аларны алып кайтып, ияләренә тапшырырга кирәктер инде...

— Тапшырдык, күптән тапшырдык, Госман Айдарович. Бәлки, үзегезгә тиешлесе кызысындырадыр сезне? Сезгә бирмәделәр, так что, бу хакта министрлыкның махсус хаты бар. Анда әйтелгәнчә, ачышларыгызны гамәлгә ашыру буенча тиешле кайгыртучанлык күрсәтмисез икән. Ә мин нәрсә эшли алам? Менә шундый хәлләрдән соң...

— «Яхшы» хәбәрегез өчен рәхмәт, Харис Сәлимович. Мондый эш сезнең катнашлыктан башка эшләнмәгәндер дип уйлыйм.

— Ничек телисез, шулай уйлагыз, анысы сезнең эш.

Шулвакыт бүлмәгә бүлек мөдире Шамкаев килеп керде.

— Комачауламадыммы, Харис Сәлимович? Иптәш Закиров өйдә булганда, сезгә эләгү кыен эш...

— Менә медаль даулый,— диде директор, Закировка ымлап.

— Һәр кешенең бармагы үзенә таба кәкре, шулай бит, Госман Айдарович?

— Монысы инде күбрәк сезгә кагыла, иптәш Шамкаев. Ә сез, Харис Сәлимович, үзара гына ачыклыйсы мәсьәләне күпертеп, мәгънәсезлек эшлисез...

— Мәгънәсезлек? Ә медаль даулау — нәрсә, мәгънәлекме?

— Мин дауламыйм, дөреслекне генә белергә теләгән идем. Сезгә бит күбрәк кирәк, алыгыз! — диде дә Госман ишеккә таба атлады.

Шулчак Шамкаев телгә килде:

— Сезнең берәр вакыт тормыштан канәгать чагыгыз булдымы икән? Элекке директор вакытында да шундый идегез, хәзер дә. Нәрсә җитми сезгә, Госман Айдарович?

— Күп нәрсә җитми безгә. Шул исәптән, селекция үзәгендә инде ун елдан артык утырып, производствога бер генә файдалы тәкъдим дә бирмәвегез борчый. Аннан соң менә шундый кешеләрнең әкренләп директорның җылы канаты астына сыенуы да ачу тудыра...

— Госман Айдарович, чынлап та, ни эшләп әле сез барын да үз өстегезгә алырга тырышасыз? Тыныч кына, жай гына эшләсәгез ни була? Иң зур хезмәт хакы сезнеке, авторитет бар, ачышларыгыз, хезмәтләрегез дә юк түгел. Нигә кирәк-кирәкмәгән җиргә борын тыгарга, нигә конфликтка керергә? Тыныч яшәүгә ни җитә?

— Нәрсә сез, гаделсезлек күрә торып, миңа кул кушырып утырырга киңәш итәсезме? Мин алай булдыра алмыйм...

— Ничек кенә булмасын, уртак тел табарга, аңлашырга мөмкин бит? — диде директор, сөйләшүне җылырак төстә төгәлләргә теләп.— Медаль мәсьәләсен ачыкларбыз. Ә улыгызга килгән вакытта, сез әйткән вариант кулайрак кебек күренә. Анысын үзегез карагыз.

Әңгәмәнең мондый юнәлеш алуын күргәч, Шамкаев авызына су капкандай тынып калды. Ул нәрсәгәдер борчылган кебек иде.

Закиров чыгып киткәч, Шамкаев ачыктан-ачык сөйләшүгә күчте:

— Нигә көйләп торырга аны? Башка институтка китәргә тели икән, китсен. Әллә бергә-бергә эшли алмабызмы? Селекция үзәге профессор Закировның кендегенә бәйләнмәгәндер бит...

— Шулай кирәк, бүген шулай кирәк, аңлыйсызмы?

...Үз бүлмәсенә чыгу белән, Закиров ишекне бикләп, киемнәрен алыштырды: халат, кирза итек киде һәм тәҗрибә кырына юнәлде. Анда аны Зариф ага ерактан ук танып, елмаеп каршы алды:

— Кайтуыгыз белән, Госман Айдарович!

— Рәхмәт. Сезнең хәлләр ничек монда? Теге борчакның алтмыш дүртенче номерлы гибриды ничегрәк күрсәтте?

— Куандыра алам: нәкъ сез уйлаганча — яңа гибрид стандарт сортка караганда уңышны җиде центнерга күбрәк бирде. Үсешен, чәчәк ату вакытын, кузаклануын фотога төшереп алдык.

— Әйбәт, бик әйбәт,— диде Госман.— Узган ел биш центнер күбрәк биргән иде. Өченче ел да уңышы югары булды...

— Уртача уңышны өч елда стандарт сортка караганда 29 процентка күбрәк бирде.

— Минемчә, быел аны дәүләт сорт сынау комиссиясенә тапшырырга мөмкин. Исемен ничек атыйбыз? «Татарстан» дисәк, ничек булыр икән?

— Элеккесе «Казан» иде. Бик яхшы, монысы «Татарстан» булсын. Авторларына килгәндә, Нәхитов үзен соавтор итеп кертүне сорый. Мин аңа, теманың җитәкчесе иптәш Закиров, дидем. Аннан башка хәл итә алмыйм, дидем. Ул кызып ук китте. Барыгыз да шуңа Аллага табынган

кебек табынасыз, ди. Аннары, Халидәне эшкә алганга бәйләнде. Ә мин, Халидәгә тел тидермәгез, иптәш Нәхитов, ул безнең өчен алыштыргысыз кадр, дидем.

— Авторлык мәсьәләсенә үзегез ничек карыйсыз соң? Мин бер сүз дә әйтми дип уйлагыз. Нәрсә эшләр идегез?

— Ничек инде ул, Госман Айдарович, әле безнең кишәрлекләрне килеп күрергә дә вакыт тапмаган кешене ничек соавтор итәсең ди? Булмаганны...

— Үзенә нәкъ менә шулай дип әйтергә кирәк иде.

— Ни әйтсәң дә, директор кеше бит. Каты бәрелеп, берәр җиреңне имгәтүең бар...

— Менә шулай шул без, Зариф Хәкимович. Турысын әйтергә тартынабыз. Ә алар тартынмыйлар, хәтта кулыңдагыны тартып алырга торалар. Яңа сортның җаваплы, төп авторы сез үзегез. Кемнең күпме көч куйганы, өлеш кертканә бары тик сезгә генә мәгълүм. Сезнең кырдан кайтмыйча, шалаш корып куна ятуыгызны бөтен кеше белә.

Бу яңа сортка кирәкле документларны әзерләп, бу атнадан да калмыйча Галимнәр Советы утырышында карарга һәм дәүләт сорт сынау комиссиясенә тапшырырга кирәк.

Шул арада Госман янына Халидә дә килеп җитте. Йөзе кояшта янган, керфекләренә тузан кунган.

— Соңгы кишәрлекне суктырдык, Зариф абый,— диде ул.— Анда борчакның Башкортстан фәнни-тикшеренү институты чыгарган гибриды чәчелгән иде. Уңышы Казан сортына караганда югарырак булса да, алтмыш дүртенче номерлы гибридтан биш центнерга калышты. Кишәрлекләрдә үстерелгән биш йөздән артык сорт һәм гибрид арасында безнең номер беренче урында. Котлыйм сезне, Зариф ага, Госман абый!

— Сиңа рәхмәт, Халидә. Сезнең кебек кызлар белән әле бер генә сорт чыгармабыз...

— Ярый, Зариф Хәкимович, килгән-килгән, Шәрәфнең кишәрлекләре белән дә танышып кайтыйм. Люцернаның Казан сорты ышанычлы, өметле күренә иде.

— Хушыгыз, Госман Айдарович. Бирешмәгез, нык торыгыз. Без дә бар әле бу дөньяда.

— Рәхмәт.

Госман абыйсы белән бергә Халидә дә янәшә атлады. Кырлар инде бушап калган. Бары тик карабодай, тары һәм күпьеллык үлән кишәрлекләрендә генә урып-җыю эшләре бара.

Селекционерлар йөри торган олы сукмакка чыккач, Халидә сүз башлады:

— Госман абый, сез кызыксынган теге диссертациянең кулъязмасы кайда икәне миңа мәгълүм. Дөресрәге, Өлфәт әйтте. Әтисе аны аспирантурага җибәрмәкче булган икән, ә Өлфәт теләмәгән, үз көчем белән юл ярырга телим, дигән... Шунда ул кемнеңдер кулы белән язылган диссертациянең оригиналын укуын әйтте. Ул хәзер Нәхитовның өендә, эш бүлмәсендә икән. Аннары, мин бирегә килгәч тә Гүзәл белән дуслашып киткән идем. Син Мәскәүдә укыган вакытта аның янында булырга туры килде. Ни эшлисең, дигәч, директорның диссертациясен басам, диде, аннары өстәп куйды: «Бирегә беркемне дә кертмәскә кушты»,— диде. Мин кызыксынып ук киттем һәм кулъязманы актарып карадым. Чынлап әйтәм, абый, аның берничә генә битенә Нәхитов кулы тигән...

— Шулай дисеңме? Мин әле алай уктыр дип уйламаган идем.

* * *

Госман белән булган соңгы очрашу Нәхитовны нык кына уйландырды. Укырга дип хәтта диссертациянең кулъязмасын сорый. Кирәк бит, ә? Нәрсә дияргә, нинди сәбәп табарга? Ташладым, дисәң,

ышанмас. Ә бу килеш биреп булмый. Эшләр болай катлаулангач, кульязманы күчермичә мөмкин түгел. Ул-бу килеп чыкса, авызын капларга да әйбәт булыр...

Ул көчне өйгә кайту белән, Нәхитов кульязманы күчерергә утырды. Беренче көнне, бик тырышып утырса да, ун биттән арттыра алмады. Икенче, өченче көннәрне дә эш өстәле артына утырды ул. Менә ничә көн инде әтисенең күзгә-башка чалынмыйча үз бүлмәсендә утыруына Өлфәт аптырады. Һәм көннәрдән бер көнне әтисе янына үзе керде:

— Әллә чынлап та галим булырга уйлыйсың инде, эти?

Нәхитовка улының «юк-бар»га игътибар итеп йөрүе ошамады:

— Комачаулама. Әйткәнне тыңламадың, бүтән мин синең белән сүз куертырга уйламыйм.

Өлфәт әтисенең өстәлендә яткан теге таныш кульязмага күз төшерде. «Ба, сүзгә-сүз күчерә. Нәрсәгә кирәк булды икән? Аңлашылмый».

Өлфәт әтисе бүлмәсеннән урамга ук чыгып китте. Ничектер, соңгы көннәрдә тулай торакка кагылып чыкмаса, күңеле тынмый, нәрсәдер җитмәгән кебек. Ул кергәндә, Халидә эштән әле яңа гына кайткан иде.

— Мөмкинме?

— Әйдә, рәхим ит, Өлфәт. Тик юынып кына өлгермәдем әле. Бүген эштән соң да озак кына калып эшләдек. Зариф аганы беләсеңдер инде: үзе дә кырдан кайтмый эшли, безне дә эшләтә белә, бүген менә соңгы кишәрлекне җыеп суктырдым.

— Алайса, арыгансыңдыр инде, Халидә. Әллә киногa барып кайтыйкмы дигән идем...

— Безнең яшьтә нинди ару ди ул, Өлфәт. Барабыз! Менә чәй генә куеп эчик тә...

— Кафега гына сугылсак?

—Алай да була.

Урамга чыгып, кафе янына җиткәннәр иде, аларны урта яшьләрдәге, бөдрә чәчле, карчыга борынлы, таза гына бер ир кеше куып җитте.

— Сез Өлфәт буласыз бит? Бер генә минутка мөмкинме? — диде аңа бөдрә чәч һәм читкәрәк алып китте.

Өлфәт ни уйларга да белмәде.

—Менә нәрсә, егет,— диде аңа теге ир.— Халидә янында бүтән эзең дә булмасын. Аның яраткан кешесе бар, аңладыңмы? Тагын бер очратсам, үзеңә үпкәлә!

Өлфәт башта каушап калды, аннары айнып киткәндәй булды һәм, тегенең изүеннән алып:

— Кем син һәм кем кушуы буенча килдең? — диде.

—Өлфәт,— диде Халидә,— кулыңны пычратма, җибәр!

Өлфәтнең үзенә дә уңайсыз булып китте. Янәшәдән генә кешеләр үтә, ә алар... Тиз генә кулын ычкындырды да Халидәгә таба атлады:

— Таныйсыңмы бу кешене?

— Каян таныйм ди? Син нәрсә, Өлфәт?!

— Халидә янында эзең дә булмасын, ди. Халидәнең кешесе бар, ди бит...

— Шушы әрәк әйтәме? Кит аннан... Әй, юләрем. Синнән башка кемем булсын ди...

— Чынлапмы, Халидә?

— Кайчаннан бирле миңа ышанмый башладың әле син?

Егет кызны култыклап алды. Алар елмаешып кафега кереп киттеләр.

* * *

Галимнәр Советы утырышы ул көнне, Нәхитов теләсә-теләмәсә дә, озак дәвам итте. Көн тәртибендә билгеләнгәнчә, анда өч мәсьәлә каралырга тиеш иде. Ләкин беренче мәсьәлә буенча бәхәс купканлыктан, шуңа гына тукталырга туры килде.

— Совет рәисе буларак,— диде Нөхитов,— мин фәнни эзләнүләрне комплекслы алып баруны максат итеп куям. Моны Мәскәү таләп итә. Шуңа күрә, телибезме, теләмибезме, аерым төркемнәрне бетерергә кирәк. Менә иптәш Умнов группасын гына алыйк. Шунда ук хөрмәтле Гөлфия Афзаловна, тагын ике фәнни хезмәткәр эшли. Алар солычага каршы көрәш чараларын эзлиләр. Ә күпме утырырга мөмкин бу тема өстендә?! Ике кеше инде кандидатлык диссертациясе яклады, ә авыл хуҗалыгы институтында шушы темага докторлык диссертациясе тәгәлләнгән. Тагын нәрсәсен өйрәнергә?! Мин бу төркемне ябарга дигән тәкъдим керттем.

— Ә җавабын кем бирер?— диде Зариф Хәкимович, урыныннан торып.— Республикабыз кырларында солыча елдан-ел киңрәк тарала бара. Аңа каршы әлегә комплекслы чара юк, ә сез иң мөһим эзләнүләрне туктатырга уйлыйсыз. Минемчә, бу хилаф эшкә юл куярга ярамый. Иптәш Умновның үзен тыңларга кирәк.

— Умновның фикере мәгълүм инде аның,— диде Каргина, урыннан тормыйча гына.— Кемнең үзе утырган ботакны үзе кисәсе килсен? Аны тыңлап, вакыт әрәм итүгә каршы мин.

Шулчак партия оешмасы секретаре Шамкаев сүз алды:

— Мәсхудә Хәйрулловна хак әйтә, мин аның белән тулысынча килешәм. Иптәш Умновны тыңлап торуны кирәк дип санамыйм, ә конкрет төп мәсьәләгә килгәндә, Нөхитовның фикере дөрес. Теманы ябарга, ә көчне мөһимрәк проблемалар өстендә эшләүгә тупларга кирәк.

— Минемчә,— диде Закиров,— Михаил Елизаровичның үзен тыңламыйча конкрет фикергә килә алмыйбыз. Сүзне аңа бирүегезне үтенәм.

Ниһаять, сүзне Умновка бирделәр. Дөресрәге, Совет утырыша яңабаштан башланды.

— Галимнәр Советын ниндидер мәче туена әйләндерүегез бер дә килешми, иптәш Нөхитов,— диде ул.— Монда, сезнең алда, балалар түгел, ә галимнәр, үз тармагын тирәнтен белә торган фәнни хезмәткәрләр утыра. Солычага каршы көрәш ысулларын эшләүгә багышланган теманы ябып беркем дә отмый, киресенчә, оттырабыз гына. Солычаның республикабызда гына да ничә миллион сумлык зыян китергәнен экономистлар тәгәл санап чыгарган инде. Ел саен кимендә утыз миллион, иптәш Нөхитов! Әлегә солычага каршы комплекслы чараның эшләнгәне юк. Дөрес, аерым алымнар бар. Әмма болар проблеманы тулысынча хәл итә алмый. Солычаны бетерәбез дип, соң чәчүне тәкъдим итәбез. Нәрсә соң бу? Дөрес, академик Терентий Мальцев соң чәчеп ота, диләр. Ләкин бездә Курган җирләре түгел, бездә башка шартлар. Соң чәчү бездә, абсолют күпчелек елларны солычага каршы көрәш чарасы булса да, уңышны киметә. Ә солыча барыбер бетми. Туфрак катламында ул йөз елга кадәр яши. Нәрсә, йөз ел буе соң чәчәрбезме?

— Мәсьәләгә конкретрак килегез!— диде Шамкаев, аны бүлеп.

— Конкрет эзләнүләргә килгәндә исә, солычага каршы көрәштә без комплекслы система эшләргә исәп тотабыз. Монда туфрак эшкәртү алымнарын җитди үзгәртергә туры киләчәк. Бу җиңел бурыч түгел. Шулай да тагын ике-өч елдан без аны производствога бирербез дип ышандыра алам.

— Ике-өч ел бик күп вакыт ул, иптәш Умнов,— диде Нөхитов.— Без моның белән килешә алмыйбыз.

— Мин үз сүземне әйттем,— диде Умнов.— Әгәр дә теманы ябасыз икән, мин бирედән китәргә мәҗбүр булачакмын.

Куркытырга тырышуы түгел иде бу Умновның. Чынлап та, аны инде Оренбург фәнни-тикшеренү институтына чакырып хат язганнар иде. Тик Михаил Елизаровичның Казаннан китәсе килми иде.

Шуннан соң селекционер Рязанов сүз алды:

— Мин Михаил Елизаровичны тулысынча яклыйм, аңа ышанам. Группа комплекслы системаны өч елдан түгел, биш елдан соң бирә алса да, бу фәннең производствога керткән гаять зур өлеше булачак.

— Галимнәр Советы членнарында тагын нинди фикерләр булыр? — диде председательлек итүче. — Әйдәгез, Букреев, рәхим итегез!

— Менә сез, Михаил Елизарович, Совет членнарын бередән китәм дип куркытасыз. Ә сез киткәннән селекция үзәгенең берәр җире кителер дисезме? Телисез икән, китегез. Ә теманы ябарга кирәк. Бер солыча өстендә күпме утырырга мөмкин? Моның бер чиге булырга тиештер бит?!

Зал гөж килде:

— Мәгънәсез...

— Акыл сатма!

— Кешене кимсетергә юл куймабыз...

Председательлек итүче, ручкасы белән графинга каккалап, залны тынычландырырга тырышты. Хәер, Букреевның бүтән әйтер сүзе дә юк иде инде.

— Болай бәхәскә киткәч, миңа да үз сүземне әйтми ярамас, — диде Госман Айдарович сүз алып. — Чынлап та, моңарчы солычага каршы көрәштә бер-берсеннән аерылган төрле алымнар өйрәнелде. Иптәш Умнов җитәкчелегендәге группа тәкъдим иткән чаралар кызыклы. Билгеле, һәр алымның үз уңай йогынтысы бар. Тик монда менә шул барлык чараларны бер бөтен итеп өйрәнергә һәм эзләнүләрне ахыргача җиткерергә кирәк. Уйлап карагыз, туфрак турындагы, басым ясап әйтәм, кешелекне туйдыручы туфрак турындагы фән бары тик узган гасыр ахырында гына туды. Ә бит шуңа кадәр генә Чарльз Дарвин үзенең бер хатында: «Безнең туфрак структурасы турындагы белемебез йөз акр җирнең бер кечкенә почмагында казынучы карт тавыкның белеменә бик тә охшаш булуы мине гаҗәпләндерде», — дип язган иде. Дөресен әйтергә кирәк, туфрак эшкәртү системасында ачыклыйсы проблемалар әле дә күп. Ни өчен туфрак искерә, ни өчен аның уңдырышы кими? Болар аны ничек эшкәртүгә бәйләнгән. Әйе, әйе, ничек эшкәртүебез белән. Бу юнәлештә хәл итәсе мәсьәләләр, димәк, ачыласы яңа ачышлар шактый. Ә без бу төркемне ябу турында сүз алып барабыз. Киресенчә, аны ныгытырга, Михаил Елизаровичка булышырга, ярдәм итәргә кирәк.

Аннары ул, председательлек итүчегә борылып:

— Фикерләр төрле булды, шуңа күрә тавышка куярга тәкъдим итәм, — диде.

— Беренче тәкъдимнән башлыйбыз, — диде председательлек итүче. — Кем дә кем иптәш Умнов җитәкчелегендәге группаны ябарга ди, шулар кулларын күтәрә.

Акрынлап куллар күтәрелә башлады. Нәхитов, кулын күтәргән килеш, сөзелеп, залда утыручыларның һәркайсын күзеннән кичерде.

— Дүртәү, бишәү, алтау... Ә сез, Ольга Давыдовна?

Шаламова, көтмәгәндә үзенең исемен ишетеп, сискәнеп китте.

— Билгеле, сүз дә юк, ябарга кирәк, Харис Сәлимович!

— Барысы сигез тавыш, — диде председательлек итүче. — Ә кемнәр каршы? Өчәү, бишәү... җидәү... сигез... ун... унике. Димәк, күпчелек тавыш белән, теманы ябарга дигән тәкъдим кире кагыла. Эшегезне ахырынача дәвам итегез, Михаил Елизарович!

Нәхитов канәгатьсезлек белән карап алды да, саубуллашмый гына, залдан чыгып китте.

Өенә кайткач, Госман Айдарович үзе дә уйга калды. Тик аны инде бүтән төрлерәк уйлар биләп алган иде. Чынлап та, ялгышмадымы икән соң ул? Менә өченче ел инде республика кырларында уңыш артмый, киресенчә, кимү сизелә. Ә бит ул тәкъдим иткән алым — сөрү катламын

тирәнәйтү тәҗрибәләрдә дә, хуҗалыкларда да берничә ел шактый өстәмә уңыш бирде. Ә менә 4—5 елдан соң үсеш бетте, уңыш та кими башлады. Сәбәп нәрсәдә?

Нәрсәдә ялгыштым соң мин? Табигатьнең закончалыкларын бозуга юл куябыз түгелме? Ә менә күпьеллык үләннәрдән соң туфрак яхшыра төшә. Ни өчен? Чөнки монда табигатьтә меңнәрчә еллар кабатланып килә торган процесс саклана — үлән чәчелгән мәйданнарны сөрмибез. Нәтиҗәдә туфракның структурасы яхшыра, ул гумуска байый төшә...

— Гөлфия, бер генә минутка кер әле минем янга! — диде Госман, кулына каләм алып.

— Нәрсә бар, әтисе?

— Безне кем дип атарга була, беләсеңме? Фәндә ялгыш юлга тайпылганбыз. Әйттем, өч-дүрт еллык тәҗрибәләр белән генә колхоз һәм совхозларга чыгу ярамас, дидем. Уңыш күзгә күренеп арткан иде шул, аннары басулар чүп үләннәреннән дә чистарды. Ә хәзер — тупик, быел да уңыш артмады...

— Үзең беләсең, ел корырак килде бит, Госман...

— Юк, Гөлфия, монда башка нәрсә. Ә былтыр ел начар килдемени? Ә шулай да уңыш 14 центнердан артмады. Хәзер үзем дә төшенәм. Теге вакытта Терентий Семенович хаклы булган. Ә без, вакытлы уңышка ышанып, ялгыштык, Гөлфия.

— Ничектер ышанасы килми. Конференцияләрдә, төрле семинарларда республикабыз белгечләре үзеңне яклап чыктылар, мактап телгә алдылар. Ил белән ялгышу була түгелме соң бу, ә?

— Әйе. Без бу хатаны соңармыйча төзәтергә тиешбез. Иң элек Гыйльми Советта күтәреп чыгарга, хатаны танырга кирәк.

— Ә Нөхитовлар, Шамкаевлар, Букреевлар нәрсә әйтер?.. Болай эшләмә, Госман. Акрынлап, җайлап кына кирәк.

Бу сүзләрдән соң Госман танымаслык булып үзгәрде:

— Нишләвең бу синең, Гөлфия? Мин сине танымыйм. Гомер буе дөресен әйтергә курыкмый торган кеше. Нәрсә булды?

— Белмим, Госман, үзем дә белмим. Бәлки, өстебездә болытлар куера барганга күрә шулай үзгәргәнмендер...

— Ни генә булса да, без турысын әйтергә тиешбез. Беләсеңме, кайда ялгышканбыз? Уңдырышлы туфрак ясалу теориясен исәпкә алмаганбыз. Ел саен сөрү катламын тирәнәйтә барып, туфракның әле моңарчы сөрелмәгән структуралы аскы өлешен эшкә җиккәнбез һәм ул уңышның артуына вакытлыча гына булышкан. Чөнки сөрү катламын чиксез тирәнәйтеп булмый...

— Алай ук түгел инде, Госман. Ашламасы булса, уңышы булыр иде әле. Бөртеклеләрнең һәр гектарына республикада нибары кырык килограмм чамасы ашлама кертелә. Бу бит җирдән уңыш белән алынган туклыклы матдәләрнең биштән бер өлешен дә капламый.

— Беләсеңме, Гөлфия, туфракны дөрес эшкәрткәндә, аның структурасын саклаганда, туклыклы матдәләр туфракның үзендә барлыкка килә. Болыннарга гына кара. Кеше аннан меңнәрчә еллар файдаланган, печәнен җыеп алган. Аңа карап, болыннарның уңышы кимемәгән. Меңнәрчә ел файдаланганнан соң да, болынлыклардан кырыгар центнер печән җыеп алабыз. Бу нәрсә дигән сүз? Туфракның структурасы сакланганда, ул тузмый, искерми.

— Ә бит болында үсә торган үләннәр белән берьеллык культураларны чагыштырып булмый. Бодай, арпа, солы — боларны бит җирне ярлыландыручы культуралар дип атыйбыз.

— Хатаның асылы менә шунда шул, Гөлфия. Туфракны ярлыландыруда бу культураларның бер гаебе дә юк. Киресенчә, гаеп үзебездә. Бу культураларны үстергәндә, без табигатьнең үзендә бара торган туфрак ясалу процессын җимерәбез, юкка чыгарабыз. Ел саен, ә кайчакта елына

берничә тапкыр сөрәбез, сөргәндә туфракны бутыйбыз, астын өскә, өстен аска әйләндерәбез. Көпшәк туфракта исә үсемлек тамырлары тизрәк таркала һәм минераллаша. Органик матдәләрнең запасы кими, туфракның структурасы, димәк, уңдырышы начарлана.

— Әтисе,— диде Гөлфия, нәрсәдер исенә төшкәндәй,— хәтерлисеңме тәҗрибәләр үткәрү өчен яңа участокка күчкән елны? Аның бер өлеше солыча белән нык кына чүпләнгән иде...

— Әйе, әйе, хәтерлим. Солыча орлыгын аскы катламга әйләндереп салмас өчен, без бу участокны берничә ел әйләндермичә генә сукаладык. Ә менә күпме уңыш алганны хәтерләмим...

— Ике елда да иң югары уңыш алынды аннан, Госман. Әмма соң чәчелгәнгә күрә, без аны типик дип санамадык һәм исәпкә дә алмадык. Ә нәтиҗәсен син дә җентекләп сорамадың, мин дә әйтмәдем.

— Шул кишәрлекнең күрсәткечләрен табарга кирәк безгә. Архивта саклангандыр дип уйлыйм. Иртәгә исә иптәш Умнов белән әйбәтләп сөйләшергә туры килер. Аның тәҗрибәләрендә төп урынны шушы проблема алып торырга тиеш. Аңа башка лабораторияләрнең дә булышуы кирәк.

* * *

Инде сентябрь керсә дә, көннәр җылы тора иде. Шуңамы, комлырак урыннарда чабыр чәчәк атып утыра, сукмак буйларына сары тузганаклар сибелгән, кайберләре инде, көмеш шарга әверелеп, кояш нурларында чагылып-чагылып ала. Янәшәдә генә гөлбадран белән меньяфрак, соңгы ромашка һәм зәңгәр цикорийлар — барысы да нәкъ җәй көнендәге кебек... «Көзнең дә үзенә бер яме бар шул... Талгын җил каяндыр бал исен алып килә. Соңгы бал, тик аңа инде әчергә насыйптыр, чөнки тирә-як тып-тын, бер генә бөҗәк тә очмый. Тургайлар инде күптән тынган, сыерчыклар да күренми, хәтта кычыткан чыпчыгы да киткән. Бал кортлары һәм төклетуралар, чуар күбәләкләр — барысы да почмакларга, үз ояларына кереп йокыга талганнар. Инде вакытлыча җылыга, көзге кояшка берсе дә ышанмый. Әбиләр чуагының соңгы балын җыяр җан иясе юк...»

Госман Буранчыда чакта мондый көннәрдә атлар көтәргә ярата иде. Чөнки бу вакытта алар бик тә тыныч, үзләрен берни борчымый. Чая кашка тай тәмлерәк үлән эзләп читкәрәк китсә, Актүшкә бер эндәшүе җитә иде Госманның, тегесе шундук кашканы калган атлар янына куып китерә иде... Җәй саен көтү көтеп, һәр атның, һәр тайның холкын белеп бетергән. Дөрес, ул элегрәк тә үз эшен начар башкармый иде. Тик яшьлеге беләнме, кызык табыпмы, кирәкмәгәндә дә яшь тайларны куып йөртә иде. Хәзер инде алай түгел. Көтүне бер тәбәккәрәк җыя да, яшел чирәмгә сузылып ята, үзенең күзләре хуҗасында...

Көннәр тыныч, аяз булганда, кояш иркәләп торганда ат көтеп йөрүе рәхәт, билгеле. Әмма җәй сиздерми генә һаман ераклаша бара. Кояш сүрәнәя. Үзәнлекләргә, тау итәкләренә көмеш келәмен җәеп әкрен генә көз якынлаша. Тагын бер, ике атна, аннары кар катыш салкын яңгыр коярга тотына. Аннан инде адаштырган ап-ак бураннарына да ерак калмый...

— Ә менә бу «бураннар»ны үткәреп, кояшлы язга чыксак, белер идем нишләргә икәнен,— дип, авыр көрсенеп куйды Госман.— Ялгыш адым ясавымны көтеп кенә торганнар диярсең! Үзем дә ашыктым теге вакытта. Йөз ел яшә, йөз ел өйрән, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул...

Тәҗрибә участогы янында Госманны Халидә куып җитте:

— Исәнме, Госман абый! Мальцев яныннан кайтканыңны ишеткәч, эш бүлмәңә сугылган идем, син юк... Кая китәр, мин әйтәм. Өйгә шылтыраттым, анда да юксың. Кәчкә эзләп таптым менә.

— Исәнме, сеңлем! Нинди яңалыклар бар соң үзеңдә?

— Хәлләр бер көе, Госман абый. Синең чыккан хезмәтләреңне, фәнни отчетларыңны тикшерергә биргәннәр. Үз-үзенә каршы килә дип гаепләмәкче булалар. Аннары туган-тумачалыкта... Мине дә «дело»га керткәннәр. Ярдәмем тимәсә дә, бәла булдым мин сиңа, абый. Башка урында да эшли ала идем бит, югыйсә!

— Борчылма, сеңлем. Болар барысы да миңа мәгълүм. Синең бер гаебең дә юк монда. Ә минем бар, аны мин үзем таныдым, үзем ачыкладым. Биләүле парны яклап ялгышканмын...

— Киресенчә, алар сине чиста парны яклаган өчен гаепләмәкчеләр.

— Монысы гаеп түгел, монысы чынбарлык. Аның дөреслегенә мин, Терентий Семенович белән сөйләшкәч, тагын бер кат инандым, сеңлем. Теге вакыттагы ялгышларым борчый мине. Бәлки, өлкә комитетына керергә, барысын да ачыкларга, аңлашырга кирәктер? Әмма авыл хуҗалыгы бүлегендә соңгы фикеремне дөрес аңларлармы? Башта ныклап уйларга, исбатларлык, башкаларны да ышандырырлык итеп әзерләнергә кирәк. Дәлилләр кирәк, Халидә.

— Уникe еллык тәҗрибә нәтиҗәләре дәлил түгелмени?

— Алар бит без үткәргән тәҗрибәләр генә, Халидә. Хәзер инде эштә сынап карау һәм шуның нәтиҗәләре кирәк.

— Кайдандыр ишеткән идем мин бу хакта. Әйе, Актанышта бер колхозның агрономы сөйләгән иде...

— Чиста пар турындамы?

— Әйе, әйе. Ул бер чәчү әйләнешендә чиста парны бетермәгән. Ялгышмасам, нәтиҗәсе әйбәт дигән кебек иде. Моны ачыкларга кирәк, Госман абый. Мине командировкага җибәрегез.

— Бераз соңрак, Халидә. Сәбәбе чыккач, барырсың.

Шулчак институт ягында кара «Волга» күренде. Тәҗрибә басуына килә иде ул.

— Нөхитов машинасы. Нәрсә исенә төшкән тагын?

— Әйе, шул. Җәй үтеп, тәҗрибә кырына килгәне юк иде... Ярый, Госман абый. Мин кыр лабораториясенә керим әле. Басу уртасында икәүдән-икәү басып тору әллә ничек.

Халидә лабораториягә кереп киткәч, Госман туфрак катламын әйләндермичә сөргән кишәрлеккә килде. Туфрак тирән итеп сукаланса да, сөрү катламы әйләндерелмәгәнлектән, анда камыл өлешчә утырып тора иде.

Кара «Волга» Госман янына ук килеп туктады. Аннан давылланып, җилләнеп Нөхитов килеп чыкты. Ул, ишекне йөзен чытып, каты итеп япты да, исәнләшеп тә тормыйча сүз башлады:

— Нинди хәл инде бу, иптәш Закиров? Ничә көн кунак булып йөрдегез. Мальцев янында булган, имеш. Кайткач, кереп күрешү юк, сөйләшү юк... Аңламыйм мин сезне...

— Кердем мин сезгә, Харис Сәлимович. Совминга киткән идегез. Сез бушаганчы тәҗрибә кырларын карап кайтырга булдым. Сүз уңаеннан әйтим, мин кунакта йөрмәдем, кирәкле, мөһим мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләп йөрдем.

— Ярар, сезне хәзер упкыннан Мальцев кына йолып кала алмас дип уйлыйм. Так что, җавабын үзегезгә бирергә туры килер. Совминда да шулай диделәр. Бүген бюро утырышы. Сезнең, коммунист буларак, отчетыгыз тыңланачак.

— Мондый вакытта, гадәттә, алдан искәртеп куя торганнар иде. Әзерләнмичә ярыймыни? Берничә көнгә кичектерүегезне үтенәм.

— Инде барысына да хәбәр ителгән. Минемчә, үз эшегез белән таныштыру өчен озаклап әзерләнүнең кирәге юктыр. Так что, сезнең карамакта ике сәгатьләп вакыт бар әле. Әйдәгез, утырыгыз машинага!

* * *

Машинада бертын сүзсез баргач, Нөхитов әле генә сөреп ташланган кишәрлеккә күрсәтте:

— Нәрсә инде бу? Нинди тәртипсезлек!.. Кая карый безнең фәнни хезмәткәрләр? Сезнең Халидә участогы дип әйттеләр моны. Нигә юл куямдыр мондый башбаштаклыкка, үзем дә аңламыйм. Сөрелгән җир кебек тә түгел, камыллары тырпаеп тора.

Госман аны бүлдермәкче булган иде дә, сүз көрәштерүнең файдасыз икәнен аңлагач, дәшмәде. Шулай да Нөхитовның соңгы сүзләреннән соң ул үзен тыеп кала алмады, көлеп үк җибәрде:

— Юкка баш катырасыз, иптәш Нөхитов. Бу кишәрлек бит нәкъ шулай эшкәртелергә тиеш иде. Методика буенча. Шуңа да тәҗрибә кыры дип атала ул...

— Юкка көләсез сез. Так что, иртәрәк көләсез дип әйтүем. Аңламыйм мин сезне, иптәш Закиров. Безгә тәҗрибә хакына тырышыргамы, әллә тәҗрибә безгә хезмәт итәргә тиешме? Аннары Халидәгезнең тәртибе дә ошап бетми миңа. Нәрсә әйтсәң дә, бер сүзгә биш сүз белән җавап кайтара. Хәтта Өлфәтне үз ягына авыштырып, миңа каршы куярга маташа...

— Бу сүзләрне нигә миңа сөйлисез сез, иптәш Нөхитов? Мин яшьләрнең шәхси эшенә катышмыйм, үз ихтыярлары. Ә менә эш ягына килгәндә, тел-теш тидерерлек түгел. Тырышып эшли, төгәл эшли, нәтиҗәле эшли. Гаепне үзегездән эзләсәгез, әйбәтрәк булмасмы икән? Бәлки, төшенерсез?.. Аннары улыгыз да аңлар сезнең күңелне.

— Сафсата сатмагыз, иптәш Закиров. Нәрсә эшләргә икәнен без үзебез беләбез. Халидәгез Өлфәт янында бүтән уралмасын! Так что, кисәтеп әйтәм...

— Тагын бер кабатлыйм: бу аларның үз эшләре. Әгәр күзгә авыру йоккан икән, табибка күренергә кирәк. Томаланган акылга ышану ярамас...

«Волга» институт ишеге төбенә үк килеп туктады. Нөхитов, бүтән бер сүз дә эндәшмичә, ишекне каты итеп япты да, үзе дә онытылып, институт фасадында үскән иң биек зәңгәр чыршы янына килеп басты. Күзләре исә аста җәйрәп яткан күлгә текәлгән, ә күңелендә давыл иде. «Табибка күренергә кирәк,— диме? Үзенә күренергә туры килмәгәе әле, Закиров. Әйе, эшне уйлаганча өзәргә кирәк. Тик диссертацияне генә һаман расламыйлар...»

* * *

Бюро утырышы нәкъ билгеләнгән вакытта башланды. Көн тәртибендә каралганча, иң элек коммунист Закировның үзен тыңладылар. Чыгышның ахырында ул хәл итәсе мәсьәләләргә, киләчәк планнарга тукталды.

— Без коллективны алда торган шул бурычларны үтәүгә тупларга тиешбез. Алар арасында иң мөһиме — яңа туфрак саклау системасын эшләү, яңа сортлар чыгаруны тизләтү... Коммунист буларак, мин бу эшләрне башкаруда үз алдымда зур җаваплылык тоям,— дип тәгәлләде үзенең чыгышын Госман Айдарович.

— Кемдә нинди фикерләр булыр? — диде партбюро секретаре Шамкаев.

— Миндә бар,— диде Нөхитов.— Сез менә, Госман Айдарович, чиста парны арттырырга кирәк, дисез. Сезнеңчә, аның мәйданы сөрү җирләренең кимендә ун процентын тәшкил итәргә тиеш. Үз-үзегезгә каршы киләсез түгелме соң?

— Бу хакта мин инде сезгә әйттем, үз хатамны таныйм. Өч-дүрт еллык тәҗрибәләргә таянып, башта шундый фикергә килгән идек, әмма унике еллык тәҗрибә безне башка нәтиҗә ясарга этәрде. Безнең шартларда чәчү әйләнешендә чиста парлардан башка мөмкин түгел.

— Ә бит әле кайчан гына биләүле парны гайрәтләнеп яклый идегез,— дип бүлдерде аны Шамкаев.— Кайсына ышанырга? Белгечләр нәрсә әйтер? Биләүле пар турында никадәр хезмәтләрегез, тәкъдимнәрегез... Барысын да макулатурагамы?

— Кирәгеннән артык күпертмәгез, иптәш Шамкаев. Биләүле пар файдасына нибары бер мәкалә, бер рекомендация әзерләдем. Әле боларын да, өлкә комитетыннан таләп иткән өчен генә, ашык-пошык кына эшләргә туры килде. Өч еллык тәҗрибәләр биләүле парның өстенлеген күрсәтмәсә, хәтта таләп иткән очракта да моңа бармый идем. Мин бөтен җаным-тәнем белән чиста пар ягында. Игенчелекне күтәрүдә бу төп чара.

— Чиста пар, дисез. Димәк, республикабызда өч йөз илле мең гектар җир ел саен уңыш бирми, тик ята диган сүз: менә шул җирдән алынмый калган уңышны нәрсә исәбенә капларга уйлыйсыз?

— Уңышның артуы исәбенә... Бүген дә түгел, иртәгә дә түгел, ә берничә елдан каплый алачакбыз, хәтта артыграк та җыячакбыз.

— Чепуха,— диде Нөхитов.— Чиста пар сез вәгъдә иткән эффектны бирә башлаганчы республика дәүләт алдындагы изге бурычын нәрсә исәбенә үтәр? Так что, иптәш Закиров, коры вәгъдәләр белән генә икмәкле булу мөмкин түгел.

— Мөмкин,— диде шулчак моңарчы тыныч кына торган Зариф ага.— Безгә күптән киләчәккә карап эш итәргә вакыт. Галим бүгенге көн белән генә яшәргә тиеш түгел. Госман Айдарович хаклы. Аның күпьеллык тәҗрибәләре нигезендә расланган соңгы тәкъдимнәрен беркем дә инкарь итә алмый. Харис Сәлимович, сез бакчама таш ата дип уйламагыз, күп вакыт бездә фәннән ерак кешеләр, фән дөньясына оялап, аңа төзәтеп бетерә алмаслык зыян китерәләр. Теге вакытта Госман Айдаровичның әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә. Ашыкмыйк әле чиста парларны бетереп, тәҗрибә җитәрлек түгел, диде. Ә ашыктырдылар, кулланма таләп иттеләр, биләүле парның өстенлеген дәлилләүче рекомендация әзерләргә боердылар. Фәндә, бигрәк тә авыл хуҗалыгы фәнендә, бер-ике ел эчендә генә ачыш ясап булмый. Хәтта бер яңа сорт чыгару өчен дә берничә ел вакыт кирәк. Әле кайчан гына мине дә ничек битәрли иделәр! Имеш, дәүләт акчасын җилгә очырам, имеш, файдалы бернәрсә дә килеп чыкмаячак... Урынны «сәләтлерәк» кешеләргә бушатуымны сорадылар, хәтта таләп иттеләр. Мин китмәдем, көрәштем, кимсетүләргә түздем, чөнки яңа сортның туачагына ышандым. Ә бүген ул сорт ничәмә-ничә өлкәдә районлашты...

— Шуңа күрә дә Ленин орденына тәкъдим иттек бит үзегезне,— диде Нөхитов, аны бүлеп.

— Сез түгел... Төп мәсьәләдән читкә киттек булса кирәк. Кыскасы, Госман Айдаровичның соңгы ачышын игенчелек системасын камилләштерүгә керткән зур өлеш дип бәялим. Гаепләргә түгел, ә яклап чыгарга дип тәкъдим кертәм.

Бик җитди кыяфәттә Мәсхудә Каргина күтәрелде:

— Сез мәсьәләгә принципиаль килмисез, Зариф Хәкимович. Партия члены кимчелекләргә күз йомарга тиеш түгел. Ни өчен Госман Айдарович, үзе инанмый торып, элек биләүле парны яклап чыкты? Бу — принципсызлык. Бүген бер төрле, иртәгә икенче төрле сөйләү — фәннәр докторы, бигрәк тә институтта фән өчен төп җаваплы кеше буларак, Госман Айдаровичка килешеп бетми. Кем белә, иртәгә ул, бәлки, бүгенге фикерен дә инкарь итәр...

Институтта әле быел гына эшли башлаган Букреев сүз алды.

— Белуемчә,— диде ул,— безнең селекция үзәгендә туган-тумачалык тамыр җибәрә. Хатыны бередә эшли, туганнан-туган сеңлесен эшкә алды, тагын улын кабул итәргә исәпли, дип ишеттем. Мондый хәлгә, минемчә, шулай ук чик куярга вакыт.

— Селекция үзәгеңә бер аягыгыз кереп, икенчесе кермәсә дә, мондый эшләрдә сезнең шома кеше булуыгыз инде безгә мәгълүм,— диде аны бүлеп, Зариф Хәкимович.— Ә менә селекция үзәге өчен иң кирәкле кешеләргә тел тидермәсәгез иде.

— Бүлдермәгез, иптәш Хәмитов! Нинди башбаштаклык бу?! Тора да кычкыра, тора да кычкыра,— диде Нөхитов, тузынып.— Ә сез дәвам итегез!

— Менә шул. Фәндә буталчык тудыруы, үз тирәсенә туган-тумачаны җыюы, күп кенә өметле яшьләргә юл бирмәве Госман Айдаровичның үз урынында түгеллеген сөйли. Моны хәл итәргә, әйе, бүген үк хәл итәргә кирәк...

— Мин дә шундый ук фикердә,— диде Шамкаев.— Менә Ольга Давыдовна гына нигәдер авызына су капкандай утыра...

— Миңа аз гына уйларга кирәк. Мәсьәләне болай җиңел генә хәл итәргә ярый микән? Сикереп чыгардан элек «һоп» дип кычкырганчы, сикерәсе урынны яхшылап карарга кирәк түгелме икән? Ялгышып куймабызмы?

Шулчак Нөхитов аңа шундый итеп карады, Ольга Давыдовна бөтенләй мескенләнеп калды һәм директорның әле кичә генә үз бүлмәсенә чакырып әйткән сүзләрен исенә төшерде: «Әгәр дә минем тәкъдимне хупламасагыз, сезнең урынга теләүчеләр бар, хөрмәтле Ольга Давыдовна...» Әйе, үзен кемнәндер бәйле хис иткән кешенең фикере дөрес булса да, аны юкка чыгару өчен «нәчәлник»нең бер күз карашы да җитә, күрәсең...

— Вакыт үтә, иптәш Шаламова, сезнең фикерне көтәбез.

— Әйберне прокатка алган очракта да вакыт бик тиз үткән кебек ул, Харис Сәлимович,— диде Зариф ага, сабырлыгын җуеп.— Әгәр дә үзенең төп фикере юк икән, нигә кешене бимазаларга?

Ольга Давыдовнаның маңгаена салкын тир бәреп чыкты, бер яктан вөҗданы, икенче яктан иртәгәсе көне турында уйлану өзгәли иде аны.

— Харис Сәлимович,— диде ул, ниһаять, үзен кулга алмакчы булып,— әгәр дә сез әйткәннәр хак икән, димәк, иптәш Закировның гаебе юк түгел...

— Тәкъдимегез нинди?

— Сез дигәнчә булыр, Харис Сәлимович, минем башка сүзем юк.

Моңарчы тыныч кына тыңлап утырган өлкән фәнни хезмәткәр Җәлилов кул күтәрде:

— Берничә сүз әйтергә мөмкинме?

— Рәхим итегез,— диде Шамкаев, елмаеп,— үзем дә сезне тыңларга дигән фикердә идем. Госман Айдарович, кемгә-кемгә, ә сезгә күбрәк таныш. Хәтерлим, теге вакытта үзегезне тәҗрибә кырыннан ничек куып кайтарган иде. Бер хаксызга бит, югыйсә...

— Хаксызга түгел... Ул хаклы иде. Мин аннан үзем гафу үтендем. Мине бүген борчыган мәсьәлә бүтән. Нигә бүгенге утырышта Дәүләт премиясе лауреаты Рязанова юк, технолог Сабитов кайда? Мин алардан башка бүгенге сөйләшүне тулы дип исәпләмим.

— Сабитов командировкада, ә Рязанова авырый, поликлиникага китте,— диде Шамкаев.

— Бюро буласын белә идеме соң алар?

— Алардан башка да безнең кворум бар, иптәш Җәлилов. Башка сүзегез булмаса, утырыгыз. Шулай итеп, иптәшләр, күпчелек бюро членнары иптәш Закировны үз вазифаларын үти алмауда гаепләделәр. Алар хаклы. Мин үзем дә шундый ук фикердә. Фәндә бүген бер төрле, иртәгә

икенче төрле сөйләп, коллективны партиябез куйган бурычларны башкарып чыгуга туплау мөмкин түгел. Коммунист Закировны партиядән чыгарырга, ә эш урынында калдыру мәсьәләсен хәл итүне дирекциягә тапшырырга. Беренче тәкъдим шундый. Кем дә кем шушы тәкъдим белән килешәм ди, кулларын күтәрә. Өчәү, ә сез, Мәсхудә Хәйрулловна, нигә тартынып утырасыз? Дүртәү. Ә сез, Ольга Давыдовна?

— Мин бер якка да кушылмаска булдым. Теләсәгез ни әйтегез, мин Госман Айдаровичны үз урынында түгел дип әйтә алмыйм, ул грамоталы, һәрчак ярдәмчел, киләчәккә карап эш итә торган галим. Ә кайбер ялгышлары өчен кисәтү белән чикләнергә кирәк. Минем фикерем шундый.

— Ольга Давыдовна, сезнең юмакайлыкка да карамастан, күпчелек тавыш белән беренче тәкъдим үтә. Һәм сезгә, Ольга Давыдовна, һәр ситуацияне тирәнтен аңлый белергә күптән вакыт...

— Дөрес әйтәсез,— диде Нөхитов, Шамкаевның фикерен хуплап.— Яшәргә өйрәнергә, кешеләрне таный белергә өйрәнергә кирәк. Сезнең дә, Зариф Хәкимович, өлкә комитетында башыгыздан сыйпамаслар, хәтта орденлы селекционер булсагыз да. Минемчә, Галимнәр Советының чираттагы утырышында иптәш Җәлиловның отчетын тыңларга. Югыйсә, кемнең кемлеген белмибез, вакыт җитми...

Ул төнне черем дә итмәде Госман. Нәрсә эшләргә? Кая мөрәҗәгать итәргә? Барысы да инде өстә килешенгән булса кирәк, кичә директорның үзен тотышыннан ук сизелде бу. Аңлашыла... Мине республикада бүген биләүле парга каршы чыгуым өчен беркем дә якламаячак. Бердәнбер юл — китәргә кирәк. Тукта! Хәтерем ялгышмаса, теге вакытны минем Аликны гомуми игенчелек лабораториясе мөдире итеп алу турында сүз чыккач, үзең директор урынбасары булып эшләгәндә ярамый, дигән иде. Бәлки, компромисска барыргадыр?..

Иртәгесен аны Нөхитов елмаеп каршы алды:

— Рәхим итегез, Госман Айдарович. Так что, нәрсәгә керүегезне төшенәм. Котлый аласыз.

— Аңламыйм, нинди куанычыгыз бар?

— Илле бишне тутырдым бит!

Госман Айдарович аңа: «Этләрнең илле бишкә кадәр яшәгәнен беренче ишетүем»,— дип әйтмәкче булган иде, тыелып калды һәм сүзне үз файдасына борырга уйлады:

— Котлыйм, бөркетләр күк озак яшәгез, Харис Сәлимович. Тик начар яктан искә алмагыз...

— Нәрсә, китәргә булдыгызмыни?

— Сез шулай телисез бит. Бу — беренчедән. Икенчедән, әгәр мин китсәм, Аликны лаборатория мөдире итеп алырга була, дигән идегез... Сез аны яхшы беләсез. Әгәр шуның белән килешсәгез, мин, сезгә артык мәшәкать тудырмыйча, китмәкче булдым.

— Гаризагызны калдырырсыз, хәл итәрбез. Шулай да, кая китәргә уйлыйсыз?

— Баш исән булса, иптәш Нөхитов, урын табылыр. Һич югында колхозда да тәҗрибәләр үткәрергә, фәнгә өлеш кертергә була бит. Әнә, Мальцев гомере буе туган авылында. Ә үзе бөтен дөньяга танылган кеше, Почетлы академик. Ярый, хушыгыз. Минем соңгы үтенечемне онытмассыз дип ышанам.

— Уңышлар сезгә. Бүтән абынырга язмасын.

— Моннан соң күзне ачыбрак атларга туры килер инде, нихәл итәсең...

* * *

Урынбасарының бер каршылыксыз гариза бирүе Нәхитовны куандырса да, икенче яктан шактый гына уйландырды да. Әллә электән үк күтәргә йөрде микән? Авыл хуҗалыгы институтына проректор итеп җибәрмиләрдер бит? Ул урын күптәннән буш тора. Алай дисәң, өлкә комитетында утырып, Хөсрәт Хәевич белми калыр идемени? Планнары аңлашылмый моның... Ә-ә-ә, конкурска материаллар әзерләп йөри, дигәннәр иде. Институтның үсемлекчелек кафедрасына бирергә йөрми микән? Немедленно шалтыратырга кирәк!

— Алло! Сәлам, Виктор Петрович! Нәхитов әле бу. Хәлләрегез ничек? Шулаймы? Ректор итеп җибәрәләр? Закировнымы? Шаяртмагыз инде. Шулай да, йөриме? Ә-ә, конкурска бирергә җыена? Нинди кафедрага? Үтенеп сорыйм синнән, дус буларак сорыйм: ул бәндәне якын җибәрмәгез. Инде сөйләштемени? Нәрсә дидең соң? Нинди хата җибәргәнсең, Виктор Петрович! Тәртибе, законы шундый, имеш. Анысы шулай, һәр галим конкурста катнашырга хокуклы. Ә бит законнарны әйләнеп тә узып була. Димәк, хәстәре күрелгән? Рәхмәт! Рәхмәт, Виктор Петрович! Хәзергә хуш!

Шулчак ишек төбендә күнлек почтаны күтәреп инде байтактан бирле басып торган Гүзәлне күргән, Нәхитов агарынып китте:

— Ничә тапкыр әйтергә кирәк сиңа, кызый, рөхсәтсез кермә, дип? Кайчан тәртипкә өйрәнәсең инде син? Так что, соңгысы булсын, аңладыңмы? Монда ишеткәннәрне берәрсенә әйтәсе булсаң, кара аны!..

— Нәрсә дисез?

— Колагың ишетсен, дим: монда ишеткәннәрне кешегә сөйлисе булма!

— Үзем дә шулай дим шул, колагым тизрәк ишетә башласа иде, дим. Грипптан соң тәмам томаланды...

— Әйттем бит мин сиңа чыныктыр үзеңне, чыныктыр, дип...

— Чыгып тор, дисезме, Харис Сәлимович? Хәзер.

Гүзәл чыгарга дип борылган иде, аны Нәхитов янә туктатты:

— Организмыңны чыныктырырга кирәк, дим мин сиңа, саңгырау! Кая, бир әле монда папканы!

Почта папкасын ачып караугач, өстә генә яткан гаризага күзе төште Нәхитовның. Алик Закировтан иде ул. Гомуми игенчелек лабораториясенә мөдир вазифаларын башкаручы итеп алуны үтенгән...

Каләмен кысып тоткан килеш, Нәхитов беразга тынып калды. Башында бөтенләй сәер уйлар кайнаша иде аның. Әгәр дә Алик дигәне бирегә килсә, тыныч кына эшләр микән соң? Бу хакта ныклап уйларга кирәк. Рязановаларны, Зариф Хәкимовичларны, Сабитов һәм Җәлиловларны үз тирәсенә туплаcа? Гөлфия һәм Халидәләр болай да үзенекеләр... Хәтта Шаламова да шулар ягына авышып бара.

Башына яңа бер фикер килеп, Нәхитов тиз генә звонок төймәсенә басты. Гүзәл тагын ишектә күренде.

— Кемне чакырырга, Харис Сәлимович?

— Шаламова тиз генә керен чыксын әле!

— Хәлимова дисезме?

— Шаламова, Шаламова! — диде Нәхитов, бүлмәне яңгыратып. Гүзәлнең чынлап та ныклап ишетми башлавына ышанды ул.

Шаламова кергәндә, Нәхитов инде Аликның гаризасына нидер яза башлаган иде. Ләкин ул, язып бетермичә, каләмен бер читкә куйды:

— Ольга Давыдовна, ничек уйлыйсыз, Алик Закировны сезнең бүлеккә эшкә алырга мөмкин булырмы?

— Ник булмасын, Харис Сәлимович! Институтны яхшыга тәмамлап, ничә ел производствода эшләде, фән өлкәсендә никадәр яңа тәкъдимнәр кертте. Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Минемчә, аны алып дөрес эшлисез, Харис Сәлимович. Мин риза.

— Аңлашылды. Так что, без аны, алсак та, сезнең урынга алабыз, иптәш Шаламова. Тик сезнең «өлкән гыйльми хезмәткәр итеп күчерүегезне сорыйм» дигән гаризагыз гына күренми әле...

— Әзер ул. Кичә үк язылган иде.

Шаламова, кулына түгәрәкләп тоткан кәгазь кисәген өстәлгә куйды да, ишеккә таба атлады. Шулчак директорның «йомшак» тавышы яңгырады:

— Ольга Давыдовна, гаризагызны кире алыгыз. Мин эчкерле түгел. Кичәге хатагыз өчен мин сезне бүген гафу итәм. Алыгыз, алай ярамый. Так что, сез әле мөдир булып эшли алырдай галим.

— Кимсетмәгез! Мин үз мөмкинлекләремне аңладым. Гаризам үз көчендә кала.

Шаламова чыгып киткәч, Нөхитов ачу белән өстәлгә сукты да бер читкә тәгәрәп киткән каләмне кулына алды: «Йөрмәсен, Закировлар нәселенең эзе дә булмасын монда!» — диде һәм гаризага: «Объектив сәбәпләр аркасында әлегә кабул итү мөмкинлеге юк», — дип язып, имзасын куйды.

Имзасын куйды куюын, әмма күңеле тыныч түгел иде директорның. Бер сәбәпсез вәгъдәсен бозганы өчен түгел, әниндидер үч, ниндидер көч җилкендерә иде аны. Ул кинәт кенә урыныннан сикереп торды да, әрле-бирле йөренергә тотынды, тик күңеле барыбер тынычланмады. Шундый минутларда ул Мәсхудә Хәйрулловна белән киңәшләшергә ярата иде.

* * *

Авыл хуҗалыгы институты урнашкан бу мәһабәт бина Казанда һәркемгә таныш. Җомга көнне шунда Гыйльми Совет утырышына җыелдылар. Инде вакантлы урынга сайлаулар тәмамланып килә. Тавыш биреп чыккан Совет әгъзалары һәркайсы Госман Закировның кулын кысты, чын күңелдән уңышлар теләде. Ә менә биш кеше каршы тавыш биргән булып чыкты. Дүрт кенә каршы... булса да, конкурстан үткән булыр иде Госман Айдарович. Юк, очраклы хәл түгел бу, кемнеңдер йөнтәс кулы уйнаган биредә. Виктор Петрович шушындый эшкә барыр микәнни? Нөхитов сүзенә карап?!

Ничек кенә булмасын, Татарстаннан китүдән бүтән чара калмый, дип нәтиҗә ясады Госман. Кая да булса башка берәр өлкәгә китәргә кирәк. Рәсәй иркен, эш табылыр, шәт... Госман Айдарович, тәмам кәефе кырылып, урамга чыкты. Уңга борылды, аннары институт янындагы бакчага кереп, бераз ял итеп алырга уйлады. Ләкин озак утырырга туры килмәде. Бакча ягыннан үтеп барганда, профессор Гобәй аның ялгыз гына утыруын күреп, янына килде:

— Госман Айдарович, нишләп ялгыз гына? Болай ярамый. Дөрес, күңелле хәл түгел түгелен. Тик, аңа карап, сез үз фикерегездән кире чигенергә тиеш түгелсез. Көрәшергә кирәк, Госман Айдарович! Көрәшергә!..

— Әйтүе генә ансат ул, Әхмәт Вәлиевич! Көрәшүе бик авыр. Бигрәк тә таяныр кешең, фикердәшең, дөресрәге, сине аңлаучы кеше булмаганда...

— Гафу итегез, Госман Айдарович, сезне аңлаучылар бар. Сез эшләгән селекция үзегездә дә, бездә дә. Мин үзем дә тулысы белән сезнең фикергә кушылам. Дөрес әйтәсез, биләүле пар тагын берничә елдан, һичшиксез, үзенең дөреслеген күрсәтер.

— Чынлап та шулай уйлыйсызмы, Әхмәт Вәлиевич? Рәхмәт сезгә! Терентий Семенович та шулай дигән иде.

— Димәк, фикердәшләрегез бар, Госман Айдарович. Монда һич тә борчылырга урын юк. Көрәшергә, фикереңне партиябезнең Үзәк Комите-

тына житкерергә кирәк. Әмма гариза биреп хата эшләгәнсез. Китәргә кирәк түгел иде, Госман Айдарович.

— Уйлар башкачарак иде шул, Әхмәт Вәлиевич. Ялгыштым, ахры.

Шулчак тукталышта Алик күренде. Ул бакчада утырган әтисенә игътибар итмичә генә институтка таба ашыга иде. Ашыга, конкурс нәтиҗәләрен беләсе киләдер, күрәсең. Алай дисәң, аны шалтыратып та белергә була иде бит.

— Алик! — диде Госман. — Мин биредә...

Таныш тавышны ишетүгә, Алик як-ягына каранып алды. Шуннан соң гына бакчада утырган әтисен күрде, сизелер-сизелмәс кенә башын какты. Күңеле төшенке иде егетнең.

—Исәнмесез, Әхмәт ага,— диде ул, профессорга баш иеп.—Сез һаман да яшь әле, бирешмисез...

— Рәхмәт, Алик улым, рәхмәт. Гомергә яшь булып каласы иде дә, тик барыбер акрынлап бирешәбез шул,— дип, урыныннан кузгалды профессор һәм, Госман Айдаровичка борылып: — Ярый, кордаш, бирешмә. Мин әйткәннәрне истә тотарга тырыш. Хушыгыз! — диде.

Профессор киткәч, беренче булып Алик сүз башлады:

— Конкурс нәтиҗәләрен беләм, әткәй. Барысы да шуның кулы. Анысы бер хәл, минем гаризаны да кире каккан...

— Күңелем сизгән иде аны... Димәк, мине алдаган! Нишләргә соң хәзер, ә?! Фәннән генә түгел, җирдән дә аерылдым түгелме? Бердәнбер юл — башка өлкәгә китәргә кирәк. Анда аңларлар, аңламый калмаслар...

— Ашыкма, әткәй. Минем эшләргә урыным бар, анысы өчен борчылма. Син үзең селекция үзәгендә калырга тиеш. Вакантлы урынга гариза бир, алар берни дә эшли алмаячак.

— Дөрес уйлыйсың. Фәнни хезмәткәр булып булса да, тәҗрибәләрне ахырына җиткерергә кирәк.

— Әткәй, Мотаһир абый килгән иде, күрдеңме?

— Күрдем улым, күрдем. Озаклап сөйләштек. Ул да шундый ук фикер әйтте. Димәк, тартышып карарга кирәк. Тик ул әле конкурс нәтиҗәләрен белми. Васильевога китте, шунда ял итә.

Алар акрын гына Ирек мәйданына таба атладылар. Урамда инде көз булса да, көне җылы, хәтта бөркү дә сыман иде.

— Иртәдән бирле яңгыр яумакчы була, һаман ява алмый,— диде Госман Айдарович.— Куна килә, ахрысы...

Театр бинасы янына җиткәч, аның сүзләрен раслагандай, агач яфракларына, куакларга, театр алдындагы көзге чәчәкләргә вак кына тамчылар сибәли башлады. Кызлар йөгерешеп трамвайга кереп тулдылар. Аталы-уллы Закировлар һаман да юл чатында кара-каршы басып торалар иде әле.

* * *

Нөхитов ул көнне соңлап кына Кремль ягына юл тотты. Бүген аның Мәсхудәне бигрәк тә күрәсе, сөйләшәсе килә иде. Улы Өлфәтнең алар арасындагы якынлыкны сизенүен Мәсхудә белми иде әле белүен. Ләкин ул Нөхитовны артык борчымады да, куркытмады да. Һаман очрашуын дәвам итте. «Яраткан кешең хакына барына да барырга була»,— дип уйлый иде ул. Юк, Нөхитов аны беркемгә дә калдырырга риза түгел иде инде. Дөресрәге, Мәсхудәгә үзенең шәхси әйбере итебрәк карарга күнегә башлаган иде. Торган саен ныграк ияләнде ул бу хатынга...

Менә Мәсхудә яши торган йорт. Әле ут яна. Нөхитов тәрәзәгә күз төшерде, ләкин анда беркем дә күренмәде. Аның тәрәзәдән балкып

күренүенә, киткәндә кулын болгап озатып калуына Нөхитов инде күптән күнегеп беткән иде. Ә бүген күренми. Кинәт кенә бүлмәсендә ут та сүнде. «Йокларга да ятты, ахры... Иртәрәк түгелме соң әле?» — дип уйлады Нөхитов.

Икенче катка күтәрелгәч, елмаеп звонок төймәсенә басты. Ләкин ишек ачарга килүче булмады. Әллә ваннада юынамы? Алай дисәң, су аккан тавыш ишетелми. Шомлы уйларга бирелеп, ул тагын төймәгә басты. Тынлык. Нөхитовның йөзендә елмаюы сүнеп, чырае сытылды.

— Бу мин, бер генә минутка ач әле,— диде ул, инде ишекне катырак кагып. Ләкин җавап бирүче булмады.

— Ач инде, Мәсхудә, син бит өйдә, әле генә утың яна иде!

Нөхитовның соңгы сүзләрен ишеткәч, Мәсхудә коелып төште. Ишекне ачарга дип талпынган иде, көчле куллар аны кире урынына утыртты.

— Ачасы булма! Көтәр-көтәр дә китәр. Хатыны бар аркылы төнлә нишләп йөри ул?!

— Шулай килеп чыгар дип уйлаган идем аны,— диде Мәсхудә.— Күңелем нәрсәдер сизенгән иде... Менә ул, озак көттермәде.

— Ә нигә шулкадәр таләп итә ул синең ишек ачуыңны?

— Чөнки ул кечкенә кенәз, шулай кирәк дип белә. Өендә дә, эштә дә һәммәсе аныңча булырга тиеш дип уйлый. Власть ярата...

— Минем монда килгәнне беләме ул?

— Моның әһәмияте юк, Мотаһир. Аңа кем булса да барыбер.

— Аны бүген килер дип көттеңме соң син?

— Юк. Сөйләшмәдек. Тик шикләнгән идем.— Мәсхудәнең тавышы калтыранып чыкты.— Бетте... Барысы да бетте.

— Һич аңламыйм. Нишләп шул тикле бәйле соң син аңа?

Звонок тагын шылтырады. Мәсхудә аңа инде игътибар итми иде. Ул бары тик сискәнеп кенә куйды.

— Тынычлан,— диде кунагы, аны кочагына кысып.— Алла хакы өчен, тынычлан. Иртәме-соңмы, бу хәл барыбер булыр иде.

Мәсхудә кунагының кулыннан ычкынырга теләп, тартылып куйды. Әмма тегесе аны үзенә тагын да ныграк кыса төште.

— Тынычлан. Болай килеп чыгуы, бәлки әле, яхшыгадыр да. Хәзер без барын да хәл итәргә тиешбез. Мин үзем инде хәл иттем.

— Ә миңа нәрсә эшләргә? Син, ялың беткәч, китәсе кеше...

— Синең тормыш болай дәвам итәргә тиеш түгелдер бит. Без бергә булырга тиеш, Мәсхудә, бергә!

Бераздан тынлык урнашты. Мәсхудә, урыныннан торып, тәрәзәгә килде. Урам инде бушап калган, ара-тирә такси һәм ашыгыч ярдәм машиналары гына күзгә чалынып китә. Йортларның әле бер катында, әле икенче катында бер-бер артлы утлар сүнә, ә каршыдагы йорт бөтенләй караңгылыкка чумган. Аның янәшәсендәге йортның бер тәрәзәсендә, киресенчә, балкып ут кабынды: бәлки, яшь ана елап уянган нәниен имезергә торгандыр... Аста Нөхитов күренде. Бу юлы артына әйләнеп карамады ул. Күрәсең, үпкәләгән, аны инде Мәсхудә тәрәзәсендә утның барлыгы да, юклыгы да кызыксындырмый иде... Кунак Мәсхудәнең кайнар күкрәген үзенә тагын да ныграк кыса төште. Бу минутта аны сәер бер хис биләп алды: шушы сөйкемле хатынны югалтмагаем берүк, дип уйлады ул. Бар дөнья йоклый, бары тик алар гына уяу, күзгә йокы керми, зөфаф кичәсемени...

— Борчылма, Мәсхудә, борчылма,— диде кунак, авыр тынлыкны бозып.— Барысы да әйбәт. Йә, ни булды инде тагын!

— Коточкыч арыдым мин бүген, Мотаһир, ә иртәгә нәрсә көткәнен уйласаң...

— Барын да башыңнан чыгарып ташлачы, Мәсхудә. Телисең икән, бергә китәбез Мәскәүгә. Тиккә генә килмәдем мин биргә. Телисең икән,

үзем монда кайтам. Күреп китәр өчен генә килгән дип уйласаң, ялгышасың.

— Рәхмәт сина, Мотаһир. Нигә мин сине элегрәк очратмадым икән?

— Әле дә соң түгел,— диде кунак, аны тынычландырып.

* * *

Иртәгесен Нөхитов Мәсхудәнең эшкә килгәнен дүрт күз белән көтеп алды. Ишекне нигә ачмаганын бик тә беләсе килә иде аның. Юкка гына түгел инде, билгеле, кем дә булса булган аның янында... Нөхитов Мәсхудәгә шылтыратты:

— Килдегезме, Мәсхудә Хәйрулловна? Бер генә минутка минем янга кереп чыгыгыз әле.

Директор янына кергәнче, Мәсхудә бераз уйланып торды. Нәрсә дип әйтергә? Өйдә юк идем, дисәм, барыбер ышанмас. Иң яхшысы — дөресен әйтеп бирү...

Ләкин Нөхитов кичәге хәлләр турында сорашып тормады. Ул сүз кузгатмагач, Мәсхудә Хәйрулловна да телгә алмады.

— Эшкә керешергә вакыт, Мәсхудә Хәйрулловна. Минем яхшылыктан файдаланып, эшне оныттыгыз. Система әле дә булса әзер түгел. Моның өчен син җаваплы. Закиров юк хәзер, үзең беләсең. Әгәр дә тагын бер айдан тәгәлләмәсәгез, ВАСХНИЛ алдында җавап тотарга туры килер. Бу кадәр ваемсыз булырга ярамый!

— Нигә болай агрессив башладыгыз әле сөйләшүне? Бөтенләй чит кеше кебек кыланасыз...

— Барысын да онып! Һәркемдә дә була ялгышу. Мин сине шушы кадәр дә урам хатыны дип уйламаган идем.

— Нәрсә дидегез?!

— Ни ишетсәң, шуны әйттем.

— Ах, оятсыз! Бүтән аяк басасы булмагыз минем йортка!

— Йә, йә, кызма. Ачуым килгәнгә генә әйтүем. Гафу ит! — диде Нөхитов, вакыйганың үзе өчен һәлакәтле юнәлеш алуын чамалап.

Ул, урыныннан кубып, Мәсхудәгә якынрак килде.

— Сине онытып буламы соң... Ә шулай да кичә нигә ачмадың?

Мәсхудә Хәйрулловна кабат һөҗүмгә күчте. Мондый чакта аклануның файда китермәсен аңлый иде ул.

— Күпмегә кадәр мөмкин хатынлы кешегә табынып яшәргә? Сез барыбер миңа өйләнмисез. Хәтта бик теләсәгез дә. Чөнки улыгыз Өлфәт моңа юл куймаячак. Шулай булгач, миңа нәрсә эшләргә кала? Үз тормышымны үзем кайгыртмасам, кем кайгыртыр, шулай түгелме?

Шулчак ишектә секретарь кыз Гүзәл күренде:

— Гафу итегез, Харис Сәлимович, сезнең янга Госман Айдарович килде. Керсенме?

— Аз гына көтсен. Мәсхудә Хәйрулловна чыккач керер.— Ул Каргинага борылды:

— Киләчәк тормышны кайгырттым, дисең инде, алайса? Тик яхшылап уйла, так шту, ялгышып куйма!

— Мине хәзер инде бернәрсә дә куркытмый, Харис Сәлимович. Хәтта эшемнән алсагыз да курыкмыйм. Сезне мин хәзер үтәли күрәм. Дөресрәге, куралмыйм мин сезне!

— Ярый, ярый, тынычлан, Мәсхудә Хәйрулловна, сине эшеңнән алырга җыенучы юк бит әле. Каян уйлап чыгардың?

Мәсхудә кинәт кенә сыгылып төште, күзләреннән ике эре яшь бөртеге тәгәрәде.

— Сез үзегез өчен генә яшәргә күнеккән. Башкаларның язмышында да, тормышында да эшегез юк,— дип пышылдады ул яшь аралаш.

Нөхитов, үзенә урын таба алмый, әрле-бирле йөренә башлады. Хәленнән килсә, Каргинаны хәзер үк бүлмәсеннән куып чыгарыр иде дә, ярамый. Ул ничек тә үзен кулга алырга тырышты:

— Мәсхудә Хәйрулловна, үтенеп сорыйм, Алла хакы өчен тынычлан. Сөйләшүне эштән соң дәвам итәрбез, ярыймы?! Тынычлана күр!..

Каргина кулъяулыгы белән күзләрен сөртте, чәчләрен тәртипкә китергәндәй итте дә ишеккә таба китте.

* * *

Ничә еллар бүлек мөдире, директор урынбасары булып эшләгән Госман Закировны хәтта гыйльми хезмәткәр итеп тә алырга теләмәде Нөхитов.

— Миңа ачуланмагыз,— диде ул ахырдан.— Бер казанга ике тәкә башы сыймый, диләр, иптәш Закиров. Сез һаман үзегезнекен сөйләячәксез, үз теориягезне көчләп тагарга омтылачаксыз «групповщина» дәвам итәчәк. Ә мондый атмосферада фәнни ачышлар ясап булмый. Аннары, сез үзегезгә үзегез каршы килгән кеше, сезгә хәзер институтта кем генә ышаныр икән? Барысын да җиде кат үлчәдем инде...

— Җиде кат үлчәгәнсез, ә менә кисәргә ярамаганын уйлыйсы итмәгәнсез! Тик ышанычлы кешеләр юк дип ялгышасыз... Бар алар,— диде Госман, басым ясап.— Хәзер үк инде шактый. Гади колхоз агрономыннан алып академик Мальцевка кадәр минем фикердәшләр. Иртәме, соңмы хакыйкать барыбер өскә чыкмый калмас...— Госман Айдарович башкача сүз куертып торуны кирәк тапмады, күрәсең, урыныннан кузгалды.

— Сез кая? —дип сорады Нөхитов, әңгәмәнең болай тиз төгәлләнүенә аптырап.— Кая ашыгасыз?

— Ашыкмыйм. Тик, күпме генә утырсаң да, бу очракта яманны яхшылык белән җиңеп булмаячак. Хушыгыз!

Өенә көч-хәл белән кайтып егылды Закиров ул көнне. Һаман да шул бер уй борчый иде аның күңелен: «Хәзер нәрсә эшләргә?» Әгәр дә Буранчыга кайтсаң, колхоз председателе белән сөйләшеп, тәҗрибә кыры ачып җибәрсәң? Беләм, каршы килмәячәкләр. Районда да хупламый калмаслар.

Әйе, була шулай эшләргә. Әмма бу җиңелү булачак, олы фәнгә хыянәт итү булачак. Авыл хуҗалыгы фәнен Нөхитов кебек «галимнәр» кулына тапшырып, зур хата ясау булачак... Моның өчен безне фән кичермәс. Изге туфрак, әйе, безне туендыручы туфрак кичермәс.

* * *

Озакламый Мәскәүдән, җавап хаты урынына, «тикшерүчеләр» үзләре килеп төште. Беренче көнне институтта булдылар, тиешле кешеләр белән сөйләштеләр, ә кичен «Татарстан» кунакханәсендә номерга җыелдылар.

Ишек бикле түгел иде. Жогина аларның кызып-кызып бәхәсләшкән чагына туры килде. Шуңа күрә Мария Яковлевна, бүлдерергә кыймыйча, бер тын ишек катында басып торды.

— Монда бөтен игътибарны шуңа юнәлтергә кирәк,— диде пеләш башлы, түгәрәк сакаллысы.— Безгә Закировның фәндә каршылыклы кеше булуын, үз-үзенә каршы килүен чыккан материаллары, хезмәтләре ярдәмендә дәлилләргә кирәк. Ә моның өчен материал бар. Икенчедән, директор урынбасары булып алгач, эш урыныннан файдаланып, туган-тумачасын үз кул астына җыюын күрсәтергә кирәк.

— Шунын аркасында янды да инде ул,— диде Нөхитов, тикшерүчене хуплап.— «Үзең китмичә, малаеңны алып булмый»,— дип шарт куйгач, китәргә үзе гариза бирде бит.

— Әкәмәт наивный кеше икән,— диде пеләш баш,— ә үзен хаклык өчен көрәшүче итеп күрсәтергә тырыша. Юк, хәзер үткәннәргә кире кайту юк, иптәш Закиров. Ялган жалобаларын барыбер безнең кулга әйләнеп килә. Ә без ничек телибез, шулай эшлибез.

Шулчак Нөхитов ишеккә таба борылган иде, Жогинаны күреп, аптырап китте:

— Нәрсә сез монда, рөхсәтсез-нисез кереп, күзәтеп йөрисез? Нәрсә кирәк?

— Бернәрсә дә кирәкми,— диде Мария Яковлевна, бер дә исе китмичә генә.— Бүген көндез Госман Айдаровичның өченче ел чыккан рекомендациясен табарга боерган идегез. Менә, алып килдем...

Бүлмә тынып калды. Пеләш баш як-ягына каранып алды:

— Нәрсә, ишек бикле түгел идемени?

— Бер дә курыкмагыз,— диде Жогина, аны бүлеп.— Мин бернәрсә дә ишетмәдем, әле кергән генә идем.

— Алай булса, ярый. Шулай да, ишек шакып керергә кирәк иде, номерда нәрсә булмас,— диде пеләш баш, һаман да канәгатьсезлек белдереп һәм Нөхитовка борылды.— Болай ваемсыз булсаң, юктан януын ихтимал.

Нөхитов дәшмәде, жәһәт кенә урыныннан торып, Жогинадан рекомендацияне алды да өстәлгә куйды. Аннары Мария Яковлевнаны озата чыкты:

— Алдыйсыз, Мария Яковлевна! Сез күп нәрсә ишеттегез. Кисәтеп әйтәм: авыз ачып сөйлисе булсагыз... Хәер, сез моңа бармассыз да. Чөнки мин сезне эшли башлаганнан бирле үз иттем. Җае чыккан саен премиядән дә калдырган юк. Әле санаторийга путевка дип йөри идегез. Сөйләштем, булачак. Кавказда бераз ял итеп, сәламәтлегегезне ныгытып кайтырсыз. Ярый, Мария Яковлевна, монда сөйләшкән монда калсын...

— Бигрәк инде сез, Харис Сәлимович, юк-бар сүз сөйләп йөрергә бала-чага дип белдегезме әллә мине? Киткән кешене, күпме генә сөйләсәң дә, кире кайтарып булмый инде аны.

— Кирәкми, май кабыгыз,— диде Нөхитов, аны бүлдереп.— Әнә Каргина да китәм дип йөри. Китсә, мөдир урынына сездән дә кулай кеше юк икәненә инандым. Ярый, Мария Яковлевна, килештек, алайса.

Ләкин Жогина китәргә жыенмый иде әле. Мөмкинлектән тулырак файдаланып калуда иде исәбе.

— Харис Сәлимович,— диде ул, бераз елмая төшеп,— үзегез беләсез, мин үз йортымда торам. Бик искергән инде, ремонтлап кына рәткә кертеп булмый. Үтенеп сорыйм: быелгы фондтан өлеш чыгара алмассызмы икән?

Нөхитов уйга калды. «Шомарган хатын! Кирәк бит, нәкъ авырткан жирдән эләктерде. Нәрсә дияргә соң инде моңа? Вәгъдә итсәң, таләп итә башлар, эшне зурга жибәрер. «Юк» дип тә булмый. Нәрсә әйтергә соң?»

Бер тын сүзсез торганнан соң, ул Жогинага якынрак килде дә:

— Киләсе ел фондыннан... Быелгы фонд инде бүленеп бетте, Мария Яковлевна,— диде әкрен генә.

— Турысын әйтеп сөйләшик, дисез икән, турысын сөйлегез, Харис Сәлимович. Бер бүлмәле квартир әле беркемгә дә бирелмәгән бит. Миңа артыгы кирәкми.

Башка вакыт булса, нәрсә әйтәсен белер иде Нөхитов. «Энәсеннән жебенә хәтле һәммәсен белеп тора бит, жен алгыры!»

Жогина, өмет итеп тә уңай жавап ала алмагач, тимерне кызуында сугып калырга уйлады:

— Каян белде икән дип бер дә аптырамагыз. Мәсхудә Хәйрулловна белән эшләгәндә, без белмәгән, без ишетмәгән нәрсә булмас, Харис Сәлимович. Сезнең ике арадагы мөнәсәбәтләр дә мәгълүм. Монысын тик мин генә беләм. Хәер, аның монда ни катнашы бар? Болар сезнең шәхси эшегез...

Нөхитов үзгәргәннән-үзгәрә барды. Бу хатынның «озын телен» ничек кыскартасын белер иде ул белүен. Әмма башка юл юк хәзергә...

— Әйе, дөрес әйтәсез, Мария Яковлевна, бер бүлмәле квартир әлегә бирелмәгән. Гомуми игенчелек бүлегенә өлкән фәнни хезмәткәрләрне читтән чакырырбыз дигән идек. Ул шуның өчен калдырылды. Әмма шул ук вакытта сезнең теләкне дә искә алмый калып булмый. Бирербез. Ә хәзергә хушыгыз, мине югалтканнардыр.

— Хушыгыз, Харис Сәлимович, барысы да сүз дигәнчә булыр, шикләнмәгез. Уңышлар телим сезгә!

Жогина төшеп киткәч, Нөхитов бер тын ялгызы гына басып торды: «Кешегә күп кирәкмени? Әнә, квартир, дигәч, авызы колагына җитте. Барысын да хәл итеп була хәзер дөньяда, тик белеп эш итәргә генә кирәк. Койрыкка басарлык булмасын. Шәкүрнең Аю урманындагы алтынын һаман да эзлиләр әнә. Ә ул инде күптәннән минем файдага эшли. Һәм беркем дә эзенә төшә алмас. Шаһитлар да берәм-берәм китеп бара дөньядан. Хәмидә дә китте. Тик берәү бар — Закировның авылдашы, мине күрсә, тануы ихтимал. Шуңа күрә Закировның миннән читтәрәк булуы хәерле...»

Нөхитов кергәндә бүлмәдә бәхәс дәвам итә иде.

— Минемчә, бу белешмә Закировның чын йөзен тулысынча ачып бирә,— диде пеләш баш.— Әмма ул язганнарның барысын да инкарь итү дә ярамас. Кайбер фактлар расланды дип башларга кирәк. Әйтик, Нөхитовның туган-тумачаны җыюга кирәгеннән артык каршы булуын, диссертация эшенә чумып, кадрлар белән эшләүгә игътибарны киметүен күрсәтергә кирәк. Тагын нәрсә?

— «Кайбер мәсьәләләрне кискенрәк хәл итә»,— дип тә өстәргә мөмкин,— диде Нөхитов.

Шулай да пеләш башны нәрсәдер борчый иде. Бер тын күзләрен каядыр еракка — үткән көннәргә төбәп карагандай утырганнан соң, ул яңадан телгә килде:

— Әгәр дә Закиров кабат Үзәк Комитетка язса, эшнең катлауланып китүе дә бар...

— Башкача кулына каләм алмаслык итеп эшкәртергә кирәк аны иртәгә,— диде Нөхитов.— Миңа җиткерделәр инде: тикшерүнең үз файдасына булмаганлыгын ишетеп, язганы өчен болай да үкенә, ди...

— Алай дисәң генә инде...— дип, тикшерүче башын кашып куйды.

«Гаепләнүче» Закиров икенче көнне чакырылган вакытка килеп җитте. Ул пеләш башлы тикшерүчене күрүгә үк танып алды:

— О, исәнмесез, кордәштәш, Михаил Яковлевич! Тормыш сукмаклары тагын очраштырды үзебезне. Ничек килеп җиттегез?

Тәмам аптырашта калган Шариков, гадәтенчә, пеләш башын кашып алды да кулын Госман Айдаровичка сузды:

— Исәнмесез, иптәш Закиров! Тик бу юлы безгә күңелсезрәк сукмакта очрашырга туры килде бит. Килүдә исәбем юк иде, академик Грязнов үзе үтенгәч, килмичә булдыра алмадым. Төпченергә, тикшеренергә бер дә яратмыйм.

— Дөнья булгач, төрлесе була инде, Михаил Яковлевич. Менә мин дә бүген үтелгән юлны күз алдымнан кичереп утырдым. Вакыйгаларга нинди бай ул! Шул ук вакытта, никадәр ачыкланмаган хәлләр... Гомер үтә, барысына да өлгереп булмый...

Шариков бу сүздән соң ничектер сагаеп калды. Госман Айдарович исә, әңгәмәдәшенең йөзеннән нур качуын күреп, сүзне икенчегә борды:

— Менә тагын күнелем белән инанган ачышны ахырынача эшләп житкерә алмыйча китәргә туры килде. Туфракның уңдырышы гумуска бәйле икәнен белсәк тә, монарчы аның формалашуына кире йогынты ясый торган тәкъдимнәр белән чыкканбыз, шул исәптән ВАСХНИЛ галимнәре дә. Ил күләмендә хаталанганбыз. Шул хатаны таныганым өчен бүген менә мин гаепле, Михаил Яковлевич.

— Гаебегез анда гына түгел, иптәш Закиров. Нигә гариза язарга иде, нигә улыгызны урнаштыру кирәк инде сезгә? Болай да, әнә, ярты коллектив сезнең кешеләр, ди Нөхитов.

— Юкны сөйләмәсен. Монда минем бары тик тормыш иптәшем дә сеңлемнең кызы гына эшли.

— Шулар житмиме әллә? Өстәвенә, үзегез эшләдегез, улыгызны алуны таләп иттегез. Гел алай булмый бит ул...

Моңарчы тыныч кына утырган Нөхитов та сүзгә кушылды:

— Анысына да түзгән булыр идек. Мин эшли башлаган көннән алып, «групповщина» белән шөгыльләнә башлады. Кайда гына булмасын, директорның сүзен үткәрмәскә омтылды. Комплекслы эзләнүләр турында мөһим сөйләшүләр башлангач, каршы төште. Галимнәр Советы утырышын базарга әйләндерде. Тәк шту, күпме прощать итәргә мөмкин?

— Әйе, ул вакытта принципсызлык күрсәттегез, иптәш Закиров. Комплекслы эзләнүләрне башлап жибәрүне өзлегез,— диде Шамкаев, урыныннан ук торып.— Ә бит эзләнүләрне комплекслы алып бару — бүгенге көн таләбе.

— Һаман да бер балык башы. Ә бит ул эзләнүләрне мөһим проблемаларга юнәлтергә кирәк иде. Мин шулай тәкъдим иттем дә. Туфракның уңдырышын күтәрү, чиста пар жирләренең өстенлеген дәлилләү, солыча һәм башка чүп үләннәренә каршы көрәштә яңа ысуллар табу, сортлар чыгару методологиясенә генетика күзлегеннән якын килү — болар мөһим проблемалар түгелме, иптәш Шамкаев? Бүген дә сез талантлы, аек фикере булган галимнәрне бирегә чакырмагансыз. Алар турысын әйтерләр иде. Беренче чиратта, принципсыз, умырткасыз кеше сез үзегез ул, иптәш Шамкаев! Ничек сезне партия күтәрә, ничек жир күтәрә?!

— Житте сезгә демагогия белән шөгыльләнергә! Житмәсә, үз гаебегезне танымыйча, кеше өстенә пычрак атып, жалоба язып ятасыз. Имеш, диссертацияне дә миңа кемдер язып биргән... Беләсегез килсә, төн йокыларымны йокламыйча үзем яздым мин аны,— диде Нөхитов, күкрәгеи кагып һәм диссертациянең караламасын өстәлгә ыргытты.— Әнә, тикшереп карагыз, минем почерк белән кем язгандыр дип уйлыйсыз? Яла ягуыгыз өчен судка бирәм мин сезне, иптәш Закиров. Эшегездән генә түгел, кирәксә, ирегегездән дә мәхрүм итәрләр...

— Монысын булдыра алмассыз, кулыгыз кыска,— диде Госман һәм урыннан торып басты.— Кәефем начар, чыгарга рөхсәт итегез.

Закиров чыгып киткәч, директор булмәсендә ниндидер бер сәер тынлык урнашты.

— Сөйләшә белмәсәң, тик кенә торырга кирәк иде инде,— диде Шариков, тынлыкны бүлеп.— Нигә кирәк иде монда диссертация мәсьәләсен күтәрү? Әгәр дә аның сез кире кага алмаслык дәлиле булса?

Нөхитов кинәт кенә урыныннан сикереп торды да телефон трубкасына үрелде. Нәрсәдер ачыкларга теләп, кабаланып квартирасының номерын жыйды. Тик жавап бирүче булмады. Аннары ул үзалдына сөйләнергә кереште:

— Күчереп бетергәч, диссертациянең төп караламасын яндырырга дип әзерләп куйган идем, тәки онытылган. Кайда гына калдырдым соң мин аны? Кичекмәстән табарга, әйе, юк итәргә кирәк!..

* * *

Шушы очрашудан соң профессор Закиров селекция үзәгендә күренмәде: туган авылы Буранчыга кайтып киткән дип хәбәр китерделәр Нөхитовка аның турында. Котсыз тынлык урнашты ул көннәрдә: Каргина да тынычланды, Шамкаев та тынды. Хәтта һәрвакыт шау-шу яратучы Жогина да кешеләргә яңа хәбәрләр сөйләп йөрми башлады. Ниндидер зур давыл алдыннан була торган шомлы тынлыкны хәтерләтә иде бу. Хәлбуки, аңа карап Нөхитовның күңеле тынычланмады: диссертациянең төп караламасын, күпме генә эзләсә дә, кемнән генә сораштырып караса да, таба алмады ул. Шулай да Закировның авылга кайтып китүен ишеткәч, үзен юатты: «Аның кулына эләккән булса, тыныч кына авылга китеп бармас иде, шәт»,— дип уйлады.

Госман Айдаровичның авылга кайтуының сәбәбе бөтенләй башка иде. Дөрес, ул колхоз идарәсендә дә булды, якынча гына булса да бергәләп эшләү мөмкинлеге турында да сөйләште. Танылган галимнең туган авылында эшләргә теләк белдерүенә кем каршы килсен ди? Тәҗрибә кырын сайлап бирүне, эшче көчләр белән булышуны колхоз үз өстенә алды. Әмма Закировны шул ук вакытта күптән онытыла язган башка бер мәсьәлә борчый иде. Аю урманы тынгы бирмәде аңа. Бигрәк тә Мәскәүдә — Шариков фатирында, Шәкүрнең «серле ачкычы»н китап арасында күргәннән соң тынычлыгы югалды аның. Бу якларга кайтырга, урманда булырга да җае чыкты.

Менә ул Аю урманы. Төшләргә кереп йөдәткән Якты Алан. Алан почмагында карт имән әле дә исән икән. Госман теге вакытта Хәмидә югалткан «ачкыч»ны кулына алды да, имән төбеннән кояшка таба йөз адым атлады. Ләкин игътибар итәрлек башка бер генә билге дә юк иде. Еллар үтү белән бөтен җир тигезләнгән, үлән баскан, вак куак төпләренә калын яфрак түшәлгән...

«Хыялый да инде мин...»— дип сукранды профессор, «операция»нең уңышсыз чыгуын тоеп. Ләкин үзе китәргә ашыкмады. Әгәр дә тирә-юньне казып карасаң? Алай дисәң, урманны казып бетереп буламыни?»

Шунда ирексездән тагын Шариков квартирасы, китаплар рәте күз алдына килеп басты. Ничек эләкте икән соң аңа бу ачкыч? Гаҗәп, бик гаҗәп...

Йөрәге түзмәде Закировның, «ачкыч»тагы билгеләр буенча тагын, эзләргә кереште. Якынча менә шушы тирәдә булырга тиеш... Казырга кереште. Ә күпме казырга мөмкин соң? Соңгысы булыр, дип, чокыр янындагы кабарып торган урынны кистереп алган иде, нәрсәдер ялтырап китте. Госман, көрәген бер читкә ыргытып, туфракны бармаклары белән актарырга кереште. Чү! Менә ул алтын тәңкә! Профессор, үз күзләренә үзе ышанмыйча, туфракны тагын да җентеклэбрәк актарырга тотынды. Кулына кабат көрәк алды. Ләкин күпме генә казыса да, башка берни дә таба алмады. Димәк, теге вакытта ук өлгергәннәр! Юкка гына җилкенмәгән икән күңел...

Госман урманнан кайтканда кояш инде тау битендәге өянкеләр артына кереп күмелгән иде. Кырын тау буеннан тузан болыты күтәреп, авыл көтүе кайта. Ә авылдан читтәрәк, кечерәк кенә урманны хәтерләтеп, зират моңаеп утыра. Госман, кайтышлый, шунда кагылды. Әнисенең, аннары абыйсының, Хәмидәнең каберләре янында тын гына басып торды. Хәмидәнең кабере өстендә кечкенә генә зәңгәрсу чыршы күтәрелеп килә иде.

Их, бу гомерләр... Әле кайчан гына сеңлесе белән яланаяк шушы яланнарда йөгерешеп уйный иде. Белгәннәрдән инде бөтен авылга берничә генә кеше калган. Кабат-кабат килгән ачлык күпме авылдашны алып киткән. Бер сынык икмәк күрергә тилмереп, күпме замандашлар дөнья куйган!..

Хәзер инде икмәк проблема түгел. Сабый чак хыяллары чынга ашты: бүген авыз тутырып туйганчы икмәк ашамаган, ачка изаланган кеше юктыр. Инде тынычлансаң да, сугыш инвалиды буларак ялга китсәң дә булыр иде. Тик никадәр эшләнмәгән эшләр кала...

Авылдан кайткач, профессор Закиров институтка барып килергә, селекционерлар белән, бигрәк тә Галина Федоровна Рязанова, Зариф Хәкимович Хәмитов белән киңәшергә уйлады. Үзләрен инде күптән күргәне юк, ниләр генә уйламаганнардыр минем турыда! Минем «хаксыз булуыма» алар да ышандымы әллә? Әйе, читләтеп үтмичә, турыдан юл арулары һәрвакыт авыр булган. Бер мин генә түгел аның корбаны...

Шул уйлар белән ул троллейбустан төште дә институт урнашкан тау башына таба атлады. Ләкин күрешергә, очрашырга насыйп булмаган икән: институт урынына ул шифаханәгә элəкте.

Күзләрен ачканда, ап-якты бүлмәдә, ап-ак урында ята иде...

* * *

Туктаусыз нерв киеренкелеге, көрәш, бәрелешләр үзенекен иткән, йөрәк тәмам тугарылган, инфарктка килеп җиткән иде. Үзе янына Каргинаның килүен дә, Нәхитовны кабул итмичә чыгаруны да авыр кичерде Закиров. Бер яктан ярсыта, икенче яктан уйландырды да бу аны. «Мине шушы хәлгә китереп җиткергән Нөхитов ни өчен бүген бирегә килгән? Билгеле, тикмәгә түгел. Аны кабул итмичә дөрес эшләдемме соң мин? Бәлки, сөйләшәсе, тел төбен «капшап» карыйсы килгәндер? Ә менә Каргина үзгәргән. Аның белән дә, бәлки, башкачарак аңлашасы калгандыр. Юк, җитәр, бүген әле тирән яраларга, чынлап та, бүтән кагылырга ярамастыр...»

Госман Айдарович кабат күкрәген тотты. Йөрәге, гүя: «Тик ят, юк-бар турында уйлама»,— дип, тагын бер кат үзенең барлыгын сиздереп алды.

Каргина калдырган хатка Госман икенче көнне генә күз төшерде. Директор белән Мәсхудәгә нәрсәләр булган, араларыннан ниндиләр кара мәче узган! Хак булса, Нөхитовның нинди генә этлекләрен белмәгән икән бу ханым! Кешенең изге хисләрендә уйнау дисеңме, премия һәм фатирлар биреп, кайбер тотнаксыз кешеләрне үз ягына аудару дисеңме, Рязанова, Хәмитов, Умнов кебек булдыклы, янадан-яңа ачышлар бирә торган галимнәрне эзәрлекләү дисеңме... Ә менә диссертация турында кутелмәгән хәбәр әйткән: «Башыннан алып ахырына кадәр Коршун язып бирде. Моның өчен ул аны вакытлыча эшкә алып, дәүләтнең мең ярым сум акчасын түләде, квартира вәгъдә итте. Ә менә Коршун үзе мәрхүм булгач, вәгъдә иткән квартираны гаиләсенә бирүдән баш тартты».

Салды, кыю дәлилләр. Дәлил дигәннән, тикшерә калсалар, диссертацияне Коршун язганны ничек исбатларга уйлый икән? Ике яклы пычак бу. Төпле дәлилең булмаса, ничек итеп дөньяда юк кешедән хәзер «яздым» дип әйттерәсең? Теге көнне Нөхитов диссертациянең үз кулы белән язган караламасын өстәлгә әнә ничек кыю һәм дорфа итеп китереп салды. Бу мәсьәләне тәмам ачыкламый торып, хатта язылганнар белән тулысынча килешүе дә кыен.

Иртәгесен Мәсхудә тагын килде Закиров янына. Дөресрәге, теге көнне калдырган хатны алып китәргә килгән иде ул.

— Хәлегез ничек, алга таба бераз үзгәреш бармы?— диде ул, Госман Айдарович каршына килеп.

— Рәхмәт, Мәсхудә Хәйрулловна. Бүген хәлем арурак кебек.

— Шулай була күрсен инде. Соңгы вакытта күпне кичерергә туры килде шул сезгә. Монда минем гаебем искиткеч зур, Госман Айдарович, кичерегез мине. Нөхитов сүзенә карап хаталандым. Гафу итегез, әгәр мөмкин булса... Мин бүген барын да яхшы аңлыйм: сез хаклы идегез.

— Тормышта ялгышмаган кеше юк. Әмма ялгышып та үз хатаңны танымау — бик начар. Бу яктан сезне гаепли алмыйм... Мин хатта язылганнар белән таныштым һәм күпчелек очракта сезгә ышанам. Ә менә диссертациягә килгәндә... катлаулырак мәсьәлә бу. Чынлап та, диссертацияне Коршун язганлыгын ничек исбатлый алырсыз икән? Бу бит бик четерекле эш.

— Анысы өчен борчылмагыз. Аның Коршун язган төп караламасы миндә. Ничек килеп эләккәне турында сөйләп тормыйм, бәлки, монда мин өлешчә гаепледер дә... Әмма ул миндә. Авыл хуҗалыгы фәненә бер бөртек өлеш кертмәгән, гомумән, бу өлкәдә профан кешенең фәннәр кандидаты булуы белән килешә алмадым, Госман Айдарович. Нык уйладым. Артка чигенү юк.

Профессор хәлсез генә елмаеп куйды:

— Мәсхудә Хәйрулловна, моңарчы кайда идегез соң сез? Нәкъ мин уйлаганча фикер йөртәсез бит, моңарчы кайда идегез?

— Тагын бер кат гафу үтенәм. Нык ялгышканмын, Госман Айдарович, нык...

— Хатагызны тануыгыз өчен рәхмәт. Сезгә уңышлар телим. Тик бу хатыгызны ВАСХНИЛга түгел, ә Министрлар Советы исеменә җибәрүегез хәерлерәк. ВАСХНИЛга җибәрсәгез, тагын шул ук Шариковлар килеп «хәл итеп» китәр. Нөхитов түгел, ә сез гаепле булып калырсыз.

— Киңәшегез өчен рәхмәт, Госман Айдарович. Сез әйткәнчә эшләрмен.

Каргина чыгып киткәч, шактый озак уйланды профессор. «Кыска гына вакыт эчендә нинди үзгәреш кичергән! Моңа нәрсә сәбәп булды икән соң?»

* * *

Күптән түгел Мотаһирга Мәскәүдә Бөтенсоюз семинарында катнашырга туры килде. Шунда очратты ул Каргинаны. Соңгы кичне Кызыл Мәйданга чыгып, озак кына сөйләшеп йөрделәр. Мәсхудәнең Казаннан килүен, Госман Айдарович белән бергә эшләвен белгәч, аңа тагын да кызыграк булып китте. Госманның авылдашы икәнен сиздермичә генә, институттагы хәлләр турында күп нәрсә белергә өлгерде ул. Шул чакта алар яңадан Казанда очрашырга сүз куештылар.

Менә ул Казанда. Аның бирегә килүе күп нәрсәне үзгәртте. Мәсхудә Хәйрулловна бер көйгә аккан тормыш агышында күпләр хәйран калырлык кискен борылыш кичерде.

Тагын бер көннән Мотаһир өчен көтелмәгән хәл булды. Төшкә кадәр Казанның тарихи урыннары белән танышып йөргәннән соң, ул институтка, Каргинага шылтыратты.

— Әле генә музейда булдым,— диде ул.— Бүгенгә җитәр дип уйлыйм. Селекция үзәгенә килеп кит, дисеңме? Әйе, әйе, танышу зыян итмәс иткән... Ярый, бер ярты сәгатьтән синең янда булырмын.

Мәсхудә аны беренче катта каршы алды. Бергәләп икенче катка күтәрелделәр. Шулчак аларга директор Нөхитов очрады. Ничектер сәерсенеп кенә карап алды да, тукталып та тормыйча, баш кагып узды. Каядыр ашыга иде, күрәсең.

Мотаһир исә, аны күргәч, өнсез калгандай булды. Аннары Мәсхудәгә борылды:

— Бу кеше сездә эшлимени?

— Безнең директор...

— Нөхитов буламыни инде бу?— диде дә Мотаһир, бер мәлгә тынып калды. Кайда күрде соң әле ул бу бәндәне? Юк, Мәскәүдә семинарда да түгел... Тукта, тукта, теге вакыт мунчада очрашкан кеше шушы бит инде ул.

Аннары Мотаһир, уенын дөреслеген расларга теләп, Мәсхудә Хәйрулловнадан сорап куйды:

— Кайсы тирәдә яши ул? Адресын белмисенме?

Көтелмәгән бу сораудан Каргина шикләнә үк калды:

— Нигә бик кызыксынасың әле аның белән? Кызыксынуга лаек дип уйламыйм мин аны, Мотаһир...

— Мин болай гына, Мәсхудә... Ничектер таныш кешене хәтерләтте.

Мотаһир тәмам үзгәрде. «Бу бит теге кеше... Мунчадан чыккач, артыннан күзәтеп кайткан идем. Аннары Черек күл буенда очраштык. Нәрсә соң бу? Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, диләр. Хак микәнни?..!»

Каргина, Мотаһир йөзендәге кискен үзгәрешләрне күреп, чынлап ук борчыла башлады:

— Мотаһир, ташла инде шуны. Белүемчә, сиңа бөтенләй таныш түгел ул. Казанга әле яңарак кына килде. Моңарчы кайдадыр Себер якларында эшләгән. Аннары ВАСХНИЛның Себер бүлегенә күчкән. Анда кем булгандыр, белмим. Шуннанниндидер сәбәп белән Казанга, безнең селекция үзәгенә директор итеп җибәргәннәр...

Шул арада коридорда Жогина күренде.

— Бу хатын безнең бүлектә эшли. Теле бик озын. Дөрес, башта Нөхитовны бер дә яратмый иде, хәзер инде табанын яларлай булып йөри. Нәрсә ишетсә дә, Нөхитовка житкермичә калмый. Аның объективына мин дә эләктем инде менә...

Шуны гына көткән диярсең, ерактан ук Жогинаның тәртмә тавышы яңгырады:

— Мәсхудә Хәйрулловна, сез миңа элегрәк: эш вакыты — эш өчен, ди торган идегез...

— Нәкъ менә эш турында сөйләшәбез дә инде без,— диде Каргина, аны бүлеп.— Менә безгә ерактан — Украинадан кунак килгән. Лабораторияләр белән танышырга исәбе бар.

— Теге вакантный урынга түгелдер бит?

— Юк, борчылмагыз,— диде Мотаһир, сүзгә кушылып.— Үз лабораториягездә үзегез эшләргә язсын!

— Без тар күңелле түгел. Теләгегез булса, рәхим итегез. Тик менә Мәсхудә Хәйрулловна гына безне ташларга җыена,— диде дә гыйльми секретарь бүлмәсенә кереп китте Жогина.

Мәсхудә, авызын ябарга да онытып, аптырап калды:

«Каян белгән бу? Югыйсә бит бу хакта, бик ачуым килгәч, Нөхитовка бераз «куркытыр» өчен генә әйткән идем. Димәк, болар бик якын сердәшкә әверелгәннәр»,— дип уйлады Каргина һәм, Мотаһирга борылып:

— Ярар, өйдә сөйләшербез калганын,— диде.

Мотаһир институттан туп-туры прокурор Минһаҗ Салихов янына китте. Моңарчы инде ул аның белән бер очрашкан иде. Озаклап, авыр яшьлек елларын искә төшереп, гәпләшеп утырдылар. Анадан ала да туа, кола да туа, ди шул. Акыллы күренә, үзе тыйнак... Салих байга тырнак очы кадәр дә охшамаган. Аңа да ышанмагач, кемгә ышанасың ди?

Мотаһирны Салихов бу юлы да бик җылы каршы алды:

— Әйдүк, яшьти, рәхим ит! Тагын нинди җилләр ташлады үзеңне?

— Дусларның хәлен белергә килдем, Минһаҗ. Мин сиңа әйткән идем бит инде селекция үзәгендә безнең авылдаш эшли, дип...

— Хәтерлим, әйткәнеңне дә хәтерлим, болай да ишетеп беләм мин Госманның Казанда икәнен. Тик үзе янына барырга, көрешергә генә туры килмәде, читенсенәм... Барырга җыендыммы, нигәдер теге еллар искә килеп төшә дә, туктап калам. Төлке тиресен әйтәм... Их, Мотаһир, бар иде заманалар!..

— Ул бүген бик авыр хәлдә, Минһаҗ. Инфаркт диләрме, хәзер больницада ята. Яңа директор белән килешә алмадылар алар,— диде Мотаһир һәм үзе белгәннәрен һәммәсен дә төкми-чәчми Минһаҗга җиткерде.

— Директорның фамилиясе ничек дисең?

— Нөхитов.

— Тукта, тукта! Бу кеше бит миңа таныш.— Минһаҗ теге вакытта аның улы Наил белән очрашуга килү вакыйгасын исенә төшерде. Әмма Мотаһирга бу хакта сиздермәскә тырышты. Зур бер түрә алдында серне беркемгә дә ачмаска сүз биргән иде ул.

— Әйе,— диде ул, кабатлап.— Очрашкан идем мин ул кеше белән. Ә менә кайда икәнен хәтерләмим.

Мотаһир авылдашының күзләренә туп-туры карады, ә тегесе ирексездән карашын читкә борды.

— Гафу ит мине,— диде ул бераздан,— күңел яраларын кузгатасы килмәгән иде. Авылдашыбыз Хәмидәнең фаҗигале үлеме уңае белән чакырган идек без аны...

— Әллә аның да катнашы булганмы?

— Юк,— диде Минһаҗ теләр-теләмәс кенә.— Очраклы рәвештә, гаепләнүченең үтенече буенча... Ярар, калдырыйк бу турыда.

Мотаһир уйга калды. Аннары ул Минһаҗның күзләренә янә тутырып карады да:

— Анысы синең үз эшең, Минһаҗ. Тик яклауга лаек кеше түгел ул. Минем сиңа бер зур үтенечем бар. Бер мәсьәләгә ачыклык кертәсе иде. Теләсәң, булдыра аласың син аны,— диде.

Мотаһир тынып калды. Кинәт кенә башыннан: «Әгәр дә Минһаҗ да аның кешесе булса?»— дигән шикле уй йөгереп узды.

— Сөйлә, сөйлә, Мотаһир, мин тыңлыйм,— диде Минһаҗ тыйнак кына.

Мотаһир һаман уйлана иде әле. «Бүре баласын күпме генә бүректә тотма, һаман урманга карый»,— диләр. Тагын бер кат сынап карады ул Минһаҗга. Ә Минһаҗ исә, башка түзеп тора алмыйча, елмаеп куйды:

— Шикләнәм, дисең? Шикләнмә, үзеңә ышанган кебек ышана аласың. Ә Нөхитов турында әйтеп бетермәвемнең сәбәбе бар. Ул хакта башка вакытта... Миңа үпкәләмә.

— Мин үзем дә нәкъ шул кеше турында үз фикеремне әйтмәкче идем, Минһаҗ. Хәтерлисеңме, әле без яшь вакытта миңа Аю урманында атканнар иде. Минем уемча, атучы кеше — Нөхитов. Әйе, әйе, шул чагында үзем дә яраладым мин аны. Бүре ядрәсе белән. Тик качып котылды...

— Инде ничәмә-ничә еллар үткән. Ялгышырмын дип уйламыйсыңмы?

— Уйламыйм. Аның тар маңгае, маңгаендагы зәңгәр күмер эзе әле дә күз алдымда...

— Маңгаена күмер кыйпылчыгы кергән шахтерлар азмыни дөньяда?

— Үзем дә шулай дип уйлый идем. Ә утыз җидедә аның белән мунчада бергә булдык. Ышанасыңмы, иңбашында яра эзе. Һичшиксез, бүре ядрәсе чәрдәкләгән эз... Шул ук көнне без аның белән Черек күл буенда очраштык,— диде Мотаһир. Һәм ул вакыйганы төкми-чәчми сөйләп бирде.

— Алайса, уйланырлык урын бар монда... Тик ашыгыч нәтиҗә ясарга ярамый. Охшаган гына булуы да мөмкин.

Прокурор Салихов кулына каләм алды. Мотаһир сөйләгәннәрне кәгазьгә теркәп куйды. Әгәр кирәк булса, кайбер нәрсәләрне ачыклау өчен, Нөхитовны да чакыртырга сәбәп бар: үтерүче Нузитов мәсьәләсе буенча кайбер нәрсәләрне ачыкларга кирәк, дип әйтергә мөмкин.

— Минһаж,— диде Мотаһир, нәрсәдер исенә төшкәндәй.— Бөек Ватан сугышы башланганда Нөхитов кайда яшәде икән? Шуны ачыклыйсы иде. Кызыксынуымның сәбәбе мине яралаган өчен генә дип уйлама. Булып узган вакыйгалар әле дәүләт байлыгын үзләштерү белән дә бәйле.

Шуннан соң ул катлаулы язмыш иясе Шәкүр яшереп калдырган алтын турында сөйләп бирде.

— Булган икән монда хәлләр!— диде Минһаж, кабатлап.— Ә нигә соң боларны элегрәк хәбәр итмәдегез?

— Иттек. Тик «ачкыч»тан башка алтынны табу мөмкин түгел иде. «Ачкыч» исә Хәмиденең бүлмәсеннән югалды. Ә урмандагы атышуларга килгәндә, ул елларда Аю урманында кан аз коелдымыни, Минһаж?

— Сүткән саен чияләнә генә бара бу. Ә син җиңел генә хәл итмәкче булган идең. Билгеле, мин үзем көчем җиткәнчә бу мәсьәләгә ачыклык кертергә тырышырмын, булышырмын. Болай булгач, безгә инде ешрак очрашырга туры килер.

— Яхшы сүзеңә рәхмәт. Чынлап та, ахырынача чишәсе иде бит шушы төенне, Минһаж...

* * *

Мотаһир кайтканда, Мәсхудә өйдә иде инде. Ул аны елмаеп каршы алды:

— Кайларда булдың, «кунак егете»? Ниләр күрдең? Көтеп-көтеп тә кайтмагач, күңелгә төрле күңелсез уйлар килә башлаган иде, югыйсә. Әллә Госман Айдарович янына кагылдыңмы дигән идем...

— Беркөнне сөйләшкән идек, бүген була алмадым. Аның янына иртәгә кереп чыгарга исәп. Бүген исә бер авылдашым белән очраштым. Яңа Бистәдә яши. Үткәннәрне искә төшереп сөйләшә торгач, вакытның узганы да сизелмәгән.

— Кем соң ул?

— Белмисең син аны. Буранчыдан ул. Исеме Минһаж. Танышырга теләсәң, иртәгә чакырам,— диде Мотаһир шаяртып.

— Миңа синең белән таныш булу да бик җиткән... Мотаһир, беләсеңме, минем башка нинди уй килде? Мәскәүгә күченеп торганчы, әллә туп-туры Казанга гына кайтасыңмы? Институтта урын бар, үзең беләсең, вакантлы урын...

— Мин Тимирязевкада вәгъдәләшкән идем инде. Квартираны да алыштырыр кеше таптым. Дөрес, бер бүлмәле генә. Мәскәүдә башкасын өмет итеп тә булмый.

— Квартиры булыр, анысы качмас. Тик менә нигәдер шушы Казаннан бер дә китәсе килми, Мотаһир. Ни әйтсәң дә, туган җир бит...

— Суы, туфрагы тарта, Мәсхудә. Мин үзем дә бик сагынып кайттым Казанны. Синең тәкъдимне уйлап карарбыз. Ләкин соңрак. Бу — үзе бер проблема. Бәлки, син үзең турында борчыласыңдыр? Мин каршы түгел. Хәзергә эшләп тор, соңыннан күз күрер...

Каргина, Мотаһирның күзләренә керердәй булып текәлгән килеш, сүзсез калды. Нәрсә инде бу? Әле кичә генә, янып-ялкынланып: «Мәсхудә, бергә китәбез Мәскәүгә!»— дигән иде, ә бүген... «Мин каршы түгел...», имеш. Ирләрнең һәммәсе бер калыптан сугылган шул аларның. Йөрәгеңне ачканчы гына «серле йомгак» булып тоеласың аларга. Ә күңелеңне бер белсә, беттең...

— Каршы түгел, дисең инде, алайса,— диде Каргина, бераз мыскыллабрак.— Кирәгең калмады, дисең...

Мотаһир кинәт үзгәреп китте. Уиламыйчарак әйткән сүзләре өчен эчтән генә үз-үзен тиргәп, Мәсхудәне тизрәк тынычландыру җаен карады:

— Аңламыйм, әллә үпкәләдең дә инде?.. Шулай ярыймыни? Телисең икән, хәзер үк китәбез. Әйтергә теләгәнем дә шул иде. Син ничек телисең, шулай эшләрбез.

Мәсхудә аның кочагына сыенды да, тавыш-тынсыз гына бик озак күзләренә карап торды:

— Син бөтенләй башка кеше шул. Күзләрең тирән, нәкъ диңгез. Ләкин ул диңгез дулкынланганда, мин югалып калмаммы, Мотаһир?

— Күкрәгеңдә дөрли икән чын ялкын, сүндерә алмыйдыр аны һич дулкын...

— Татлы бәлзам кебек синең сүзләрең, яраларым төзәлгәнен сизәмен...

Мәсхудә Мотаһирның кочагында тәмам эреде. Шулчак аның күңеленә нигәдер Нөхитов әйткән сүзләр килде. «Кешенең күңелендәген күзеннән укып белергә кирәк»,— дигән иде ул. Чынлап та, Мотаһирның күзләре моңлы диңгез. Күпне күргән, әмма үзенең сафлыгын, юмартлыгын саклаган диңгез. Шундый авыр сынауларга юлыгып та, кешелеклелеген, кешеләрне ярату, киләчәккә омтылыш кебек изге сыйфатларын җил-яңгыр тидермичә саклап калган... Язмыш әнә шундый кеше белән очраштырды. Очраклы хәлме бу? Алай дисәң, ул моны көтмәде дә, хыялланмады да, югыйсә. Кызык бу тормыш... Ә менә хәзер бу кешедән башка бер генә көн дә яши алмас кебек. Әгәр дә ул, ялгышып кына: «Синнән китәм...»— дисә? Мондый хәлне кичерә алмас кебек. Ул чагында тормышның бер кызыгы, бер яме калмаячак. Әле кайчан гына бөтенләй белмәгән кешегә ничек шулкадәр тиз ияләнергә, күнегергә мөмкин? Әгәр дә Мәскәүдә очрашып сөйләшмәсәләр... Бөтенләй башка хәл булыр иде... Шулай да, ул хәзер нәрсә эшләр иде икән? Һаман да шул Нөхитов белән буталыр идеме? Яхшы кешеләр очрасын икән шул тормыш юлында. Алар үзеңне дә, тормышыңны да әнә ничек үзгәртәләр, сафландыралар. Андый кешеләр белән күңелеңдәген тартынмыйча уртага салып сөйләшергә, серләшергә була...

— Мотаһир,— диде Мәсхудә, тынлыкны бүлеп.— Мин синең алда бер серемне ачарга уйлыйм. Белмим, моның өчен мине гаепләрсеңме? Мин Нөхитов өстеннән Мәскәүгә шикаять җибәргән идем. Бик озакламас, анда язылганнарның дөреслеген тикшерү көне дә җитәр... Әмма мин курыкмыйм, чөнки чынлыкны яздым. Гомеремдә беренче тапкыр яздым. Дөресен әйтим, Мотаһир, миңа ул кешенең зыяны тимәде. Ә менә үз-үзен тотышы, кешеләрне кыерсытуы, фән өлкәсендә буш кеше булуы мине язарга мәҗбүр итте... Ниндидер көч этәрде мине моңа...

Каргина сөйләнә-сөйләнә китап шкафына үрелде. Аннан газетага төрелгән калын гына папка тартып чыгарды:

— Менә, минем кулда аның диссертациясенең караламасы. Син, бәлки, мине гаепләрсең, тик бу бик кирәк иде. Әйе, аның чын йөзен ачар өчен кирәк иде!

Мотаһир, гамьсез генә тыңлаган кебек күренсә дә, чынлыкта Мәсхудәнең тормышындагы кискен борылыш аны тирәнтен уйланырга мәҗбүр итте. «Әле генә тату яшәгән дуслар бүген пычакка-пычак килергә мәҗбүр,— дип уйлады ул.— Моңа нәрсә сәбәп соң? Бу кеше — бүген аның дошманы. Сәбәбе шул: Мәсхудә үзенең яшәешенә яңача карый башлаган һәм бу аның табигатькә, кешеләргә булган мөнәсәбәтен тамырыннан үзгәрткән. Ул бүген үзен дөреслек, хаклык өчен көрәшүче дип исәпли, башкалардан да шуны таләп итә. Әйе, күпләр тормышында булырга мөмкин мондый яңарыш-борылышлар...»

— Нигә бер сүз дә әйтмисең?— диде Каргина, Мотаһирның уйларын бүлеп.— Аңлыйм, мине хупламыйсың!

— Алай димәдем бит әле, Мәсхүдә. Мәсьәлә бик катлаулы, әзеп кенә ни дә булса әйтүе читен. Менә бу диссертациянең караламасын алуың бераз борчый мине...

— Кеше мөлкәтенә кул сузуда гаепләрләр, дисеңме? Ул бит аның хезмәте түгел, мәрхүм Коршунныкы. Икенчедән, мин аны урлап алмадым, ә Нөхитов үзе бездә онытып калдырган. Әйткәнемчә, ул минем янга кергәли иде. Моның өчен гафу ит мине, Мотаһир!

— Әгәр дә исбат итә аласың икән, мин каршы түгел. Тик, ашыгып, барысын да бутап ташлый күрмә. Әгәр дә ул синең кулдагы бу караламадан баш тартса, күргәнем юк, дисә?

— Ә бит аның ВАКка җибәргән диссертациясе бу караламага сүзгә-сүз туры килә.

— Караламаның шантаж өчен күчерелүе дә ихтимал бит.

— Юк, Мотаһир. Коршун үлгәндә, аның диссертациясе әле каралмаган да, машинкада да басылмаган иде. Ә үлгән кеше теге дөньядан кайтып яза алмый. Димәк, бер генә юл кала...

Мотаһир нидер әйтмәкче булган иде, әмма тынып калды. Аннары тәрәзә янына килде дә, пәрдәне ача төшеп, меңнәрчә утлар белән балкыган шәһәр өстенә текәлде.

* * *

Махсус клиникада эшләүче врачларның таләбе каты иде, әгәр терелəсең килсә, кузгалмый, селкенми тыныч кына ят, бик шатланырга да, кайгырырга да, уйланырга да ярамый, диделәр. Госман шуларның барысын да үтәргә кирәклеген аңласа да, бер генә минут та уйланмый ята алмады. Бер уйны башыннан чыгаруы, күзен йомуы була, яңадан-яңа уйлар биләп ала. Дуслар, танышлар, әллә кемнәр күз алдында бөтереләә, башына бөтенләй башка фикерләр кереп тула. Кирәк бит, инде күптәннән онытылган Салих бай исенә килеп төшә. Әйтерсең гафу үтенергә килгән. Рәнҗемә инде миңа, ди кебек. Мәрхүм, нишләп уена киләсе итте соң әле? Күптән онытылган иде бит инде. Ә менә Хәмидә күз алдыннан китми, нәрсәдер көтә... Әнә, Хафиз абыйсы, ул да ачулы, Макарның бугазына без белән кереп чыккандагы кебек... «Әнием! Син бит бу! Бәрәңге тукмагын шәлеңә төреп, һаман нарасыең кебек итеп иркәлисең...» Кемнәрнең генә язмышлары килми күз алдына! Түшәмгә карап яткач, анда нәкъ телевизор экранындагы кебек: үлгәннәрнең дә, тереләрнең дә рәсемнәре алышынып кына тора...

Менә Шариков. Кеткелдәп көлгән була. Закировны төп башына утырттым дип куана бугай. Көләргә иртәрәк әле, Вязьма буендагы буталчык вакыйгаларны ачыклыйсы бар... Доктор Василенко кайда?

Шулай уйга чумып ята торгач, янына дәвалаучы врачның килеп басканын да сизми калды Госман. Күзләре ап-ак түшәмгә текәлгән, күңеле кайдадыр ерак Вязьма буйларында гизә иде аның...

— Иптәш Закиров,— диде врач,— сезгә инде бераз йөри башларга да ярыйдыр.

Профессор сискәнеп китте. Әмма «йөрергә ярый» дигән сүзләрне ишеткәч, киң елмаеп, терсәгенә таянды.

Мотаһир кергәндә, ул инде аякка баскан иде. Күрештеләр, бер-берсен кочаклап алдылар. Мотаһир, авыруны ялыктырмас өчен, нәрсә турында сөйләшергә, үзен ничек тотарга кирәклеген алдан ук уйлап куйган иде. Шуңа күрә вак-төяк нәрсәләргә тукталып тормады. Нөхитовны күрүен, Минһаҗ белән күрешүен сөйләде. Әмма Мәсхүдә турында бер

сүз дә әйтмәде, читенсендеме, сүзнең куерып китүеннән шикләндеме? Ә менә Госман диссертациянең караламасы Каргинада икәнен искәргәч, Мотаһир үзе дә сизмәстән: «Әйе, әйе, анда саклана ул»,— диде.

Профессор аптырап Мотаһирга карады, йөзе җитдиләнде:

— Каян беләсең син аны? Нәрсә, әллә Каргина бу хакта очраган бер кешегә сөйләп йөри башлаганмы?

Телең тик тормаса, шулай була ул! Мотаһир Мәсхудә белән ике арадагы мөнәсәбәтне аңлатып бирергә мәҗбүр булды. Госман исә, бер тын басып торганнан соң, Мотаһирның иңенә кулын куйды да:

— Әкияттәге кебек бу. Шулай да син дөрес юлда, Мотаһир. Аңлыйм мин сине. Миннән хәер-фатиха!— диде.

— Рәхмәт, Госман!

— Теге чакта әйтергә онытканмын: мин бит авылга кайткач, тагын Аю урманына бардым...

— Юкмы?

— Күптән җилләр искән. Шулай да бер алтын тәңкәне «орлыкка» онытып калдырганнар.

— Күпме еллар үткәч, ничек таптың син ул урынны, Госман?

— Урыны билгеле иде бит, онытырлыкмы соң, Мотаһир, ул чакларны? Ә күмелгән урынны табарга «ачкыч» ярдәм итте.

— Каян алдың?

— Мәскәүдә курсларда укыган вакытта... Шариков квартирасында, китап арасыннан,— диде Госман һәм һәммәсен дә бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Күреп алып, юк итмәсләрме аны? Шундый шигең юкмы?!

— Күптән онытканнардыр инде. Шариков, бәлки, әле үзе белмидер дә. «Ачкыч» ничек килеп эләккән аңа, безгә менә шуны ачыкларга кирәк. Монысы — каты чикләвек. Безгә бу эштә ярдәм итсә, бары тик Минһаҗ гына ярдәм итә ала...

— Мин аның белән үзем сөйләшеп карармын, Госман. Нәрсә әйтер?

— Ялың беткәнче эшләргә кирәк моны.

— Тырышырмын. Аннан Мәскәүгә күченәсе булыр. Инде квартира да тапкан идем.

— Күчкән-күчкән, Казанга гына кайтсаң, бергә-бергә дулкыннарны яру җиңелрәк тә, ышанычлырак та булмас идеме икән?!

— Бу хакта соңрак, Госман... Андый уй бар-барын. Ярый, хуш хәзергә, тизрәк сәламәтлән!

* * *

Мотаһир белән булган очрашу прокурор Салиховны ничектер канатландырып җибәрде. Бигрәк тә «ачкыч» вакыйгасы тынгы бирмәде аңа. Бу хакта ул Госман белән очрашып, бик тәфсилләп сөйләште. Ничек итеп Шариковка эләгергә мөмкин ул? «Ачкыч» белән Нөхитов арасында берәр бәйләнеш юкмы икән? Аның Бөек Ватан сугышы алдыннан кайда яшәве хакында дөрес мәгълүмат бирмәве бу шикне тагын да арттыра төште. Сугышка кадәр Себердә яшәмәгән ул. Җибәрелгән сорауга шундый җавап килде. Эшләр болайга киткәч, Салихов «дело»ны якыннан белгән Хәйдәров дигән тикшерүчегә тапшырды. Ә үзе исә эшкә юнәлеш биреп, киңәшләшеп торды...

Бу юлы Нөхитовны инде Хәйдәров чакырды. Тикшерүче аның үги улы Нузитов турында да, ата буларак җаваплылыгы турында да искәртеп тормады, ә турыдан-туры:

— Сез сугышка кадәр кайда яшәвегезне дөрес күрсәтмәгәнсез. Сәбәбе нәрсәдә? Нигә болай эшләдегез?— дип сүз башлады.

— Мин бит аны сүз уңаеннан гына дип уйладым, әһәмият бирмәдем. Тәк шту, мине башка мәсьәлә буенча, Нузитовның үги әтисе буларак чакырганнар иде. Мин Себердә сугышка кадәр түгел, ә соңгы елларда, ягъни Казанга күчеп килгәнче яшәдем.

— Ә сугыш башланыр алдыннан кайда идегез?

— Ул йорт юк инде хәзер, бомба төшеп җимерелде...

— Адресы ничек иде?

— Оныттым инде. Сезгә ул берни дә бирми. Мин анда пропискада түгел идем.

— Эш урыныгыз?

Нәхитов кызарып-бүртенеп чыкты. Тикшерүчегә каш астыннан гына сөзеп карады да үзе һөҗүмгә күчте:

— Миннән сорау алырга сезнең ни хакыгыз бар? Шул Каргина жалобасына карап кешене күпме тинтерәтергә мөмкин?

— Без сезне бер генә нәрсәдә — белешмәне дөрес бирмәүдә генә гаеплибез, шуны ачыкларга телибез. Чөнки сез галим кеше, фәннәр кандидаты, абруйлы фәнни оешманы җитәклисез. Шуңа күрә дөрес булмаган белешмә бирүнең законга сыймаганлыгын белергә тиеш идегез.

Нәхитовның кайнарлыгы сүрелә төште.

— Әгәр дә минем ул елларда кайда яшәвем сезне чын-чынлап кызыксындыра икән, миңа вакыт бирегез. Булган документларны алып, караштырып килим. Ни әйтсәң дә, шактый еллар үткән, тагын ялгышып куюың бар. Ә документлар өйдә кайдадыр бар минем, тик эзләргә генә кирәк...

Хәйдәров уйга калды. Кем белә, бәлки, дөресен сөйлидер... Шулай да Салихов белән киңәшмичә ярамас.

Ул, күрше бүлмәгә чыгып, Салиховка шылтыратты:

— Нәрсә эшләргә соң хәзер аның белән? Өенә кайтсын, дисезме? Аңладым. Иртәгә нәкъ шушы вакытка килергә. Ярый... Үзегез бирегә буласызмы? Ярый, көтәм!

Нәхитов чыгып киткәч, күп тә үтмәде, ишектә Минһаҗ Салихов күренде.

— Эшләр катлаулана бара, дисез, алайса? Тик монда без болай төпченеп утырып, «ачкыч»ны кулдан ычкындырып куймыйк. Иртәгә безгә икебезгә дә Мәскәүгә китәргә кирәк. Профессор Закировның хәле әйбәтләнгән, теләсә, аны да үзебез белән алып барырбыз.

— Сез бит Нәхитовны иртәгә кабат чакырырга куштыгыз.

— Әйе, куштым. Аның белән үзең генә сөйләшерсең. Эшеңне тәгәллисең дә «Татарстан» поездына киләсең. Без сине шунда көтәрбез.

* * *

Шариков Казаннан килгән кунакларны җылы каршы алды. Кērә-керешкә барысын да кунак бүлмәсенә чакырды. Таныштылар. Аннары үзе, чәй әзерләргә дип, кухняга уза башлаган иде, аны Салихов туктатты:

— Рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез... Без озакка түгел. Сүзнең кыскасы әйбәт дигәндәй... Сезнең белән бер нәрсәне ачыклыйсы бар иде.

— Сөйләгез, тыңлыйм,— диде Шариков, шикләнүен сиздермәскә тырышып.— Кулдан килгәнчә булышырмын.

— Сез Татарстанда ничәнче елларда яшәдегез? Алабуга шәһәренә кайчанрак тукталдыгыз?

Шариков җиңел сулап куйды. Чөнки ул, бирегә фронтташы Госман Закиров та булгач, сүз Вязьма урманнары турында булыр дип курыккан иде.

— Татарстандамы? Берничә ел Бөгелмәдә яшәргә туры килде. Ә минә Алабугада булганым юк.

Алар сөйләшкәндә, Закиров китап шкафыннан күзен алмады. Кайсы тирәдәрәк иде соң әле ул китап? Шариковның биләүле пар турындагы монографиясен исенә төшерде. «Ачкыч»лы китап та шуның белән рәттән генә иде. Госман кинәттән генә Шариковка мөрәҗәгать итүен сизми дә калды:

— Михаил Яковлевич, биләүле пар турындагы монографиягезне карарга мөмкинме?

— Рәхим итегез!— дип, Шариков тиз генә монографиясен алып бирмәкче булган иде, аны урынында күрмәде, эзли торгач, ул аны теге вакытта Госман куйган урыннан табып алды:

— Алыгыз, менә ул!

— Рәхмәт!— диде Закиров һәм китапның берничә битен генә ачып карады да тагын шкафка текәлде.

Салихов профессор Шариковтан тагын нәрсәдер сорарга җыенган гына иде, Закиров, урыныннан торып, шкафка таба атлады:

— Ә менә бусы без эзләгән китап!— диде Закиров, Алабуга интернат мәктәбенең мөһере сугылган таныш китапны Салиховка сузып.

Салихов китапны җентекләп карарга кереште. Аны бигрәк тә китап эчендәге «ачкыч» кызыксындырды.

— Хәтерем ялгышмаса,— диде ул, Шариковка мөрәҗәгать итеп,— сезнең чын атыгыз — Миңнәхмәт? Фамилиягез дә Шариков түгел, ә Шәрипов. Нигә кирәк булды сезгә әткәгез-әнкәгез кушкан исемнән ваз кичү?

— Бигрәк тә Мәскәүдә яши башлагач, татарча исем йөртү уңайсыз тоелды. Әйтергә читен... Тоттым да алыштырдым. Юк, мине «перевертыш» дип гаепли күрмәгез, мин үз халкымны яратам... Дөрес, бата башлаган корабтан иң элек күселәр кача, диләр. Ләкин мине алар исәбенә кертә алмыйсыз...

— Фәлсәфәгә керешмичә генә сөйләшик әле, иптәш Шәрәпов. Менә бу китап сезгә ничек килеп эләкте, шуны төгәл генә әйтә аласызмы?

— Бирегез әле, нинди китап икән ул?— Шәрәпов китапны кулына алды һәм, эчендәге «ачкыч»ны күреп, хәйран калды:

— Монысы нинди иероглиф тагын? Берни дә аңламыйм. Чынлап әйтәм, бу китапны мин беренче мәртәбә күрәм... Ә-ә-ә, бу бит Нөхитов китабы...

Кинәт ул телен тешләгәндәй туктап калды. «Нигә кирәк иде инде монда Нөхитовны бутарга?— дип уйлады.— «Белмим» дияргә иде дә, вәссәлам. Телең тик тормаса... Тартай теленнән табар, диләрме. Хак икән.»

— Нөхитов еш буламыни сездә?

— Булгалый иде. Хәзер бик күренми инде.

— Бу китапны ул кайчан алып килде икән? Хәтерлисезме?

— Күптән инде. Сугышка кадәр үк булса кирәк, аның бернинди дә кыйммәте юк хәзер.

— Шулай дисезме?

Шулчак ишектә звонок чыңлады.

— Сез утырып торыгыз, хәзер үзем ачам,— диде Салихов, хуҗага туры карап.

Шәрәпов кинәт кабынып китте:

— Сез нәрсә, прокурор санкциясеннән башка сорау аласыз, тентү үткәреп маташасыз әле?!

— Андый кәгазь бар,— диде тикшерүче, Шәрәповны тынычландырмакчы булып.

Шулчак ишек артында ниндидер таныш сыман тоелган тавыш ишетелде:

— Өйдә, өйдә, әйдә, керегез. Кунаклар янында ул, рәхим итегез,— диде Салихов һәм керүчене шундук танып алды.

Түр бүлмәдә Шәрәпов белән янәшә утырган Госман Закировны күрүгә, яна кунак кинәт кенә чыгу ягына борылды:

— Монда, чынлап та, кунаклар күп икән. Комачауладым, ахры, гафу итегез,— диде ул, үзен танытмаска тырышып.

— Николай Григорьевич, сез кая?— диде Шәрәпов, борчылып.— Түргә узыгыз!

— Башка вакытта,— диде кунак, тизрәк чыгып китәргә омтылып.— Иртәгә керермен. Ярый, хәзергә хушыгыз!

— Туктагыз! Беркая да бармыйсыз, Гыйлаж,— диде Салихов, боерулы тавыш белән.— Түргә узыгыз!

«Качарга кирәк»!»— дигән уй йөгереп узды Гыйлажның күңеленнән. Күзе почмакта яткан гантельгә төште. Әмма аны алып маташырлык җае юк иде инде. Ул кинәт кенә борылды да, чамасын онытып, Салиховны бар көченә этеп җибәрде һәм ишеккә атылды. Аннары баскыч буйлап аска томырылды, әмма Хәйдәровның «капкын»ына эләгеп, җиргә капланды...

Госман Закиров мондый көтелмәгән очрашудан таң калган иде. Шулай да врачларның әйткәнен исеннән чыгармаска, дулкынланмаска тырышты. Ләкин бик җиңел эш түгел иде шул бу! Онытылып китеп, ул шунда ук Салиховка ярдәмгә ашыкты.

— Борчылма, Госман, беркая да китә алмый ул. Анда безнең кешеләр... Үзегезне тыныч тотыгыз, Гөлфия Афзаловнага сезне исән-сау килеш кайтып тапшырырга сүз бирдем мин...

— Шушындый хәлләрдә ничек тыныч кына калырга мөмкин, Минһаж?

Берничә минуттан Гыйлажны тотып өйгә алып керделәр. Шул кыска гына мизгелдә ул бөкерәеп, кечерәеп калган, иңнәре салынып төшкән иде. Аның чәчләре күзгә күренеп агара кебек тоелды Госманга.

— Йә, нихәл, авылдаш? Суга төшкәндәй әллә кая юкка чыктың, эт белән эзләтеп тә табып булмый үзеңне. Ярый әле, вакытын белеп, үзең бирегә киләсе иткәнсең?

— Көлмә, Госман энем, көлмә. Көлке көлә килер, артыннан куа килер, ди.

— Нәкъ шулай булып чыкты шул, качак-дезертир. Күпме көлдең авыл халкыннан теге вакытларда! Инде хисап бирер көнең җитте. Мәрхүмә Майҗан һәм Мәчтүрәләр өчен, госпитальдән чыккач синең кулдан һәлак булган адашың өчен, Мотаһирлар язмышы өчен... һәм, ниһаять, Аю урманыннан урлаган алтын өчен...

— Алтынны мин алмадым,— диде Гыйлаж.— Харис Нәхитов эше ул.

— Менә бу «ачкыч» астына да Нәхитов язганмы?— диде Салихов, аңа китапны күрсәтеп.

Гыйлаж дәшмәде. Чөнки инде сөйләүнең дә, аклануның да мәгънәсе юк иде. Кылган гөнаһларын аклар өчен ун гомере булса, унысы да җитмәсен аңлый иде ул.

— Сез дә киенегез, иптәш Шәрәпов!

— Ә мин нигә?— диде Шәрәпов, аптыраган кыяфәттә.— Минем бер катнашым да юк монда. Кеше үтермәдем, урлашканым юк. Мине нигә катнаштырасыз җыен жуликлар эшенә? Җинаять кылганнар икән, җавабын да үзләре бирсеннәр.

Алдан хәбәр бирмәгәне өчен ачуы чыккан Гыйлаж ахирәте Шәрәповның бу сүзләреннән соң тәмам кызып китте:

— Нигә бөтен гаепне безгә ударасың әле? Үз өлешеңне алгач, Нәхитовныкын күпме каердың! Ул мескен сүз әйтергә дә курка иде шул синә.

Шәрәпов ачу белән иреннәрен тешләде дә элгечтәге пальтосына үрелде:

— Каян гына бәйләндем җыен йолкыш белән! Үзләренә дә рәхәт юк, кешегә дә... Булдыксызлар!

Аның ачу катыш нәфрәт белән әйтелгән сүзләрен Госман Закиров кына түгел, башкалар да тыелгысыз бер гаҗәпләнү белән сүзсез генә тыңладылар. Иң мөһиме — чияләнеп беткән төеннең, кәбестәдәй катлы-катлы табышмакның җавабы табылган иде.

*1984—1989.*

## АЛДАГЫ САННАРДАН УКЫГЫЗ!

**Аяз Гыйләҗев**

# ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА!

РОМАН-ХАТИРӘ

«И-и, төрмәнең сөенечле мизгелләре!» — дип башлап китсәм, хөрмәтле укучым, «Бу бәндә әллә әзрәк ычкынганмы?» — дип, рәнҗеп-сүгенеп китапны ябып куярга ашыкма, зинһар! Әгәр бик күпләр күзеннән яшерелгән төрмә тормышы бары тик кайгы-хәсрәттән генә торса, аннан берәү дә исән-аман чыга алмас иде!

Төрмә эчендә — тоткыннарны бергә җыйнап яткырган караңгы дөньяда да нәни генә, чәнти бармак очы хәтле генә юанычлар, хәтта ки сөенечләр дә була. Һәр мәхбүскә ияреп, беренче нәүбәттә, тынчу, кысан камераларга Өмет керә. Язмышыңны урталай бүлеп тамырыңа балта чапсалар да, адәм балаларының соңгы Өметенә иң явыз җәлладлар да хөкем чыгара алмый. Башың калса — Өмет яши. Һәр төрмәнең үз кануннары, гадәтләре, төсе, исе, ашатуы үзгә, үзенчә була. Ләкин һәр төрмәдә дә тоткыннар күмәк юаналар, берәүләр капкынга яңарак төшә, икенчеләр читлекләрдә күптәннән саргая, ирек көтеп дөнья белән хушлашып куючылар да очраштыра. Төрмәгә һәркем ияртеп кергән тормыш өзек-өзек кебек тоелса да, андагы Хәтер чылбыры берчакта да өзелми, һичбервакыт буш тормаган төрмә тоткыннары юаныч-өметләрен елдан-елга, буыннан-буынга, түкми-чәчми тапшыралар. Төрмәгә килеп кергән сәгатьтә, синең үтә нык борчылган, тәмам рухың сынган чакта сине ошбу төрмәнең караңгы тарихы белән таныштыра башлыйлар...

**Күренекле әдип, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Аяз Гыйләҗев үзенең «Йәгез, бер дога!» исемле роман-хатирәсен әнә шулай башлап китә. Язучының үз гомер юлына һәм Ил язмышына бәйләп, татар халкының Октябрь инкыйлабыннан бүгенгәчә узган катлаулы язмышын чагылдырган гыйбрәтле бу әсәрне сез журналыбызның алдагы саннарыннан тулысынча укый алачаксыз.**

# ШИГЪРИЯТ



## Фәрит Габдрәхим

### Кичер мине, халкым!

«Алтын Урда изгән урысларны,
Вәхши татар — кансыз: аскан-суйган...» —
Эчтән генә әйттем, эчтән генә:
«Нигә ялганлыйсың, «өлкән туган»? —
Кичер мине, халкым!

Туктаталмыйм чиркәү нигезендә
Рәнжеп яткан кабер ташларының
Сызлануын. Җылый алам бары
Диварларга терәп башкаемны.—
Кичер мине, халкым!

«Мирсәетләр, Исхакыйлар — дошман!» —
Ил акырды көн-төн тамак ярып.
Мин лаеклы улың булалмадым:
Такмадылар «дошман» дигән ярлык.—
Кичер мине, халкым!

### Чикләр, сапер, миналар

Төрле битлек кигән империя,
Ә соңгысы иде кызылдан.

---

Фәрит ГАБДРӘХИМ (1933) — *Уфада яшәүче татар шагыйре, башкорт телендә басылган китаплар авторы; Казан көндәлек матбугатында, шул исәптән журналыбызда шигырьләре даими басылып килә.*

Милләтләрне бүлгән чикләребез
Очлы штык белән сызылган.

Ошбу чикләр бүген тартышалар,
Көзән җыергандай сеңерне.
Ничә гасыр инде сызлый җаны
Казан ханлыгының, Себернең.

Империя буйлап йөри Хаклык,
Тарих катламнарын актарып.
Чын чикләрне җуйган «бөек» халык
Богаулаган башта татарны.

Ике йөзләп кавем кол ителгән,
Мәхрүм булгач татар иркеннән.
Чын Азатлык алмый торып татар,
Азат булмас, ахры, беркем дә.

Явыз Иваннан да, Ермактан да
Төрепкәле грузин уздырган:
Чәнечкеле ялган чикләр сузган,
Милләтләрне чәчкән-туздырган.

Шул мыеклы сапер чикләр буйлап
Миналарны күмеп калдырган.
Абхаз, әрмән, осетиннар... ошбу
Миналарны тели алырга.

Утлы чикләр бәргәләнә җанда,
Көне-төне шартлый миналар.
Кабердәге грузин мәкереннән
Кан коела, ава бинала...

Онытмаган сапер Ык төбенә
Хәтәр миналарын салырга...
Татар бәгыреннән бу җәберне
Шартлатмыйча ничек алырга?!.

## Имгәтмәгез безне!

«Татар белән башкорт — игезәкләр!» —
Әйтелгәндер шулай мең-мең тапкыр.
Башкорт белән татар соңгы телем
Икмәген дә бүлешкәннәр. Хактыр!

Бер-берсенә яу чапмаган алар,
Гомер бакый яшәгәннәр тату.
Хакимият әһелләре бүген
Шул татулык белән итә сату.

Адәм ышырамы: төче сүзләр...
Бутыйлар гел акны кара белән.
Очрашулар, кунак йөрешүләр —
Рөхсәт белән, махсус карар белән.

Фестивальләр үтә, атналыклар:
Башкорт бара Казан каласына.
Татар килә Өфе каласына.
«Дошман түгел, имеш, җил дә үтмәс
Башкорт белән татар арасына».

Сәхнәдәге рәсми үбешүләр
Фәкать ерагайтты араларны.
Башкортстан, телсез иттең бер мәл
Үзеңдәге татар балаларын.

Казан килә Өфе каласына:
«Башкорт дуслар, ничек хәлләр сезнең?»
Тик бер тапкыр сорасалар икән:
«Ничек яши милләттәшләр безнең?»

Башкорт бара Казан каласына:
«Башкорттарзан һезгә кайнар сәләм!»
Башкортстан татарыннан никтер
Тапшырмыйлар сәлам — ахры, хәрам.

Күрше белән дус яшәргә була...
Янындагы татар ничек яши?
Туган телдә китап бастыралмый,
Филармония дә ачтыралмый,—
Кем башына тамар каргыш яше?

Өфе-Казан рәсми «Әпипә»гә,
Рәсми «Карабай»га бии — күрче!
Башкортстан татарының гүя
Бәгырендә бии ике күрше.

Кочаклаша (махсус карар белән!)
Ике күрше халык, ике Алып.
Безнең күңел гаripләнә бара,
Ике халык арасында калып.
Имгәтмәгез безне, ике халык!

## Чабак, Табан, Чуртан

*Мәсәл*

Елганың бер тыныч култыгында
Чабак белән Табан балыгы
Көн итәләр...
Табан: «Минем култык!»
Чабак әйтә: «Ходай байлыгы».

Күкрәк кага Табан: «Ләм минеке.
Камышлык та. Яшә бер читтә!»
Чабак: «Минсез кыен булыр сиңа:
Мин бит суалчаннар үрчетәм».

Көтмәгәндә гениаль фикер килде,
Бар дөньяга Табан чаң какты:

«Тәнкә-йөзгечләре хас минеке,
«Табан» булсын аты Чабакның!»

Чабак хәтта судан сикереп чыкты:
«Сүзеңне син сөйлә чамалап!»
... Зур авызлы Чуртан икесен дә
Таш астында ята сагалап.

* * *

«Якты киләчәк хакына!»
Табындык гел кызылга:
«Марксизм», «ленинизм»
Һәм дә «бәлшәвизм»гә...
Күптән вакыт табынырга
«Яхшы яшәвизм»гә.

* * *

Су астына бара батып
«Социализм» дигән кораб.
Курка-курка йөзә халык
«Базар» атлы ярга карап.

* * *

Татар-башкорт арасыннан
Кара песи үткән, ди.
Иван Иваныч нигәдер
Шул песине үпкән, ди.

## Надан

Мәктәп. Вуз. Аннан аспирантура.
Менә шушы инде гыйлем юлы.
Хәтер бик шәп: телләр үзләштерде,
Тора-бара абзаң галим булды.

Ул укыган бөтен китапларны
Санап кына бетерерлек түгел.
Ләкин гыйлем һаман чамалы шул,
Ләкин һаман шактый ярлы күңел.

Озын формулалар. Искитмәле
Күпне белә. Ләкин надан әле:
Бабасының кабер ташындагы
Язуларны укымаган әле.

# Асылларын кисәләр

Урманмы бу? Урман дип әйтмәсәң,
Бу төбәкнең калыр хәтере.
Күккә ашкан шәмдәй кәүсәләр аз,
Күпләре, күр, зәгыйфь, кәкере.

Төп-төзләре кирәк мачтага,
Төп-төзләре кирәк матчага;
Тиеш алар, тиеш ярарга
Тирән субайга да, дарга да.

Аһ, аяулы күзгә ак сала шул.
Халкым тарихына күз салам.
Яуда ауган, дастаннарда калган
Асыл ир-егетләр сүз ала:


«Аягөсте торып калалмадык,
Кичерегез безне, оныклар!
Тик булмадык куркак. Сатылмадык.
Сакланамы безнең холыклар?..»

Шәмдәй агачлар аз. Асылларның
Гомерләре иртә өзелә.
Берсе тора, берсе андыйларның
Ботак-чатаклының — йөзенә.

Ауганнарның язмышыннан курку
Тамырларга хәтле үткәндер:
Күп төпсәнең алмашлары — кәрлә,
Бер нәселсез хәтта — күпләре.

Бик ерактан ишетелеп куя
Кемнәрнеңдер агач кискәне.
Яшь алмашның кәрләләре түгел,
Зифалары китә сискәнеп...




Казан утлары
китапханәсе
Мансур Вәли
Качу

## Мансур Вәли

# КАЧУ

ЗАМАНДАШ ЯЗМАЛАРЫ

**... Күптән түгел, һич тә уйламаганда-көтмәгәндә, минем бер якын танышым үлеп китте. Яшь иде әле ул — бары тик утыз биш яшь кенә иде әле аңа.**

**Бу хәл булганда мин үзем ерак шәһәрдә командировкада идем, шунлыктан аның үлеме сәбәбен төгәл генә белә дә алмадым. Ә соңрак сүз чыккан чакларда моны һәркем үзенчә аңлатты. Берәүләре икеләнеп кенә: «Йөрәге тоткан, ахрысы...» — дисә, икенчеләре бу көтелмәгән үлемне хәмер зәхмәте белән бәйләде, өченчеләре исә: «Ул торган фатирга кемдер кызыгып йөри иде булса кирәк...» дип, үзенчә өр-яңа шик белдерде.**

**Намус белән яшәгән яшь кешедән, фатирыннан тыш, әллә ни зур байлык кала алмый шул инде. Әлеге танышымның да меңнәр, миллионнар белән исәпләнә торган байлыгы юк иде. Аның каравы, ул үз башыннан кичкән кайбер хәлләрне кәгазьгә төшерә барган икән. Бер килүемдә күршеләре миңа калын гына өч дәфтәр биреп җибәрделәр.**

**Танышымнан калган әлеге язмалар бик гыйбрәтле тоелды. Аның үлеменең дә тирәндәге бер серен, сәбәбен аңладым шикелле мин аларны укыгач. Бүген — безнең көннәрдә — еш кына килеп чыгучы фаҗигалнең башын, бәхетсезлекнең ничек һәм ни рәвешле тууын, тамыр җибәрүен шәйләдем мин ул язмаларда.**

**Шуңа күрә, кайбер урыннарын аз гына төзәткәннән соң, ул язмаларны укучы игътибарына тәкъдим итәргә булдым. Бәлки кемнәрдер үзләренә берәр гыйбрәт алыр...**

## Төнге юлчы

I

Аһ, бу төнге вокзаллар!

Аһ, бу төнге сәгатьләр — вакытны уздыра алмыйча аптырау, тилмерү газаплары... Ни өн, ни төш түгел бит дип, утырасың шулай аңгы-миңге хәлдә, тынчу вокзал бинасы эчендә. Мәш килеп торган кеше арасында... Утырган килеш кенә йоклап та булмый — поездыңны ишетми

калудан куркасың. Шулай ук урамга чыгып йөреп тә керә алмыйсың — инде төн: бөтен гәүдән арыган, хәлең беткән. Бары тик менә шулай утырырга, газаплануыңны дәвам итәргә генә кала.

Болай да гаять йончыган, алҗыган кешеләрнең тагын да ачуын китереп, шикле адәмнәр күренгәли. Аларның кайсыбере, почмакка барып сыенган җиреннән ара-тирә күзен ачып, дөньяга усал бүре карашы ташлап ала.

«Бу дөньяның бөтен бәхетсезе вокзалга җыела инде әллә?..— дип уйлап алды Билал аларга карап.— Әллә инде алар өчен вокзалдан да уңайлырак урын юк?.. Тәннәренә һәм җаннарына җитмәгән җылыны бу мескеннәр әллә менә шушы кырмыска оясына кушылып, кеше көтүенә елышып кына таба ала инде?»

Менә бит әле: язмышы Билалны да җиде төн уртасында шушы җан сөймәгән, күңел тартмаган пычрак вокзалга алып килде бит әле. Барысыннан бер юлы котылу өчен, бер юлы качу өчен поезд көтә хәзер Билал.

Туйды, тәмам туйды ул! Мондый эссе җәйләрдә мәхшәргә әйләнә торган шәһәреннән дә туйды! Соңгы араларда котып салкынлыгы иңгән гаиләсе белән дә яши алмый ул хәзер... Кайчандыр бик яраткан эше дә сөендерми башлады аны.

Тик вокзалга алданрак килгән икән шул әле. Әнә югарыдагы сәгать әле шактый гына вакыт барлыкны күрсәтә. Тик, ничек кенә кыен булса да, вакытны үткәрергә кирәк... Менә шулай бер кереп, бер чыгып булса да. Яисә инде перронда арлы-бирле таптана-таптана.

Әйе, Билалга бу шәһәрдән аерылуы бер дә җиңел түгел.

Ачуы килеп, ташлап китеп барса да — һич тә җиңел түгел аңа бу шәһәр белән аерылышу! Чөнки... Чөнки аның бөтен хыяллары инде бәләкәйдән үк менә шушы шәһәргә килеп тоташкан иде.

Бу шәһәргә килеп архитектура институтында уку — иң зур бәхет иде кебек... Аннары, укып бетергәч, шул шәһәрдә калып, җаны тарткан, күңеле ашкынган эштә — архитектор булып эшли башлау иң-иң олы мәртәбә иде.

Аннан соң да Билалның бик күп өметләрен үзенә бәйләде бу кала. Еракта, бик еракта, «җир чите» дип йөртелгән якта хезмәт иткәндә, иң бәхетле кешеләр менә шул шәһәрдә торадыр кебек тоела иде аңа. Шул калага кайту, кайтып өлгәшү, анда тормыш көйләп җибәрү — ике ел буена аның иң төп теләге, максаты булды.

Боларның барысына әкерен-әкерен генә ирешеп тә килә сыман иде ул. Ләкин юк икән: иң-иң төптәгесе — барысына да терәк һәм нигез булып торганы, иң беренче ниргәсе бик үк таза булмаган икән ул салган йортның. Ул корган тормышның. Мәхәббәт дигән нәрсәнең уңышлы килеп чыгуы — кеше тормышында иң беренче ниргә икән ул... Әнә шул ниргәнең нык һәм таза да, саф һәм чиста да булуы кирәк икән иң әүвәл һәр кешегә!

Ә менә Билалның алай булып чыкмады шул. Әгәр дә алай булган булса, ул күтәргән бура уптым илаһи ишелеп төшмәс иде. Билал менә хәзер бирегә төн кошы сыман бер үзе басып тормас иде.

Ул сәгатенә карап алды. Перронда таптана торгач, поезд килергә инде күп тә калмаган икән калуын. Тик әле һаман перронда кеше күренми. Билал һаман бер үзе, бер ялгызы.

Әйе, бүтән юлчылар күбрәк көндез йөрергә ярата шул. Аларга рәхәт. Билалга гына менә төнге поезд туры килде... Нишлисең инде, бәхетең шундый булгач.

Тик поезд килер минутлар якынлашкан саен, Билал үз эчендәге ниндидер бер хиснең үзенә каршы төшеп маташуын сизде. Бераздан гына аңлап алды ул аны. Ә-ә... эш менә нәрсәдә икән: Билал бит башта үзенең китүен һич тә болай булыр дип күз алдына китермәгән иде... Үз-үзенә бик

нык ышанган кыяфәттә, горур һәм бәйсез адымнар белән вагон баскычына менеп баруын күрсәтә иде бит аңа хыял көзгесе. Кинодагычарак итеп... Ә менә чынлыкта, үз башыңа төшкәч, алай горур булып калу җиңел түгел икән.

Тиздән килеп җитәчәк поезд да йөрәккә ят нәрсә шикеллерәк тоела. Элекке заманнарда, ичмасам, пар ат җигеп, кибиткаларга утырып киткәннәр. Билал сыман моңсу халәттәге кеше..е ерак юлга атлар алып киткән... Алар, әлбәттә, аерылу сагышына чум..ан кешенең аз гына булса да күңелен күтәргәндер. Аның ялгызлыкта, төшенкелектә калган җанына бер юаныч булгандыр.

Ә Билал язмышына менә тимер атлар — җансыз юлдашлар гына калган шул. Билгеле, алар тиз юырта юыртуын. Ләкин алар бит тимер! Алар бит җансыз.

Менә хәзер җан өнәмәгән тимер аргамак төн караңгылыгыннан килеп чыгар. Килеп чыгар да, Билалны еракка, бик еракка алып китәр. Әллә кайларга, яңадан бер дә кайта алмастай җирләргә илтеп ташлар сыман ул аны. Ничектер, бүтәнчә яшь торган җир булыр кебек ул. Билалның күңеле шулай сизенә.

Их син, җырларда нурлы диеп макталган данлыклы шәһәр! Нигә соң син миңа теләгән зур бәхетемне бирә алмадың?! Нигә соң мине дә үзең кебек нурлы итә алмадың, бәхет нурыннан балкучы кеше итә алмадың?!

Хәер, сиңа — зур шәһәргә — үз эчеңдәге кечкенә генә бер җан иясенең «бәхет» дип аталган сәер тойгысы кирәкмени соң?! Синең бит аңа чынлыкта исең дә китми! Синең кайгың бөтенләй икенче төрле нәрсәләрдә бугай бит, зур шәһәр! Сиңа күбрәк шау-шу, дәртлерәк һәм көчлерәк музыка, тагын да яктырак балкырдай урам утлары гына кирәк бит!

Ә менә адәм баласы өчен, ныклап уйлап караганда, боларның берсенең дә артык әһәмияте юк икән... Тып-тыныч кына калып уйланган чакларында үзенең пар канатлы икәнен тою гына кирәк икән аңа...

## II

Ниһаять, төнге вокзалга җан керде — каядыр югарыга, күзгә күренмәстәй урынга элеп куелган репродуктор «Мәскәү — Төмән» поезды килүен хәбәр итте. Шул сүзләр белән бер үк вакытта диярлек көнбатыш яктан тепловозның көчле прожекторы да күренде. Вокзал тирәсендәге барлык почмакларны үзенең куәтле нур көлтәсе белән тиз-тиз генә айкый-айкый, көчле бер сихер иясе кебек бик тиз якынлашты ул поезд.

Үзенең иләмсез зур гәүдәсе белән шыгырдый-ыңгыраша һәм пошкыра-пошкыра озакламый килеп тә туктады ул. Билал аның тәмам туктап җитүен көтеп тормады, үз вагонын эзләп китте. Тапты, ишекне ачып, вагон эченә үтте. Нишләптер аңа озатучы-проводник та очрамады. Әллә инде йоклый иде...

Шулай да, үз вагонының тамбурына кереп баскач, ул эчкә үк узарга ашыкмады әле. Кулындагы портфелен тимер идәнгә куеп, ачык ишеккә таба борылды. Китәр алдыннан саубуллашу өчен соңгы тапкыр шәһәренә күз салырга теләде. Бу калага карата күңелендә бер-бер җылы хис уянуын көтте. Ләкин стенасының буяулары уңып һәм пычранып беткән, биек һәм ярым караңгы тәрәзәләре әллә нинди бер шом сибүче вокзал бинасы — Билал гомер иткән шәһәрнең үзе кебек үк — күңелдә җылы хис тудыра алмый иде шул. Төнлә бу вокзал әкиятләрдәге куркыныч җанварга ук охшый икән. Безнең төнге юлчыбызның болай да шәп булмаган кәефен ул тагын да хәртиләтә. Аны тагын да күңелсезрәк, ямансурак уйларга тарта.

Билалның монда бердәнбер кызы кала... Ул инде менә хәзер, бу минутларда: «Әти кая? Кая китте ул?» — диеп йөридер, әнисен аптырата торгандыр... Ә аның әтисе Билал менә китеп бара... Кызын калдырып китә ул. Бәгыре телгәләнсә дә, тешен кысып түзә-түзә, китеп бара.

Монда аның дуслары да кала. Эшендәге фикердәшләре, иптәшләре... Аларга үзенең китүен әйтеп тә тормады Билал. Кан кызган чагында шулай килеп чыкты инде: иптәшләрен кисәтүне кирәксенмәде. Ә дөресен генә әйткәндә, үз күңелен, җанын аңлап бетүләренә шикләнде Билал. Аңлап бетермәстән, үзенә каршы төшәрләр дип уйлады. Шуңа күрә аларга әйтеп тә тормады. Үпкәләрләр инде. Тик соң шул инде. Хәзер берни дә эшләп булмый!

Әнә поезд да кузгалырга итенеп, кымшана башлады. Билал да баскан урыныннан купты, портфельне кулга алды. Бүтән кеше күренмәгәч, тышкы ишекне дә аның үзенә ябарга туры килде. Әнә шул авыр тимер ишекне шапылдатып ябуы — үзенең ничә ел гомер иткән шәһәре белән саубуллашу да булды. Шулай итеп, төнге юлчының төнге сәфәре башланды. Ул вагон эченә үтте.

Хәзер инде Билалга үз купесын табарга һәм тизрәк кереп ятарга, онытылырга, ял итәргә кирәк иде...

Менә беренче купе. Икенчесе... Аның билетына «тугызынчы урын» диеп язылган, димәк ул шушында, өченче купеда булырга тиеш.

Анысы ярый да, тик хәзер кеше йоклый торгандыр бит инде. Борчымый гына ничек кереп ятарга соң әле?

Аның күп төрле сораулар, шикләр белән эчтән газапланган җанына тагын бер «корт» килеп керде. «Мин монда да артык кеше, ахрысы...» — дигән шик иде ул. Моңа кадәр бер генә җирдә дә үзенә ипле, җайлы урын таба алмаган нечкә җан биредә тагын бер мәлгә шик-шөбһә дулкыны арасында калды.

Бераздан, үзен җиңеп, ишекне шакымыйча гына тартып карарга булды. Шудырмалы ишек бәлки әкрен генә ачылып та китәр әле...

Бик тә иплән кенә, бик зур саклык белән генә, тотканы әз генә дә кыймылдатмыйча, башта аңа ябышты гына ул — шылт иткән тавыш та чыкмады. Аннары, берәр минут чамасы шулай торгач, бик акрын гына ишекне уң якка таба этеп карады. Билалның бәхете — ишек төнгә бикләнмәгән булып чыкты.

Бик тар гына ачылган ишек ярыгында иң башта төн уртасы өчен шактый көчле тоелган яктылык күрде Билал. Бу аны бик тә гаҗәпләндерде. «Төн уртасында нишләп әле ут яна соң?» Билгеле инде, моның ише очракта сыңар күз белән генә карамыйча булмый. Билал да шулай итте — ишеккә таба иелә төште, эчкә күз салды... һәм... шактый аптырап калды.

Эчтә, уң яктагы сәкедә, яшь кенә бер ханым китап укып ята иде... Юка ак җәймә аның гәүдәсен яртылаш кына каплаган. Ачык яшел төстәге халаты аның зифа буен һәм күкрәкләрен яшерә алмаган. Ханым мендәрен терсәк астына салган да, кырын яткан килеш шуңа таянып, нииндидер китап укый... Күрәсең, ул китап дөньясына шактый тирән чумган — аны бәхетле бер тойгы, серле бер халәт биләп алган... Әнә шул көчле тойгы кочагында бу яшь ханым бөтенләй эреп беткәнгә үк охшый. «Хатын-кызны китапта бары тик мәхәббәт кенә шулай мавыктыра аладыр», — дип уйлап куйды Билал секундның меңнән бер өлеше эчендә.

Аннары инде күзе өстәл өстенә төште. Ачылган коньяк шешәсе, юлда чәй эчә торган стаканнар һәм тагын әллә нинди затлы-затлы савытлар иде анда. Конфетлар, печенье, ипи, ит кисәкләре дә күренә.

«Тукта, ә сул як сәкедә кем соң? Билал карашын җәһәт кенә шунда юнәлтте. Икенче сәкедә дә хатын-кыз иде. Ул, биш-алты яшьлек баласын кочаклаган да, башын артка ташлап, тыныч кына йоклый бирә.

«Әйе... бик тә кызык хәлгә эләктем бит әле мин... Бүген Вахитлардагы бер эчү мәҗлесеннән качып котылдым дигәндәинде монда икенчесенә килеп кабам түгелме соң?! Бу дөнья гел эчүдән һәм ызгышлардан гына торамы соң әллә?!»

Әмма үз шәһәрен һәм андагы үз фатирын ташлап китеп баручы безнең төнге юлчыбызның бирегә — үз купесына керми хәле юк иде инде. Ул ишекне кирегә тартып, янадан ябып куйды да, әле генә ишек төбенә килеп баскан кеше төсле, акрын гына шакыды.

Беренче шакуга эчтән тавыш бирүче булмады. Билалның кыенсынуы, чыннан да, бик көчле идеме, әллә теге ханым укый-укый йоклап ук киткән булдымы — һәрхәлдә, ишекне ныграк итеп янадан шакылдатырга туры килде.

— Әйе, әйе, керегез!

Күрәсең, ханым аның беренче шакуын да ишеткән, ләкин нигәдер көттерүне кирәк тапкан, яисә укыган дөньясыннан аерылып өлгерә алмаган. Югыйсә, тиз генә арада шундый матур, чиста тавыш белән җавап бирә алыр идемени?!

Кулындагы иләмсез портфелен тар гына булып ачылган купе ишегеннән көчкә сыйдыра-сыйдыра Билал эчкә үтте. Аскы сәкеләрдә буш урын тапмагач, әйберен өскә — сул як киштәгә куярга туры килде. Аның астагы үз урынын алганнар иде.

Ул купега килеп кереп әллә ни күп хәрәкәт тә кылырга өлгермәде — ләкин шул арада да сизеп, тоеп торды: ханым сәер бер елмаю белән Билалның һәр кыймылдавын күзәтеп ята. Бераздан ул иплəп кенә әйтеп тә куйды:

— Сез бер дә кыенсынмагыз... Бу сезнең үз купегыз бит. Тик менә без генә... сезнең урынны алганбыз ахры, шулаймы?

— Ә, юк-юк, анысы өчен борчылмагыз,— дигән булды Билал, ханымга таба борылып.— Мин түбәнге урынны барыбер сезгә биргән булыр идем.

— Рәхмәт инде, алайса. Туктале, мин торыйм әле. Югыйсә болай сезгә дә уңайсыз бугай.

Ханым халатын рәтли-рәтли торып утырды, ябынып яткан җәймәсен почмакка табарак этеп куйды. Төнге зәп-зәңгәр тәрәзә фонындагы бу зифа сын ниндидер әкияти тәэсиргә ия иде. Аның әле тәртипкә китерелмәгән чәчләрендә, мендәр рәхәтлегеннән аерылырга өлгермәгән бөтен тәнендә менә шул төн уртасы серлелеге белән кушылган, көчәйтелгән сихер, тылсым, күз буу хикмәте тулы иде. Күрәсең, хатын-кыз төнлә генә, әле аның да билгеле бер сәгатьләрендә генә шуның кадәр сихергә ия була ала торгандыр инде...

Ниндидер бер мизгелдә аларның күз карашлары очрашты. Гаять тиз арада, акыл ирешә алмаган әллә нинди бер сүзсез сөйләшү булып узды. Һәм, Билал ни эшләргә белмичәрәк калган бик кыска мизгелдә, яшь ханым гаҗәеп бер экчерсезлек белән:

— Әйдәгез, танышыйк — мин Нина булам! — диде. Билалга таба назлы гына итеп кулын да сузды.

Кыю иде бу ханым! Төн уртасында килеп чыккан бу очрашу үзе дә төш белән өн арасында кебек иде.

Менә шушы хәлнең чынлыгына инанырга теләгәндәй, Билал аның кулын учына алды. Иялəнелгән гадәте буенча нык кысып җибәрүдән куркып кына, ләкин шул ук вакытта бу матур затка җавап та бирә алырлык итеп кысты ул аны... Ләкин өнме, төшме икәнне һич тә аңышмады шикелле.

Үз исемен әйтергә кирәклеге дә соңыннан гына башына килде аның. Байтак вакыт узгач кына:

— Ә мин Билал исемле! Сезне төн уртасында борчып йөрүче адәмнең исеме шулай була,— диде ул, бераз каударлана төшеп.

— Соң, нинди комачаулау булсын инде бу. Без дә йомыш белән йөрибез, сез дә тик дуамалдан гына төн уртасында юлга чыкмагансыздыр инде. Әйдәгез, кыенсынмагыз, менә монда утырыгыз...

Ул Билалга үзе белән янәшәдән диярлек урын күрсәтте. Билал теләсә дә, теләмәсә дә җәелгән урынга утырырга мәҗбүр иде инде. Сәгатьләр буе аяк өсте йөреп, поезд көткән кеше мондый йомшак, уңайлы урыннан ничек баш тарта алсын соң?!

Аннары — купедагы берданбер буш урын бит әле бу. Калган бөтен җирдә чемоданнар, сумкалар... Шулай булгач, инде тагын кая утырасың!

Салкыннан соң әнә шулай җылыга да килеп эләгә икән кайчак адәм баласы!

## III

Билал үзендәге аруны, ят ханым алдындагы кыенсынуны җиңәргә тырышып утыра, ә Нина һич нигә исе китмичә, җай гына сөйли бирә:

— Халидә белән бергә эшлибез без...— Ул, сизелер-сизелмәс кенә ым ясап, йоклаган ханымга таба күрсәтте.— Менә, бер атнага ял алдык та, Төмән өлкәсендәге дус кызыбыз янына барып кайтабыз әле. Бик матур җирдә, тайга уртасындагы поселокта яши ул анда. Мин аңа баргалап йөрим. Минем ир кәмәшем каршы иде, билгеле. Әмма, бәхеттән, әни килде. Ә минем карт кеше алдында бик тә тату күренергә ярата ул!.. Шәп сыйфат бит, әйеме?!. Тик сез аны бик тәкъва кеше икән дип уйлый күрмәгез тагын,— шактый югары постта утыра ул...

Билал үзе белән әле генә танышкан бу ханымның шулай тиз арада ачылып китүенә гаҗәпләнеп тә куйды. Ирен дә өнәми генә телгә алды бит әле шул арада... Хәер, нишләп миннән шикләнеп торсын соң инде ул! Мин аңа кем соң! Җиде ят бер кеше бит... Бүтән җирдә гомергә дә очрашмаячак, күрешмәячәк, очраклы бер юлдаш кына бит мин аңа...

Тукта әле! Әллә хатын-кызның барысы да шундыймы соң югыйсә? Үз хатыны Галия дә аны кешегә гел хурлап сөйли иде лә. Имеш, Билал йорт турында бөтенләй уйламый. Имештер, ул Галиягә дә тиешенчә игътибар бирми. Аны кирәгенчә кадерләми. Бәһасен белми аның, янәсе.

Шул хакта чит-ятлар Билалга җиткергәч, күңелгә бик авыр була иде. Галиянең күңеле белән аннан канәгатьсезлеге түгел, ә бәлки гаиләдәге хәлләрне җиде ятларга сөйләп йөрүе бәгырьне телгәли иде. Әгәр дә Галия үзе моны аңлый алса — кешегә сөйләп йөргән шул сүзләре белән ирен үзеннән ничек ерагайтуын белә, төшенә алса иде...

Менә монда, Нина белән сөйләшеп утырган вакытта, шулар искә төште дә — Билалның күңел кояшын бер мәлгә тагын болыт каплап алды. Аннары, күңелсез уеннан котылу өчен генә, Нинага сорау биргән булды:

— Мәскәү каласы ни хәлдә яшәп ята соң?

Сөйләшә-сөйләшә Нинага таба да борылды. Аның күзләренә дә карап алды. Зур күзләр, чиста зәңгәр күзләр — тыныч кына карап тору мөмкин булмаган күзләр иде алар!

Нина аның кыюсыз гына карашын, әлбәттә, бер секундта ук сизеп алды, ләкин үзе тиз генә күтәрелеп карамады. Яңа танышын үзенә бераз ияләндерү идеме бу, бөтен чибәрлеген күздән үткәрергә юл кую, рөхсәт бирү идеме, әллә бөтенләй безнең башыбызга да килмәгән бүтән бер нәрсә идеме — ничек кенә булмасын: аның бөтен кыланышы ипле, табигый, ягымлы килеп чыга... Эчендә җаны булган адәм аңа битараф калырлык түгел иде.

Билал да тора-бара Нинага ешрак күз салды. Аның баштагы кыенсынуы әкренләп бетә барды. Ул кыенсыну урынына эчкә ниндидер җылы

хис, инде байтактан бирле татылмаган рәхәт, ләззәтле тойгы тула, җыела бара иде. Моны, әлбәттә, әллә нинди нечкә җепләр аша Нина да бик яхшы аңлап утырадыр, ләкин тыштан ул берни дә сиздерми. Бары тик тагын да ягымлырак тавышлы, назлырак карашлы, йомшаграк хәрәкәтле генә була бара...

Билал сирәк-мирәк бер-ике сүз кыстыргалап куя. Нина исә күбрәк үзе сөйли, үзе ачыла. Әйтерсең, менә хәзер Билал күз алдында ямь-яшел болыннан бер зәңгәр чишмә бәреп чыкты да, шул чишмә туктаусыз челтер-челтер ага, җырлый... Гүя Билал шуның йомшак чирәмле ярында искиткеч рәхәтлек кичереп утыра. Күптән күрелмәгән рәхәтлек кичереп.

Инде ничә айлар буена аның күңелендә кайнаган ачу, аптырау, әрнү хисләре бер мәлгә артка чиккәндәй булды. Эшендәге күңелсезлекләр, гаиләсендәге туктаусыз гауга — һәммәсе соңгы айларда Билалны никадәр талчыктырган, талкыган, тәмам туйдырган булса — һич көтмәгәндә килеп чыккан менә бу очрашу да ир-ат җаны өчен шулкадәрле үк тансык иде.

Шәһәр шау-шуыннан һәм ыгы-зыгысыннан нишләргә дә белми аптыраган адәм баласы, әйтерсең лә, һич уйламаганда җиләс урман эченә килеп керде дә, бер мәлгә элеккеге дөньясын онытты, урманның шифалы саф һавасын ләззәтләнеп сулый башлады.

«Кара әле, — дип үз-үзенә ачыш ясады шунда Билал. — Инде ничә ел буе минем менә шулай ихлас сөйләшеп, ял итеп утырганым да юк икән бит! Гел эш мәшәкате белән һәм гаилә ыгы-зыгысы эчендә үткән икән бит гомер соңгы арада».

Менә шушы уена ялганып ук диярлек күңеленә кызык бер чагыштыру да килде. Хатыны Галия белән шушылай иркенләп, җай белән генә рәхәтләнеп сөйләшеп утыра аламы соң Билал? Аның янында шушылай җаны-тәне белән туарылып, бөтен дөнья ыгы-зыгысын онытып, күңеле белән ял итә аламы ул?

Әйе, безнең бик күбебезнең бәхетсезлегенә күрә, бирергә уңай җавап килеп чыкмый шул. Билал белән Галиянең мөнәсәбәте, үзара сөйләшүләре дә күңелсез көнкүреш кысасыннан ерак китә алмый. Җитмәсә әле үзара гаепләшүләр, үпкә-сапка гел өстәлә, чүп өеме үсә тора... Кая инде анда хисләр, кая инде анда җан тартылу, күңел очыну!

Ә менә Нина бер мизгелгә артта кала барган яшьлеген искә төшергән төсле булды. Көзгә калып туңган күбәләкне, гүяки, җылы бүлмәгә алып кerделәр дә, әйтерсең лә, ул күбәләк менә хәзер: шунда, күз алдында ук, үзенең матур канатларын күтәргәли, тибрәндерә башлады. Очарга, өскә таба күтәрелергә итенә башлады... Билалның йөрәге дә әнә шул күбәләк хәлендә иде. Салкыннан соң ул кинәт җылыга килеп эләккән иде. Күңел, җан җылысына. Хатын-кыз җылысына!

— Менә, юлга чыккач кына Халидәнең туган көне икәне исебезгә төште әле... Башта, Түмәнгә барабыз дип җенләнеп йөреп, бөтенләй онытканбыз да! Әйдәгез, Мәскәү эчемлеген сез дә авыз итегез булмаса.

Нина йолдызлы савытны аңа табарак кузгатып куйды. Аның пешкән чия төсендәге маникюрлы бармаклары шулчакны пыяла савыттагы йолдызларга кушылып елтырашты. Әйтерсең, Билал каршыннан бихисап күп һәм тирә-юньгә ут, ялкын сибүче йолдызлар өермәсе узды.

Юк, Билал артыгын кыстатырга һич тә яратмый. Гомумән, кешенең иң әйбәт гадәте дип — аның табигыйлеген, үзен бервакытта да, беркем алдында да кочләп һәм ясалма кыяфәттә тотмавын исәпли. Әнә шуны ул иң дөрес яшәү дип саный. Теге яисә бу кешенең ихласлыктан качуын да ул бары тик курку гына дип бәяли, ул кешенең үзенчә яшәргә хәленнән килмәү, эчке көчсезлек дип күрә.

— Әйдәгез, сезнең өчен, Нина! Сезнең менә шушы сихри гүзәллегегез өчен!

Билал үзенең теленә шундый баллы сүзләр килүгә аптырый төшеп,— шәрабнең илһам китерә диюләре хак инде әллә,— төбенә әз генә, матур итеп кенә эчемлек салынган стаканны Нинага сузды. Хатын аны нәфис бармаклары арасына килешле генә итеп бастырып куйды. Аның бераз кыстату исәбе дә бар төсле иде... Ул ашыкмый, көтә иде. Соң, әлбәттә, Билал кыстарга тиеш иде инде аны... Бүтән кем булсын?!

— Безнең танышу хөрмәтенә була инде бу, Нина ханым... Шушындый матур итеп танышу бик сирәк буладыр әле ул! Уйлап кына карагыз: Төн. Безнең поезд шау-шулы Европаның үзәгеннән килеп, ерак төньякка китеп бара... Цивилизацияле Европаның уртасында яшәп тәмам туйган, аның шау-шуыннан, төтен-корымнан, ясалма матурлыгыннан интеккән адәм балалары икенчерәк, табигыйрәк тормыш эзләп бүтән якка, икенче материкка ашкыналар...

Билал уйнап-шаярып кына башлаган тост сыманрак сүзен әйтә-әйтә, үзе дә сизмәстән, эчендәге уйларына кереп киткән икән. Сөйләп бетергәч кенә искәреп алды... Зәп-зәңгәр тәрәзәгә карап әйткән икән ул үзенең ялкынлы монологын... Шуннан соң күзен кинәт Нинага күчергән иде — мәңгелек түгеләм дип торган, түгелеп китү өчен бары тик бер генә тамчы хис көткән ике зәңгәр ут күрде... һәм шунда, үзе дә әллә нинди тыныч, ипле, сабыр тавышка күчеп:

— Әйдә әле, Нина...— диде... Ә күзе аерылмаслык булып әлеге ике ут учагына ябышкан иде инде...

Нина — Мәскәү хатыны — кайчан кыстатырга, кайчан кыстатып тормаска икәнлеген яхшы белә иде булса кирәк: савыты төбендә бик юка гына катлам калдырып, матур гына итеп уртлап алды ул... Билал конфет сүтеп, аның кулына бирим дигән иде дә, Нина әле савытын куймаган, кулыннан җибәрмәгән икән — аның бармаклары назлы гына булып өстәл өстенә таралганнар, ә алар арасында матур бер күренеш хасил итеп алсу балкышлы савыт утыра... Нина үзе дә, чак кына иелә төшеп, әнә шул сәнгать әсәренә төбәлгән...

Билал кулындагы конфетын Нинаның иреннәренә таба китерде... Эчемлектән соң әле берни дә капмады бит... Нина аның кулы якынайганын тойды, ләкин ул кымшанмады... Шоколад конфет сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәт белән Нинаның иреннәре арасына күчте... Билалның буш калган бармаклары үзләреннән-үзләре аның битенә кагылдылар... Кап-кайнар иде ул... Бармаклардан соң әкренләп уч төбе дә кагылды... Шунда, Билалның учы Нинаның кайнар яңагына тулысы белән тиеп кенә өлгергән идеме, әллә юкмы, әллә инде аның учы Нинаның битенә якынаеп, сыланып кына алган идеме — шул мизгелдә Нина «Аһ...» диеп кисәк кенә борылды һәм... иреннәр үзләренең уртак ялкынына ташландылар...

— Аһ!.. Нишлибез без!.. Әгәр Халидә уянса! — Нина аннан кисәк кенә аерылды да, ашыга-ашыга шулай диде... Бу сүзләрдә акланырга теләү дә, үзенең ашыгуы өчен уңайсызлану да бар сыман иде...

Төн уртасында, төш белән өн арасындагы әнә шундый бер сәер халәттә тагын күпмедер гомер утырдылар алар. Ә Халидә уяныргa уйламый да, кымшанмыйча да диярлек, рәхәтләнеп йоклый бирә. Аның баласы гына йокы аралаш авызын чыпылдаткалап ала һәм сирәк-мирәкниндидер сүзләр әйткәләп куя.

Ә Билал исә, җылы купеда баручы Мәскәү хатыны Нина янәшәсендә озаграк утырган саен, үзен һәм үзенең хәзерге чын хәлен оныта барды. Аннан ераклаша барды. Бу дөньяда, гүя, аның яраткан кызы Раушания да юк, әйтерсең лә аның хатыны Галия дә булмаган. Әйтерсең Билал менә хәзер япь-яшь егет, буйдак кеше. Ә Нина аны тагын да әсәрләндерә, күңелен үзенә тарта, алгысыта иде.

Биш йолдызлы шешәдә инде күп калмаган иде — алар бер-берсенең күзләренә текәлгән хәлдә әллә эчемлекне, әллә бер-берсенең карашын дөньядагы иң тәмле ризык кебек итеп тагын йотып куйдылар... Бу юлы шоколадның кирәге юк иде инде.

Бераздан купелардагы утны да сүндерделәр...

Ә поезд тәгәрмәчләре ашыга-ашыга тыкылдый бирде. Ул «югары культуралы» дип даны чыккан һәм шау-шулы Европаның үзәгеннән — Мәскәүдән килеп, еракка төньякка таба чаба иде.

Бу төнге поездның караңгы вагоннарында Ниналар, Билаллар һәм тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр... Караңгы вагоннарда бер мәлгә зиһен чуала, фикер таркала. Ә кайчагында анда, караңгы вагоннарда, башлар югала, җаннар таркала...

Мәскәү ягыннан килгән поезд шул ул! Төнге юл шул бу!

..................

— Билал...

— Әү.

— Йоклыйсыңмы?

— Юк. Йокламыйм.

— Бер нәрсә сорыйммы?

— Сора... Рәхим ит.

— Синең моңарчы юлда мондый эшкә тарыганың бар идеме?

Билал бер мәлгә уйга калды — «Заманнан артта калгансың дип миннән көләргә җыенмыйдыр бит... Мәскәү хатыннарын белмәссең!»

— Әйдә, болай итәбез, Нина!

— Әйе, Билал. Мин сине тыңлыйм.

— Әйдә бүген барысын да ачыктан-ачык сөйләшәбез. Бер-беребездән бернәрсәне дә яшермичә! Чөнки сиңа минем алда кыенсынасы юк, миңа шулай ук синнән уңайсызланыр урын күренми.

— Әйдә, Билал! — Нина кискен бер хәрәкәт белән яткан җирдән башын күтәрде дә, терсәгенә таянды. Үзенең күзләре Билалда. — Башта мин сөйлимме сиңа үзем турында?!

Ул күз карашын стенага күчерде, кулын җайлабрак куйды... Аның бармаклары Билалның тәненә тиеп-тиеп алалар... Ул пианинода бик сак кына итеп моңсу да, ягымлы да көй уйнаган кебек. Гүя, аның бармаклары клавишларга кагылып-кагылып ала, ә иреннәре арасыннан ул уйнаган көй үзе чыга. Каяндыр эчтән, йөрәк түреннән үк чыга сыман ул моңлы авазлар.

## IV

— Иремә яратып чыктым мин... Байтак кына белә дә кебек идем аны. Чөнки институтның соңгы ике курсын без бергә укып бетердек. Ул заочныйдан безнең төркемгә күчте... Хәзер инде миңа ике балабыз бар. Бер кыз, бер малай үстерәбез... Кечесе дә мәктәпкә бара инде хәзер... Анысы шулай — балалар үсә үсүен, тик нишләптер минем өчен хәзер тормышның кызыгы китте. Нигә дип сорыйсыңмы? Әйтәм. Менә инде мин балаларымны үстердем, аякка бастырдым, ди. Тагын, алга таба нәрсә инде?! Җирдә үзем кебек аптыраган адәмнәр санын арттырдыммы? Минем дөньяга кирәгем шуның өчен генә идеме?! Бу гына бик аз бит... Шуңа күрә яшәүнең әлләни сере, кызыгы калмады хәзер минем өчен...

Нина ашыкмый гына, үз эченнән уйлана-уйлана, тыныч кына тавыш белән сөйли дә сөйли... Ә Билал сүз дәшми. Тыңлый бирә... Аның ихлас тыңлавын Нина да сизә. Шуңа күрә ул сүзен дәвам итә.

— Ә ирем... Ул үзенең эш мәшәкатенә чумган! Аның өчен яшәү дигән нәрсә ай саен план үтәүгә генә кайтып кала! Аның айлык планны, еллык планны үтисе бар!.. Мин аны кызганам да инде, билгеле,

мескенне... Ләкин кешегә бер генә бирелә торган «яшәү» дигән нәрсә шулай көн-төн дөнья куып, чутсыз акча туплауга гына кайтып калмаска тиештер бит инде ул! Алай гына булса — бик тә начар, лабаса!

— Нина, ә ирең синнән канәгатьме соң?..

Билалның бу соравына Нина көлемсерәп кенә куйды:

— Һе, канәгать булмыйча тагын!.. Әйтәм бит: аның хатын-кыз, гаилә мәсьәләсендә таләпләре артык зурдан түгел. Иң заманча куелган менә дигән мебельле иркен фатиры бар, эшенә иртән машина килеп ала. Кайтуга чибәр генә хатыны каршылый... Ә акча күп безнең, мин хәзер аның тәмен дә югалтып киләм бугай инде. Күп булгач, ничектер, акчаның да кызыгы китә икән аның!

Болары инде Билалга моңа кадәр ишетергә туры килмәгән сүзләр иде. Бай кеше хатынының сүзләре болар. Шулай да гаҗәпләнүен артык сиздермәскә тырышты:

— Әйе, һәр гаилә үзенчә бәхетсез, ә бөтен бәхетле гаиләләр бертөсле, дигәнме әле Толстой бабай...

Нинаны исә үз уйлары биләп алган, ул күңелен түгә бирә:

— Мин аңа бер мәртәбә әйткән дә идем — әйдә әле, аерым яшәп карыйк, дип... Күзе шар булды! «Син нәрсә! — ди.— Минем бүтән мәшәкатем беткән мәллә! — ди. Эшсезлектән аптырасаң, әнә балалар белән күбрәк шөгыльлән!» — ди... Аңа карап кына мин барыбер үз уемнан кире кайтмадым, билгеле. Минем әле бер мәртәбә чын табигать эчендә яшәп, шундый җирдә эшләп карыйсым килә! Күңелем сизә — ошар кебек ул миңа! Дус кызым янына да әнә шундый өмет белән барам әле... Әгәр дә ул риза икән, тотам да күченеп киләм балаларым белән! Иремнең сүзенә карап тормыйм! Мин бит чит телләр факультетын бетергән кеше. Поселокта берәр эш табылыр әле.

Әйе, Билал да үз яшәвендә шундыйрак үзгәреш тели түгелме соң? Ул да шулай уйлый, шулай эшләмәкче була бит... Нинаның сүзенә кушылып үз фикерен белдермәкче иде, ләкин аның әле әйтеп бетерәсе бар икән...

— Беләсеңме, Билал, уңайлы квартирада, байлык эчендә йөзеп яшәгән кеше тормыштагы иң гади, әмма иң мөһим, иң кирәк нәрсәләрнең бәһасен белми, кадерен оныта башлый икән ул!.. Менә мине генә алыйк. Мин — Мәскәүдә туып, Мәскәүдә үскән кыз. Анда инде, син үзең беләсең, болай карауга барысы да бар, барысы да җитә кебек... Әйткәнемчә, акчабыз да күп, теләгән җиргә йөреп тә кайтып була. Әмма... Әмма күңелем сизә — бу чын тормыш түгел! Кайдадыр матуррак тормыш бар, чынрак тормыш бар! Кайдадыр, нindидер әнә шундый тормыш бар! Минем, бик соңга калганчы, әнә шуны табасым, шуңа ирешәсем килә! Әнә шул чын тормышның тәмен татыйсым килә минем! Ә болай... ялган тормыш туйдырды!

Нина тынып калды. Яңадан мендәренә авышты.

Билалны да уйлар биләгән иде. Нина турындагы уйлар. Үзенең инде айлар буена башыннан чыкмаган чуалчык фикерләре... Тик менә хәзер аларның барысын да ничек итеп тиз генә сөйләп, аңлатып бетерәсең?! Әле күбесенә үзең дә төшенеп җитмәгән нәрсәләрне... Шулай да сөйләмичә булмый.

— Ә мин генә гаиләмне ташлап китеп барам, Нина... Дөрес, әлегә бер генә айга, ялга диеп кенә китәм... Ләкин кире анда кайтып яшәүне күз алдына китерә алмыйм инде мин... Эштә дә күңел үсми хәзер. Анда да, алла белсен нәрсә икәнен!

Билалның сүзләрен Нина йөрәгенә бик якын кабул итте, ахры.

— Әй, мескенем... Син дә шул хәлдәмени соң? Өстәвенә балагыз да бардыр бит әле?

— Бар шул... Җиде яшьлек кызым бар.

— Аны ташлап китә алам дип уйлыйсыңмы?!

— Моңа кадәр аерылмый яшәвем дә шуның өчен булды инде.

— Белмим, белмим — озак түзәрсең микән! Син бик бала җанлы, нечкә күңелле кешегә охшагансың.

— Тукта әле, Нина, син дә күңелне нечкәртмә әле! Күңел, күңел диеп, болай да күп җәфа күрәм инде мин... Әнә шул күңел белән тиз алдандым, тиз әсәрләндем дә инде!.. Хәзерге акылым булса, мин хатын-кызларның да, ир-атлар сыман ук, гап-гади кешеләр икәнлеген белер идем... Аларның да әйбәт күңелләре һәм каты күңелләре, таш бәгырьләре булганын аңлар идем... Хәзер инде тышкы матурлык кына миңа бөтен хатын-кызны да матур итеп күрсәтмәс, үзенә баш идермәс иде...

Билал үз эчендәге бөтен ачуы, дөньяга карата моңарчы җыелган ниндидер үче чыга баруын тойды, ләкин моңа кыенсынмады, сүзен дәвам итте:

— Мин дә яратып өйләнгән төсле идем, Нина... Аның тәрәзәсе төбендә сәгатьләр буе басып тора идем. Кинолардагы сыман серенадалар сузарга әзер идем... Ләкин... Ләкин ул чагында мин бит аны бөтенләй аңламаганмын икән... Бары тик фасадына, тышкы кыяфәтенә генә алданганмын икән... Миңа — әле хатын-кыз дөньясында тәҗрибәсез кешегә — аның кем һәм нинди кеше булуы түгел, ә, гомумән, хатын-кыз булуы, ир-атны тартучы зат булуы тәэсир иткән икән! Мин шуны гына күргәнмен.

— Йә, шуннан ни әйтмәкче буласың инде...

— Берни дә... бары тик уйланам гына... Мин монда сиңа сөйләүгә караганда күбрәк үзем аңлап җитәргә телим әле нәрсә булганын... Ялгышым нәрсәдә булды икән дим?

— Син, Билал, үзеңнең иң төп сүзеңне һаман әйтмисең әле... Нишләп соң син хатыныңнан риза түгел? Сиңа нәрсә җитми?

— Мин аның күңел тупаслыгыннан, тышкы матурлык астындагы эчке ямьсезлегеннән җәфа күрәм бугай... Мин хатын-кыз маскасына төренгән кешелексезлекне аера алмаганмын әлек... Тышкы матурлыкның кибет витриналары һәм күргәзмәләр өчен генә яратылганлыгын аңлый алмаганмын икән мин ул чакта!..

— Әйе, мин сине аңлыйм кебек... Синдә дә әзрәк... максимализм дип әйтимме, бар икән. Без үз якыннарыбызның үзебез өмет иткәнчә булуларын телибез бугай... Ләкин мин, үз иремнең үзгәрәчәгенә инде ышанмыйм! Чөнки... Чөнки бөтенләй икенче холык бит анда! Кеше ничек шуның кадәр үзгәрә алсын инде, әкият!

— Максимализмның катнашы юк монда, Нина! Мин сиңа үз башымнан үткәнне генә сөйлим!

— Барыбер инде: сиңа күңел дөньялары түбәнрәк булган кешеләр ошамый, аларның эчке ярлылыгы ошамый... Әнә шул нәрсә синең теңкәңә тия адым саен! Ә үзең син рухи яктан каядыр югарыдарак яшисең...

— Бусы салпы якка салам кыстырудыр инде аның — шулай бит? Ләкин моннан гына хәл үзгәрми шул!

— Аннары бит әле, Билал, мәсьәләнең менә бу ягы да бар: кеше белән кеше беркайчан да охшаш була алмый бит! Табигать бит ул, дөнья бит ул...

— Шулай шул, теория һәрчак җиңел ул... Аннан әллә нинди матур фикерләр китереп чыгарырга мөмкин.— Билалның тавышында кырыслык чагылып китте. Моны Нина да шундук сизеп алды һәм:

— Ярар, шактый нәрсә ачыкладык бугай, инде әзрәк ял итеп алыйкмы әллә?— диде.

Алар йокыга киткәндә тәрәзәдә инде таң беленә башлаган иде.

... Иртән барысыннан да алда Билал уянды.

Ә уяну белән башына килгән иң беренче уй шул булды — ничек болай килеп чыкты соң әле? Һич тә көтмәгәндә, уйламаганда...

Хастаханәдә, операциядән соң наркоздан айныган чагында шулай әкрен генә әрнү, авырту тоя башлыйсың... Билал да үзендә шуңа охшашрак халәт сизде. Ул да тылсымлы исерүдән соң ушына килде, әчтә, бик тирәндә нәрсәнеңдер сыкрап авыртуын сизде...

«Әй-яй-яй... Кайчандыр үзем бик тә нык ышанган мәхәббәтне шушындый вакытлы очрашуларга алмаштырырмын диеп уйлаган идеммени соң мин?!. Минем өчен бик тә изге хис иде бит ул... Ә чынлыкта менә ничек килеп чыкты.

Әнә шундый җан әрнү хисе белән бергә үк диярлек аның күз алдына кызы Раушания килеп басты. Килеп басты да, һич кенә дә китмичә, кымшанмыйча Билалның күзләренә карап тора башлады. Текәлеп-текәлеп!

Юк, бу аның кызы Раушания генә түгел иде бугай...

Бу — Билалның моңа кадәр килгән намуслы яшәү юлы иде. Бу — шушы көнгә кадәр нык сакланган әхлак-әдәп кануннары иде. Бу — Билал шәхесен тотып һәм саклап торган бер эчке үзәк иде.

Көнбатыш яктан, Мәскәү каласыннан килгән төнге поезд һәм андагы төнге чибәр хатын безнең Билалның башын әнә шундый тәшвишле уйларга салды.

Билал иртән үзен битәрләде, яшь хатын-кыз сихере белән күзгә-күз очрашкач, тыелып кала алмауда гаепләде. Салкын акыл саклап кала алмауда һәм тагын әллә нинди гөнаһларда үзен гаепле санады.

Мондый уйлар куерып китеп, аның бәхетсезлеген тагын да арттырды, аны эчтән көчсезләндерде.

Инде хәзер эшендәге җитәкчесе дә аны дөрес ачулангандыр кебек иде. Билалның: «Архитектурада бары тик сәнгать кануннары гына хакимлек итәргә тиеш!» — дип йөрүләре дә буш сүз генә сыман иде. Билалның әнә шуның өчен күпме көрәшүе — ихлас булмаган, чын күңелдән булмаган кебек иде.

Әле кайчан гына эшендәге зур түрә белән бик тә ышанып югары сәнгать өчен көрәш алып барган Билал менә хәзер, бер ялгыш адым нәтиҗәсендә, төпсез коега очты кебек. Бүтән өскә менә алмаска, күтәрелә алмаска!

Әйтерсең лә, Билал менә шушы сәгатьтән башлап, хәзер җир корты дәрәҗәсендә генә, югары интеллектуаль тормышны онытып, бары тик физик яшәү яссылыгында гына тереклек итәргә тиешле иде! «Дөньяның асты өскә килүе — шулдыр инде, күрәсең» — дип зур һәм гаять күңелсез нәтиҗә ясагандай булды Билал.

Ә бераздан аның башында бүтән төрлерәк уйлар да җилпенде:

«Йә, әйт әле, бу очракта бүтәнчә эшли ала идеңме соң син?! Син үзеңне чын тормыштан аерып, нindидер бер кирәксез, ясалма кыса эченә кертеп бикләмәкче түгелме соң?! Андый ясалма кыса эчендә яшәү, көн күрү, ул мескен һәм кызганыч кешеләр язмышы гына түгелме соң? Син андыйлардан үзең үк көлә идең ләбаса!»

Әйе, иртән иртүк Билалны чолгап алган уйлар тиз генә котылырдай түгел иде. Инде моңа кадәр дә үз кайгысыннан башы каткан Билалга бу төн шулай итеп тагын яңа сораулар, катлаулы уйлар өстәде. Аларга җавап таба алмыйча газапланган Билалның башында исә бер генә фикер: «Барысыннан да котылырга — китәргә, качарга!» — дигән уй гына чәбәләнде.

Аскы сәкедә Мәскәү хатыны Нина рәхәтләнеп ял итә.

Күрше сәкедә Халидә баласын кочаклаган килеш йоклый.

Ә кара шәүлә төсле поезд, дөбер-шатыр килеп, Көнбатыштан Көнчыгышка таба ашыга...

# Якты күл

## I

Икенче көнне кичкә кадәр дә Билал үзенең төнге юлдашлары белән барды әле... Хатыннар берөзлексез диярлек Мәскәү хәлләрен сөйләштеләр, андагы уртак танышларын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыктылар.

Ә Билал күбрәк тәрәзәгә карап утырды. Сүзгә сирәк катышты. Хәзер инде аның башында барысы бергә буталган иде. Эшендәге низагка һәм гаиләсендәге гаугага менә бусы да килеп өстәлде бит әле. Һич тә уйламаган җирдән Билал шәһәр хатыннарының «мәхәббәт маҗарасына» килеп капты бит әле. Бу хәлдән соң инде хәзер Билалны битәрләүчеләрнең сүзе дә дөрестер сыман иде. Алар хаклыдыр кебек иде.

Бары тик күз карашлары Нина белән очрашкан чакларда гына ул аннан озак аерыла алмый карап торды. Аның кем икәнен аңларга теләгәндәй... Ә Нинага нәрсә — аңа рәхәт, аңа күңелле!

Билал төшәсе тукталыш тагын төнлә булачак икән! Моны әйткәч кызлар көлешеп тә алдылар:

— Сине безгә төн биргән иде, төн үзе ала да... Әллә төш кенә булды инде бу!

Төнге сәгать бер тулып килгәндә Билал поездан төшеп калды... Аңа хәтле алар бер җаен турып китереп, Нина белән адреслар алмашмакчы иделәр — әмма икесе дә шаккатты: икесенең дә әлегә ныклы адресы юк икән бит! Шулай да Нина үзе бара торган дус кызының адресын әйтте. «Бәлки, син дә килеп чыгарсың әле...» — дип, өстәп тә куйды җитмәсә.

Билал да үзе бара торган ял йортының адресын язган булды. Аның бердәнбер урыны шул бит инде хәзергә.

... Менә, ниһаять, «Якты күл» тукталышы. Вокзалы да бик кечкенә икән. Билал, вагондагы танышлары белән тиз генә саубуллашып, перронга төште. Аннары, поезд киткәнен дә көтеп тормастан, эчкә үтте. Көтү залы да бик бәләкәй икән моның. Унлап кына диван куелган. Алары да искеләр — тырналып, уелып беткәннәр, әллә нинди сүзләр язылган. Билал әзрәк чистарагын сайлап, иң почмактагысына барып ауды. Аның кергәнен искәрүче дә булмады шикелле.

Бераз утыргач исенә килеп, портфеленнән пинжәген тартып чыгарды. Аны диванга җәеп салып, шуның өстенә ятты. Әмма болай гына каты иде — ул тиз генә җайлап ята алмады: боргаланды, сыргаланды, әллә ничә тапкыр торып та утырды... Шулай шактый изалангач кына онытыла алды, йокыга китте.

... Искиткеч бер рәхәтлек, хәтта, әйтергә мөмкин, ниндидер наз, иркәләү тоеп уянды ул. Инде күптән татылмаган рәхәт тынычлык, әйтерсең, моңарчы җыелып килгән дә менә шушы уяну вакытына гына бирелгән. Әйтерсең, бу — җир йөзендә озак җәфаланып йөргән адәм баласының ниһаять яңадан бәхетле һәм иркен булып уянуы!

Баксаң — инде шактый югары күтәрелергә өлгергән кояш нурлары төшкән икән аңа! Кояш аны үзенең мәрхәмәтле кочагына алып иркәли икән... Әнә шуңа күрә Билалга рәхәт икән...

«Әллә минем тормышның бәхетле дигән өлеше менә шушы иртәдән башланып китә микән?» — бу адәмнең күңеленә шундый уй да килде. Чыннан да — яшь, тормыш дәрте ташып торган егет менә шушындый гүзәл иртәдә ничек инде үзен бәхетсез сизәргә тиеш?! Башы исән-сау, күңеле изгелектә, бөтен барлыгы дөньяга мәхәббәт белән тулы — мондый кеше гаиләм таркалды дип кенә кара көеп йөрергә тиешмени соң!

Шулай булгач — менә бу кояшлы көннең үзе сыман балкысын әле ул! Шушы тыныч, матур иртә бәхетен кичерсен! Мондый иртәләр алар

үзләре — бик зур бәхет, үзләре бик олы байлык бит! Без, тыныч тормышка артык иялэнеп, артык күнегеп киткәнбез дә, бу матур иртәләрнең чын кыйммәтен белеп житкермибез... Безгә һаман нидер житми, һаман нидер кирәк... Ә менә кешенең, яисә, алла сакласын, кешелекнең тормышында нинди дер зур бәхетсезлек, күңелсезлек килеп чыксын — ул чагында инде кайдадыр еракта, артта калган теге матур иртә иң зур бәхет булып тоелачак! Кешегә, кешеләргә барысыннан да кадерле истәлек, хатирә булып искә төшәчәк ул!.. Нинди дер зур күңелсезлеккә тап булгач кына матурлыкның, рәхәтлекнең чын кадерен белә ала торган адәм баласы, шулай итеп, үзенең үткән гомере кырыннан чәчкә җыйгандай, иң матур көннәрен, иң бәхетле сәгатьләрен җыячак... Җыячак та, иң гүзәл букет сымак итеп, үзенең йөрәк турысына күтәреп — аңа озак, бик озак карап торачак... Сокланып, баш иеп, сагынып, тагын бер кат шуларны яңадан кабатлыйсы килеп карап торачак ул аларга — үзе кайчандыр кичергән бәхетле көннәргә, бәхетле сәгатьләргә!

Әнә шундый якты уйлар килеп, Билалның йөрәк ярасы сызлавын беразга булса да бастырды, башындагы борчулы уйларын оныттырды кебек. Кызы Раушания исенә төшкәч тә Билал, «әнисе янында бит әле...» дип үз-үзен сабырлыкка өндәде.

Соңгы көннәрдә күпме җан газабы кичергәннән соң инде, ниһаять, бераз ял итәргә теле иде ул. Ялны бик тә сагынган иде шул.

Вокзал янындагы мәйдан ындыр табагы кебек, зур, иркен икән... Якын-тирәдә бер-ике катлы өйләр... Әнә мәйданның аргы почмагында автобуслар да тора... Билал салмак кына адымнар белән шуларга таба юнәлде.

«Ял йорты» дип маңгаена ук язылып куелган автобус әллә кайдан күзенә ташланды. Шәһәрдә күнегелгән гадәт буенча, үзе дә сизмәстән, йөгерә үк башлады Билал. Автобус тирәсенә җыелган халык:

— Ашыкма, ашыкма, әле бүтәннәрне дә көтәбез! — дип тынычландырды аны.

... Юл асфальт иде, ул бик матур каен урманын ярып узган. Юлы шәп булгач, автобусы житез элдертә, иртәнге юлда әле машиналар да очрамый диярлек... Ян тәрәзәләр яртылаш ачылып куелган. Күкрәкләрне рәхәтләндереп урманнан саф, салкынча һава керә...

Чынлап та матур шул! Тоташ урман бит — ап-ак һәм ямь-яшел төстән генә торган каен урманы! Дөньядагы урманнарның иң гүзәле булган каен урманы! Аклык, зифалык, нәфислек, чисталыкны мактауга багышланган җыр шикелле.

Шул мизгелдә, нинди дер серле бәйләнеш аша, аның уйларына кызы Раушания килеп керде... Ә-ә-ә... бәлки шуңадыр — ул бит төсле буяулар белән ямь-яшел каен агачын ясарга ярата иде... Һәм ни өчендер үз рәсеменең астына балаларча кәкре-бөкре итеп, утыртма хәрефләр белән «Ак каен» диеп язып куя иде. «Каен» диеп кенә, авылча гади генә әйтергә өйрәнгән Билалга бу бик кызык тоела иде.

Әйе, ел саен яз җитү белән алар шәһәр читендәге каенлыкка йөри башлыйлар иде шул. Кызын агачлар танырга да шунда өйрәтте бугай инде ул. Күрәсең, шул вакыттагы язгы каеннарның аклыгына, чисталыгына сокланып Билал үзе башта «ак каен» дигәндер инде. Кызы шуннан исендә калдыргандыр...

Автобус тәрәзәсе артында ак каеннар йөгерешә... Алар арасында кечкенә кызы Раушания дә бар төсле... Ак каеннар белән бергә ул да кала, артта кала, еракта кала төсле...

Бу уйлардан соң иртән йокыдан уянганда сизелгән чиксез бәхет тою хисе ничектер бәләкәйләнеп, кечерәеп калды...

Күңеленә тула башлаган моң ташкынына артык ирек куймас өчен Билал күзен тәрәзәдән алып, автобус эчендәгеләрне күзәтергә тотынды... Иң алгы урындыкка берәү дә утырмаган икән — әйе, урын күп шул,

иркенләп урнашырга була... Әнә, яшьләр, сул як рәттәге икенче урындыкка утырган егет белән кыз ничек матур итеп баралар. Кызы егет кочагына ук кереп беткән, күзләрен ярым йомган, үзе бәхетле елмая. Егете исә уң кулы белән йомшак кына итеп аны кочаклаган, сул кулының терсәге белән ачык тәрәзә рамына таянган...

Алардан артта тагын буш урын... Анда ике зур чемодан гына куйганнар... Әнә, ул чемоданнарның хуҗалары — ике ир-ат иплэп кенә нәрсә турындадыр сөйләшеп баралар. Аларның да күзе тәрәзәдә, урманда.

Билал үзе утырып барган рәтне күзәтә башлады... Менә аның алдында гына бер абзый белән карчык... «Кара әле, болар да ял итәргә бара микәнни?! Кызык! Бу яшьтә ял йортына йөрү бик сәер түгелме соң ул?!»

Ул да түгел — Билалны тәмам шаккаттырып — әлеге абзый ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән татарча җыр да көйләп җибәрмәсенме! Җыруның да ниндиен әле:

> Туган ягым гөл арасы,
> Үзем авыл баласы...

Абзыйның үз күңеле булганчы җырлап бетергәнен көтте дә, иплэп кенә сүз кушты Билал:

— Бабай, әллә син дә ял йортына барасыңмы?

Бу тирәләрдә татарча эндәшү аның өчен ят түгел иде ахрысы — абзый бер дә гаҗәпләнмичә генә аңа таба борылды да, аннары карчыгына карап, көлә-көлә:

— Әйе шул! Без дә ял йортына барабыз! Әйеме, карчык?! — диде.

Билал моны ничек аңларга да белми торганда, бабайның карчыгы ярдәм итте:

— Шунда якында гына торабыз без. Ял йортыннан ерак түгел генә... Менә шәһәргә барган идек әле. Оныгыбызның хәлен белергә. Шуннан кайтып килеш...

Гаять ачык чырай күрсәтеп сөйләшә башлаган бу карт белән карчык Билалга бик ошады. Аның тагын да сүзне дәвам итәсе, алар турында күбрәк беләсе килде.

— Ә оныгыгызга ни булган соң?

Бу юлы инде бабай уфтанып-ыбрак тотынды:

— Әй заманнар, диген син! Нинди заманнарга килеп җиттек бит! Бердәнбер оныгыбызга духтырлар: «Урманга чыгарга ярамый, авыл җиренә кайтырга ярамый!» — дигәннәр... Югыйсә чире көчәя икән...

Билалның мондый нәрсәне әле гомерендә дә ишеткәне юк иде. Чын булыр микәнни бу?! Шундый авыру да була микәнни дөньяда?!

Сорамыйча да булдыра алмады:

— Ә нинди чир ди соң ул?

Бабайның җавабы кыска булды:

— Кем белсен инде аны! Хәзерге мең төрле чирне!

— Нигә белмәскә! Әллиргия ди! Малаең шулай диеп кайтып әйтте бит, оныттыңмыни! Шуңа күрә хәзер оныгыбызны күрергә тилмереп ятабыз бит инде... — Соңлап булса да сүзгә кушылган әбинең тавышында борчылу да һәм кемгәдер, нәрсәгәдер ачу да сизелә иде.

Билал тынып калды.

Бик тә сәер яңалык иде бу аның өчен! Кешегә, яшь-яшь кешегә, әнә шул табигатькә чыгарга ярамасын әле! Йа, дөнья! Кая барасың син!

Байтак кына вакыт тешләрен кысып, йөзен чытып, нишләргә белми барды ул.

Аннары Нинаның да Мәскәүне ташлап, еракка — тайга арасына китәргә теләве исенә төште... Ул да качарга тели түгелме соң?! Хатын-кыз сизгерлеге белән әнә шул куркынычны алдан тойган түгелме соң Нина?!

Бик күңелсез бер ачыш ясап һәм үзе үк шуннан куркып — сүзсез, бернинди уйсыз калды Билал.

Аның бу халәте шактый озакка сузылды.

... Автобустагылар җанлана, кыймылдаша башлагач кына исенә килде ул. «Инде әз генә калды», «Килеп җитәбез» ише сүзләр ишетелә иде. Шул арада әлеге яшь пар кызык кына тәкъдим дә кертте:

— Әйдәгез, калган юлны җәяү үтәбез! Ә әйберләр... әйберләр автобус белән барсын!

Моны шундук күтәреп алдылар. Шофер да дустанә елмаеп автобусын туктатты.

Җитез генә коелдылар. Һәм, чыгу белән, барысы да диярлек югарыга текәлде. Ә анда ямь-яшел ябалдашлар, яшь кызлар кебек, бер-берсенә сизелер-сизелмәс кенә кагыла-кагыла пышылдашалар, серләшәләр... Пышылдашулары күңелдә дәрт, тормыш, яшәү дәрте уята.

Билал иң артка калып, бер ялгызы китте...

Рәхәт шул табигатьтә берүзең ләззәтләнеп йөрү! Урманга көтү-көтү булып баруны кечкенәдән үк җене сөйми аның. Мәктәптә шулай, экскурсия дигән булып, барысын бергә урманга алып баралар иде. Шау-шу була иде. Нindидер начарлык эшләнгән кебек тоела иде Билалга ул вакытта. Нәрсә өченлер бик уңайсызлана иде ул...

Ә иң бәхетле минутларны ул урманда яки бүтән иркенлектә бер үзе генә калгач кичерә. Авылда укыган чагында да яз көне кичләрен елга буенда йөри иде ул... Аларның авылы янынннан гына ага торган елга бу чакларда бик нык киңәя, аның киңлеге өчәр-дүртәр чакрымга хәтле җитә иде... Агымы бөтенләй сизелми үк башлый иде.

Кичкырын килеп, тәмам караңгы төшкәнче йөри иде Билал әнә шул дәрья буенда... Чиксез рәхәт тә, гаять ямансу да, әллә нинди — үзәкләрне өзәрлек моңлы да була иде ул чагында... Исенә бик еш кына Штраусның «Дунай дулкыннары»н хәтерләткән сузынкы да, әчке дәртле дә музыка килә иде... Чөнки, монда төшмәгән кичләрдә ул, өендә тәрәзә төбенә үк килеп утырып, репродуктордан ерактагы музыка авазларын тыңлый иде... Баеп баручы кояшка карап, ул кереп югалганнан соң да әллә никадәр гомер утыра иде әле ул моңга бирелеп...

Соңгы елларда аңа ялгыз гына калу, бигрәк тә менә моныңише ямьле җирләрдә берүзе генә йөрү бик эләкми башлады. Эш һәм гаилә дигән ике ыгы-зыгы арасында чабып үтте аның көннәре... Ул инде үзенә үзе булып та күренми башлады, әллә нинди ят кыланмыш-холык үзләштергән кеше төсле тоя ул үзен...

Менә хәзер Билал бер ялгызы урман сукмагыннан бара. Олы юлны калдырып, юри тар сукмактан кереп китте ул. Адашмам әле, югалмам, дип уйлады... Урман адаштырмый ул йөри белсәң... Киресенчә, авыл малайлары, авылда, табигатьтә үскән егетләр шәһәрнең төп-төз урамнарына килеп кереп адашалар күп чакларда. Минем кебек, мәсәлән... Ә урман юллары адаштырмый аларны. Чөнки урманда, табигатьтә алдау, хәйлә дигән яман нәрсә юк — анда барысы да ачык һәм күңелгә якын, гади һәм кабатланмас матур. Бөек табигыйлек монда.

Сукмак борылып-борылып барды да, зур булмаган бер ачыклыкка килеп чыкты. Ә ул ачыклык күлгә килеп ялгана икән. Билал кечкенә таллар арасыннан иң элек ул күлнең бер башын күрде... «Менә шулдыр инде, алайса — Якты күл дигәннәре...» Үзе барган сукмакны бөтенләй онытып, әллә инде ул сукмак үзеннән-үзе юкка чыкты, Билал зур сер, могҗиза күрергә җыенгандай күлгә якынрак килде. Килгән саен ул, әйтерсең, үзенең, үз гәүдәсенең, хәтта алай гына да түгел — һәмма чынбарлыкның әкренләп эри, югала баруын тойды...

II

Якты күл!

Исеме җисеменә бик тә туры килә шул! Менә шушы ямьле урман уртасындагы сихри зәңгәр күз шикелле икән ул... Эчкерсез күңелләрнең якгылыгы шикелле икән ул! Мөлдерәмә тулы икән... Ап-ак каеньы ярлары бу кадерле байлыкны ничек итеп түкми-чәчми сакларга дигәндәй, тыныч кына уйга талган...

Билал күл буена чыккач башта бөтенләй туктап калды. Үзе каршына китереп куелган шушы гүзәллекне күзләре белән эчеп бетерергә өметләнгәндәй, аның һәр куагын, агачын, үләнен, чыбыгын озаклап-озаклап күзәтте. Күл өстенең ышанып булмастай зәңгәр тигезлеге вакыты-вакыты белән хәтта үзенә таба тарткан, суырган төсле дә иде...

Билал алга таба бер адым атлады да туктады. Шул арада инде өр-яңага әверелгән табигый сәнгатьне яңадан да каушый-каушый, дулкынлана-дулкынлана үзенә иңдерә, сеңдерә башлады...

Тагын әз генә алга китте дә, тагын туктады... Тагын-тагын шулай кабатлады... Әле ике көн элек кенә шәһәр мәхшәрендә нишләргә белми азапланган Билал өчен бу — әйтеп, аңлатып бетерә алмастай ләззәт, бер нинди сүз дә колачлый алмастай рәхәтлек, үзе кичермәгән бер кем дә төшенә, күзаллый алмастай иң югары бер мәртәбә иде... Әйе, әйе — монда һәртөрле купшы сүзләр артык: мондый тирән, тулы җан рәхәтлеген бары тик кеше үзе генә тоя ала, белә ала.

— Чыннан да, шушындый гаҗәеп җирдә яшисе иде бит, ә!!.

Озак йөрде Билал күл буенда. Бу аның өчен балачактан бирле үз һәм кадерле булган су стихиясе дә иде. Күңелендәге иң якты истәлекләрне уятучы урын да иде ул. Тагын аның өстәвенә, моның ише зур сулар Билалны тынычландыра, үз ярына кайтара да ала иде. Менә шушындый вакытларда инде Билал кайлардадыр йөреп югалта башлаган үзен, үз асылын, үзенә иң кулай һәм иң кадерле булган яшәвен тапкан сыман тоела. Шуңа күрә, тормышында мондый минутларга очрамый башласа, аларны ничектер җуйса — Билал ниндидер караңгылыкка чумгандай хис итә башлый үзен. Утсыз, яктысыз юлга килеп кергәндәйрәк итеп тоя. Әйтерсең, ул юнәлешне дә җуя мондый вакытларда. Кая барырга кирәклеген дә.

Күл буенда шулай соклана-соклана йөри дә Билал: «Менә нәрсә җитмәгән икән миңа! — дип куя үз-үзенә. Менә ни өчен җаным таланган икән. Табигатьтән читләшкәнмен икән бит мин ул тынчу калада яшәп. Гел дә эш артыннан чаба-чаба мин үземне үстергән Табигать-ананы онытa язганмын ич!»

... Билал ял йортына кайтканда бүген килүчеләр инде иртәнге ашка да утырганнар иде. Аны:

— О-о, менә, югалган кеше кайта! — дип каршы алдылар. Билалга түр яктагы почмактанрак урын калдырылган икән — ул елмая төшебрәк кенә залны кисеп үтте дә, шунда барып утырды. Өстәлдәшләренә хәерле иртә теләгән булды, «ашыгыз тәмле булсын»ны да әйтте — кыскасы, бөтен шартын китергәндәй итте.

Алар дүрт ир-ат бергә утырачаклар икән. Икесе Билалдан олырак күренә, ә берсе аның чамасындарак, яисә чак кына, бер-ике яшькә генә артыграктыр. Алар яңа очрашкан кешеләргә хас булганча, ашаган җайга акрын гына әңгәмә куерта. Билал аларның исемнәрен дә әллә ни исендә калдыра алмады, шул, үзенекен әйтте дә — гомуми сүзгә кушылмыйча гына ашавында булды. Аның әле генә урманда, Якты күл буендагы алган тәэсирләрен югалтасы, өстәл артындагы гадәти әңгәмәгә кушылып китеп, үзе качкан ыгы-зыгы шаукымына яңадан кайтасы килми иде... Шул ук вакытта ул болардан аерымрак халәттә утырганын да сиздермәскә тырышты. Шуңа күрә тыштан гына булса да тегеләр көлгәндә көлеп,

сөйләшкәндә «әһә, әһә» диеп утырган булды. Ә эчендә, җанында тыныч бер иплелек, салмак агышлы бер ләззәт һәм аннан да мөһимрәге: тагын да зуррак рәхәтлек, бәхет көтү бар иде.

Ашаганнан соң һәркем үзенең бүлмәсенә китте. Билалга дигән аерым бүлмә коттеджда, төп бинадан бер йөз метрлар чамасы читтәрәк икән. Аның караваы, күлгә якын! Бәләкәй капкадан гына чыгасы да, тау гына төшәсе!

Бүлмәсенә кергәч креслога утырып әз генә ял итим дип уйлаган иде, бераз утыруга йокысы килеп китте һәм Билал, тиз генә чишенеп, урынына менеп тә ятты. Менә шушындый иркен чакларда, ял вакытларында, йокының кирәгeн бирә торган гадәте бар инде аның... Гаеп итмәгез, берүк! Аннан соң бөтенләй икенче, өр-яңа кеше булып тора бит ул! Көче, дәрте ташып торган кеше булып!

Байтак йоклады Билал. Уянып сәгатенә караган иде — унбер тулып килә икән. Тыштагы эсселек инде бүлмәгә дә үткән, көннең нинди кызу икәнен моннан да чамалап була... «Эссе» дигән сүз артыннан ук аның алдына күл килеп басты. Янында гына Якты күл бар бит! Һәм Билал сикереп тә торды, трико чалбар белән майка гына эләктереп, чыгып та китте. Күлгә!

Нәкъ бала-чага сыман сөенеп чапты Билал күл буена!

Күл буена җитәрәк акрынайды. Аның яшендә болай йөгереп йөрү бик үк килешмидер бит инде...

Хәзер, көн уртасында, урман эче дә шактый кызган икән. Менә сукмак кечкенәрәк бер чокырга төшеп менде дә, бөтен күл буен ап-ачык итеп күрсәтеп торучы калкулыкка килеп чыкты. Билал туктальп, байтак күзәтте аннан. Кая гына караса да — кеше иде монда. Барысы да эшләпәдән яисә яулыктан, өсләренә зонт көйләп куючылар да бар... Урмандагы күл буена шуның хәтле халык җыела ала дип Билал күз алдына да китермәгән иде.

Тынычрак, кешесезрәк урын эзли-эзли яр буенча китте. Чирәмлерәк, ятып торырдайрак һәр почмакка кеше кунаклаган. Чибәр-чибәр хатын-кызлар, түгәрәк-түгәрәк ир-атлар... Ә кайберләрен күкрәкчә буенча гына аерырга була — иренең дә, хатынының да гәүдәләре бер үк, бүтәнчә һич аерырмын димә!

Шулай — кайсына сокланып, кайберсенә гаҗәпсенеп бара иде, якында гына аның исемен кычкырдылар:

— Әй, Билал! Әйдә, монда кил!

Караса — тегеләр, өстәлдәшләр! Бер агач күләгәсенә кереп чүгәләгәннәр дә, шушындый эссе көндә кәрт сугып маташалар! Ышанырга да, ышанмаска да белмәссең, билләһи... Бу адәм баласы үзенең иялӛнгән гадәтен кая гына барса да һич ташламый бит...

Нишлисең, барды инде Билал алар янына...

— Әйдә, утыр! Безгә менә бер кеше җитми...

Нәрсә әйтергә дә аптырарсың монда... Кисәк кенә баш тартырга да уңайсыз...

— Җегетләр, мин уйный белмим бит! Ышанасызмы?! — Билал шундый хәйлә белән котылмакчы булды.

— Нәрсә, дуракны да уйный белмисеңме?!

— Әйе шул... — Үзе елмая төшеп, тегеләргә карап тора бирде. Янәсе, ышансагыз — ышаныгыз, ышанмасагыз шаярту дип кабул итегез. Алай да ярый!

Әдәп өчен алар янында бераз басып торды да, аннан бик үк еракка китмичә чишенеп атты, күз-колак булсыннар дип, киемнәрен болар янына китереп куйды. Суга кереп китте.

Яр буенда бик күп бала-чага, карт-коры мәш килә иде, Билал бераз суга ияләнү өчен генә күкрәк тиңентен суда басып торды да, рәхәтләнеп, колач сала-сала, ирләрчә сикерә-сикерә, йөзеп китте... Бу рәхәтлек инде

ярдан карап тору эше генә түгел иде! Монда — йомшак, салкынча суда йөзгәндә — һәр күзәнәгең искиткеч иркенәеп, киңәеп китә иде, үзеңне чын-чыннан бер су җанвары сыман тоясың!

Билал күлнең уртасына ук керде. Күпләр монда хәтле йөзәргә кыймыйлар идеме, иренәләр идеме — уртада беркем дә юк. Тик биредә су салкынрак икән... Күрәсең, шактый тирәндер бу күл... Әнә бит, каршы як яры ничек текә! Ә бу ягы сөзәк һәм ул ямь-яшел чирәм белән капланган.

Шулай озак кына киңәнде ул күл уртасында. Бер хәрәкәтләнмичә чалкан да ятып торды, диңгезчеләрчә дә йөзеп карады, тик кенә, тирә-яктагы урманны гына күзәтеп тә торды...

Әйе, Билал биредә килеп һич тә ялгышмаган иде! Ярый әле путевка булды! Югыйсә, болай да миңгерәгән Билал эсседән чатнаган таш арасында — шәһәрдә нишләр иде икән хәзер!

Соңгы елларда гаиләсендә ешаеп киткән тавыш-гаугалардан бик тә туйган, эшендәге бәрелеш-чәкәләшүләрдән тәмам изаланган Билал ниһаять иреккә чыкты. Ул — ирекле! Ул хәзер табигать баласы! Аның хәзер берниндидә четерекле мәсьәлә чишәсе, нәрсә өчендер җан-фәрман көрәшәсе юк!

Ирек — татлы! Ял — рәхәт!

Байтак кына юангач, Билал ярга таба йөзеп китте.

Чишенгән җирендә — егетләр ягына караса — алар кәрт уйнаудан туктаганнар, өсләрен салып куйганнар һәм күлгә текәлеп, Билалны күзәтеп утыралар.

## III

Ярга бераз калгач Билал боларга кычкырган булды:

— Әйдәгез, су керәбез!

Тегеләр аны-моны дәшмәделәр, һаман карап утыра бирделәр. Ярга чыгып елмая-елмая яннарына килгәч кенә аларның яшькә Билал чамасындарагы — ул Саша исемле иде, ахрысы — үзенең нечкә тавышы белән сүз башлады:

— Сине йөзү буенча бүлмә чемпионы дип игълан итәбезме инде?

Ә икенчесе шундук аңа каршы төшәргә ашыкты:

— Нинди чемпион ди тагын! Просто акылсыз бер адәм!.. Шушындый эссе көндә кисәктән суга кереп китәләрмени!.. Башта бер ярты сәгатьләп су буенда юынырга кирәк бит, суга күнегергә кирәк!.. Аннары инде әкрен генә керергә дә мөмкин!!

Бусы — Сергей Николаевич дигәннәре — чын күңелдән ачуы килеп, канәгать түгел тавыш белән сөйли. Тик Билал аңлап җитә алмады — ни өчен кәефләре кырылган боларның?

Ул йөзеп килгән кызулыктан соң тиз генә туктап кала алмый иде — берникадәр вакыт аллы-артлы йөренгәләп алды, тирән-тирән итеп сулады, тирә-юньдәгеләргә күз аткалады. Дөнья матур, дөнья күңелле, ә кәеф тагын да шәбрәк!

Ә тегеләр, ни гаҗәп, һаман әлеге сөйләшүләрен дәвам итәләр.

— Мин үзем, радикулит эләктермәгән булсам, әзрәк су коенуга каршы түгел, әлбәттә... Ну, нишлисең — радикулит уен эш түгел! Су уртасында каптырса — беттең дигән сүз! Сакланмыйча ярамый! Ярамый! — Бусын бик тәмләп кенә, нечкә тавышын сузып-сузып кына Саша әйтте. Билалның әле аңа ныклап, текәлеп дигәндәй караганы юк иде — менә хәзер кызыксынып китеп байтак кына күзәтеп алды ул Сашаны. Кызык дип әйтергәме, кызганыч дияргәме бу кешене? Кайсы сүз туры килерәк микән соң аңа?

Саша, яше буенча аның белән бер чамадарак булуга карамастан, Чехов геройларын искә төшереп җибәрде Билалга... Чехов китапларында

күләп тасвирланган, бер дә җан әсәре сизелмәгән типларны... Әле җитмәсә, шулар өстенә, кулына бик җитди генә рәвештәге күзлек тә тоткан! Юк, кара күзлек түгел — чын күзлек, җитди кешеләр күзлеге...

Әйе, Билалның андый тип кешеләрне күргәне бар: алар һәрчак үтә җитди булып күренергә тырышалар, үзләренә кеше алдында (ә бәлки һәрвакыт шулайдыр!) бернинди тегенди-мондый малай-шалайлык, беркатлы кыланмыш рөхсәт итмиләр. Бу аларның тышкы кыяфәтләреннән, киенүләреннән үк башлана һәм үзләрен тотуга, һәр сүзне әйтүгә, сөйләшү интонациясенә кадәр килеп җитә.

— Сез дөрес әйтәсез, билгеле, Александр Петрович, кеше иң элек сәламәтлеген кайгыртырга тиеш, сәламәтлек барысыннан да мөһимрәк...

Сергей Николаевич, үз-үзенә нык ышанган кыяфәттә бернинди шиккә урын калдырмастай тавыш белән, күзләрен ярым йомган килеш сөйли. Шундый урында — урман уртасында, менә дигән ямьле, һәммә җан иясе үзен иркен тотардай җирдә — ничек кеше үзен-үзе шулай җансыз саклап тора ала икән?

Моңа хәтле боларны авыз ерып кына күзәткән, аларның сүзләренә артык игътибар да бирмәгән Билал тора-бара авызын җыеп, үзе дә җитдиләнеп китте. Ул боларның кыланышына гаҗәпләнеп, шуның серенә төшенә алмаганга уйчанланып калды. Болар чынлап та шаяртмыйча, ихластан әйтәләрме соң? Әллә булмаса беркатлы Билал алдына куелган юмористик күренешме бу?!.. Юк, аларның үз-үзләрен тотышлары юморга охшамаган иде...

— Хөрмәтле Сергей Николаевич, сез менә шушындый искиткеч матур көндә рәхәтләнеп су керү ләззәтен дә аңлый алмыйсызмыни? — Билал үз тавышына битараф-тынычрак тон бирергә тырышкан иде, бик үк алай килеп чыкмады, күрәсең. Андый тыныч кына тавыш белән сөйләшә аламыни соң ул?! Эчендәге дулкын һәрчак тышында бит аның! Эчендә туган дулкын шул ук минутта теленә, үзен тотышына, бөтен барлыгына чыга бит аның!

Ә Сергей Николаевич коеп куйган мәһабәт сын иде Билал каршында. Бу сүзләргә ул керфеген дә селкетмәде. Бөтенләй ишетмәгән үк кыяфәт белән, ачу чыгарырлык бер битарафлык саклап тора бирде...

Кызык! Тукта әле, Билалның мондый күренешкә элек тә очраганы бар иде бит!

## IV

Институтка яңа директор килеп эшли башлагач та шундыйрак бер күренеш булды түгелме соң?

Әйе, ул көн бик тә хәтерендә Билалның.

Ул ниндидер йомыш белән шәһәрдә йөреп, бераз соңлабрак кайткан иде үзләренең эш бүлмәсенә. Ишекне ачуга ук, бүлек мөдире Хәкимҗан абый янына килеп утырган юан гына гәүдәле, бик җитди кыяфәттәге бер кешене күреп алды. Үзләренең яңа директорын якыннан күргәне юк иде әле Билалның, шуңа күрә: «Әһә, бу шул икән!» — дип куйды. Тыныч кына исәнләште, үз урынына барып утырып, эшли башлады... Әмма тегеләрнең сүзе колакка керми каламы соң инде, бер бүлмәдә утыргач! Билал шуны аңлады: ул эшләгән проект буенча сораша икән яңа директор. Ә бүлек начальнигы Хәкимҗан абый, үзе конкрет белмәгән нәрсә булгач, якынча гына сөйләп утыра...

Хәлне аңлап алуга, түзмәде Билал: тегеләр тынып торган арада, сорамаган-нитмәгән кешегә үзенең бар белгәнен сөйләп тә бирде! Кызып-кызып, дәртләнә-дәртләнә сөйләде әле!

Ә яңа директор нишләде дисез шунда?! Үзләренең ипле генә сөйләшүләренә шулай җайсыз кушылып китәргә теләгән Билалга күз генә

төшереп алды да, кыл да кыймылдатмый нәкъ элеккечә утыра бирде, тыныч кына. Сөйләп бетергәч, Билал аптырап китте. Тукта әле, әллә мин саташаммы соң?!— дип уйлады.— Төш кенәме соң әллә бу?! Тегеләр бу проект белән чынлап кызыксыналар төсле иде бит!

Кызганыч, өндә иде шул ул, өндә! Билал көпә-көндез саташкан иде! Яңа директор да пенсиягә киткән Газиз абый сыман булыр дип ялгышкан иде ул! Үзенең бу ялгышын тора-бара бик нык аңлады ул, билгеле, аңлады.

Билалның инде күп мәртәбәләр сынаганы бар: яңа директор кебек һәм менә мондый кешеләрнең эш өчен, халык өчен, бүтәннәр өчен бервакытта да исләре китми. Алар беркайчан да үз өсләренә зур җаваплылык алмыйлар. Алар бер генә вакытта да күкрәкләрен куеп бүтәннәрне саклап калмыйлар. Алар беркайчан да бер генә мәсьәләдә дә беренче булмыйлар. Алар беркайчан да, бер генә мәсьәләдә дә кистереп җавап бирмиләр!.. Һәм алар, мондый кешеләр, беркайчан да тулысынча ачылып, иң төптәге уйларын бүлешеп сөйләшмиләр... Алар һәрчак сак, уяу, куркучан булалар. Менә шушы сыйфатларны үзләрендә булдырырга тырышу аларны, гомумән дә, чикләнгән натура итә. Күпмедер вакыттан соң, аларның әнә шул эчке һәм тышкы тормозлары — үзләрен гел тыеп, туктатып яшәүләре — эчке бәләкәйлеккә, рухи тарлыкка, чикләнгәнлеккә китерә...

Менә шушы уйларына Билал торган саен, яшәгән саен ныграк ышана килә.

Сергей Николаевичка карап торганда Билалның башыннан әнә шундый уйлар үтте. Хәзер инде бу бәндәнең кем икәнлеге, нигездә, билгеле кебек иде... Тик менә ничек итеп аның аркасында биредә кәефен бозмаска да, ничек итеп мондый әңгәмәләрдә тынычлык саклап калырга — бусын нык кына уйларга кирәк иде Билалга.

— Ярар, әйдә кайтабызмы инде, герой!— Сергей Николаевич, үзен хуҗаларча тоеп, кулын Билалның җилкәсенә китереп салды. Хәтта җилкәдән тотып җиңелчә генә селкетеп тә караган булды.

Бу кешеләрнең бөтен хәрәкәтләре ничек үлчәнгән, никадәр таныш, кабатланган! Ничек бер-берсенә охшаганнар алар — бер-берсен беркайчан да күрмәгән һәм күрмәячәк бу адәмнәр!

Билалның танышлары әдәпле генә иттереп саубуллашканнан соң, ял йортына менеп киттеләр. Өченче өстәлдәшләре Василий Петрович та тыныч кына аларга иярде...

Ә Билалның моннан бер кая да китәсе килми... Монда җан рәхәте тапты ул! Тик менә «иптәш» дияргә тиешле кешеләр генә әллә ниндирәк булып чыктылар бит әле... Каян килгәннәр микән соң алар? Әле мин анысын да белмәдем бит... Хәер, шул ук мин качкан мәхшәрдән — шәһәр җиреннән килгәннәрдер инде.

Ул бернәрсә җәеп тормастан, яшел чирәмгә сузылып ятты. Өстән кояш кыздыра, аста салкынча чирәм, якында гына менә дигән күл — рәхәт иде аңа, табигать баласына!!!

## V

Шулай озак ятты ул. Аннары, артык эссе кояш астында инде тәмам чыдар хәле калмагач, суга кереп китте — тагын кинәнеп, онытылып йөзде. Тагын ярга чыкты, тагын тәне яна башлаганчы кыздырынды...

Ләкин шунысы сәер — тәне, гәүдәсе ничек кенә рәхәтләнеп ял итмәсен — үзенең башын, үзенең уйларын, барыбер, монарчы иңләнгән тормышыннан аера алмый иде Билал... Барыбер ул искә төшә иде.

Менә хәзер дә, үзе ул кайнар кояш астында кызынып ята, ә уйлары, күңеле әллә кайда — еракта, эшенә бәйле вакыйгалар арасында... Күз алдында һаман шулар...

— Шулай итеп, сез Сәнгать сараен проектлаштырырга булдыгыз инде, ә?!

Яңа директор Билал эшләгән бүлек архитекторларын үз кабинетына җыеп алды да, әнә шулай кискен генә итеп башлап җибәрде сүзен. Әле дә хәтерендә Билалның: шуннан соң бүлмәдә бик озакка тынлык урнашты. Ниндидер начар тынлык, күңелсез тынлык — кешеләр бер-берсен аңлый, аңлаша алмаганда була торган тынлык иде бу. Эченнән генә ике директорны чагыштырып та алган иде Билал ул көнне: «Газиз абый сөйләшүне болай башламый торган иде... Аңа карагач, үзеннән-үзе киңәшәсе, сөйләшәсе килеп тора иде...»

Тынлыкны, әлбәттә, бүлек мөдире Хәкимҗан абый бүләргә тиеш иде. Бөтен сызымнар, исәпләүләр аның кулында бит... Әмма менә аның холкы гына артык юаш. Үтә талантлы архитектор булуга карамастан, кайчакларда — бигрәк тә берәр тупасрак кеше белән очрашса — коела да төшә, бөтенләй сүз дәшә алмас хәлгә килә ул. Элекке директор Газиз абый, билгеле, аның җаен тапкан иде. Милли архитектура өчен гаять үзенчәлекле талант булган бу кешене ул җаваплы эшләргә тарта иде. Хәкимҗан абый җитәкләгән Билаллар бүлегенә дә бөтен республика өчен вакыйга булырдай олы объектларны ышанып тапшыра иде ул. Һәм алар бергә-бергә җиңеп тә чыгалар иде. Шул хөрмәткә матур итеп мәҗлесләр дә үткәрәләр иде... Кыскасы, алар эшне күңелле итеп оештыра белделәр. Әнә шуңа күрә иртән дә дәртләнеп, йөгерә-йөгерә дигәндәй киләләр иде...

Ә бу көнне Хәкимҗан абыйның үзен тотышы ук бүтәнчә булды. Башта кулындагы төргәктән тиешле ватман кәгазен таба алмый аптырады ул. Аларны идәнгә коеп бетерде... Аннары тагын да ныграк каушады — куллары ук калтырый башлады... Талантлы белгечнең мондый хәлгә төшүен күрү үзе үк кызганыч һәм ачуны китерә иде.

Бүлек егетләре булышкач кына, Хәкимҗан абый тиешле сызымны табып, директор өстәленә китереп сала алды.

— Без... Без бу проектны... Газиз Нәбиуллович вакытында эшли башлаган идек... Үзебез сайлап алып...

Хәкимҗан абый ватман кәгазе кире бөгәрләнмәсен өчен ике кулы белән басып торган да «Безне нишләтәсең инде?» дигән нәүмиз караш белән директорга төбәлгән. Ә директор — чын директорларча! Йөзендә бернинди җан әсәре юк аның! Анда бернинди уй, тойгы дигән нәрсә сиземли алмыйсың.

— Әйдәгез, сөйләгез, сөйлә! Нәрсә, дәресен белмәгән мәктәп баласы кебек, туктап калдыгыз!

Мескен Хәкимҗан абыйның сөйләү сәләте болай да бик чамалы иде, ул «ык-мык» итте дә, аптырагач, тәмам ачуы килеп:

— Соң!.. Менә шушында күрсәтелгән инде барысы да,— диде.— Менә үзегез карагыз шуннан.

Архитектор халкы, чыннан да, сүзгә бик оста түгел инде ул — Хәкимҗан абый тәкъдим иткән юл барысына да котылу булды. Яңа директор үзе дә урыныннан торып:

— Әйдәгез, карыйк алайса...— дияргә мәҗбүр булды.

Алар барысы да директор өстәле тирәсенә җыелдылар.

Ә анда Хәкимҗан абый җитәкчелегендә архитекторлар бер ел буена тырыша-тырыша эшләгән эш — Сәнгать сарае! Бөтен шәһәр өчен горурлык булачак Сәнгать сарае!

Бу сарай шәһәр үзәгендәге Олы күл буена урнашырга тиеш. Шуңа күрә яшь архитекторлар иң башта бу тирәне бик каты өйрәнделәр. Кайсы

яктан караганда ничек күренәчәк ул? Яр буеның нинди үзенчәлекләрен искә алырга кирәк? Су өсте белән дә, яр белән дә аны ничек уңышлы бәйләргә, ялгарга?

Бик озак уйлашканнан соң, Сәнгать сараен ике катлы озынча бина итәргә булдылар. Бу урын нәкъ әнә шундый форма таләп итә иде! Ә бинаны өске яктан төгәлләп тору өчен сәнгать алиһәләренең сыннарын, милли һәм заманча фикерләүгә корылган башка матур-матур алымнарны файдаландылар... Әнә шулай иткәч, күл буен бизәп торачак бик гүзәл сарай туарга тиеш иде.

Яңа директорга иң башта бинаның өске өлеше ошамады. Озын, кара карандаш белән әлеге фигураларга төртеп:

— Практик әһәмияте булмаган артык элементлар күп!— диде ул һич тә икеләнү сизми торган тавышы белән.

Архитекторлар моңа каршы ни дияргә дә белмәделәр. Бераздан Билал сүз әйтим дип авызын ачкан иде, директор бүлде:

— Нишләп әле сезнең сарай ике генә катлы?! Шәһәрдә һәрбер төзелеш өчен урын табу нинди зур проблема икәне сезгә билгеле түгелме әллә?!

Ничек инде таныш булмасын ди ул проблема егетләргә?! Бик таныш, билгеле!.. Таныш!.. Әмма, урын җитми, урын тар дип, бөтен шәһәрне бер төсле биек тартмалар белән тутырып булмый бит инде! Соңгы елларда үсеп чыккан андый игезәк шәһәрләр бүтән җирләрдә дә байтак бит инде!.. Сәнгать сарае булгач — кешечә сарай булсын, кешелекле сарай булсын!— дип тырышты бит егетләр! Хәзер, гомумән, архитектурада кешечәлеккә омтылыш көчәеп бара бит... Чөнки замана кешесенең күңеле шулай тели!

Ул көнне яңа директор кабинетындагы сөйләшү буеннан-буена гел әнә шул рәвешле — бик тә кискен һәм кызып китүләр белән барды. Яңа директор иң кызыклы табышларга, иң оригиналь идеяләргә каршы иде. Аларны, гомумән, кирәк түгел дип исәпли иде ул.

Билалның ул көнне үзләренең бүлмәсенә дә, беркая да керәсе килмәде. Коридор башында бераз миңгерәп басып торды да — аска, чәй эчәргә төшеп китте... Анда буфетка чират торучы кызлар белән сөйләшә башлагач, бераз тынычлангандай булды... һәм әнә шунда аның башына беренче мәртәбә шикле уй килде... Аның күңеленә шик үрмәләде.

Озак та тормый булып узган бер-ике конфликт әлеге уйны тагын да көчәйтте...

... Үзенең хәзер кайда ятуын искә төшереп, як-ягына каранган иде — сызгырып җибәрде Билал! Яр буенда халык бик азайган иде. Ә көн һаман шәп! Кояш һаман шәп! Тукта — халык кая киткән соң? Ашарга микәнни?! Читтәгерәк каен төбендә үзе кебек ялгыз гына кызынып ятучы егеттән сораган иде — сәгать өч тулып килә, ди!

Тиз-тиз генә киенде дә, югарыга чапты Билал!

Юк, ашаудан калырга ярамый! Ашисе бар!

## Таптылар...

### I

Билалның бирегә килүенә инде менә бер атнадан артты.

Мөгаен, моңарчы аның тормышында бу кадәр дә рәхәт үткәрелгән ял булмагандыр. Юктыр ул моның кадәр рәхәт һәм тыныч үткән көннәр... Андый көннәрне искә төшерә алмый Билал. Авылдан киткәннән алып моңа хәтле булган гомере гел ашыгудан, нәрсәнедер эшләп

өлгермәм дип куркудан, кабаланудан — әнә шулай тоташ чабудан, нервланудан, арлы-бирле ташланудан торган икән аның...

Ә монда ул беркайчан да булмаганча, үз сүзләре белән әйтсәк, дворяннарча яши башлады. Иртән ашыкмый гына йокыдан торды, иркенләп, бөтен шартын китереп кенә физзарядка ясады, озаклап-тәмләп юынды, аннары кырынды, төзәтенде — шуннан соң, шулай ук пошмый гына салкынча урман юлыннан бер урап керде. Иркенләп кенә атлады ул, әле йокыдан да уянмаган төсле генә... Әйтерсең, монда — шундый ямьле урманда — ашыгып, каударланып йөрү аның өчен бик зур гөнаһ иде. Әйтерсең, әнә шул катгый кагыйдәне бозудан сакланырга тырыша иде ул.

Бүген дә үзенең көнен шулай башлады Билал. Барысын да ияләнгән тәртип буенча эшләде. Ә иртәнге аштан соң кайткач, бүлмәсендә берәр сәгать чамасы китап укып ятты. Иң яраткан язучысының — Әмирхан Еникинең калын гына бер китабын алган иде ул үзе белән. Гомумән, бу китапны ул барлык командировкаларга диярлек үзе белән алып йөртә башлады соңгы елларда. Язучының дөньяны, кешеләрне аңлавы, сурәтләве Билалга да бик якын, ягымлы тоела, һәр әсәре диярлек халык җырлары сыман — көчле моң белән тәэсир итә. Тагын да кызыгы шул: ул әсәрләрне ничә мәртәбә генә укысаң да, туйдырмый, ялыктырмый алар. Киресенчә, укыган саен яңа моң катламы ачыла, һәрбер уку бик моңлы яңа җыр тыңлаган төсле була...

Бу юлы да шулай булды. Билал язучының «Тынычлану» исемле хикәясен исе китеп, соклана-соклана укыды... Никадәр дөрес яза әдип! Бүгенге чор тормышының нинди ачы хакыйкатен әйтеп бирә ул... Чын сәнгать, олы әдәбият шулай булырга тиештер инде...

Укып бетергәч тә озак ятты ул түшәмгә карап... Уе белән әллә кайларга, еракларга китеп... Үз тормышы белән дә бик зур уртаклык тапты ул әсәрдә. Күрәсең, оста язучы бөтен кешене борчыган әйберләр турында язгандыр шул.

Аннары, гадәтенчә, күл буена юнәлде Билал. Килеп үзенең иялэнгән урынына урнашты. Тик бүген, нишләптер, тиз генә суга кереп китәсе килми иде — эшләпәсе белән битен каплап сузылып ятты. Укыган китабы аны җәй көннәре өчен бик үк хас булмаган тирән уйга салган иде, озак кына ятса да, һаман шулар тәэсиреннән ычкына алмады. Тирә-яктагы чыр-чу һәм якында гына җәелеп яткан Якты күл дә кинәт кенә көчсез булып калдылар... Кеше үз эчендәге тирән күлгә — уй-кичерешләр дөньясына кереп китте...

Бүтән көннәрдәге сыман бик артык хозурлана алмаса да, барыбер озак итеп су керде Билал. Сәгать икеләр тирәсенә якынлашкач, кайтырга кузгалды...

Үзе йөрергә яраткан аулак сукмактан менде ул. Эшләпәсен салып кулына тотты, ничектер, башындагы уйлары белән менә бу эшләпә — бераз купшырак һәм артык күзгә ташланып торган сомбреро — үзара килешмиләр, ярашмыйлар, бер-берсенә каршы киләләр сыман иде... Хәер, баш үзе дә, бүтән көннәрдән аермалы буларак, әз генә аскарак иелгән иде бугай. Берәрсе игътибар белән читтән караса, һичшиксез, шуны искәрер иде.

Билал ял йортының кечкенә генә капкасын да үтте. Хәзер сукмак яшь юкәләр арасыннан уза да, ул яшәгән коттеджга таба борыла. Ярый әле, сукмакның як-ягындагы ямь-яшел чирәмне саклап кала алганнар. Мондый кызу көннәрдә ул күзне ял иттерә, әз генә булса да күңелне күтәреп җибәргәндәй итә...

Шулай атлый Билал акрын гына. Әле ашханәгә барырга да ашыкмый ул, бүтән чабар җире дә юк аның...

Яшь юкәләрне узып әлләни күп тә китмәгән иде әле ул, кинәт алгы яктан, Билал бөтенләй әле искәрмәгән җирдән:

— Әти!— дигән тавыш ишетелде. Билал башын күтәрде һәм, үзенә таба йөгереп килүче кызы Раушанияне күрде! Ямь-яшел чирәм өстеннән, бөтен көченә, менә-менә абынып егылыр дәрәҗәдә ашыгып-кабаланып, туфлиләрен төшереп калдыра-калдыра чаба иде ул!

Билал туктап калды, кинәт кенә берни эшли алмас булып китте, сүз дә әйтә, бер хәрәкәт тә кыла алмады. Таш кебек, җансыз сын сыман — катты да калды.

Ул арада кызы килеп тә җитте, кочагына да ташланды! Билал элекке гадәте буенча аны югарыга күтәреп алды, нык, бик нык итеп кысты... Билалның тәне үзенең иң кадерле, иң яраткан җылысын тойды... Шушы кечкенә генә гәүдә аңа гомер буе җитмәгән, җитешмәгән җылыны, йомшаклыкны менә шушы санаулы минутлар эчендә бүләк итеп өлгерде. Кызын озак, бик озак төшермәде ул кулыннан.

Ниһаять, Раушания төште. Һәм төшешли үк: «Әни тегендә, синс көтә...»— диде, бармаклары белән Билалның коттеджына таба күрсәтеп. Күрәсең, тышта чирәмдә уйнап йөргән җиреннән күреп алып, каршысына чапкан иде ул әтисенең...

Билгеле, кызының бу кадәр җиргә үзе генә килә алмаячагын Билал аңларга тиеш иде инде. Ләкин «әни тегендә» дигән сүз аны — кызы белән сөенешеп атлап киткән кешене — тагын туктатып калдырды. «Аның белән ничек күрешсен инде ул хәзер... Ташлап, качып кит тә — хәзер елмайган булып килеп күрешергәме... Нигә генә килде икән соң ул? Бу кадәр җиргә...»

Ләкин бүтән чара юк иде инде. Раушания үзенең кечкенә куллары белән, аны нык итеп җитәкләгән иде...

Алар кояштан, яктыдан караңгы коридорга килеп керделәр. Коридор башындагы холлда, креслода ул утыра иде. Кырыенда артык зур булмаган чемодан һәм хатын-кыз сумкасы, тәрәзә аша каядыр еракка караган... Юлда килеп арыганмы, әллә Билал чыгарган борчу аңа шулай тәэсир иткәнме — тартылып киткәндәй күренә... Билал, керү белән, шуларны искәреп алды. Ә инде Раушания ишектән керүгә үк әнисенә чапкан иде.

— Әни, әни!.. Менә әтине таптым!

Шул сүзләрне ишетүгә, борылып аларга карап тора башлаган Галия мыш-мыш килеп елап та җибәрде... Кулындагы кульяулыгы белән күз яшьләрен сөртергә тотынды. Күрәсең, алар кергәнче дә елап алган инде ул — кульяулыгы алай әзер булгач, кулында ук булгач...

Билал аңа якынайды да тәрәзә кырына ук килеп басты. Арада бер-ике метр чамасы җир калды.

— Килдеңмени...— диде, тавышына усалрак төсмер биреп... Ул аңа әйтергә бүтән сүз таба алмады.

Галия бераз тынычланганчы ике-өч минутлап вакыт үтте. Аннары ул кискен генә хәрәкәт белән яшен соңгы кат сөртеп алды да шулай ук төксе тавыш белән:

— Килдек шул!— диде.— Әллә бездән качып котылырмын дип уйлаган идеңме?!

Мондый дорфалык-кискенлеккә гомере буе күнегә алмыйча интексә дә, бирелә Билал борчылып тормады, кызыксынып сорыйсы гына итте:

— Ә ничек таптыгыз соң?

Җавап ачулы һәм коры булды:

— Ха, путевка каян алганыңны онытгыңмыни!

«Тагын минем эшкә барган, тагын тикшереп, сорашып йөргән икән бу».

Монда хәзер Билалның каршы дәшүе дә, аңа нәрсәнедер тагын-тагын аңлатырга, төшендерергә тырышуы артык иде. Ул тәрәзәдән күзен алмыйча гына:

— Әйдәгез, алайса... Капкалап килик...— диде.

Раушания янә аңа килеп сарылды:

— Әти! Әти!... Мин синең янга утырам, яме!

Билалның күзенә яшь килде... Тамагында да авыр төер иде. Аны көч-хәл белән үткәреп җибәреп:

— Ярар, кызым, бергә утырырбыз...— дип әйтә алды.

Әйберләрне тиз генә бүлмәгә кертеп куйдылар да, өчәүләп ашханәгә киттеләр.

Өстәлдәшләре әле китмәгән иделәр. Аларны:

— О-о, кунаклар килгән икән!— дип, ачык чырай белән каршы алдылар.

Саша исә:

— Синең шундый кызың да бармы инде?— дип гаҗәпләнеп тә куйды.

Официант кызга хәлне аңлатты Билал. Бераздан бухгалтериягә барып акча түләячәген әйтте. Алар, мөмкин булган хәтле тату күренергә тырышып, бүтәннәрнең вак-төяк сүзенә кушылгалап ала-ала, әйбәт кенә тукланып чыктылар.

Әле ярый аның бүлмәсендә икенче диван да бар иде — Билал Галия белән Раушанияне үз урынына яткырды, үзе диванга урнашты. Галия аңа бер сүз дә әйтмәде, кызы белән генә сөйләшкәләп алды. Ә Раушания, әтисе белән яңадан бергә булуга шулкадәр нык сөенгән иде бахыр — ул минут саен аңа килеп сырпаланды, иркәләнеп, Билалның өстенә үк менеп киткән булды, әтисе белән уйныйсы килде. Ул шулай шактый шаярып алгач, әнисе:

— Раушания, әйдә, йоклыйк инде, кызым...— дип, аны үз янына алды.— Әтиеңә синең белән без кирәкмибез шул аңа... Әллә кемнәр, бүтәннәр кирәк аңа...

Раушания үзе яныннан китүгә, Билал тагын әлеге китабын алды. Берәр хикәягә тукталырга теләп, исемнәрен карап чыкты. Ләкин шул арада бер нәрсәне төшенде: аның үткән атнадагы сыман көннәре, тыныч көннәре бүтән булмаячак икән инде... Ә алдагы көннәре ничек, нинди булачак — анысын да ачык кына күз алдына китерә алмый әле Билал...

Ә, иң мөһиме, менә бүген-иртәгә булачак сөйләшү ни төсле булыр, аннан да курка төсле әле Билал. Ниндидер керләнгән, пычранган нәрсәне яңадан актару, аңа яңадан кагыласы килмәү, аннан чиркану кебек иде ул тойгы...

## II

Әллә ни озак йоклый алмады Билал. Урын үзгәртү ярамадымы, әллә икенче бер үзгәреш аның йокысын качырган идеме — ярты сәгать боргаланып ятканнан соң, торып юынырга булды. Кызы белән Галия әле йоклыйлар иде, арыганнар, күрәсең... Билал өстен бөтенләй ачып ташлап, рәхәтләнеп йоклап яткан кызына озак карап торды. Газиз, бик газиз иде бу җан аның өчен. Аңа болай гына карап тору да мөмкин түгел — якынаеп үбәсе, иркәлисе, яратасы килә иде. Ул үзенә Билалны түзеп тора алмаслык дәрәҗәдә нык тарта иде... Билал иелеп аның бер битеннән генә үбеп алды да, тиз-тиз атлап юынырга чыгып китте.

Юынырга чыккан җиреннән озак кына верандада утырып торды. Баш бер нәрсә дә уйлый алмый, шулай ук әле тиз генә кереп юынасы да килми иде.

Билал юынып кергәндә кызы белән Галия дә уянып маташалар иде. Билал матур итеп, балаларча киерелеп яткан Раушанияне күреп, ирексездән елмаеп җибәрде:

— Әй, әйбәт йокладың соң, әйеме, кызым!

Раушания әле бик ушына килеп җитмәгән иде, күзендә йокы иде әле — «әйе» дигән сүзен ым белән генә күрсәтте... Кызының сабыйларча киерелүе дә, менә шушы баш хәрәкәте дә, кечкенә генә, нечкә генә гәүдәле кызының ап-ак урын-җир өстендә онытылып утыруы да — Билалның инде күптән күрелмәгән, үтә тансыкланган, нык сагынылган күренешләр иде... Болар барысы да кайчандыр ул бик матур итеп күз алдына китергән, шулай булыр дип хыялланган гаилә тормышы дөньясыннан иде. Хәзер, аның «гаилә тормышы» дигән матур хыялы килеп чыкмагач, менә шушы аерым-аерым гына булган эпизодлар да Билалга искиткеч зур рәхәтлек, кешелек бәхете бирә иде. Шулай — адәм баласы үзенең бәхете дигән нәрсәне башы белән бер төрле уйлый, ә чынлыкта һич тә күзалламаганча килеп чыга шул...

Галия дә юынып керде. Төзәтенде, ясанды. Раушанияне дә урыныннан кузгатып, аягына бастырдылар.

— Әйдә, берәр җиргә алып бар инде, күрсәт безгә...— диде шуннан соң Галия. Аның моннан тиз генә китәргә дә, ашыгып кына нәрсәдер сөйләшергә, хәл итәргә дә исәбе юк иде, ахрысы.

— Йөреп керик соң алайса...— диде Билал. Үзе Раушаниянең кулыннан җитәкләп алды. Әйтерсең, менә шушы җылы һәм йомшак кына куллар аңа хәзер бик кирәкле ныклыкны, тәвәккәллекне, кыюлыкны бирергә тиешләр...

Билал үзе йөри торган сукмактан алып чыкты аларны урманга. Зур капка ягын алар болай да, килгән чагында күргәннәр инде. Ул як парадчарак итеп бизәлгән. Аннан соң табигый матурлыкка бик урын калмаган хәзер анда. Юлның ике ягына очлары кыркылган топольләр утыртылган, түтәлләр ясалган, төрле-төрле чакыру сүзләре язып плакатлар, паннолар куелган. Кыскасы, Билал ял йортының ул почмагында күзне иркәләрлек почмаклар тапмады... Ул тирә, артык тәртиптә булганга күрә, солдатлар яши торган хәрби шәһәрчекне хәтерләтә иде.

Кечкенә капкадан үткәч тә күлгә таба алып китмәде әле ул кунакларын. Бераз урман күрсәтеп йөрткәч, иң ямьле урыннарда булгач кына, Якты күлгә китереп чыгару иде аның исәбе...

Һәм ул аларны уң яккарак киткән сукмакка алып керде. Бу сукмак урман эченә керә дә, тирән генә бер чокырга төшеп китә, аннары күлгә хәтле шул киң һәм рәхәт салкынча һава бөркелеп торган ямь-яшел чокыр төбеннән бара. Монда кешене әллә нинди серлелек, әз генә курку һәм кара урманда адашып калгандагыдай эчке бер шик-шөбһә биләп ала. Ә бит хәзерге урманнарда мондый урынны бик сирәк очратасың. Күбесе хәзер юл буендагы посадка кебек: үтәли күренеп, эчендә ни бары-ни югы ялтырап тора. Әйтерсең, алар бүгенге кешеләрнең үзләре сыман: аз яфраклы, сыек кәүсәле, нечкә ботаклы...

— Әти, ә без кая барабыз, ә? Без кая барабыз?— Кызы аны бертуктаусыз шулай диеп аптырата. Билал җавап бирергә ашыкмагач, кулыннан тарткалый... Ә Билал бу сорауга ничек җавап бирергә дә белми... «Урман карап йөрибез»,— генә дияр идең, бу гына бала өчен ят тоеладыр, мөгаен. Аңа бит үзләренең кая таба баруын белү кирәк. Үзләренең кая килеп чыгарга тиешлекләре күбрәк борчый менә шушы нарасыйны. Ямь-яшел күлмәк кигән матур, искиткеч матур күбәләкне...

Ә Галия үзалдына караган да тып-тын гына бара бирә. Аның өчен урман да юк, Билал күрсәтергә теләп алып төшкән менә бу гаҗәеп урын да юк. Әллә инде эченнән нидер уйлап бара, әллә болай гына бара. Хәер, моның ише җирләргә аның артык ушы китмәвен Билал күптән белә бит инде. Бу бит аның белән сигез ел торган кеше өчен яңалык түгел. Галия матур таш корылмаларга сокланып карарга мөмкин, оригиналь төзелгән йортларга көнләшергә мөмкин — ләкин табигатьнең әлеге корылмаларга караганда мең тапкыр сокландыргычрак могҗизалары аның күңел күзенә күренмиләр. Ул аларны күрә дә, алар бирә алган эчке ләззәтне татый да алмый. Бу олы бәхеттән мәхрүм ул...

Билал аның белән бергә тора башлаганнан бирле бу хакта күп уйланды — нишләп шундый бәндә булып үскән бу? Хикмәт нәрсәдә? Ул унбиш яшьтән алып шәһәр җирендә үскән, шунда тәрбияләнгән. Шулмы төп сәбәп? Алай дисәң, Билал табигатьне үлеп яраткан байтак шәһәр кешеләрен белә...

Озак кына уйлаганнан соң, инде ничәнче тапкыр Билал гел бер фикергә килеп туктала — канындадыр хикмәт, нәселендәдер. Әнә шуңа күрә адәм баласын тиз генә үзгәртеп булмый торгандыр...

Раушания алга таба йөгереп китә, эчтәрәк матур яфрак яисә чәчәк күреп алса, агачларны аралый-аралый, шунда да чума, югалып та кала, тагын йөгереп килеп чыга да, әтисен килеп җитәкли. Үзе чырык-чырык көлә, кулындагы яфрак һәм чәчәк букеты зурайганнан зурая бара... Билал моңа бик канәгать. Ул туктап-туктап сокланып тора Раушаниянең шулай иркенләп чабуына, рәхәтләнүенә.

— Кая соң бик ямьле дигән җирләрең?! Безне шунда алып бар инде... Мондый урын безнең авылда да күп, туеп беткән чокырдан!..— Галия бу сүзләренең Билалга ничек тәэсир иткәнен аңлый алмый, билгеле. Югыйсә, акылы җитеп үзенең нindирәк сүз әйткәнен чамалый алса — менә хәзер, Билалны эзләп күпме чакрым җир килгәннән соң, әлеге салкын сүздән үзе дә чирканып китәр иде ул. Әмма аның бөтен холкы шундый иде шул: ул кеше күңеленең нечкә борылышларын тоймый, сизми — үзе күргән туры таш юл буенча гына атлый. Әнә шундый каты таш рәвешендә яшәгән әйберләрне генә күрә һәм аңлый ала ул...

Билал үзен эчтән адым саен кисәтте: «Түз! Бу — бәхәсләшеп йөрү урыны түгел! Безнең арадагы бәхәс кызык түгел инде хәзер. Тагын ызгышу, әрләшү белән бетәчәк ул. Иң әйбәте — дәшми түзәргә, чыдарга». Шуңа күрә тыштан битараф тавыш белән генә:

— Бүтән ямьле урын юк шул инде монда...— диде, юаш кына итеп.

— Мондый урынны каян эзләп таптың әле!— Бусы инде көлү, артык әрсезләнеп, аннан көләргә маташу иде. Ир кеше түзеп кала алмады:

— Мин сине чакырып китермәдем! Йөрсәң кеше төсле генә йөр! Йөрмәсәң...— дип тукталды.

— Куасың да мыни? Ялыңны боздыкмыни килеп?!

Билал йөгереп барып, кызын җитәкләп алды:

— Әйдә әле, кызым, әнә анда матур чәчәк күренә...

Галия сукмак уртасында баскан килеш тагын мышкылдап калды.

Билал белән Раушания агачларны, куакларны аралый-аралый әллә кая, алга киттеләр. Җиләк тә ашап алдылар, чәчәк тә җыйдылар, Билал да тынычлангандай булды... Бераздан алар Якты күлгә килеп чыктылар.

— Нинди мату-ур...— диде Раушания, күрү белән исе китеп.— Әти, тирән микән бу күл?.. Сине күмәме ул?

— Күмә, кызым...— диде Билал, күңелендә инде бернинди ачу калдырмыйча.— Бик тирән күл бу. Исеме дә бик матур аның — Якты күл дип йөртәләр аны.

Алар сөйләшкәндә артларыннан килеп җиткән Галия дә янәшә басты, ул да күлгә текәлде. Йөзе бераз ачыла төшкән сыман...

Якты күл бүген дә халык белән тулы. Бүген дә яр буенда бала-чага, карт-коры мәш килә. Эчтәрәк егетләр күренеп китә. Кайберәүләр өреп кабартылган резин капчыкта йөзә...

— Су керәбезме соң?— Бу сүз Билалның авызыннан чыгарга да өлгермәде, Раушания:

— Керәбез, керәбез!— дип сикергәли дә башлады. Ә Галия дәшми дә, кымшанмый да басып тора. Билал аның дәшүен дә, кымшануын да көтмәде — кызы белән суга кереп китте. Су күкрәгенә җиткәч, Раушанияне күтәреп алды, аны уйната, йөздерә башлады. Аның белән күңелле, рәхәт иде — бертуктамый шулай шаярып кына торасы килә иде. Рауша-

ния исә судан туярга уйламый да — чыркылдый-чыркылдый йөзә бирә әтисе кулында. «Тагын, тагын!» — дип һаман эчкә, тирәнгә табарак күрсәтә.

Аларның күңелле уенын Галия тавышы бүлде:

— Кызым, әйдә, чык... Суда озак мавыгу ярамас. Салкын тияр ату.

Әмма Раушанияне болай тиз генә судан аеру мөмкин түгел иде инде. Ул һаман әтисенә килеп ябышты — «Әйдә тагын йөзәбез, әйдә!» дип кабатлады бер өзлексеез һәм эчкә, тирәнгә табарак тартты...

Билал уйлап куйды: «Яр башында торган кешегә мондый хисседә бик рәхәт түгелдер... чыгарга кирәк». Раушанияне күтәреп, ул ярга чыкты, тегесе аның кулыннан ычкынырга теләп тартышты, һаман суга тартылды. Ә Билал көлә-көлә булса да аны җибәрмәде — тәнен сөртештереп, бергә-бергә киендерделәр. Киенгәч тә китәсе килмичә, барысы бергә тагын судагыларга карап тордылар.

## III

Кайткач, бүлмәләренә кермичә, коридордагы уңайлы кәнәфиләргә утырып, хәл җыйгандай иттеләр. Мондый эссе көндә иң әйбәт урын хәзер менә шушы кебек иде... Кызык, үзе генә яшәгәндә Билалның бу кәнәфигә беркайчан да утырганы булмаган икән... Нишләп микән? Аңа урманда, күл буенда рәхәтрәк булганмы ул чагында әллә? Монда тукталып торырга туры килмәгәнме аңа? Чыгып киткән, кайтып кергән.

Билал үз алдына елмаеп куйды — кайчагында ул тәрәзәдән генә дә чыгып китә иде бит әле! Аның белән бер өстәл янында утыручы танышлары моны күрсәләр яисә белсәләр, нишләрләр иде икән?! Ушлары китеп егылмаслар иде микән?! Һәрхәлдә, Билал белән бөтенләй сөйләшми башларга мөмкин иделәр алар ул чагында... һа, һа! Кызык та инде бу дөнья — мин аларга кызык кебек, ә алар минем өчен кызганыч кешеләр... Әллә дөньяның бөтен кызыклыгы да әнә шунда микән: кешеләрнең төрле-төрле, бер-берсенә бөтенләй охшамаган булуларында микән?

— Син миннән көлеп утырасыңмы инде шулай? — Галиянең тавышын ишеткәч, ул сискәнеп китте.

— Ю-ук әле, бер кызык искә төште дә шуннан көләм... Минем кайчагында тәрәзәдән йөргәнне белсәләр, мондагы танышлар нишләрләр иде икән, дип елмаеп утырам.

— Нигә, син тәрәзәдән дә йөрисеңмени? — Галия аның уен-көлкеле сүзен бөтенләй икенче якка борып алды, Билал аптырап ук китте... «Ә бит, чыннан да, салкын акыллы кеше тик кенә торганда, бер сәбәпсез, көпә-көндез тәрәзәдән йөрүне аңлый алмый. Ул аны күз алдына да китерә, башына да сыйдыра алмый...»

Әнә шундый уйламаган җәтмәләргә Билал элек тә бик еш килеп каба иде. Соңгы елларда инде ул моның ише очракларда дәшми генә котылу җаен тапкан иде. Шулай әйбәтрәк, тынычрак уза сыман иде.

— Раушания кызым, бар, тышта, чирәмдә уйнап тор әле әзрәк...

Галия, икәү генә калып, нинди дер сүз башларга җыена иде. Раушания теләр-теләмәс кенә чыгып китте дә, ишекнең теге ягыннан янадан башын тыгып:

— Только сез ызгышмагыз! — диде.

Билал аптырап, ток суккандай телсез калды. Каян белә ул шундый сүзне? Моңа ничек акылы җитә аның? Аңа бит әле җиде генә яшь!!

...Эх, дөнья... Кечкенә кызың шулай дип өзгәләнеп әйтерлек булгач, нинди тормыш булсын инде ул! Эх, Раушания... Әгәр бу дөньяда мин кем алдындадыр гаепле булсам, ул бары тик синең каршыңда гынадыр! Мин сине тормышның менә шундый әшәке якларыннан саклый, кечкенә

чагында аралый алмадым шул... Безнең арадагы бөтен салкынлык, тарткалаш, ямьсезлек синең күзең алдында, синең күңелең каршында барды... Һәр очракта да дәшми калырга, салкын кан саклап, бүтәнрәк юл белән, салкын акыл белән хәл итәргә түземлегем җитмәде минем... Синең алда менә шул түземлегем җитмәгәнгә генә гаеплемендер дә мин... Ә сиңа бит бу яшьтә мондый сүзне әйтү түгел, аның барлыгын белү дә кирәкмәс иде!

Раушания чыгып китте. Алар икәү генә калдылар. Кызык, тагын ни дип башлар икән Галия сүзен?

— Кемгә өйләнергә уйладың инде?

Галия үзенең яшькелт пыяла кебек күзләрен Билалга текәде. Күзләр кешенең күңел көзгесе, дип дөрес әйтәләр икән... Галиягә карата бу бигрәк тә туры килә иде. Эчендәге катылык, усаллык ничек ачык чагыла аның күзләрендә... Ә бит бүтән күзләр барлыгын да белә Билал — җылылык, акыллы тыйнаклык, хатын-кызга гына хас ягымлылык һәм кайгыртучанлык бөркеп торган күзләр дә... Билал алар алдында һәрвакыт баш иде, бөтен йөрәге белән хөрмәт итте аларны. Андый бәхеткә ия ирләрдән, гаиләләрдән ихлас көнләште.

Әйе, Билалның бередә бер дә сөйләшү теләге юк иде шул. Шуңа күрә ул бер сүз әйтсә, эчтән мең уй уйлап утырды. Галиянең аны бораулап, барысын да белергә, белеп тынычланырга теләгән карашыннан качарга тырышып утырды.

Әмма куелган сорауга җавап бирми дә калып булмый инде. Бары тик рәвешен китерү өчен генә дә дәшү, җавап бирү кирәк.

— Мин сиңа мең мәртәбә әйттем бит инде! Менә тагын — мең дә беренче тапкыр кабатлыйм: минем әлегә бернинди исәбем дә юк! Миңа бары тик аерылу гына кирәк! Мин бүтән алай яши алмыйм!

— Нигә соң син минем шундый икәнне элегрәк, балабыз булганчы күрмәдең?!

Ике арада бәхәс килеп чыккан саен Галия менә шул сүзен китереп кыстыра һәм Билалны гаепләп калдырырга тырыша. Ягъни, сиңа гына ярамый инде дигән сүзе ул аның. Чыннан да, ул үзенең Билал әйткән сыйфатларын бер дә начар дип санау ягында түгел иде. Ул аларны заманчалык, егерменче гасыр кушканча яшәү дип исәпли. Шулай бер чакны, Билал хатын-кызга хас булырга тиешле йомшаклык, тыйнаклык хакында сүз кузгаткач, ул:

— Син унсигезенче гасыр хатын-кызын күрергә телисең! — дигән иде кырт кына кисеп. Бу сүзләрне, мондый фикерне, күрәсең, алар эштә, иптәш хатыннары белән бергә киңәшә-киңәшә эзләп тапканнардыр. Галия үзенең бик күп кимчелекләрен әнә шулай дип акларга ияләнеп китте. — Син хатын-кызны һаман мескен итеп, кыюсыз итеп, хәтта кол итеп күрмәкчесең! Сиңа безнең заман хатын-кызларының үзләрен иркен тотуы, кыюлыгы, азат булуы ошамый. Бу — синең авыл гыйбаты булуыңнан килә! Хәер, хәзер авылда да хатын-кызлар бик әллә ни баш биреп тормыйлар. Алар үзләре акча табалар, ирләре белән теләсә — торалар, теләмәсәләр... Шулай булмыйча соң! Һе!

Әле бу хәтле үк ачык итеп ишеткәне юк иде Билалның мондый фикерләрне. Хатын-кызның заманча булырга тырышып котыруын ул әле һаман, ниндидер бер юмористик нәрсә кебегрәк, чын тормышка әллә ни кагылмаган күренеш диебрәк кенә уйлый иде. Аңа артык әһәмият бирми иде... Ә менә соңгы елларда Билал моның уен эш түгеллегенә ышана башлады. Җитәрлек дәрәҗәдә эчке тәрбия, рухи тәрбия алмаган хатын-кыз өчен «ирек, иркенлек» дигән нәрсәләр иге-чиге күренмәгән һәм чиксез матур чәчәкле болын сыманрак күз алдына китерелә иде. Теләсәң кая бар, теләсәң кая йөр, теләсәң ни эшлә — сиңа беркем дә бер сүз дә әйтмәскә тиеш, янәсе! Үз эчендә бары тик хатын-кызлык дәртенең уянуын гына тойган, әнә шул дәрттән керер урын тапмаган, ә күңелендә

бернинди жылылык, матурлык булмаган хатын затлары өчен «егерменче гасыр» диган сүз бик тә җайлы сәбәп иде. Хатын-кыз буларак, бөтен кимчелегенне, тупаслыгыңны — барысын да менә шушы сүзгә аударып калдырырга мөмкин иде.

## IV

Билал үз эчендәге уйларыннан янадан чынбарлыкка кайтты. Алар бит әле һаман шунда, коридорда утыралар икән. Бүлмәгә керергә, шунда сөйләшергә кирәктер бит инде...

— Әйдә, керик...

Галия сүзсез генә аңа иярде.

Бүлмәгә кереп икәүдән-икәү генә калгач, ул әз генә йомшаграк, ягымлырак булып киткән төсле тоелды Билалга. Бәлки янымa килер, шуның белән барсы да җайланыр, онытылыр диган өмете дә булгандыр, ахры. Аның әкрен генә йомшак караватка барып утыруын, ир-атны ымсындыручан тавыш, интонация белән сөйләшә башлавын Билал шулай аңлады... Ләкин Билал, нәкъ коридордагыча, тәрәзә янына килеп басты да, тәрәзә янагына уң кулы белән таянган килеш тора бирде, бер дә исе китмәгән хәлдә. Урманны, агач очларын күзәткән булды.. һәм үзе дә әллә ни уйлап тормастан:

— Монда озак булырга җыенасыңмы инде? — дип сорады, борылмый гына.

Галия аның кисәк кенә болай дип соравын көтмәгән идеме, әллә чынлап та ишетмәдеме — яңадан, кайтарып сорады. Билал нәкъ шул ук тавыш белән, шул ук соравын кабатлады. Бусына каршы Галия бер сүз дә дәшмәде. Аның мондый тотышы Билалга таныш — үзе теләмәгәнрәк сүзләргә шулай дәшми кала белә ул.

Кичен дә шуңа охшашрак хәл булып алды. Кызлары йоклагач, Галиянең аңа якынаясы, иркәләнеп аласы килде. Ул ир-атны да сагынган һәм, шуннан файдаланып, үзенең хәлен дә көйләп җибәрергә тели иде шикелле. Тик Билалда аңа карата бернинди дә җылы хис тумады.

Хәтта әле киресенчә иде: караватта ялгыз яткан Галиягә караган саен, эчендәге күңелсез күренешләр искә төшә, кәефне кыра. Аларның соңгысына да шушы ук Галия сәбәпче булды бит.

...Яңа түрә үз бүлмәсенә чакырып кыздырырга бик оста иде. Юк кына сәбәп табып, хуҗа икәнлеген сиздерергә ярата ул. Күрәсең, иҗат кешеләре булган архитекторларга да каты кул кирәк дип саный. Шуңа күрә дилбегәне бик еш тарта. Кулында камчысы барлыгын да искәртергә онытмый.

Ул көнне үзен директор бүлмәсенә дәшүгә үк Билалның кәефе кырылды. Нинди дер хәвефнең буласын алдан ук сизенде шикелле. Чыннан да, йөрәге алдамаган икән. Директор бүлмәсендә, кульяулыгы белән күзләрен сөртә-сөртә, Галия утыра иде.

Бу хәлне күрүгә Билалның кинәт, һич уйламаганда аяк буыннары һәм бөтен гәүдәсе мамык кебек йомшап, хәлсезләнеп китте. Менә шул минутта, гүя, аның өстенә фани дөнья бөтен авырлыгы белән авып төште дә, гүя, Билал аста, иң аста калды. Бернинди чарасыз, котылырга һичнинди өметсез калды.

Директор исә мондый чакларда ничек сөйләшергә кирәк икәнен бик яхшы белә. Тавышы үтә дә кырыс, кыяфәте таш сын диярсең.

— Гаиләне җимерергә уйладыңмыни, Билал дус?!

Билалга төбәп автоматтан аткан кебек иттереп әнә шулай диде ул. Аның «дус» диган сүзе дә соңгы пуляның күкрәкне тишеп үтүе кебек тәэсир итте.

Ә Билал ни эшләсен, ни дип әйтсен?!

Әйе, үткән төнне бик соң гына өеннән чыгып китте ул. Иптәш егете Вахитларга барып кунды.

Ни өчен төн уртасында чыгып китте? Чөнки өйдә тагын тавыш купты. Хатыны: «Акчаны аз аласың!» — дип тавыш чыгарды. Ә ул каян тапсын соң?!

Хәер, эш акчада гына да түгел иде бугай. Галия аның соңга кала-кала эшләүләрен дә ошатмый бит. Билал кайтып кергәндә аның йөзе кара көйгән, эчендәге уйлары чыраена чыккан була.

Ләкин Галия алдында боларны тагын бер кат директорга сөйләп утырасы килми. Билал моны һич тә эшли алмаячак! Галиянең үзенең килеп зарлануы да бик җиткән! Ә директор чын хәлне аңларга тели икән, соңыннан Билалның үзе белән генә сөйләшсен, барысын да әйтер Билал. Сорашсын...

Әмма директор бүтән уйда, башка ниятгә иде шул.

— Сезнең мондагы эшегезнең дә рәте юк! Инде дә килеп, гаиләдә дә тавыш куптарасыз икән!

Әйе, әйе — нәкъ менә Билалга карап «тавыш куптарасыз!» диде ул. «Эшегезнең рәте юк!» диде ул аңа хатыны алдында... Кызыклы проектлар белән мавыгып караңгыга кала-кала утыручы, байтак эшләрен өйгә дә алып кайтып, анда да дөньясын онытып сызымнар сызучы, ә өйдә акчаның ни өчен аз кайтканлыгын хатынга бик үк аңлатып торырга яратмаучы, керсез күңелле Билалга карап әнә шундый боз сыман салкын, үтергеч сүзләр әйтте әлеге түрә.

Бүтәнчә директор бүлмәсендә тору мөмкин түгеллеген шунда аңлап алды Билал. Бер сүз дә әйтеп тормастан, ишекне шапылдатып ябып, чыгып китте ул.

Әнә шул көннән бирле Галияне дә күргәне юк иде. Ә менә хәзер, гәүдәсе күзгә чалынган саен, аның директорга зарланырга, Билалны хурларга килүе искә төшә дә — яңадан каны ката, бәгыре суына Билалның. Начальнигы белән сүз берләшеп, Билалга каршы сугыш ачкан сатлык җан кебек тоела аңа хатыны.

Тик нәрсә тели соң алар?

Билгеле — берсенә бик күп акча кирәк. Ә икенчесенә исә күндәм эшче, кушканны һичсүзсез үтәүче, аның һәр сүзенә ләббәйкә дип торучы хезмәткәр кирәк.

Ләкин болар белән һич кенә дә бер сүздә була алмый бит Билал. Аларга кол булу — үлем, рухи үлем дигән сүз бит! Эчендә җаның, иманың, йөз тоткан кыйблаң калмау дигән сүз ич бу!

... Әйе, Билал якында гына мышнап яткан Галиягә күз салырга да теләмәде. Укып утырды да, бераздан онытылды, йокыга китте.

Тагын ике көн бер түбә астында бергә булды алар... Ә шулай да суынган җан бер-берсенә берекмәде.

Ире үзенә якын килмәгән саен Галиянең ачуы кабара, аңа булган үче, нәфрәте арта бара иде. Ул Билалны эзләп килүен дә, яңадан килешергә теләп йөрүен дә, үзенең егерменче гасыр хатын-кызы турындагы карашларын бозуны да — барысын-барысын да эчтән авыр кичерә, үзе өчен түбәнлек дип саный, мыскыллану дип кабул итә иде. Аның көннән-көн ныграк ярсый, усаллана баруы кызы Раушаниягә мөнәсәбәтенә дә сизелде. Беркөнне Билал хәтта аның кызына нык кына сугып алуын да күрде. Күрде һәм шундук Галияне каптырып алды да:

— Хәзер үк гафу үтен!!! — диде, үзе дә күптән ишетмәгән куркыныч тавыш белән.

Галия гарьлегеннән кычкырып елап җибәрде. Аларның сөйләшүен ишетеп торган Раушания дә «Әни!» дип килеп ябышты. Ә иң нык кичергәне, бу хәлгә иң әрнегәне Билал иде... «Эх, эх! Нинди оят хәлләргә төште бит башым!..»

Түзә алмады, йөгереп тышка чыгып китте. Төн житеп килсә дә, күл буена төшеп, озак кына су кереп алды. Әле генә булганны да онытырга, тынычланырга теләде...

Уйлаган саен Раушания алдында җир тишегенә кереп качарлык дәрәҗәдә авыр, кыен, оят була аңа. Боларның барысына да Билал бары тик үзен генә гаепле итеп тоя. Үзенең тиешле вакытында кешене таный, аера, аңлый алмавының төп корбаны итеп ул Раушаниянең — бер гөнаһсыз сабыйның — бәхетсезлеген күрә...

Беркатлылык аркасында шундый зур бәхетсезлек килеп чыгу мөмкинлеген элегрәк Билал уена да китерә алмас иде. Ә хәзер менә ул — күз алдында! Билал менә шушы ике ут арасында көячәк бәхет күбәләген өзгәләнә-өзгәләнә күзәтә. Күзәткән саен аның йөрәгеннән кан саркып тама! Ул кан Билалның күз алдында күбәя, җыела, арта бара... Һәм, әйтерсең, әнә шул куркыныч кара кан диңгезендә Билал үзе дә, аңа бик кадерле булган икенче бер кечкенә җан иясе дә бата бара, төпкә китә бара...

...Билалны эзләп ял йортына килүе, шулай итеп, Галия көткән нәтиҗәне бирмәде.

Тагын ике көннән, Билал уйламаган-көтмәгән чагында, Галия бик тыныч кына итеп:

— Озат безне, станциягә хәтле...— диде.

Нәрсә әйтсен соң Билал аңа каршы? Тагын әзрәк торыгыз әле, дисенме, булмастай нәрсәгә өметләндерсенме?.. Яисә, Раушанияне күреп туймадым бит әле дисенме ул?! Үзе ташлап китеп, хәзер үзе сагынган, җибәрәсе килмәгән булып кылансынмы?..

Ул бер сүз дәшә дә, ниндидер бер фикер тәкъдим итә дә алмады.

Ул арада Галия кызына да җыенырга кушты.

Билал төп бина янына барып автобусның кайчан киләсен белде. Бирелән станциягә еш йөриләр икән, берәр сәгать чамасы вакыт үттеме-юкмы, алар Якты күлгә кул болгап китеп тә бардылар.

Билалның якты күленнән бәләкәй аккош китте... кызы китте...

Станциядә исә кирәкле поездны бик озак көтәргә туры килде. Ул кичкә таба гына килә иде. Вакытны ничек узарга белми аптырадылар, әллә ничә мәртәбә вокзал янындагы ашханәгә кереп чыктылар, капкалап алдылар. Юлга диеп тә сумкага ашамлыклар салдылар. Ял итеп утырып та тордылар...

Поезд килеп, урыннарына кереп урнашкач, Раушания тагын үзәкне өзде:

— Әти, ә син кайчан кайтасың?

Билал ни әйтергә дә белмичә тын калды. Күпмедер минут үткәч кенә:

— Озак тормам, кызым, кайтырмын...— диде, аны кочаклаган килеш... битләреннән үбә-үбә...

Галия белән алар кул бирмичә генә, «Ярар, исән бул!» — диебрәк кенә саубуллаштылар.

Билал вагоннан чыгып китте. Раушания белән Галия утырган купе тәрәзәсе каршына барып басты. Билалның үз гомерендә әле беркайчан да мондый авыр озату кичергәне юк иде шикелле. Бу озату — үз тәнеңне, үз җаныңны икегә бүлеп, икесен ике якка җибәрү, аларны Сак белән Сок язмышына дучар итү шикелле иде.

...Поезд китеп барды. Билалның бәхетле һәм бәхетсез ялгызлыгы торып калды. Ярты җаны булган кызы — Раушаниясе китте...

Артык хискә бирелмәү өчен, бик озак тормады ул поезд киткәч. Кире кайтырга автобус караштыра башлады. Автобус инде кузгалып бара икән, Билал кул болгый-болгый йөгергәч, туктап утыртты. Алар яңадан Якты күлгә кайтып киттеләр. Тик Билалда беренче килүдәге сыман шатлыклы, бәхетле тойгының эзе дә юк иде инде хәзер.

Авыр изә торган, кыен бер эчке халәт иде анда... Гүя, олы җинаять кылган... Вөҗданы, үз-үзе каршында гомер буе оялырлык бер начар эш эшләгән ул, әйтерсең...

Әйе, ул кызы алдында гаепле...

Моны ул яшәгән саен, торган саен ныграк, тирәнрәк аңлый бара. Әнә шул аңлавы аның һаман эчтәнрәк йөрәген тырный, йөрәген парә-парә телгәли.

Әй, адәм баласы... Күпме яшәсәң дә, никадәр укысаң да, һаман шыр дивана булып калган адәм баласы...

## Яшьлеккә кайту

### I

Көннәр акрынлап уза торды.

Ял йорты тәки үзенекен итте — берәздан борчулар басылгандай булды. Тора-бара Билалның күз алдына төнге поезд һаман ешрак килде. Нина гел искә төшә башлады.

Ә бер кичне, кинодан кайткач, Билалның кечкенә генә куен дәфтәре сумка төбеннән алынып, өстәл өстенә куелды. Нинаның дус кызларындагы адресы әллә ничә мәртәбә укып чыгылды.

Әйе, Билал аның килүен, үз янында булуын тели башлады. Гаиләсез дә калган, озакламый эшеннән дә китәчәк, дусларыннан да аерылачак — димәк, һәр яктан ялгыз, бер үзе калачак Билалның менә хәзер күңеле тарткан бер генә кешесе бар иде. Анысы да очраклы рәвештә танышкан, бер генә тәүлек янәшәсендә булган Нина.

Ләкин ул да бит әле дус кызларында кунакта. Бәлки ул инде Билалны бөтенләй оныткандыр да? Адресны язып алган иде алуын... Ә поезддагы кичне икесе ничек матур итеп үткәрделәр алар... Иң тирәндәге серләрен, иң кадерле уйларын уртаклаштылар. Бер-берсенә нindiдер күңел, җан якынлыгы тойдылар шикелле. Аңлашу таптылар кебек... Чынлап та, ә бәлки менә шушы минутларда Нина да аның турында уйлыйдыр?

Күңелендәге шушы кечкенә генә өмет кисәге көннәрдән бер көнне Билалны почтага алып барды. Әлеге өмет чаткысы Нинага телеграмма да бирдерде.

Почтадан кайтканда исәпләп карады. Телеграмманы Нина кайчан алачак? Бару-бармау хакында күпме уйланачак, киңәшәчәк? Билет алу күпме вакыт сорый? Ә юлга ничә сәгать кирәк икән?..

Икенче көнне дә шуның ише уйлар аның башына бер генә мәртәбә кереп чыкмады.

Бик теләгән нәрсә чынга аша, диләр. Билалның да хыялы тормышка ашты. Ул Нинадан телеграмма алды. «Киләм. Каршыла» дигән.

Каршыламыйммы соң Билал! Телеграмманы алу белән һәммәсен: автобусның кайчан китәсен дә, поездның сәгать ничәдә киләсен дә, шундук белешеп куйды ул. Һәммәсен!

Һәм менә хәзер Нина — бу көннәрдә Билал өчен дөньяның иң гүзәленә әйләнгән хатын, бөтен кешедән ныграк сагынылган ханым — Билал каршында басып тора!

Билал киноларда күргән чагында кешеләрнең бер-берсе белән кочаклашып күрешүләренә, ничектер, ышанмый иде. Бу аңа төчеләнү, кылтаю булып тоела иде. Кайвакытларда, үзенең озак күрешмәгән дуслары аның белән кочаклашып күрешергә теләсәләр дә, ул уңайсызланып кала, кызара, боргалана — ничек тә монсыз гына күрешү ягын карый иде. Үзенең аларны сагынуын нык итеп һәм олыларча ике кул биреп кул кысышу аша гына сиздерә иде ул.

Ә менә монда бөтенләй бүтәнчә килеп чыкты.

Әллә инде Нина үзе шулай ымсынды: вагон баскычыннан төшешли үк күтәреп алды аны Билал. Күтәреп алды һәм аның җиңел-җиңел гәүдәсен нык итеп күкрәгенә кысты. Диңгездә һәлакәткә очрап, батып баручы кеше су өстендәге һәрнәрсәгә әнә шулай ябыша торгандыр, мөгаен...

Алар әнә шулай сәер генә кочаклашкан хәлдә, аруны-талуны онытып, шактый басып тордылар... Ә бераздан автобус килде, алар шуңа утырып, юлга чыктылар.

Аннары, зәңгәр күктәге ике кош кебек очына-очына, Билалның бүлмәсенә кайттылар... Кайтып җиткәнче ханымның кулын җибәрмәде Билал.

— Нина... Әйдәле, мин сиңа чәй куеп эчерим әле.— Билалның бүлмәсендә электр кайнаткычы бар иде.— Ә соңрак, ашханәгә барырбыз...

Чәй тиз кайнап чыкты, алар Нинаның букчасындагы тәм-том белән чәй эчтеләр... Шунда Билал әйтеп куйды:

— Бу арада минем баштан нинди уйлар кичкәнен белсәң икән син, Нина...

Ханым, эчә торган чәеннән аерылып, Билалга карады.

— Нинди уйлар икәнен әзрәк чамалыйм мин, чамалыйм...— Ул, кулын сузып, Билалның битенә кагылды... Бу минутта ул барысын аңлаучан хатын-кыз да, кызганучы ана да, иң ихлас дус та булып күренде.

...Чәйдән соң Нина бераз арыганлыгын әйтте...

— Син бит әле поездда да юньләп йоклый алмагансыңдыр,— дип, Билал аңа урын көйләп бирде... Нина ак җәймә астына сабый бала кебек бөгәрләнеп кереп ятты... Әзрәк тын яткач:

— Ә син?..— дип сорады.

Билалга менә шулай — сокланып утыру да бик рәхәт иде, шуңа күрә ул:

— Ә мин менә шулай, синең йокыңны саклап кына утырам...— диде.

Нина яратып, рәхмәт дигән төсле итеп елмайды...

Ә бераздан, ханым йоклап киткәч, Билал сак кына атлап, тәрәзә янына килде. Ачык тәрәзә аша янәшәдәге юкә ябалдашын күзәтте. Юкәдә дә йомшаклык, нәфислек, бәхет төсмерләнә кебек иде... Аннары ул тәрәзәгә карап, китап укырга утырды. Күптән тансыкланган хатын-кыз янәшәсендә булу рәхәтеннән бәхет, тынычлык кочагына чумды. Нинаның кай арада торып, аягүрә басуын искәрмәде дә ул. Аяк очларына гына басып килгән икән дә, менә йомшак куллары белән Билалның күзен дә каплап өлгерде. Ә үзе көлә-көлә:

— Сөйгәнең кем, әйт! — ди...

Билалның җавабы билгеле инде:

— Үзең беләсең ләбаса! — ди ул.

Нинага бу сүз генә аз тоела:

— Өч тапкыр әйтмичә ышанмыйм!

Билал ялт кына борылды да, Нинаны кочагына алды. Дулкынланудан еш-еш сулап:

— Син! Син! Син!! — диде.

Алар, кызынып ятарга җәймәләр, башларына эшләпәләр алып, күл буена киттеләр... Якты күлнең үзенә!

Билалның әле Нинага шушы гүзәл урынны күрсәтәсе бар иде бит!

Үзенең дә күңеленә якын бу хатын белән бергә шушы тылсымны яңадан ачасы, шул бәхетне өр-яңадан, яңабаштан кичерәсе килә иде аның!

Алар тиз генә чишенеп аттылар. Нина ачык яшел төстәге тоташ итеп тегелгән купальниктан гына калды. Билал аның зифа гәүдәсен күзләре белән иркәләп алды. Моны хатын-кыз сизми каламы соң?!

— Оялтасың бит, Билал... Бик алай карама, зинһар...— диде Нина.

Шушы сүз аны ниндидер тоткынлыктан чыгарды. Ул:

— Аннары туйганчы кызынырбыз, әйдә, башта су кереп чыгыйк! — диде, Нинаның кулыннан тотып.

Яр буена килеп баскач Нина шикләнебрәк калды. Ә Билал шундук суга ташланды, зур-зур колачлар белән эчкәрегә таба йөзеп китте... Ярдан шактый гына ерагайгач, борылып Нинага күз салды. Ә ул һаман суга керә алмый тора икән әле! Үзе Билалга караган да елмая.

Билал тавыш биреп аңа ярдәм итәргә теләгәндәй:

— Әйдә инде, курыкма! — дип кычкырды.

Нина тагын да эчкәрәк керде, су аның тубыгыннан узды, аннан да югары күтәрелде... Аннары, Билал өчен һуш китәрлек матур, назлы тоелган хәрәкәт белән, ике кулын бергә кушып алга сузды да, шул килеш йомшак кына итеп суга иелде һәм, су белән әллә ни арада уртак тел табып, аның үз дулкыны сыман булып, җай гына тирбәлә-тирбәлә Билалга таба йөзеп китте... Нинаның суга шулай матур итеп керүен, искиткеч зифа буйның, гәүдәнең су гүзәллеге белән уртак матурлыкка кушылу тантанасын беркайчан да күргәне юк иде Билалның... Һәм мондый ягымлы, йомшак, матур, иркәли торган хәрәкәтне — инде суга кергәнче үк, өстә үк йөзә башлагандай тоелган моның ише ишарәне — бүтән бер җирдә дә, беркайчан да, күрә дә, таба да алмады Билал... Хәтта бөтен гомеренә дә... Хәтта атаклы балериналарның иң гүзәл биюләрендә дә моның кадәр җанга якын, кадерле, күңелне тутырырдай камил һәм нечкә хәрәкәтне тапмады, күрмәде ул...

Әнә шул минутлардагы соклануы чиксез иде Билалның!

Эчендәге әнә шул хис көченнән, аның тышка ургылуыннан йөрәге ярылыр, тәне, гәүдәсе меңгә, миллионга шартлар кебек иде.

Билалның бу сәер халәтен йөзеп килүче Нина сизмәде, билгеле. Ул әле Якты күл белән беренче очрашу тәэсирен кичерә. Ят та һәм үз дә булган ир-егеткә караган килеш, әкрен генә йөзә, аңа якыная бара иде...

## II

Туйганчы йөзделәр алар Якты күлдә... Чөнки бу, чыннан да, аларның тормышындагы яп-якты бер күл, яп-якты бер көн иде...

Икенче як ярга да чыктылар... Ап-ак каеннарның кайсы берсе авып, суга ук иелеп тора, кайберләре исә таулы ярда үсеп зәңгәр күккә ашкан... Нина яр буендагы әнә шул зифа каеннар янына чыгып басты... Ямь-яшел купальниктан, бөтен матурлыгы белән балкып, басып торды ул... Якты күл буенда, ап-ак каеннар янәшәсендә, купальниктан гына калган Нина дөньядагы бер генә киноартисткага да алыштыргысыз чибәр һәм табигый иде... Аның әкрен генә, әллә нинди нәфислек белән генә бер урында кузгалып куюлары...

Билал да аның янына, ярга чыкты. Бераз хәл җыйды. Аннары тау бите буйлап, урман эченә менеп киттеләр. Җитәкләшеп, ялан тәпиләре белән җирне капшап кына баса-баса, каеннар, юкәләр, яшь усаклар арасында йөрделәр. Бөтен тарафта яшеллек һәм яшьлек иде, аларның һәммәсе үсүгә һәм мәхәббәткә дәшә, яратуга, сөюгә-сөелүгә ымсындыра һәм илһамландыра иде... Монда — Якты күлнең икенче ярында — аларны кеше дә күрми иде. Тауны менеп җиткәч Билал Нинаны күтәреп алды, күтәргән килеш үпте, күтәргән килеш ашыкмый гына сукмакка чыкты һәм шул рәхәтлекне мәңге сузарга теләгәндәй, як-якка карый-карый, борылмалы сукмактан алга таба атлады. Аларның баш очында чип-чиста, зәп-зәңгәр күк, әйләнә-тирәләрендә ямь-яшел урман, алларында озын-озын сукмак иде... Ә эчтә, йөрәктә — быелгы җәйнең кояшыннан да кайнаррак ут, яшь чагында гына кичерелә торган кайнар тойгы!

...Урман эчендә йөреп туйгач, әлсерәп, тагын Якты күлгә төштеләр... Ике көмеш балык кебек, янәшә йөзеп киттеләр... Билал һаман Нинага бик якын йөзде, йөзгәндә дә ул аннан күзен ала алмады...

Үзләре чишенгән ярга чыктылар. Билал кулыннан килгәнчә нәзакатьлерәк булырга тырышып, җаймә җайде, әле судан чыгып хәл дә алырга өлгермәгән — тирән-тирән итеп сулап торган Нинага ятып кызынырга урын тәкъдим итте...

— Моның кадәр ямьле урынны каян эзләп таба алдың син, Билал?..— Нинаның соклануы да, бүгенге көн бәхетеннән ләззәтләнеп куануы да һәм, хәтта, үзен шушында чакырганы өчен Билалга йомшак кына итеп рәхмәт әйтүе дә сыман иде бу... Ул, әле генә суга кереп киткәндәге сыман матур итеп, әкрен генә җаймәгә ятты. Кояш кызуыннан саклану өчен эшләпәсен алып киде. Үзе күзләрен тутырып Билалга караган. Иреннәре баягыча ярым ачылган. Ә Билал, уң кулының терсәгенә таянган да, шулай ук аңа төбәлгән... Дөнья онытылган, әйләнә-тирәдәгеләр онытылган. Гүя, бу Якты күл аларның икесе өчен генә, гүя, урман эчендәге менә шушы искиткеч матур җәй аларның икесе өчен генә. Гүя бөтен тормыш, барлык яшәү — алар да — боларның икесе өчен генә... Әйе, әйе, бик мөмкин, ә бәлки чыннан да: җирдәге бөтен нәрсә — яшьлек һәм ярату, гашыйк булу өчен генәдер?! Бәлки бөтен нәрсә, һәммә җан иясе үз гомерендә бер мәртәбә әнә шул бөек бәхетне кичерү өчен генә яшидер??!

Әзрәк вакыт үткәч, Нинаның күпмегә килгәнен сорыйсы итте Билал. Әмма теленнән ычкынам дигәндә, тагын эчкә йотты ул бу соравын. Сораса, Нина нindидер бер көнне әйтер дә, менә шушы бөтен рәхәтлекнең, бәхетнең ахыры күренер, аның чиге бар икәне беленер һәм әнә шунда аларның икесенә дә бик күңелсез булып китәр сыман иде. Шул тотып калды Билалны.

Шулай да әкренләп телгә килделәр, сөйләшә башладылар...

— Ә телеграмманы?.. Ә телеграмманы ничек алдың?...

— Мин аны саклыйм әле... Син бит үз яныңда вакытта аның ише сүзгә бик саран! Синнән андый матур сүзләр бик сирәк чыга...— Нина, үзенең мөлаем елмаюы белән елмаеп, Билалга якын ук иелде.— Шулай бит?

— Сүзләргә бик үк ышанып бетмим мин, Нина... Алар инде тузып, таушалып беткән шикелле. Алар хәзер берниндә тере хис, кичереш тә алып килми шикелле тоела миңа еш кына... Яныңда вакытта минем күңелемне күзләрем, йөзем белгертмимени соң?.. Мин дә, хатын-кыз алдында боргалана-боргалана, сандугач кебек сайраучылар рәтенә басыйммыни соң?..

— Сине бик яхшы аңлыйм мин, Билал! Ирләрне без, хатын-кызлар да, тел осталыкларына карап түгел, ә күңелебезнең әллә кайсы төше белән генә тоеп була торган чын ир-ат сыйфатлары буенча сайлап алабыз... Аннан соң шәһәрдәге ир затлары хәзер шактый үзгәреп тора бит. Алар әкренләп хатын-кызга әверелә бара шикелле... Әнә теге компаниягә күз сал әле, сиздерми генә.— Нина ым белән генә бер төркемгә күрсәтте.— ...Әнә, уртадагы, барысын да үз авызына караткан ир затын күзәт. Аның бөтен кыланмышы, хәтта кул хәрәкәтләре, аяк басулары да хатын-кызларча түгелме соң?!

— Кара әле, кызык кына килеп чыга бит бу!.. Минем шуның ише нәрсәне хатын-кызларда да күзәткәнем бар. Бик күп кенә кызлар хәзер үзләрен ирләрчә тотып, ирләрчә кыланып, абруй казанмакчы була... Хатын-кызга хас йомшаклыкны, назлылыкны, сизгерлекне, күнел нечкәлеген — алар үткән чорлар калдыгы дип ышандырырга тырышалар... Бүгенге заман хатын-кызы үткен, кыю, бәйсез булырга тиеш, янәсе. Ул ирләрдән берничек тә калышмаска тиеш!

— Әйтәсең дә инде син...— Нина җитди генә сөйләшкән җирдән кинәт елмаерга итте, кулындагы нечкә генә үлән сабагы белән Билалның колак артын кытыкларга кереште...

«Моның ише сүз күпкә китте, ахры»,— дип уйлап алды Билал. Аның инде ничә мәртәбә: «Хатын-кыз белән җитди сүзне ачык сөйләшергә ярамый» — дип, үз-үзенә сүз биргәне бар. Аның уйлавынча, бу табигыйлеккә каршы килә, бу — ясалмалык!

Әмма башлаган сүзен әйтеп бетермичә, туктый алмый ич инде ул! Аннары, ул бит әле Нинага сөйлим дип, үзе өчен дә кайбер нәрсәләрне ачыклый. Сөйләгәндә байтак әйбер үзенә дә ачыграк күренә бит ул.

— Менә, бер генә нәрсә әйтәм дә, аннары мондый акыллы сүзләрне туктатабыз, кадерле Нина ханым!.. Шуны гына әйтмәкче булам мин: боларның барысы да шәһәрләшү аркасында килеп чыга шикелле. Чөнки шәһәрдә яши башлаган ир-атка физик эш, аны чын мәгънәсендә ир-ат ала торган эш бик аз кала. Шуның өстенә, әле тагын акыл хезмәте белән шөгыльләнүче ир затлары күбәйде... Билгеле, башкача булмый диючеләр дә бар. Ләкин чынлыкта табигатькә, табигыйлеккә каршы килә торган нәрсә түгел микән бу??

Билал сөйли башлаганда тиз генә туктар кебек иде, әмма сүз артыннан сүз агыла торды, ул тиз туктый алмады.

— Хәзер кеше үз кыланмышларын табигать белән, аның мәңгелек һәм гаять көчле кануннары белән ризалаштырмыйча эшләргә өйрәнеп килә... Ул бары тик җәмгыять кануннарын гына санга сугарга өйрәнгән хәзер... Ә болай итү, минемчә, тирән һәм зур ялгышка китерергә мөмкин. Ни өчен дисеңме?! Менә ни өчен. Чөнки кеше — җәмгыять җимеше генә түгел әле ул! Ул — күбрәк табигать җимешедер әле! Табигый кануннар искә алынырга, санга сугылырга тиеш!

...Нина үзенең каршында үсеп утыручы юкәгә караган да, ята бирә. Билалның сүзләре аңа ничек тәэсир иткәнен тиз генә аңларлык түгел. Ике кулын ияк астына куеп терсәкләренә таянган ул... Әллә тыңламауның бер формасы бу, әллә әнә шулай, уйлана-уйлана тыңлый ул — кем белсен!

— Җә, житте! Бүтән мондый фәлсәфә сату юк! Шушындый ямьле көндә, мондый гүзәл хатынга җитди сүзләр сөйләп ятканымны белсәләр — дөньяның бөтен ир-аты җыелып, мине асып куяр иде!

— Мин синең сүзләреңне бик яхшы аңладым, Билал. Ләкин ул хакта үзем бер сүз дә әйтә алмыйм... Уйланган нәрсәм түгел чөнки... Моңа синең генә баш җитә. Минем баш юка бит ул...

— Юк, алай димә син... Просто, хатын-кыз натурасы башкачарак бугай инде ул. Үзең бая гына әйткәндәй, алар күбрәк күңел белән тоялар бугай дөреслекне, табигыйлекны, чынлыкны...

— Шулай шул... Әйдә, коенабыз! — Нина тиз генә сикереп торды да, Билалның кулыннан алды. Аны сөйрәп диярлек торгызды. Сүз белән мавыгып, кояшта нык кына кызганнар икән, башта әзрәк юынгалап тордылар. Аннары Билал эчкәрәк керде дә, Нинага су сипте. Тегесе аңа ике куллап чәчрәтте. Куыша-куыша, эчкәре үк кереп киттеләр. Бу юлы да рәттән, янәшә йөзделәр. Су салкынча, рәхәт, кояш шәп кыздыра, алар әлегә бәхетле — тагын ни кирәк мондый көнне сау-сәламәт булган адәм баласына?!

Шулай, көн саен төшке аш җиткәнче рәхәтләнделәр алар. Аннары ял йортына менәләр, тамак ялгап алалар, Билалның бүлмәсенә кайталар. Билал үзе икенче караватка ята, үз урынын Нинага бирә. Көн саен шулай черем итеп алырга өйрәтте Билал Нинаны да.

Йокыдан торгач көн дә диярлек урман сукмагына алып чыкты ул аны. Әз-мәз гөмбә дә таптылар. Савытлары булмагач, аларны агач төбенә калдырып китәләр дә, аннары «ак болыт астындагы», яшереп куелган гөмбәләрне таба алмыйча аптырап бетә иделәр... Кайбер көнне шул яшерелгән җирдә табылмый да кала бирде гөмбәләр. Хәер, гөмбә табу идемени соң төп максат!

Ә бер көнне икәүләп йөргәндә аларга аз сүзле өстәлдәшләре, керәшен татары Василий Петрович очрады. Кулына юан гына таяк тоткан, гадәтенчә, салмак кына адымнар белән килә. Башта Билалларны танымады шикелле — йөзен дә, адымнарын да үзгәртмәде. Биш-алты адымнар калгач Билалны танып алды да, кояштай балкып, кочагын җәйде:

— Менә бит нинди хөррият, ә?!

Ул туктап, әллә кайчангы танышлар шикелле, һәр икесе белән кул биреп күреште. Үзе бертуктаусыз елмайды, балкыды. Билал бу кешенең киң күңеллелегенә, олы җанлылыгына сокланды. Менә хәзер Билалның бәхетле булуы Василий Петровичның үзе өчен дә бик зур куаныч, бәхет шикелле иде. Шушы минутта, ахрысы, Билалның күңел төбендә йөргән бер уй да калкынды. Ул да күңеле булган чакларда бер фикерне кабатлый иде бит. «Керсез күңелле кешеләрнең бәхетле булуы — минем үз бәхетем кебек»,— дигән сүз иде. Менә шуны гел-гел искә төшерә ул... Әле хәзер дә, үзләре алдында чын-чыннан куанып торган Василий Петровичны күргәч, яңадан шул исенә төште... Әллә Василий Петрович та шундыйрак микән? Аны да кеше бәхете шулай нык сөендерә микән әллә?! Алайса үзе дә бик бәхетле кешедер ул!

Василий Петрович сокланып Нинага карап торды, Билалга ягымлы гына күз салып алды, аларны канатландырырдай сүзләр әйтте... Бераздан, яшьләрнең каушау галәмәте сизелә башлагач:

— Ярар, алайса... Мин киттем... Сезгә күңелле сәфәр,— диде. Алар яныннан китеп бер-ике адым узгач, яңадан артына борылды да:— Ә бу сукмак бит адаштыра... адашмассызмы икән соң?— диде. Билал аның сүзен чынга алып, ихлас күңелдән: «Юк, адашмыйбыз без!» — дигән иде, Василий Петрович сүзен бөтенләй икенчегә борып куйды:

— Ә мин сезнең урында булсам, адашыр идем!

Билал моңа каршы сүз таба алмыйча, кычкырып көлгән генә булды. Нина әз генә кызарып китте.

— Курыкмагыз, адашсагыз — иң беренче үзем эзләргә чыгармын!— Василий Петрович үз алдына елмайган килеш китеп барды.

Бу искиткеч яхшы күңелле кеше белән очрашканнан соң Билал да, Нина да тагын да үсенебрәк киткән төсле булдылар...

Көннәрдән бер көнне, урманда йөргәндә, Нина сорап куйды:

— Ә син монда озак булырга уйлыйсыңмы соң әле?

Бу сорауның Билал өчен ни икәнен, әлбәттә, яхшы белә иде. Шуңа күрә аны сүз арасында әйткән кебегрәк итеп кенә, артык мөһим мәсьәләгә санамагандайрак итеп кенә әйтте... Шул юл белән сорауның куркынычлыгын, хәвефлелеген киметергә теләде төсле.

Ә ачык кына итеп әйткәндә, Билалның әле һаман нык бер фикергә килгәне юк. Әнисе, гаиләсе исенә төшкәндә ул аларны хәтереннән чыгарып торырга тырыша... Гел диярлек, искә төшкән саен, котылырга тели ул уйлардан.

Менә хәзер Нинага җавап бирергә кирәк... Ул инде, мөгаен, берәр фикергә килгән дип уйлый торгандыр. Бу кадәр вакыт эчендә ир-ат үзенең уенда ныгый төшкән булырга тиеш дип ышанадыр... Ә Билал менә һич тә алай дип әйтә алмый шул әле... Ачык кына сүз әйтү, ай-һай, кыен аңа...

Ләкин ул, ачык кына бер карары күренмәсә дә, эченнән уйлана-уйлана, Нинага үз хәлен аңлатып карарга булды...

— Шундый-шундый карарга килгән идем дип синең алда күкрәк суга алмамдыр. Нинди дә булса бер юлны сайлап өлгермәдем әле. Тик шунысын ачык сизәм: кире кайтасым килми, бер дә килми минем!.. Анда кайтып яңи башласам, мин, гомумән, рухи яктан үз-үземне һәлак итәрмен сыман!.. Кире анда кайткан кеше — ул инде мин булмас төсле. Ә минем үз-үземнән алай тиз генә баш тартасым килми әле... Үзем өчен көрәшеп карыйсым килә!

Аның сүзләреннән соң Нина:

— О-о... әле сине буйсындырырга!..— дип куйды, сокланулы караш белән көч өстәгән сыман.

Әзрәк тын баргач, ханым болай дип тә әйтүне кирәк санады:

— Менә нәрсә, Билал... Мин сине ныграк белгән саен, шуңа ышана барам... Ә монда килеп бер атнага якын яшәү дәверендә инде ныклап ышанып та җиттем дияргә була...— шулай диде дә, никтер туктап калды Нина. Иреннәрен кыскан һәм нәрсәнедер бик киеренке уйлаган рәвештә бара бирде. Һаман дәшмәде... Аптырагач, Билал үзе сорады:

— Нәрсәгә ышана барасың? Нәрсәгә ышандың? Ник әйтеп бетермисең?— ул, шактый каты итеп, Нинаның кулыннан алды.— Әйт инде...

Юк, Билалның тавышында да, эчендә дә бернинди ачу юк иде. Бары нииндидер борчылу, нииндидер хәвефле сүз ишетермен дип шигәю генә көчәя төште аның күңелендә.

— Сүземне башлагач куркыбрак калдым әле менә мин, Билал... Бик әллә нинди сүз әйтергә җыенганмын икән бит!... Шул сүз телемә килгәч, синең өчен куркып куйдым...— Аның күз карашы сүрән, Нинаны нииндидер аңлаешсыз моң биләгән, ул хәзер шуның эчендә... Әлеге Билалга билгесез хәсрәтнең газабын кичерә Нина... Тик ни бу, нәрсә ул??

Билал, кызганып, аны кочагына ук алды. Чәчләреннән сыпырды, битеннән үбеп алды...

— Йә... әйт инде... Ни уйлыйсың?..

— Беләсеңме, син... син беркайчан да гаилә бәхете таба алмассыңдыр, ахры, дип уйладым мин... Чөнки син, чын ир-ат булсаң да — ә менә нәкъ шуның аркасындадыр да — бүген күпчелек хатын-кыз теләгәнчә гаилә кешесе була алмыйсың син... Бары тик гаилә турында гына уйлап, бары тик аның өчен генә яши алмыйсың син. Монда синең яныңа килгәндә минем күңел төбендә кечкенә генә бер хыял да бар иде әле, хәтта. Икебезнең уртак киләчәкне дә уйлап килгән идем әле мин... Ләкин юк икән. Без бергә була алмыйбыз икән! Синең күңеленә, рухыңа артык зур киңлек, артык зур иркенлек кирәк! Нииндидер хөр яшәү, киң колач белән, канатлы яшәү кирәк сиңа... Менә шул! Гаиләгә генә сыя алмыйсың син!

Нина тын калды. Бераздан тагын өстәп куйды:

— Беләм, бик авыр сүз бу... Гафу ит син мине, Билал...— Шулай диде дә Билалның кулын алды. Аны каты итеп кысты.— Мондый язмышлы кешегә нык, бик нык булырга кирәк!! Югыйсә... югыйсә... Ай, бу тормыш дигәнең! Адәм баласын күпме караңгы почмак сагалый анда...

...Аларның соңгы җитди сөйләшүләре әнә шундыйрак булды.

Билалның ничә көн буе көтеп алган Нинасы, үзе дә нииндидер яңалыкка, үзгәрешкә ымсынып килгән Нина, шундый ук матур бер иртәдә саубуллашып китеп барды...

## III

Нина киткәннән соң бик кәефсез йөрде Билал.

Нииндидер бүләк көтеп тә алалмаган, алданган сабый бала кебек — үпкәләгән, турсайган кыяфәттә иде ул.

Аннары ял йортының рәхәт тормышы аны әкренләп үз кочагына алды. Ул башкалар сыман тыныч кына яши башлады. Йокыдан торды, ашады-эчте, су коенды, йөреп килде, йоклады... Тагын ашады, тагын йөреп килде, тагын су коенды, тагын йоклады... Гүя, ул үзенең каян килүен дә, кем икәнен дә онытты.Тик әнә шул ипле тормышы тагын бер мәртәбә бозылды аның. Уйламаганда, көтмәгәндә килеп кергән бик куркыныч бер төш бозды аның тыныч ялын. Һич тә истән чыкмастай, чәчләрне үрә торгызырдай куркыныч, начар иде ул төш!

Каян килеп керә диген син аны!..

Имеш, Билал кулына бик зур, галәмәт зур пычак тоткан да... кызы Раушания йоклап яткан караватка таба килә! Билал үзе жылый, үзе үзәге өзелеп: «Кызым! Кызым!» — дип кабатлый... Ә үзе һаман килә, һаман якыная... Ниндидер көч аны этә, арттан этәрә — Билал шуңа каршы торалмый, туктый алмый — отыры якыная... Менә ул пычагын да бик якын китерә! Үзе торган саен кычкырыбрак: «Кызым!» — дип кабатлый... Ә Раушания берни сизми, тыныч кына йоклый бирә. Билалның ярдәм сорап кычкырасы килә, кемгәдер үзен туктатырга кушасы килә — тик күпме көчәнмәсен, тырышмасын — тавышы чыкмый, ул кычкыра алмый! Бары тик жылый гына. Ә үзе кулының кызы муенына таба һаман якыная барганын күрә!..Көч-хәл белән ычкынды ул шушы вәхши төштән. Уяну белән — шундук барып утын кабызды. Аннары әзрәк тынычлану өчен кранны ачып, битенә учы белән су бөркеде. Шуннан соң караватына килеп утырды да:

— Уф-ф, алла! — дип куйды. — Уф, алла... Миңа тагын нинди жәза инде бу!

Билалның төшләргә ышану гадәте бар иде. Төш белән чынбарлык арасында әлегә кеше аңлап житә алмаган зур бер бәйләнеш булырга тиеш дип саный иде ул. Әнә шуңа күрә үзенең төшләренә әһәмият бирә, алар хакында байтак кына уйланып йөри иде.

Ә бу юлы уйлану гына түгел, яктыра башлаганчы ятагында аунап чыкты. Йокысы тәмам качкан иде. Һич кенә дә күз йомарлык түгел иде шул.

Нәрсә диган сүз бу? Билгесезлектән нинди куркыныч хәбәр бу миңа?

Шул сораулар аның миенә кызган ук кебек килеп кадалдылар. Әмма зиһене аларга жавап таба алыр дәрәжәдә түгел иде. Бары тик ул сорауларның «зың», «зың» итеп баш миенә килеп кадалуы гына ишетелә кебек иде... һәм ара-тирә «Раушания» дигән бик якын исем чагылып китә иде...

Төн тәмам эреп бетеп, инде көн беленә башлаганчы әнә шулай миңгерәп ятты да, яктыргач кына тынычлап, янадан йокыга китә алды ул.

Әмма теге яман төш һич тә хәтердән чыгарлык түгел иде инде. Быелгы кайнар кояш кебек — баш очындагы гомерлек эссе юлдашына әйләнде ул Билалның...

## Нишләргә?

### I

— Ну, кызык та кеше инде син, ә!

Соңарып кына кичке ашка килеп кергән Билалны егетләр көлешә-көлешә каршы алдылар.

Билал аларның ни өчен шулай көлүләрен аңламады. Шуңа күрә, өстәл янына килеп житсә дә, утырмыйча, аптыраган кыяфәт белән басып тора бирде... Тегеләр һаман дәшмәгәч, аннары инде:

— Ә нәрсә бар соң? Ни булган? — дип сорарга мәжбүр булды.

Сергей Николаевич, ашавыннан бүленеп, аңа текәлде.

— Нәрсә, нәрсә! Яныңа кызлар үзләре килеп йөргәч, син хәзер совет почтасын санга да сукмыйсыңмыни?! Әнә, иртәдән бирле бер хат ята анда сиңа!.. Йөгер тизрәк!

Ләкин Билалның исе китмәде. Иплән кенә үз урынына кереп утырды... Аның хат көтәр кешесе юк бит, бәлки шаяртудыр... Аннары бирегә хат алу, хат язу ише мәшәкать белән изаланасы да килми

иде... Билалның лаеклы ялы бит бу! Бөтенесеннән, барысыннан туеп, качып киткән кешенең үзе теләгәнчә яшәргә хакы бардыр лабаса!

Кичке ашын тынычлап, тәмләп кенә ашаганнан соң — тәмам байларча кыяфәттә урамга чыгып барышлый гына алды ул үзенә килгән хатны.

Хат матур гына чәчкә төшерелгән гади конвертка салынган иде. Аның әллә көтелмәгәндә килүе Билалны бераз шыкайтты — кулына алгач та хатны ачарга ашыкмады. Салмак кына адымнар белән үзенең торагына таба атлады.

Эчкә кергәчтен дә әле турыга бүлмәсенә үтмәде. Холлдагы кәнәфи янында туктап алды. Нииндидер дөнья мәшәкате, дөнья кайгысы алып килгән бу хатны бүлмәгә алып керәсе килми иде. Аны алып кереп, тыныч бүлмәнең күнегелгән яшәү рәвешен бозасы, монда килгәч инде ияләнә башлаган тыныч, ипле яшәү көен җибәрәсе килми иде... Әнә шул монда тапкан рәхәтлеге бик кадерле иде дөнья ыгы-зыгысыннан арыган Билалга!

Теләр-теләмәс кенә конвертны ачты. Ачкан вакытта почта штемпеленә күзе төште. Анда Билал калдырып киткән шәһәр исеме иде. Бик тә канәгать булмаган чырай белән генә укый башлады...

**«Исәнмесез, Билал әфәнде!**

**Сезнең тыныч ялыгызны бүлеп, хат язарга җөрьәт итүче кешеләр кемнәр икән бу дип аптырамагыз — эштәгеләр исеменнән, яшь дустың Марат хат яза. Безне онытмагансыздыр бит?**

**Ялдагы кешене борчып хат язуыбызның сәбәбе шул: колагыбызга яман хәбәр керде — имеш Сез безгә яңадан кире кайтмаска уйлыйсыз икән. Каядыр ераккарак, тынычрак җирләргә китмәкче буласыз икән.**

**Шактый ышанычлы кешеләрдән ишетсәк тә, без бу хәбәргә башта ышанмадык. Чөнки ул хәбәр без белгән Билалның холкына туры килми. Ул кеше, безнең уйлавыбызча, алай эшләргә тиеш түгел иде.**

**Әмма, тора-бара, без сагая калдык. Соңгы вакытта Сезнең үз-үзегезне тотышыгызны кабат-кабат күз алдыннан үткәрдек. Әйткән сүзләрегезне яңадан-яңадан искә төшердек. Һәм... безнең колакка тагын бүтән имеш-мимешләр дә ишетелде... Шуннан соң инде, әлеге хәбәрнең чыннан да дөрескә чыгу ихтималын күреп, шул мөмкинлекне уйлап, байтак кына киңәшкәннән соң, Сезгә менә шушы хатны язарга булдык.**

**Без монда кайта-кайта шуны уйлыйбыз — Сез, архитектурага, эшкә, чын иҗатка шулкадәр нык бирелгән кеше — ничек шундый карарга килә алдыгыз? Сезне моңа нәрсә этәрде икән?**

**Әйе, безнең еллар буена дәртләнеп, илһамланып эшләгән, иң матур идеяләребезне салып иҗат ителгән Сәнгать сараебыз зур гына каршылыкка очрады. Әйе, уртак иҗат җитмешебезне тормышка ашыру өчен безгә иң элек үзебезнең яңа директорыбызны килештерергә туры киләчәк. Бу эш җиңел булмас, билгеле. Аннан соң шәһәр Советы башкарма комитетында зур көрәш тотарга туры киләчәк.**

**Бәлки, Сезне әнә шулар барысы куркытадыр?**

**Дөреслекне Сездән яшерергә кирәкмәс — без төзергә, без күрергә теләгән Сәнгать сараеның язмышы, чыннан да, кыл өстендәрәк. Яңа директор бу вариантка бик нык каршы, үз сүзеннән һич тә чигенергә теләми. Безнең башкалабызда үсеп чыгачак Сәнгать сараена ул стандарт бер бина итеп кенә карый. Атна саен диярлек җыеп, безне шундый проект төзергә өнди, шуңа күндермәкче була...**

**Менә шундый хәл. Монда хәзер Сәнгать сарае өчен чын көрәш башланып килә. Һәм ул җиңел булмаячак. Бик авыр булачак. Ләкин, Билал әфәнде, Сез шуны уйласагыз иде: тормышта каршылыкка очраган һәркем шулай үз эшен, үзенең позициясен ташлап кача башласа, бу дөнья кемнәр кулына калыр икән соң?!**

**Көчле кешеләрнең холкы, беләсезме, нәрсә белән аерылып тора? Алар үзләре ошатмаган яшәү рәвешен ташлап, калдырып качмыйлар. Алар әнә шул яшәү рәвешен үзләре теләгән якка, матур якка таба үзгәртү өчен көрәшәләр. Әйе, шуның өчен көрәш ачалар! Әнә шундый кешеләрне сокланып: «Көчле кешеләр!» — дип атыйлар!**

**Тагын шуны исегезгә төшерегез — Газиз абый вакытында без ничек күмәк булып эшли идек! Хәлбуки, ул вакытта да зур идеяләрне тормышка ашыру җиңел түгел иде! Без иҗат эченә чумып, шул дөньяда гына кайнап, ул каршылыкларны бары тик күрми, тоймый гына идек!**

**Аларны, ул каршылыкларны җиңүне, барысын да Газиз абый үз өстенә ала иде ул вакытта! Без ул чагында тылда, ягъни саф иҗат дөньясы эчендә кала идек.**

**Менә бит төп хикмәт нәрсәдә! Ә хәзер Газиз абый алып барган байракны үзебезгә алырга кирәк! Үз кулыбызга. Газиз абыйның юлына тугры калыйк дисәк, бездән хәзер әнә шул таләп ителә...**

**Гүзәл Сәнгать сарае өчен — әнә шул матурлыкны чынга ашыру өчен — без үзебез үк җиң сызганып көрәшергә тиеш! Чөнки... Чөнки бүтән кеше юк! Чөнки көрәшнең бу тармагы, бу өлеше безнең язмышка туры килгән!**

**Бик тә купшы сүзләр яза болар диеп уйламагыз... Хәер, без Сезне беләбез бит. Сез купшылык белән чынлыкны бик тиз аерасыз.**

**Әлбәттә, биредәге тормышыгызның башка якларын без бик үк белеп бетермибез... Бәлки Сезнең башка кыенлыклар, каршылыклар да килеп чыккандыр... Ләкин... Ләкин, үзегезнең хәлегез ничек кенә авыр булып тоелса да, Сез барысын да ташлап качарга тиеш түгел!**

**Хатыбызның ахырында бер мисал китерәсебез килә... Александр Фадеевның «Тар-мар» дигән әсәрен онытмагансыздыр, шәт. Ерак Көнчыгыш тайгасындагы партизаннар отряды аклар белән бер бәрелеш вакытында тәмам тар-мар ителә, юкка чыгарыла... Отряд командиры Левинсон тайга уртасында бер ялгызы утырып кала... Аны тәмам өметсезлек баса, күңелен төшенкелек били... Чарасызлык... Шулай, нишләргә дә белмичә, озак, бик озак тора Левинсон... Әмма, ахыр чиктә, беләсезме нәрсә уйлый ул? Менә шушы, соң дәрәҗәдәге өметсезлек хәлендә дә ул:**

**— Ләкин яшәргә һәм алда торган бурычны үтәргә кирәк! — дигән нәтиҗәгә килә!**

**Бу сүзләр бүген барыбызны да уйландырырга тиеш дип саныйбыз без.**

**...Ярый, хатка язып сүзләр бетмәс. Сау булыгыз!**

**Биредә, үзебезнең эш бүлмәсендә очрашуга бик нык ышанабыз. Без элекке Билалга, көчле ихтыярлы Билалга, ышанабыз!»**

## II

Хатны укып чыкты Билал...

Аннары, бер мәртәбә укудан гына әллә ни аңламыйча, шундук аны өр яңадан укый башлады... Тагын бер кат укыды...

Шуннан соң инде, баскан урынына кадаклап куелган сыман, бер адым да атлый алмаенча, бик озак вакыт тәрәзәгә карап торды... Юк, инде байтактан бирле ял иркендә яшәүче, рәхәт җәй кочагында иркәләнүче кешенең башына тиз генә сыя алмыйлар иде әлеге хатка язылган сүзләр. Алар, ул сүзләр, ниндидер китаптан — зур фаҗигагә тарыган көчле геройлар хакындагы китаптан — адашып килеп кергән төсле иде Билалның тормышына. Ә Билал үзе, үз яшәве белән андый кискен сүзләргә һич тә лаек түгел кебек иде! Ул ничек кенә яшәсә дә, барыбер, саф һәм керсез намус белән калыр шикелле иде! Әлеге хаттагы сыман сүзләргә ул беркайчан да дучар булырга тиеш түгел иде!

Нишләптер, ни өчендер бары тик әнә шулай гына булырга тиеш иде сыман...

Ә менә аны дуслары бик зур начарлыкта гаеплиләр. «Курыктыңмыни? Качасыңмыни? Син шундый кешемени?..» — диләр.

— Мондый хәл булмаска тиеш! Юк, бу дөрес түгел! — дип, ниһаять, хатны өченче мәртәбә укый башлады Билал. Бу юлы инде кәнәфигә утырып, иркенләп, хаттагы һәрбер юлны, һәр җөмләне аерым-аерым алып — әнә шулай итеп, ни язылганны тәмам аңлап җитәргә теләп укыды ул.

Әйе, чыннан да, шулай иде шул... Ничә еллар буе бергә эшләгән дуслары аны качуда гаеплиләр иде.

— Барыбер дөрес түгел! — Ул сүзен рәсларга теләгәндәй, үз фикерен барысыннан өстен чыгарырга ашыккандай, кулындагы хатны конверты ние белән тумбочка өстенә атты. — Минем хәлне аңламыйсыз, аңлый алмыйсыз сез! Сез гаепли генә беләсез!

Ярсыган, үзен-үзе яклап хәтта сугышыр хәлдә, урыныннан сикереп торды. Кечерәк кенә холлның иңен-буен бер итеп, арлы-бирле йөрергә тотынды. Эчендә, күңелендә моңарчы җыелып килгән сүзләр, уйлар, бөтен газаплы кичерешләр менә хәзер ниһаять юл табып, кайнап ташкан булып тышка агыла иде.

«Юк! Сезнең берегезнең дә минем хәтле — иртә таңнан кичке караңгыга кадәр эш бүлмәсендә кала-кала, уртак эшебез булсын-булсын дип җан атып, бөтен дөньяны онытып, тырышканыгыз юк! Сез — шәһәр егетләре! Сез үз көчегезне акыл белән исәпләп, дөрес итеп бүлә-бүлә файдалана беләсез! Автомат машина кебек... Ә мин менә алай булдыра алмыйм! Мин үземнең яраткан эшемә муеннан чумып, җаным-тәнем белән бирелеп кенә эшли алам!.. Әнә шуңа күрә... шуңа күрә мин артыгын борчылам да!

Менә бу кеше белән дә — бөтен сәнгатьнең, архитектураның кан дошманы булган яңа директор белән дә — бергә эшләргә һәм аны җиңәргә, аны килештерергә кирәк, дисез сез! Ә мин аны, гомумән, күралмыйм! Безнең архитектураны бетерергә яралган бәндә ул! Аның белән инде ничек бергә эшли алыйм мин! Моның өчен бит миңа тимер булырга, җансыз булырга кирәк!»

Әнә шулай бик озак кайнады, дулады Билал.

Бу минутта ул бары тик үзен генә хаклы, дөрес итеп сизә иде. Аны беркем дә аңламый, аңларга теләми кебек тоелды. Ә менә бу хат инде аны бирегә, ял йортына килеп изәр өчен язылган төсле иде...

Аннары... атып бәрелгән хатны теләр-теләмәс кенә барып алып, бүлмәсенә кертеп куйды. Үзе шундук кире чыкты. Әйтерсең, анда — бүлмәдә хәзер ниндидер тешли торган явыз җәнлек бар!

Ниһаять, ул һавага — җәйге кич канат җәйгән табигать кочагына чыкты. Бу юлы, гадәтенчә, урман юлы белән түгел, аллея буйлап китте.

Биредә дә күзенә ак-кара күренмәде. Аның бөтен барлыгын әлеге ярсу, ачу биләп алган иде. Ул нәрсәнедер рәслап, ышандырып бетермичә һич кенә дә тынычлана алмас төсле иде.

Шулай аһ-уһ килеп йөргәндә, аны берәү туктатты. Күтәрелеп караса — Василий Петрович икән! Аңа караган да елмаеп тора.

— Йә, нәрсә булды?.. Нигә балтасы суга төшкән кешедәй, аптырашта калдың әле?

Бераз ык-мык итеп торганнан соң, сөйләми булдыра алмады Билал. Үзләренең эшендә туган хәлне әнәсеннән җебенә хәтле сөйләп бирде... Василий Петрович аны бер дә бүлдермәде. Бары тик тыңлады гына. Билал тынып калгач та сүз башларга ашыкмады ул. Сүзсез генә бардылар да бардылар. Ике ягына яшь юкәләр утыртылган аулак аллея менә шушы сүзсез әңгәмә өчен бик кулай урын иде.

— Беләсеңме, мин сиңа нәрсә сөйлим хәзер, Билал?!— Василий Петрович барган җиреннән туктады. Акыллы коңгырт күзләр тагын да уйчанланып китте.— Үз башымнан кичкән бер бик гыйбрәтле вакыйганы сөйлим мин сиңа... Фронтта булган хәлне.

### III

Кырык бернең көзендә булды бу... Төп-төгәл исемдә. Бүгенгедәй.

Фронтта безнең эшләр шәптән түгел. Немец тимер ташкын булып, ыжгырып килә. Бөтен яктан ут ява — дөньяның асты өскә килә, адәм чыдамастай мәхшәр... Ул да булмый: немец йә теге яктан, йә бу яктан оборонаны өзә дә, әллә ничә чакырымга эчкәре үтә. Уяурак тормасаң, шул арада чолганышта да каласың... Шуңа күрә солдатлар арасында төрле хәлләр очрый, куркучылар да шактый.

Октябрь башларында безнең дивизия дошманны берәр атна чамасы туктатып торды. Ул елны бик сирәк очрый торган хәл иде бу. Шунлыктан тиз-тиз оборонаны ныгытабыз. Мөмкинлек туса, бәлки әле һөҗүмгә дә күчәрбез, диләр. Әмма оборона булса да, һөҗүмгә күчсәң дә — гел разведка кирәк. Шунсыз булмый.

Көзнең салкын бер төнендә Женя исемле украин егете белән мине разведкага җибәрделәр. Немец бездән бер-ике чакырымда булыр. Аның ныгытмалары ничек урнашканын белергә.— Безгә шундый бурыч куелды.

Ике арада тирән-тирән чокырлар, адым саен агач, куак. Аларның төнлә ни икәнен дә аерып булмый. Тирә-юнь дөм караңгы. Әкрен генә атлыйбыз шулай... Абына-сөртенә калсак, немец ишетмәдеме дип, озак кына тыңлашып та торабыз... Аннан тагын кузгалабыз... Тагын тыңлашабыз... Шулай байтак кына ара үткәч, немецлар урнашкан калкулыкка якынлаштык. Ул яктан җил искәндә сөйләшкән тавышлары да ишетелә башлады инде... Ләкин болай гына булмый безгә. Ерак чөнки. Тагын да якынрак килергә кирәк. Ничек, каян барырга дип җай эзлибез... Ул арада Женя пышылдый:

— Иптәш сержант, мин теге калкулыкка барып килим. Аннан шәбрәк күренергә тиеш... Ә сез монда торып торыгыз!

Чыннан да, алда бер бәләкәй генә үр бар иде — шуңа күрсәтә икән теге.

— Ярый,— дидем. Килештем.

Китте бу әкрен генә, сак кына шуышып. Тиз арада күздән дә югалды. Мин дә тик ятмыйм. Икенче яккарак барып, тегеләрнең траншеяларын күзлим, ут нокталарын барлыйм... Шулай байтак кына гомер үтте. Инде Женя кайтырга да вакыт кебек. Әмма, юк... Тагын көтеп карыйм... Һаман юк бу! Нәрсә булды икән?— дим... Ул киткән калкулыкка да шуышып барып карадым — юк, бер кайда да юк!! Суга төшеп батты диярсең.

Инде дә бүтән мөмкинлек калмагач — тиздән яктырачак иде — немецның үзем күргән ут нокталарын, траншеясын истә калдырып, берүзем борылып кайттым, нишлисең...Менә шундый бер хәл булды кырык беренче елның көзендә...

Инде хәзер сугыш беткәнгә дә кырык ел. Әмма шул вакыйга һич истән чыкмый! «Ни булды икән бу егет белән?» — дип уйлыйм.

«Теге якка качарга мөмкинме, юкмы ул?» — шул сорау гел тынгы бирми миңа бүген дә...

Хәзер аның турында бөтен белгәннәремне хәтергә төшерәм. Холкын, табигатен тулысынча аңламакчы булам. Кем икәнен, кем булуын ахырынача төшенәсем килә!

Юк, болай без күреп өйрәнгән куркакларга охшамаган иде ул. Андый түгел иде... Ләкин менә шунысы да бар: бер ә үзенә кыенлык китерергә яратмый иде инде! Теләсә нинди җай табып, теләсә нинди хәйлә белән, барыбер, үзенекен өскә чыгара иде! Әнә шул яктан бик шома иде... Аның нинди дә булса изге санаган нәрсәләре, ныклы иманы булуы да сизелмәде...

Әйтәм бит, һаман искә төшә ул, кайта-кайта уйлыйм: «качарга мөмкинме, юкмы ул? Мондый кеше, мондый адәм иң авыр чагында икенче якка — дошман ягына — чыга аламы юкмы?»

Әйтмим, сугышта төрле хәлләр була. Кеше хәбәрсез дә югала. Ләкин күпләрне мин белә, аңлый идем: юк, бу ташлап качмаячак! Моның белән разведкага барырга була! Ә байтагында әле икеләнәсең — авыр чагында ничек булыр бит, дисең... Кайберсен инде алдан ук сизеп, белеп торасың — моның белән разведкага барып булмый. Бу үзенә җайсызга калса, сине язмыш кочагында калдырачак!

Ә менә теге егет хакында мин әле һаман үземә ачык кына җавап бирә алмыйм. Кем булды ул? Нинди кеше булды?

Ул елны фронтта безнең хәл авыр иде бит...

Менә шулай, Билал дус...

## IV

Әйе, Василий Петровичның хикәяте гыйбрәтле иде. Бүлмәсенә кайткач ул сөйләгәннәрне бик озаклап миенә, башына сеңдереп утырды Билал.

«Кешене ныклап белү өчен аның белән бер пот тоз ашарга кирәк»,— диләр... Ә без менә тыныч тормышта тегене дә, моны да дус дип йөрибез... Адым саен мәҗлесләр җыябыз. Үзара макташабыз! Ә шундагы дистәләгән «дус»ның кайсы чыннан да дус — моны үзебез дә ачык кына белмибез! Авыр чакта кемнең дошманга әйләнүе мөмкин икәнен дә белмибез!

Ни өчен белмибез?

Чөнки... Чөнки, моның өчен әлегә дә баягы — бер пот тоз ашау — четерекле хәлләр аша үтеп карау кирәк! Бик каты сыналу кирәк!..

Үз уйларының әнә шул җиренә җиткәч, кинәт, сискәнеп китте Билал.

— Тукта... Билал үзе дә хәзер сынау алдында тора түгелме соң? Билалның иптәшләре хәзер анда, ул ташлап киткән эссе шәһәрдә тырыша-тырмаша, җан-фәрман эшләп ята түгелме соң?!

Әйе, алар анда... Ә соң Билал кайда?..

Шушы гап гади сораудан соң, бу бик тә борчулы җәйнең озакка сузылган эссесендә инде тәмам чуалып беткән баш бераз яктырып, ачылып киткәндәй булды. Әйтерсең лә, кайчандыр томаланган чишмә яңадан саркып кына үзенә юл ала башлады.

Әйе, куелган сорауга җавап бирмичә булмый шул. Билал хәзер Якты күлдә ята. Якты күл — билгеле, бик тә рәхәт җир. Тыныч урман, матур ял итү урыны... Әмма шунысы бар: күл шул ул, күл генә шул! Ә бит әле дөньяда дәрьялар бар. Яшьлек хыяллары аша Билалга бик тә таныш, бик тә үз булган дәрьялар бар! Шаулап, гөрләп агучы — киң сулы, ярсу агымлы дәрьялар бар!

Шәһәрдә калган иптәшләре, фикердәшләре бер-бер артлы аның күз алдына килде.

Кызы Раушаниянең алсу иреннәрен турсайтып: «Әти, син кайчан кайтасың инде?» — дип йөдәтүләре тагын бер мәртәбә үзәкне өзеп, бәгырьне телеп алды.

Һәм Билал тора-бара үзен аучылар чолганышында калган, менә хәзер, алар ихтыяры буенча, шулар теләгән якка чабучы бер кыргый

җәнлек итеп сизә башлады. Әлеге аучылар Билалны ниндидер бер тар утарга, җан теләмәгән бер кысан аранга куып кертергә һәм аны шунда кулга ияләштереп, гомергә әнә шунда яшәтеп калдырырга телиләр иде сыман.

Яңа уйлары белән күбрәк очрашкан саен безнең бу качкын егетебез әлеге «аучылар»ның үзен уратып алган күзгә күренмәс чылбыры бик нык икәнен аңлый барды. Билал үзендә әлеге чылбырны өзәрлек көч таба алырмы? — Әлегә ул моны үзе дә белми иде...

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Рәсәй турында фикерләр

**Ф. М. Достоевский:**

«Россия, упкын өстендә чайкалып, ниндидер ахыргы ноктада басып тора.

... Кан белән юылса гына нык булачак, имеш. Андый бәдбәхетләр шуны оныталар — кан коючыларның түгел, каны коелучыларның аяк асты нык булачак».

**Л. Н. Толстой:**

«Әгәр Россия иманын югалта икән, ул ришвәтчелек, эчүчелек һәм фәхишәлек сазлыгына кереп батачак».

**Н. Н. Страхов:**

«Кешеләр аңга килсен өчен коточкыч бәлаләр, тулы бер өлкәләрнең бушап калуы, янгыннар, шәһәрләрне җимерү, миллионнарны рәнҗетү кирәк. Хәзергә әле чәчәкләре генә»

**Хәрби министр Д. А. Милютин:**

«... Мин Петербургта гаҗәеп хәл күрдем: хәтта хөкүмәт дәрәҗәсендәге югары даирәләрдә дә радикаль үзгәрешләрнең кирәклеге хакында сөйләшәләр, хәтта «конституция» сүзен кулланалар. Тормыштагы тәртипләрнең ныклыгына берәү дә ышанмый».

**Хәрби прокурор хатыны А. П. Философова:**

«Мин хәзерге хөкүмәтне күралмыйм, болар — Россияне һәлак итүче караклар төркеме».

# ШИГЪРИЯТ



## Шамил Маннап

### УЙЛАНУ

### МИЗГЕЛЛӘРЕ

* * *

Зурны кече итеп буламыни —
Басып аның иңе өстенә?
Түбәсенә авыр кар басса да,
Түбәнәйми таулар һич кенә.

* * *

Тау өстенә шәһәр салса кеше,
Тау таулыгын җуя.
Таудан биек саный икән үзен —
Уяулыгын җуя...

* * *

Җомга намазына бара картлар
Адымнары салмак, тын, сабыр.
...Ашыга да яшьлек, соңга кала,
Юлын бела картлык —
Соңармый...

* * *

Татар өчен нигә газиз
Сөембикә манарасы? —
Ул бит татар йөрәгенең
Кардиограмма энәсе.

---

Шамил МАННАП (1938) — *шагыйрь һәм прозаик. Дистәдән артык китап авторы. Казанда яши.*

* * *

Кемнәр яши икән бу өйдә, дип,
Тәрәз каршысында тукталам гел.
Тәрәзәдән карап, яңгыр кәтә
Түбе коргаксыган, сусаган гөл.

* * *

«Халкым, халкым!» диюләрең нигә,
Җылы хисең синең калмагач.
Ничек сыяр йөрәгеңә халык,
Бер кешегә урын тапмагач?

* * *

Манарасын кисеп мәчетләрнең,
Чиркәүләрнең алып чаңнарын,
Теләделәр бугай халыкларның
Башсыз, телсез, тынсыз калганын.

* * *

Фамилиябезгә тагылган
«Ов»лар, «ский», «ин»нар.
Булсын диделәр микәнни
Болар — «сукин сын»нар?!

* * *

Үләргә теләгәндә дә
Үлалмыйча калдым мин —
Ләүхелмәхфүздә язылган
Язмышка ышандым мин.

* * *

Ник кайвакыт төрле шикләр белән,
Чикләү белән сине борчыйм соң?
Йә мин сине белеп бетермимдер,
Йә беләмдер күбрәк — тормышны...

* * *

Шигырь — илаһи сүз, — сөйләгәндә
Кычкырма, йә йодрык болгама.
Ишетмичә калмас сине халык,
Әйтер сүзең ихлас булганда.

* * *

Бабаларым җирне яратканнар,
Яратканнар эшчән атларны...
Югалудан — җире белән аты
Саклап тота бугай татарны.

* * *

Яшә бу фани дөньяда,
Каргалсаң да — каргамыйча.
Пәйгамбәрләргә дә элек
Таш атканнар — аңламыйча...

* * *

Һич ашыкма, үзгәрешләр юк, дип,
Хаклык йоклый, диеп әрләргә,—
Җир үзе дә хәрәкәтсез кебек,
Ә бит әйләнә ул, әйләнә...

* * *

Бакчабызда үскән таллар кебек,
Без туганнар — бер үк тамырдан.
Беребезгә әгәр дым җитмәсә,
Барыбызга килә авырга.

* * *

Тәҗрибәсез идек,
Кайчак Хамның
Этлегеннән бары көлдек тик...
Көлә-көлә аңа дәрман бирдек,
Шулай алды Яман — өстенлек.

* * *

Безне, улым, сугыш гарип итте,
Без әтисез үскән буын ла.
Шуңа, бәлки, өйрәнәлми калдык
Үзебез дә Әти булырга...

* * *

— Гел үзгәртеп кору, дисез,
Ни ул үзгәртеп кору?
— Уртак йортны җимерү һәм...
Үзеңә ташып тору.

* * *

Империяне —
Дуслык иле диеп,
Күпме яшәп була ялганлап?
...Үлгәнне бит саклап булмый — тагын
Мавзолейга куеп, бәлзамлап...

* * *

*Илһам Шакирга*

Ярый әле
Син тугансың, Илһам! —
Замандашлар булдык:
Нинди бәхет! —
Милләт урамыннан
Бергә җырлап уздык...

* * *

Әдәби телдә — тигәнәк,
Безнең якта — кырмавык...
Арасында кызлар кочтык,
Кырмавык дип тормадык.

* * *

Кояштан алган яктысын
Җир белән бүлешә Ай.
Шуңа аның йөзе нурлы,
Шуңа — ул хыялга бай.

* * *

Яшьлек узды.
Кайчакта ул
Була миндә кунакта:
Ят күзләрдән кача-кача
Шигырьләр язган чакта...

* * *

Үзенең парын табу өчен генә
Сайрый, диләр былбылны.
Мин дә сиңа атап җыр чыгардым, —
Ил тыңлады җырымны.

* * *

Шигырьләрен илгә таратса да,
Шагыйрьләрен, бәлки, яратмый? —

Үзенчәрәк яши бирә дөнья,
Безнең теләк белән санлашмый.

* * *

Очма! — дип әйтеп буламы кошка?
Исмә! — дип әйтеп буламы җилгә?
Акма! — дип әйтеп буламы суга? —
Ә ник киртә куя дөнья шагыйрьгә?!

* * *

Син кайгырма, шагыйрь, бу арада
Аерылдым, диеп, җырлардан...
Сиңа түгел, хәтта пәйгамбәргә
Вәхи бит гел иңеп тормаган.

* * *

Узган хатаң өчен тәүбә итү —
Соңлап килгән яңгыр шикелле...
Күз яшьләрем агып, битләремдә
Ерганаклар калыр шикелле.

* * *

Кыраулар төшмәсен дисәң
Бәхетеңнең гөленә,—
Узганыңа үкенмә дә,
Киләчәккә — көенмә.

* * *

Дөрес яшен аның белим дисәң,
Карашын бел мәхәббәткә:
Картайганның, диләр, мәхәббәте
Әверелә тик мәшәкатькә...

* * *

Кемнәрдер гаепләр сине,
Кемнәрдер, бәлки, аңламас.—
Йөрәгең кушканча яшә,
Йөрәгең сине алдамас.

* * *

Карашларны күккә юнәлдереп,
Калкып тора яңа манаралар.

Янардымы әллә заманалар,
Иманнармы әллә яңаралар?

* * *

Борын заманда кяферләр
Табынган жансыз сыннарга.
Шул потка табыныпмы, без дә
Әйләндек имансызларга?

* * *

Картайганга мәллә — нигә Җиргә
Игътибар юк, хөрмәт-кадер юк?
Җирнең безгә ихтирамы бетсә,
Нәрсә булыр? — уйлыйк хәзер үк...

* * *

Курыктылар: шагыйрьләр дип арта,
урын җитмәс гәзит-журналда.
Ләкин шагыйрьләрдән күпкә артты
сугышучы яшьләр урамда...

* * *

Узганны яманлап та
яшәп була икән бит,
яңа «иман» үзләштергәч,
әйбәт була икән бит...

* * *

Туган тел көчле корал ул
Туган халкың саклауда.
Тик — туган тел үзе әле
Мохтаҗ бүген яклауга.

* * *

Шәһәр өстеннән агыла
әллә болыт, әллә төтен,
әллә минем өметсезлек,
әллә минем өметем?

* * *

Хәким кебек шагыйрьләрнең
бар иде бит «Дуга»сы.

Эх, безгә дә дуга белән,
пар ат җигеп, дога белән
олы юлга чыгасы...

* * *

Ник тавышы моңлы дисәң
кулларымдагы сазның? —
Язмаган чакта — авырдым,
авырган чакта — яздым...

* * *

Картаяммы? —
Бер сүз белән кайчак күңлем була,
Бер сүз белән кайчак күңлем тула.
...Елганың да койган җирендә
Дулкын ярга ныграк сизелә.

* * *

Әниемдәй газиз кеше булып,
Кердең, иркәм, син тормышыма:
Әнием тәүге авазыма шаһит,
Ә син, бәлки — соңгы сулышыма...

* * *

Бу дөньяда байлык түгел,
Эзләдем Хакыйкатьне.
Җитә миңа бер аршын җир —
Язу өстәлем чаклы...

* * *

Туган җирнең бер кисәге ич мин:
Канда — сихәт биргән чишмә суы,
Тәндә — икмәк белән сеңгән нуры,
Күңелемдә бабамнарның җыры —
Шушы җиргә тартылмыйча, нишлим?!

* * *

Яшь вакытта булдык җүләр без,
Мәхәббәтнең кадерен белмәдек.
Һәм Мәхәббәт төшеп ватылды...
Хәзер инде без бик акыллы.



# Мансур Шиһапов

## Бәхилләшмим — саубуллашам

*Җыр*

Мин дөньяга килү белән
Анам кат-кат юган чишмә...
Саубуллашырга дип килдем
Язгы кичтә, чумып хискә.
Саубуллашам ярлар белән,
Ярда үскән таллар белән,
Тәпи баскач, нурга күмеп,
Юл яктырткан таңнар белән.

Беренче хис хатирәсе —
Юл чатында ялгыз каен.
Каен төлгәшләре кебек,
Булды башым игән аем.
Ялгыз яндым көннәр-төннәр,
Тик сынмадым, сыгылмадым.
Бәхилләшмим — саубуллашам,
Бала чагым, туган ягым.

Яшәү көче биргән әнкәм,
Җан җылысын өрә-өрә,
Ак күлмәктән, ак чәчәктәй,
Пакь җан булып төшкә керә.
Кызыл, зәңгәр, ак, шәмәхә
Чәчәкләрдән чәчәк туган,
Бәхилләшмим — саубуллашып,
Китеп барам кайтыр юлдан.

Пар ат җигеп, язмыш юлын
Парлап үткән тормыш дустым,
Яраланган яшьлегемә
Канат биргән очар кошым,
Яшь җилкенчәк тә көнләшсен,
Сөю хисен чәчик әле,
Тагын йөз ел — бәхилләшми,
Җир җимереп яшик әле.

---

Мансур ШИҺАПОВ (1940) — *«Әйләнеп кайтыгыз» исемле китап, шул исемдәге һәм башка күп популяр җыр сүзләре авторы. Журналыбызда беренче мәртәбә басыла. Казанда яши.*

## Яңа елның туар көне

Иске елның соңгы киче,
Ай никтер тоныкянып,
Әйләнә җирне уратып,—
Уйланып, сагышланып.

Яңа ел алды кичендә,
Теләкләр тели-тели.
Ай күк әйләнеп күңелем
Сезнең якларда йөри.

Өй түрендәге чыршыда
Мин йолдыз булып янам.
Тәрәздән исеп — серле җил —
Чәчеңнән сыйпап багам.

Талган күзеңнең нурларын
Җан җылым белән төреп,
Керфегеңдә калган яшьне
Киптердем өреп-өреп.

Яңа язган яңа җырым
Моң булып агыла ла,
Әрнүләрне таратырга
Кайттың, дип, безнең янга.

Үзеңә авыр булса да,
Сораштың минем хәлне.
Яңа елда бәхет теләп,
Сәгать сукты бер мәлне.

Парлылар җырлап уздылар,
Тибрәтеп йөрәк түрен...
Ялгыз ай тыңдәшен эзли,
Айкап дөньяның күген.

## Сагынам

*Җыр*

Чылтырап аккан чишмәле,
Айлы, кояшлы ягым.
Кем генә сагынмый икән
Кырда бәрәңге пешереп,
Кинәнгән бала чагын.
Авылдан киттем — авылны
Шашып сагыныр өчен,
Язгы ташкын булып кайтып,
Таңда каршыңда тезләнер —
Кат-кат табыныр өчен.

Чалгы яңый чишмәлектә
Кем булсын, әткәй җаным.
Төшкә керә әнкәй язын,
Көянтәсен иңгә салып,
Талир тәңкәләр тагып.

Күкләреннән йолдыз чүпләп,
Күзләрне күзгә багып,
Ничек сагынмасын күңел
Беренче сөю китергән
Сагышлы авыл таңын?

Сабантуйда пар ат җигеп,
Кем урлый сөйгән ярын?
Ул без идек кыз урлаучы,
Тальян гармун кыңгыравы
Чыңнарын моңга салып.

## Сынмадым-сыгылмадым

*Җыр*

Кыр казлары белми әллә,
Күктән барыр юлларын?
Кайда илтеп аттың, язмыш,
Илнең гүзәл улларын?
Кемнәр сатты, кемнәр атты
Татар зыялыларын?

Юл чатында ап-ак шәлдән
Калдың — яулык болгадың,
Себер урманнарын ярып,
Тальян булып чыңладым.
Дошман сынды, син — мәхәббәт,
Сыналдың, сыгылмадың.

Зил-зиләле давылларда
Илдән хәбәр тыңладым.
Тамырларымны куптарды,
Ләкин үзем сынмадым.
Туган яктан җыр агылса,
Дус-ишләрне уйладым.

Күпме язлар, кошлар кайтты,
Мин юк идем, дускаем.
Салават күпере чыкса,
Кавышуга юрадың.
Яшьләр түктең, рәхмәт, көттең,
Сынмадың-сыгылмадың.



## Рафаэль Хәким

# ИМПЕРИЯ КОЯШЫ БАТКАНДА

(МИЛЛӘТ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР)

### Кереш сүз

**Динозаврлар үлеп юкка чыккан сыман, империяләр дә мәңгелек түгел. Теләсә кайсы империя төрле халыкларның, аларның җирләренең, мәдәниятләренең ясалма бер кушылмасы, анда табигый бөтенлек булмый, шуңа күрә дә, мәркәзе хәлсезләнүгә, ул төрле-төрле кисәкләргә бүлгәләнә башлый. Һәм иң элек ул милли, ә аннары мәйданый яктан да таркалырга тотына. Аурупа мондый үзбилгеләнү дәверен кичергән инде. Әүвәлге Госманлы һәм Австро-Венгрия империяләреннән Югославия, Болгария, Чехословакиядәге милләтара проблемалар гына торып калды. Бу яктан карaганда, Русия әле үзе бер ачылмаган дөнья кебегрәк. Ул иске колониаль Аурупаның соңгы баганасы дияргә була.**

**Яңа XXI гасырга керер алдыннан кешелек дөньясы коллыктан тәмам котылырга тели шикелле. 1917 елгы инкыйлабтан соң Русия, үзендә көч табып, империясен совет нигезенә корып, яңарта алды алуын. Төрле халыкларның милли мәдәниятләре, диннәре белән каты көрәш, урыслаштыру, бөтен-бөтен халыкларны юкка чыгаруга кадәр барып җиткән ассимиляция, марксистик идеологияне көчләп тагу иҗтимагый тормышны вә фикерне бер генә төрле итеп кору, республикалардагы җитәкчелекне турыдан-туры үзәктән билгеләүләр милли ирекне буып килде. Сәяси һәм идеологик кыршаулар юкка чыккач, халыкларның милли җегәре уяныш, алар кымшана башлады — үз мәнфәгатьләрен үзләре кайгыртырга тотынды. Мәскәү әмерен көтеп тормастан, мөстәкыйль үсеш юлларын үзләре билгеләргә керештеләр.**

**Русиянең әле яңа туып кына килә торган демократиясе шулхәтле күптөрле телгә, дингә, мәдәнияткә ия булган, гасырлар буе кимсенеп яшәгән, Мәскәүнең тагын алдамаячагына инде тәмам өметен җуйган халыкларга нәрсә әйтә, нәрсә тәкъдим итә ала соң? Асылда бернәрсә дә тәкъдим итә алмый шул...**

**Бу юлы Русия милли төбәкләрне үз кулына тотып кала алырмы, алмасмы? Башкача әйтсәк: коллыктан котылу гамәле Русиянең үз эченә керсә, ни дәрәҗәдә кергән? Шушы мәсьәләнең ничегрәк хәл кылынуына карап, илдәге**

---

**ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгат улы (1947)** — *галим, фәлсәфә фәннәре кандидаты, «Җиде көзге кичә», «Идарә мөнәсәбәтләре» китаплары һәм башка фәнни хезмәтләр авторы, Татарстан президенты киңәшчесе. Казанда яши.*

генә түгел, Аурупадагы, хәтта дөньядагы хәлләр дә төрлечә үзгәрергә мөмкин.

Бүген инде әүвәлге Союз республикаларын Русия канаты астында тотып булмаячагы көн кебек ачык. Димәк ки, империя төсендәге СССР бетте дип ышанып әйтергә була. Әмма Россия Федерациясенең тамыры ныграк әле.

Русиянең, империя буларак, үз хасиятләре бар. Әгәр дә Урта Азия республикалары классик колониаль сәясәт кысаларында торган булса, Русиядә гасырлар буе янәшә яшәү дәверендә халыклар бик нык аралашып та, кушылып та беткәннәр. Фәкыйрьлек һәм хокуксызлык ягыннан республикалар гына түгел, урыс өлкәләре дә ярым коллык дәрәҗәсенә төшкән. Ә Мәскәү (һәм аның йөзләрчә министрлыклары) үзен метрополия дип тоя башлады.

Русия түрәчелеге турында аерым әйтеп үтмичә булмас. Бу дәүләттә ул гомер буе паразит булып килде. Сәбәбе — аның бер сыйныф сыман күп санлы һәм өстенлекле булуында. Ул дәүләт эчендәге бер дәүләт кебек булып, барысын да изеп яшәде. Урыслар исеменнән чыгып эш итсә дә, изелгән халыкларга гына түгел, урысларның үзләренә карата да коллык режимы тудырган өчен җаваплылыкны үз өстенә ул алырга тиеш. Беренче Петр заманыннан алып Русия, үзенә борылып карарга да онытып, һаман Аурупага муенын сузып килде. Түрәләрне шуннан алдырды. Алары каннары белән дә, җаннары белән дә Русия кешесе булмагач, урысның да, башка милләтләрнең дә мәнфәгатьләрен караудан ерак тордылар.

Җәмгыять хөрриятләшкәндә империянең саклануы мөмкин түгел. Демократия Русияне кызганыч хәлгә куйды. Ул «бердәм һәм бүленмәс» дигән төшенчәне какшатты. Патша империясе, монархия принциплары таләп иткәнчә, көчкә таянып кына яшәп килде. Совет империясе дә көчкә таянды һәм аның халыкларны көчләвен аклый торган идеологик коралы — пролетариат диктатурасы дигән сафсата булды. Яңа килгән җитәкчеләр, демократия принципларын корал итеп алып, иске нигезләрне җимерделәр һәм шуңа бәрабәр рәвештә тиешле нәтиҗәсен дә алдылар — илләре таркалды. Демократия хокук чыганагы итеп көчне куллана алмый, ул халык фикерен ачыклауны таләп итә, шул исәптән, милли-дәүләтчелек өлкәсендә дә, СССР чикләре генә түгел, Россия Федерациясенең дә чикләре даимилеген җуеп бара, әүвәлге хокук нигезләре юкка чыкты, теге чактагы конфигурация бары тик тарихи традицияләр аркасында гына торып тора. Әмма бу хәл беренче тетрәүгә кадәр генә дәвам итә ала. Татарстан һәм Чечән Республикаларының бәйсезлеге, Курил утрауларының Япониягә кире кайтарылу ихтималы дәүләт корылмасының ныклыгын сыный. Башкача әйткәндә, Русия Федерациясе чикләрендәге Русия, СССР чикләрендәге БДБ кебек үк, тотрыксыз организм. Бу проблема инде күптән ишек шакыса да, Русия җитәкчеләренең бу гаять катлаулы мәсьәләне аңлап җиткергәннәре юк әле.

Русия урыс булмаган халыкларның милли хокукларын тәэмин итә ала торган ил түгел. Шуңа күрә заманыбызның иң төп мәсьәләсе булып төрле милли территорияләрдә яшәүче халыклар мәнфәгатен гарантияли торган дәүләтләр булдыру тора. Монда дәүләтнең әүвәлге исеме бик тә томанлы булып чыга. Нәрсә ул Русия? Элегрәк аны СССР дип карыйлар иде. Шул империя чикләрендә урыс халкының үзбилгеләнүе гамәлгә ашты. Хәзер Русия — Русия Федерациясе белән тәңгәлләштерелә башлады. Татарстан белән Русия Федерациясе һич тә тәңгәл күренеш түгелләр. Алай булгач, Русия Федерациясе чикләре кайда бетә дә, аларны билгели торган юридик нигезләр кайда соң? Демократлашу шартларында урыс халкының үзбилгеләнүен ничегрәк аңларга икән? Урыс милләте үз язмышын үзе күчеп килгән республикалардагы төп халыклар белән бәйләрме, әллә Русия Федерациясе чикләрендәге империясен сакларга тырышырмы? Сорау өстенә сорау...

Урыс «демократлар» тоталитар структура катламнарын «саф» демократия категорияләренә кертеп карамакчылар, милли мәсьәләне гомумән демократлашу проблемасы белән алыштырмакчылар. Моңа охшаган нәрсәне 1917 елны тарих күргән иде инде. Большевиклар демократия һәм Русиядәге бөтен халыкларның милли үзбилгеләнүе, тигезлеге һәм суверенлыгы турында лозунглар игълан иткән иделәр. Ә инде чын хокуклар турында сүз кузгалгач, «халыклар төрмәсен» яңадан торгызуны артыграк күрделәр. Русия «демократлары» да большевиклар эзеннән бара, аерма шунда гына — большевиклар, тигез хокуклар һәм үзбилгеләнү турындагы лозунглар белән башлап, «бердәм һәм бүленмәс Русия» принцибын ачсалар, «демократлар» ахырдан тотындылар, әле аларның киләчәктә тагын кая барып чыгасыларын белгән кеше юк...

Ошаса да, ошамаса да, миллилек социальлектән өстенрәк тора. Литва,

Латвия һәм Эстониянең аерылып чыгуында социаль мотивка, демократия проблемаларына караганда шул илләр халыкларының милли мәнфәгатьләре ныграк роль уйнады. БДБ халыклары демократия дигәннән, барыннан да элек, милли азатлыкны аңлый. Аларны милли мәнфәгатьләрдән тыш, «саф» демократия лозунглары белән алдап булмаячак. Август фетнәсе вакыйгаларыннан бөтен республикалар да Русия белән якынаю өчен түгел, ә, киресенчә, мөстәкыйльлек, бәйсезлек игълан итү өчен файдаланганнар икән, бу бит юкка гына түгел иде. Алга таба да Русиянең хәлсезләнүеннән милләтчеләр үзләренең дәүләт үзбилгеләнүе өчен файдаланачаклар һәм моны «мәскәүләр» аңлавындагы «саф» демократия белән бәйләп азапланмаячаклар.

Бер генә халыкның да әле үз хокукларын көрәшсез-нисез генә ала алганы юк. Аерма шунда гына: кайбер халыклар бәйсезлекләрен тануга бераз тынычрак юл белән ирешә алган булса, күпчелек үзбилгеләнүләренә каннарын коя-коя иреште. Соңгы елларда БМОның булуы ярдәм итә итүен, әмма аның да мөмкинлекләре чиксез түгел. Аннары бу халыкара җәмгыятьтә күп кенә халыкларның җир йөзендә яшәп ятканнарын да белеп бетермиләр әле...

Әүвәлге СССР империясе җирләрендәге милләтара мөнәсәбәтләр, хәвефле рәвешкә кереп, төрле илләрнең һәм бөтен дөньяның тынычлыгын ала. Көнбатыш политологларының иң өметсез фаразлары да дөрескә чыкты — совет империясе сүтелде дә төште, кешеләрнең аңын бутап, халыклар арасына киртәләр салды, республикалар һәм кешеләр арасына суык өрде. Көнбатыш тансыклаган көннәр килде: совет империясенең җимерелүе дөньяда көчләр торышын үзгәртте, анда бер генә олы дәүләт — АКШ кына торып калды. Ә бу хәл халыкара сәясәттә яңа омтылышларга юл ачмый калмас һәм моның дөньяда урнашкан мәгълүм бер тәртипне дә бозуы ихтимал.

Җир шарында бездә бара торган низагларны игътибар белән күзәтеп, аларны чикләү турында борчылалар. Балтыйк буе республикалары сыман башкалар да «тынычрак» кына аерылып чыга алырлармы, әллә «Сербия-Хорватия» җәнҗалы килеп чыгармы? Аурупа белән Азиядә атом-төш коралына ия Украина һәм Беларусь аерылып чыккач, нинди үзгәрешләр булыр? Урта Азиянең мөселман республикалары һәм Әзербайҗан үзләрен ничек тотар? Хасил булган хәл Русия Федерациясенең бөтенлегенә, аерым алганда, «мөселман» Төньяк Кавказына, мөселман-христиан Татарстанына вә Башкортстанына нинди йогынты ясар? Сораулар, сораулар... Һәм аларның һәркайсы мәсьәләләр тезмәсен үз эченә ала, һәм аларга бертөрле генә җавап та юк. Халыкларның үзбилгеләнү хәрәкәте тизләнгәннән-тизләнә, халыкара җәмгыятькә яңадан-яңа бәйсез милләтләр кушыла бара. Аларның әле бик үк утырып житмәгән мәнфәгатьләре һәм дәгъвалары да бар.

Милләт, дәүләт һәм халыкара җәмгыять — өчесе дә бер-берсе белән үзара бәйләнгән төшенчәләр. Аларда дәверебезнең тирән сәяси үзгәрешләрен күреп була. Бөтен халыкара сәясәт, җөмләдән, безнең ил тормышы да шулар тирәсендә әйләнә. Халыкара җәмгыятьтә милләтләр үз дәүләтләре төсендә вәкил булып торалар. Халыкара эшләрдә башкача катнашу юк. БМО әгъзасы булмаган халыклар, саннары миллионнар белән исәпләнсә дә, «уен»га катнаша алмый, юл читендә басып кала. Мәдәниятләре планета үсешенең магистраль юлыннан бара алмый.

Дөньядагы дәүләт формалары бу халыклар өчен богауга әверелә. Һәм бу нормаль хәл түгел. Бүгенге Русия житәкчелегенең милләтара мөнәсәбәтләрне акыл белән чишү юллары күренеп тормый. Ул һаман да «бердәм һәм бүленмәс Русия» тезисына ябышып ята. Ә бу бөтен халыклар мәнфәгатенә генә түгел, демократия дигән төшенчәнең үзенә дә каршы килә. А. Сахаровның конституция проекты Русия демократиясе тарафыннан чынлыкта кире кагылды, шуңа күрә Русияне реформалаштыруның цивилизацияле юлына өмет итүе кыен. Ул гына да түгел: көрәш коралы итеп А. Солженицын концепциясе алынды. Анда татарлар гына аңгыра халык итеп түгел, хәтта украин һәм белоруслар да бөек урыс милләтенең кыйпылчыклары итеп кенә карала. Бер әдәби курьез итеп кенә кабул ителергә тиешле нәрсә Русиядә рәсми идеологиягә әйләнде, житәкче директива булып чыкты. Димәк ки, кыен сынауларга әзер булырга кирәк. Алда юллар озын әле. Империяләр тыныч кына үлеп китми, аңа кадәр дөньяга шактый сасы таратып ята.

# I. Этнос-халык-милләт: дәүләтчелеккә бару

## Милләтара мөнәсәбәтләрнең чияләнгән төене

Милләт һәм дәүләт — болар асылда аерылгысыз төшенчәләр. Теләсә кайсы дәүләт билгеле бер милләт мәнфәгатен гәүдәләндерә. Ул милләтнең теле, мәдәнияте, йолалары монда беренче урында тора. Урындагы түрәләр шушы милләт өчен кадерле булган идеаллар сагында тора. Франция — французлар дәүләте, Төркия — төрекләрнеке, Япония — япоиларныкы, Русия — урысларныкы. Урыс хөкүмәте, әйтик, татарлар мәнфәгатен яклау өчен билгеләнеп куела дип уйлау гаять беркатлылык булыр иде. Ул хөкүмәт, башка тирәндәрәк яткан нәрсәләрне әйтеп тә тормастан, татарның хәтта телен генә дә белми ләбаса. Дәүләт милли кадере булган нәрсәләрне үстерү һәм киңәйтү өчен нигезләнә. Бар халыклар турында да бертигез дәрәҗәдә кайгыртучы дәүләт дөньяга тумаган әле. Бер күпсанлы халыкның мөстәкыйльлеккә тарихи аклана торган дәгъвалары булганда, бу бигрәк тә шулай. Мондый халык хакимлек итүче этносның реаль көндәше була ала ич.

**Милләтара мөнәсәбәтләрдә төп мәсьәлә — дәүләтчелек мәсьәләсе.** Соңгы вакытта әдәбиятта: халыкларның, үз дәүләтләре булмаган хәлдә дә, имештер, гомумдемократик процессларны үстереп, милли-мәдәни автономия һ. б. тудырып, үзбилгеләнә алуы турында сафсата шактый еш күренә башлады. Шунысы кызык, шулай дигәндә берәүнең дә бу милли-мәдәни автономия дигәненең ни-нәрсә икәнлеген ачыклап маташканы юк. Тагын да кызыграгы — беркем дә шушыңа ярашлы закон проекты тәкъдим итеп тормады. Башкача әйткәндә, Русиядә бу «үҗәт милләтчеләр»дән, «демократлар» галәм проблемаларын чишеп чиләнгәндә, аларның аяк астында чуалмасын өчен, ничек кенә булса да котылырга тырышалар.

Еш кына «милләт» төшенчәсе «этнос» төшенчәсе белән алмаштырыла башлады. Алай иткәндә, бу төшенчәдән дәүләтчелек элементлары төшереп калдырылып, халыкларның үзбилгеләнүе — ул тел, уку-укыту һәм мәдәният өлкәсендә хокукларны ниндидер бер эфемер сурәттә киңәйтелүе һәм шул рәвешле фикер офыгыннан сәяси процессларның юкка чыгуы булып калыр иде.

Кайберәүләр, бала-чагаланып, имештер, паспортта кайсы милләттән икәнене күрсәтмәсәң, милли мәсьәлә хәл ителер иде, дип тәкъдим итәләр. Бу очракта алар көнбатыш илләрен мисал итеп китерәләр. Анда, чыннан да, кешенең кайсы милләт баласы икәнен язып тормыйлар, чөнки сәбәбе бик гади: фәлән-фәлән дәүләт ватандары, чыгышы белән кем генә булмасын, шушы дәүләт милләтеннән дип исәпләнелә. Ләкин бездәге кебек үзбилгеләнү гадәти геноцидка китерүе бик ихтимал. Хокуклары бүгенгә кадәр торгызылмаган Кырым татарларына нишләргә калыр иде соң? Идел буе алманнары, әгәр дә бөтен кеше дә Русия ватандары, ягъни «урыс» дип исәпләнсә, үз дәүләтчелекләрен ничек кайтарырлар иде? Аннары: паспортка кайсы милләттән икәнеңне язмау белән генә кешеләрнең үзаңнарын үзгәртеп буламы соң әле?! Менә, халыкларның үз дәүләтчелекләрен булдырып, үзбилгеләнүе тәмамлангач, республикалар тигез хокуклар алып, үз ватандарлыгын булдыргач, чыннан да, андый язуның хаҗәте калмаячак.

Дәүләт формаларыннан тыш үзбилгеләнү дигән нәрсәне алга сөрү — ул Русия империясен демократиясез-нисез генә саклап калырга маташудан башка бернәрсә дә түгел. Милли мәсьәләне хәл итү — ул, димәк, халыкара җәмгыятькә керергә әзер, тарихи үсештә катнашучы рәвешендә житешкән халыкларның үз дәүләтләрен булдыру дигән сүз.

Беренче карашка гади генә кебек күренгән «халыкларның үзбилгеләнү хокукы», бу хокук субъектын анализлап карагаңда, шактый катлаулы булып чыга. Мәгълүм төбәктә шушы җиргә хуҗа булырга хаклыгы тарихи яктан ачык күренеп торган берәр халык яши икән, монда инде үзбилгеләнүнең бәхәссезлеге дә аермачык: шушы милләт нигезендә милли дәүләт нигезләнергә тиеш. Әгәр дә инде ул мәйданда берничә милләт, халык яши икән, монда мәсьәлә катлаулана. Бигрәк тә бер милләт халкы — төп утырган халык булып, икенчесе басып алу вакытында килеп урнашкан булса, катлаулык тагын да арта. Менә тагын Русия Федерациясендә гадәти хәл булган республикаара чикләрнең милләтләрнең кайда-ничек урнашулары белән туры килмәвен дә бергә кушсаң, проблемалар төене шундый каты булып чияләнә ки, аны инде чишеп торасы да килми башлый: кулыңа балта ал да чабып кына ташла...

Бу дәүләтнең җәфаланган нәрсәсе халыкларның берсе эченә берсе кереп урнашуында гына да түгел, ә табигый кыенлыкларга өстәп, ясалма төстә республикалар төзелүендә дә. 1920 елда Татарстан АССРны кору үзбилгеләнү акты булудан бигрәк, киресенчә, шушы эштән котылырга омтылыш иде. 1918 елны «Идел-Урал» штаты булдыру турындагы һәм шул ук елгы «Татар-Башкорт республикасы» («Кече Башкортстан»сыз) төзү вариантлары хәзерге чикләрендәге Татарстанга караганда күркәмрәк иде. Хәлбуки, большевикларның шундый әһәмиятле аралашу юллары өстендә куәтле дәүләт калкып чыгуыннан котлары алынды. Аннары гади генә: Татарстанның Казагыстан белән чиктәш булып китүеннән курыктылар. 1920 елгы декрет аңлы рәвештә татарларны зур-зур кисәкләргә бүлде дә, аннан соң ике арага Ырынбур өлкәсен салып, татар, башкорт, казакълар арасында коридор булдырды. (1926 елга кадәр Ырынбур Казагыстанның башкаласы иде.) Ләкин хикмәт монда гына да түгел. Хикмәт шунда ки — Татарстан республикасы чынлыкта бер өлкә генә булып калды, аның бары шул «дәүләт» дигән исеме белән дәүләт тамгалары гына бар иде. Реаль хокуклары юк иде.

1990 елның августында Татарстан ССРның дәүләт суверенитетын игълан итү үзбилгеләнү акты булды. Ул үз алдына реаль дәүләт хокуклары булдыруны максат итеп куйды. Татарстанның суверенитеты, табигый инде, Русия Федерациясендә яшәп килгән структуралар белән каршылыкка килде. Бу каршылык Республикабыз язмышы өчен иң әһәмиятле нәрсәгә әйләнде. Әмма шул ук каршылык — Русия өчен дә язмыш «башваткычы». «Татарлар мәсьәләсе» күңелсез бер сызлавыктан Русия милли-дәүләт корылышының төп проблемасына әверелде. Ул Русия житәкчелеген милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә берсеннән-берсе ашыгычрак адымнар ясарга этәреп тора.

РФ Президентының милли мәсьәләләр буенча киңәшчесе булып торган Г. Старовойтова Татарстанга карата рәсми позицияне күп тапкырлар кабатлап килде. Имештер, Татарстан Республикасының суверенитетын Русия һәм башка республикалар танысын өчен, татар халкының күпчелек тәшкил итүе кирәк, ә Татарстанда татарлар 48 процент кына булгач, Русия эчендә суверен дәүләтнең булуы һич мөмкин түгел. Г. Старовойтованың тел төбендә нәрсә ята иде? Ул Татарстанның суверенитеты республикадагы татар халкының гына мәнфәгатен чагылдыра дип фараз итте. Әмма шунысы бар: «Декларация» татарлар исеменнән генә түгел, бөтен халыклар исеменнән игълан ителде. Һәм ике телне — татар һәм урыс телләрен дәүләт телләре дип карар кылды. «Декларация»не бөтен депутатларның да (бер битараф депутаттан башка) яклап тавыш биргәнлекләре бик тә житди сәяси факт булып тора. Татарстан Республикасы Югары Советы карарларының очраклы түгел икәнлекләрен күрсәтүче башка фактлар да бар. Татарстанда Русия Президентын сайлаулар хурлыклы төстә җимерелде, ә Татарстан Президенты өчен татарлар гына түгел, урыслар, чуашлар һ. б. халыклар да үз тавышларын бирде. Шулай икән, Татарстанда кемнең үзбилгеләнүе хакында, — татарларның гынамы, әллә бөтен халыкнынмы, — сүз куертырга кирәкме? Республика мөстәкыйльлегенең хуҗасы, иясе кем булып чыга соң?

Сәясәтчеләр һәм галимнәр, күрәсең, шуннан чыгып фикер йөртәләрдер: янәсе, урысларның үзбилгеләнүе күптәннән булган һәм аларга кабат үзбилгеләнеп торуның кирәге юк. Русиядән читтә, бигрәк тә татарлар белән бергә! Шуңа күрә суверенитет татарларга гына кирәк. Әмма бу очракта сәяси хәл истә тотылмый: урыслар милләт буларак яши торган дәүләт — империя җимерелде ләбаса. Инде ул дәүләт юкка чыккан икән, аның төп этносы булган урысларга да кабат үзбилгеләнүдән башка юл юк. Бу процесс инде бара һәм мондый хәл урысның язмышына язылган.

Моңарчы урысларның үзбилгеләнү территориясе булып СССР торды, ул ук Русия дә иде, чөнки СССРда дәүләт теле — урыс теле иде. Союз органнарында асылда урыс кешеләре генә утырды, массакүләм коммуникация чаралары урыс телендә эшләде. Урыс булмаган халыклар вак милләт дип исәпләнде, аларның хокуклары бик нык чикләнгән иде. Һәрхәлдә, Союздаш республикаларның хокуклары, мәсәлән, Дания кулы астындагы Гренландиянекенә караганда күпкә ким иде. Шушындый хәл булмаган булса, «суверенитетлар парады» да килеп чыкмаган булыр иде. «Зур Русия» хәзер юк инде. «Чит» дәүләтләрдә калган урысларга, мәскәүләрнең ни кылануларына да карамастан, торган урыннарда җай табып яшәргә туры килә. Дөнья бу!

Аңлау һәм аңлатуны таләп итә торган тагын бер кызыклы факт бар — ул РСФСРның үз дәүләте суверенитетын игълан итүе. Һичшиксез, бу урысларның

«кече» Русия буларак Русия Федерациясе чикләрендә икенче тапкыр үзбилгеләнергә тырышып караулары иде. Әгәр дә, шактый гына кешеләр расларга маташканча, аларның дәүләтчелеге мен ел буе яшәгән икән, урысларга әр-янадан үзбилгеләнүнен нигә кирәге булды икән соң? Әйтик, французларның да, японнарның да үз дәүләтләренен суверенитетын янабаштан игълан итү уе башларына да кереп чыкмыйдыр. Бу эшкә тотынсалар, алар көлкегә генә калыр иде. Ә менә урыслар очрагы беркемгә дә көлке тоелмады. Димәк, урыслар нәкъ менә үзбилгеләнү стадиясендә тора. Ләкин үз дәүләтләрен бүген тудырганнары өчен түгел, ә империянең таркалуы аркасында.

РСФСРның үз суверенитетын игълан итүенә җавап рәвешендә Русия автономияләренең «суверенитетлар парады» башланды. Чөнки алар Русиядәге унитар корылыштан туйган һәм тарихи процесстан читтә калулары белән моннан ары килешеп яшәргә теләмәделәр. «Кече» Русия, аягына торып басарга өлгергәнче, таркала да башлады һәм урыслар тагын үзбилгеләнү проблемасы белән йөзгә-йөз очрашты: бу юлы инде әүвәлге автоном республикалар баш күтәрде. Русия Федерациясе үзенең милли-дәүләт корылышына тәэсир итә торган ике җитди проблема белән очраша. Аның беренчесе — урыслар белән аралашып, уртак җирдә яшәүче халыкларга карата мөнәсәбәтләрне ачыклау. Икенчесе — «урыс» Русиясен чагыштырмача мөстәкыйль регионнар исәбенә бимәркәзләү (децентрализацияләү). Ерак Көнчыгыш, Сахалин, Ставрополь крае, Петербург, Өркет өлкәләре һәм башкаларның үзләренә автоном республика хокуклары таләп итүе бу омтылышның шактый җитди икәнлеген күрсәтә.

Әйтеп кителгәннәр урыслар өчен яна, мәгълүм дәрәҗәдә кәтелмәгән проблемалар, һәм мин урысларның «бөтен һәм бүленмәс Русия»не теләсә нинди юллар-ысуллар белән дә саклап калырга әзерлеге хакында бик ашыгып хөкем чыгармас идем. «Меньеллык Русия» дигән империяне саклап калу хакына урысларның көч куллана башлаулары икеле. Ул булмаса, нишләп соң алайса Союз таркалды? «Зур Русия» таркалып, «урыс калалары анасы Киев» тә чит илгә «киткән» икән, татар каласы Казан Русия Федерациясе составында калыр дип кем гарантия бирә алыр?!

Психологик яктан әһәмияте җитәрлек булган тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә. «Урыс телле» булганнары хәлдә дә ни өчен ни СССР, ни РСФСР урыс мәдәниятен үстерү турында уйламады, ә икътисади вә социаль яктан урысларның хәле башка халыклар хәленнән әллә ни аермалы түгел? Шуңа күрә, аннарында «бөек патшалык» фикере әле ятса да, урысларны автоном республикаларда алай чит итмиләр. Андагы урыслар үзләрен «милләтчеләр» кебек үк таланган һәм кимсетелгән халык дип саный. Моңа өстәп тагын катнаш гаиләләрне дә искә алып узыйк. Кыскасы, урысларның «тәртибе» Русия сәясәтенә караганда урыннардагы җитәкчелеккә ныграк бәйле.

Урыс милләте ике «милләт»кә аерылган булып чыкты: аның берсе — мәркәзнең үз кулында метрополия вазифасын тотып торган түрәләр милләте. Аннан башка Мәскәү якын араларда үз-үзенең дә тамагын туйдыра алмаячак. Һәм икенчесе — башка төбәкләрдә, башка уйлар-мәнфәгатьләр белән яшәп ятучы урыс коллары «милләте». Еш кына бу «милләт» милли республикаларда төп халык белән бергә кардәшләрчә гомер итеп ята. Бу сәяси чынбарлыкны санламаучы кеше урыс халкын аңламый да, белми дә дигән сүз.

1917 елгы инкыйлабтан соң урыс милләтендә кире кайткысыз үзгәрешләр булды. Совет хөкүмәте урысларның чит илләргә чыгып качкан мөһаҗирләрен дошман күрде. Милли як сыйнфый як белән алыштырылды һәм милли мәнфәгатьләргә төкереп карау совет дәүләтенең кагыйдәсенә әйләнде. Бүгенге көндә дә әүвәлге Союздаш республикаларда калган урысларга Русиянең мөһаҗирләргә караган кебек каравы һич тә гаҗәпсендерми. Шушы фикер сөреше белән барсак, Русия Федерациясенең үз эчендә дә урыслар мөһаҗирләр хәлендә кебегрәк дип әйтергә тиеш булабыз. Һәрхәлдә, Русия җитәкчелеге «демократ»лар артыннан иярмәгәннәргә нәкъ менә шулай карый.

Димәк, ни тышкы, ни эчке сәясәтендә Русия урыс халкының хокукларын яклаучы да, саклаучы да булып тора алмый. Шуңа күрә урысларга төрәкне урыннарда, республикаларда өмет итәргә генә кала. Шуннан соң Татарстанны суверенлаштыруда һәм 1992 елның 21 мартындагы референдумда Татарстанның бәйсезлеге өчен күп урысларның тавыш бирүенә ничек гаҗәпләнмәк кирәк?!

Татарстанда дәүләт суверенитеты бар халыклар исеменнән игълан ителде. Ләкин нинди берлек соң ул «бар халыклар»? Төрле этнослар бүген бер дәүләттә яшәп, киләчәктә дә бергә торырга ниятлиләр икән, мәгаен, монда ниндидер берлек бардыр. Нинди исем бирергә аңар? Суперэтносмы ул, яна бер милләтме,

күпмилләтле халыкмы? Бер-берсеннән шулкадәр үзгә халык булган татарлар белән урысларның бергә яшәве мөмкинме? Ул вакытлы гына хыялый бергәлек булып чыкмасмы? Әллә ул бәхетле киләчәккә йөз тота аламы?

## Этнос һәм милләт

Татар, урыс, чуаш, мари һ. б. турында сөйләгәндә, аларны «милләтләр», дибез. Шул ук берлекләрне күз алдында тотып, аларны «этнос», дибез. Ниһаять, шул ук күренешләргә без «халык» дибез. Бер үк объектны билгеләгәндә нигә өч төшенчә кулланабыз соң? Берсен генә алырга килешсәк, яхшырак булмас идеме икән? Ә бәлки, без бүгенге атамаларга хаталы мәгънә салабыздыр?

**Этнос — биосоциаль күренеш.** Ул табигатьне җәмгыять белән бергә кушып карый. Этнос биологик җегәргә ия була, һәм, социаль процесслардан битәр, башка кануннарга буйсына. Күп вакытта «үзеңнең ата-бабаңны оныт, без бөтенебез бер халык балалары» дигән сүзләрне дә ишетәсең. Бу фикерләр әлеге күренешнең асылын төшенмәгәннән генә килә. Этнос буенча аермалык — ул кемдер теләге белән түгел, ә табигать биргән тамга белән аерымлыктыр. Адәм баласына, өйрәтә-өйрәтә, башка бер этнос хасиятләрен иңдереп булса да, аның үз канында булганын чыгарып ташлавы мөмкин түгел.

Этносларның табигый холкы милләтара низаглар вакытында бик ачык күренә башлый. Тиешле чагында туктатып кала алынмаганда, алар кешеләр арасында турыдан-туры сугыш китереп чыгара һәм, икътисади, сәяси, хокукый һәм башка чараларны санга сугып тормыйча, үзләренең биологик бакчасына килеп керәләр. Күреп торабыз бит, мондый низаглар озакка сузылып китә: мәгънәсе дә бетә, әмма алар барыбер бара, чөнки аларны бетерерлек мөгамәлә юк. Шунда инде көч куллану мәсьәләсе алга килеп баса.

Элеккеге совет әдәбиятыннан безнең көннәргә чаклы милләт белән этносны сәер генә бутап йөртү ияреп килде. Шул ук вакытта, иҗтимагый процессларны юньләп аңлата алмаса да, һаман да милләт турында Сталинның сүзләре кулланыла. Турыдан-туры да, күчереп тә, йә булмаса, башка кием кидереп тә кулланалар. Хәтта үзләрен сталинизмның кан дошманнары дип атаучылар да фикерләү инерциясенә бирелә.

Этносның яшәве өчен Сталин аңлатуындагы берлекнең — «тел, мәйдан, мәдәният, икътисад һәм халык берлеге» им түгел. Татарлар, гаять киң мәйданнарга утырып, төрле республика, төрле илләрдә яши. Мисал өчен: Польшадагы татарлар татар телен һәм мәдәниятен инде оныткан, ләкин мөселман динен, исемнәребезне, халкыбыз тамгаларын саклап килә. Һәм, татар этносының төп өлешеннән гасырлар буе аерым яшәүләренә дә карамастан, үзләрен татарның аерылгысыз бер өлеше дип исәплиләр. Бер үк вакытта алар поляк милләтенең дә бер өлеше, алай гына да түгел, шул милләтнең бик тә мөхтәрәм өлеше булып санала. Чөнки алар һәрвакыт тугрылык белән король гвардиясендә, ә соңрак Польша армиясендә хезмәт итеп килгән.

Этнос берлеге булсын өчен уртак дин тоту да им түгел. Керәшен татарлары, православие динендә булулары аркасында, татарның төп массасыннан шактый үзгәрәк, әмма барыбер алар татар этносының бер өлеше.

Этнос берлеге булсын өчен кайвакыт үзаң булу да җитә. Сталинның милләт төшенчәсен аңлатырга хәленнән килми, чөнки анда милләтнең төп сыйфаты — дәүләтчелеге төшереп калдырылган. Кешеләрнең нинди дә булса берлеген милләткә әверелдерүче төп сыйфат — дәүләт. Берәр дәүләттә уртак мәнфәгатьләр белән яшәп ятучы ватандарлар милләт хасил итә дә инде. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: нәкъ менә шуның өчен Көнбатышта паспортка «милләт» тамгасы сугылмый. Кайсы этностан чыгышларына карап тормастан, бөтен ватандарлар шушы милләт вәкилләре дип санала. Әйтик, Франциянең теләсә кайсы ватандары — тумышы белән французмы ул, алманмы, алҗирлымы, төрекме — барыбер француз дип исәпләнелә. Әйтелгәннәрдән бу ике төшенчә арасындагы аерманы чамаларга мөмкин. Этнос булсын өчен, үзаңның булуы да җитә икән. Ә милләт оешу исә, дәүләтчелек булу зарур. Милләт — ул уртак мәнфәгатьләр белән бер дәүләттә яшәүче кешеләр берлеген чагылдыручы социаль организм.

Бер караганда, этнос тулысы белән милләткә әверелеп китәргә мөмкин кебек. Ләкин моның гамәлгә ашуы бик икеле: этнослар утырган җирләр чиге

белән дәүләтләр чикләрен тәңгәл китерүе бик кыен нәрсә: бөтен дөньяда этнослар башка халыклар белән аралаш утырган — ә бу дәүләтнең максатларына һәм хәтта хосусиятенә дә төзәтмәләр кертә.

Этнос белән милләтнең бер-берсеннән килеп чыкканлыгы аермачык һәм бу бик зур роль уйный. Милләт һәм аның тиешле дәүләте билгеле бер этник культура нигезендә генә туа ала. Чөнки дәүләт идарә итә алырлык, уку-язуны, фәнне һ. б. үстерергә сәләтле кешеләр катлавы булуны таләп итә.

Югары үсешкә ирешкән этнос — милләт һәм дәүләт калкып чыксын өчен мәҗбүри шарт. Шул ук вакытта социаль тормышта төрле этнослар бер-берсе белән даими рәвештә бәйләнештә тора һәм милләт, кагыйдә буларак, этник чыгышлары төрле-төрле булган ватандарлардан җыела, ләкин боларның уртак максатлары, нормалары һәм кыйммәтләре булып, алар үз ирекләре белән шушы дәүләт тарафыннан урнаштырылган тәртипләргә буйсынырга әзер торырга тиеш. Кыскача әйткәндә, милләт — ул этник чыгышларының нинди булуына карамастан, бергә берекән ватандарлар берлеге.

Дәүләт бөтен ватандарларны бербөтен итеп тота ала торган мәгълүм бер мәдәни даирә булганда гына яши ала. Берлек бетсә, дәүләт тә бетә. Әлбәттә, тарихта бер-берсенә каршы булып, бер милләткә укмаша алмаган этносларны үз эченә алган империяләр булганлыгы билгеле нәрсә. Көчләп тупланган мондый конгломератлар була ала, ләкин аларның гомере этнослар гомере белән чагыштырганда (Л. Гумилевча — 1200ләп ел) бик кыска була. Ләкин хәтта империяләр дә, бер идеология яки дингә, ассимиляция һ. б. таянып, нигидер ялган берлек булдырырга омтыла. Ләкин эчке бәйләнешләр булмаганда, бер генә дәүләт тә озак яши алмый.

Милләт бер генә этностан торырга да, полиэтник булырга да мөмкин. Мәсәлән, Японияда япон булмаган кешеләр бик аз (бары 1 процент). Әле шунда да төп тамыр дип бөтенесе 20 мең кеше булган айналар исәпләнә. Мөгаен, шуңа күрә Япония милли омтылышлар бик ачык чагыла торган дәүләт булып торадыр да. Бу идеологиядә, мәдәнияттә һәм сәяси кыйммәтләрдә генә түгел, бөтен нәрсәдә дә — хәтта экономикада да (мәсәлән, сәүдә мөнәсәбәтләрендәге протекционизм), салымнар системасында, идарә итүдә, фирма эчендәге мөнәсәбәтләрдә дә күренә. Мондый монолит милләтнең мәдәниятне артык унификацияләү кебек үз кимчелеге дә бар, ә бу хәл җәмгыятьнең иҗади җегәрен киметергә мөмкин. Японнар, җитәрлек төрлелек булдыру өчен аерым провинцияләрдә мәдәниятне үстерүне стимуллаштырып, әлеге кимчелектән котылырга тырышалар.

Нинди дә булса берәр мәдәниятнең ачыктан-ачык өстенлек иткәне хәлендә бик тә төрле этнослардан торган милләтләр дә була. Американнар шундыйлардан. АКШ — мөһаҗирләр (эмигрантлар) иле. Монда төрле-төрле этник төркемнәр инглиз телле даирәдә тегермәндә тартылгандай он урынына тартыла. АКШта этник проблемалар тирәнтен характерда түгел. Алар асылда индеецларга, алеутларга, пуэрториканнар, мексиканнарга гына кагыла. Боларның башкалардан аерым үз менталитетлары бар. Ләкин бу әле инглиз телле даирәдә ирландлар, итальяннар, кытайлар һ. б. бөтенләй эреп юкка чыга дигән сүз түгел. Беренче буын мөһаҗирләр чыннан да мондагы социаль нормаларга яраклашырга, үз тамырларын искә төшермәскә тырыша. Болар үз ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булган кешеләр, күкрәкләрендә еш кына аңа карата үпкә хисләре тулган була, шуңа күрә өметләрен алар яңа ватаннарына бағлыйлар. Икенче буындагылар инде «йөз процент американ» булып күренергә тырыша. Һәм бары социаль статус ныгып җиткәч кенә, өченче-дүртенче буыннарда гына этник хисләр уяна, кешеләр үзләренең чыгышларын искә төшерә, бабалары телен өйрәнергә керешә, аларның ватанына кайтып, каберләрен эзли, гомумамерикан даирәсендә нинди дә булса хосусият белән аерылып торырга тели башлыйлар. Этник тамырларга кайту үз-үзеңне танытуның бер формасына әверелә.

АКШны этносара җитди проблемалардан монда халыкларның чәчелеп урнашуы да коткарып килә. Әгәр дә нинди дә булса бер төбәктә бер этнос вәкилләре генә күпчелек алып торган булса, иллә Канаданың француз телле Квебек шәһәрендәге кебек проблемалар килеп чыкмый калмас иде. Мәгълүм дәрәҗәдә АКШта этник проблемаларны салым салу системасы да йомшарта. Ул монда астан өскә таба юнәлтелгән, ә бу хөкүмәткә күп кенә проблемаларны, хәл ителәсе мәсьәләләрне җәмәгать яки муниципаль дәрәҗәгә төшерергә ярдәм итә. АКШ — мул тормышлы, чәчәк атучы ил. Әгәр дә анда икътисад аска тәгәрәсә яки сәяси кризис башланса, этносара каршылыкларның ничегрәк күренәсен әйтүе кыен. Тормыш бозыла калганда, этник казанның Америкада да кайный башлавы бик ихтимал.

Өстенлек итүче бер мәдәнияте булган, ләкин үз эченә югары үсешкә ирешкән, үзбилгеләнүне таләп итүче этносларны да алган милләтләр дә була. Моңа мисал итеп Квебек проблемасы булган һәм Атлантика провинцияләре АКШ ягына омтыла торган Канаданы, Басклар иле һәм Каталониясе булган Испанияне, Төньяк Ирландия, Шотландия һәм Уэльсларның сепаратизмы булган Бөекбританияне алырга мөмкин. Шотландия мисалы һәрьяктан да гыйбрәтле, чөнки Бөекбритания — хокукый дәүләт өлгесе, анда кеше хокуклары саклана һәм этносара конфликтлар монда күренмәскә тиеш иде кебек. Хәлбуки, эш башкачарак тора — шотландлар үзләренең автономиясе белән килешми, аларның мөстәкыйль милләт буласы килә. Бөекбритания федеральләшү проблемасы алдында тора. Үз вакытында валлон һәм фламанд этнослары басымы белән Бельгия дә федеральләшүгә барырга мәҗбүр булган иде.

Безнең өчен аеруча кызыклы тагын бер төр милләт бар. Ул дәүләт хасил итә торган тигез хокуклы, берничә этностан гыйбарәт Швейцария. Анда дүрт этнос бар, алманча сөйләшүче швейцарлар сан ягыннан күбрәк булса да, хакимлек итүче мәдәният һәм тел монда юк. Швейцария полиэтник милләт кенә түгел, полиэтник федератив дәүләт тә. Шуның белән АКШ һәм Германиядән аерылып та тора. Ләкин бу хакта сүз алдарак булыр.

## Милли азчылыклар, төп халыклар һәм мигрантлар

Милләт хасил иткәч, этнослар юкка чыкмый, яши бирә, әмма хәзер инде аларны дәүләтләре яклый. Аларның теле, мәдәнияте, гадәтләре, йолалары рәсми статус ала, аларның максатлары һәм дәгъвалары дәүләтнекенә әверелә. Дәүләт хасил итүче була алмаган этнослар белән эш башкачарак тора, аларның хәле, сәяси ситуациягә карап, төрлечә тулы хокуксызлыктан алып автономия статусына кадәр булырга мөмкин.

**Моноэтник (бер генә этностан торган) дәүләт — ул иллюзия, гамәлдә җир йөзендә андый дәүләтнең булганы юк.** Теләсә нинди дәүләттә төрле-төрле этник төркемнәр яши. Аларның хокуклары яклауга мохтаҗ була. «Саф милли дәүләт» идеясе үзе үк еш кына башка халыкларның ихтыяҗларын күрергә комачаулый. Хәлбуки, ул ихтыяҗлар һәрвакыт була һәм алар тора-бара сәяси факторга әверелә.

Милли азчылыклар — ул дәүләт хасил итүче этнос эчендә яшәүче этник төркемнәр. Алар этник билгеләрен һәм үзләренә генә хас ихтыяҗларын саклый. Безнең китапларда еш кына социаль хокуклар белән милли хокуклар буташтырып йөртелә. Бу буташтыруның авторлары, гадәттә — инде мондый хокукларга ия халык вәкилләре. Социаль мәгънәдәге тигезлек хакимлек итүче башка тел һәм мәдәният уртасында яшәүче милли азчылыкларның этник үсешен тәэмин итә алмый. Әгәр милли азчылыкларга аерым хокуклар тәэмин итмәсәң, кысудан аралау мөмкин булмый — алар ассимиляция, йотылу куркынычы алдында кала. Андый хокукларга туган телне куллану, үз мәктәпләрен ачу мәгариф һәм мәдәният учакларын оештыру, милли азчылыкларның хокукларын яклау һәм саклау өчен сәяси һәм башка җәмәгать оешмалары булдыруны кертергә кирәк. Күп илләрдә милли азчылыклар өчен парламентта урыннар гарантияләнә, хөкүмәт постларында квоталар бар, ә кайчакта «автономия» статусы да кертелә. Милли азчылыкларның хокукларын яклауга мисал итеп Финляндиядәге шведларның хәлен алырга мөмкин. Алар монда 300 мең чамасы (барлык халыкның 6 проценты). Аларның теле монда дәүләт теле һәм ул этник шведларга гына түгел, финнәр өчен дә мәҗбүри өйрәтелә. Аларның күпләбрәк яши торган урыннарында ул әле рәсми тел дә булып тора. Этник шведларның үз газетләре, партияләре, университетлары, махсус радио һәм телевизион каналлары бар. Моңа, кагыйдә булудан бигрәк, аннан «чыгарма» дип карарга да ярый. Гадәттә милли азчылык теле дәүләт теле булып тормый, ә аларның хокуклары белем бирүнең автоном системасы һәм мәдәни ихтыяҗларны үтәү белән чикләнә. Ләкин Финляндиядә шведларның хәле бик тә гыйбрәтле, ул милли азчылыклар мәсьәләсен хәл итүнең дөрес юлларын күрсәтә.

Кайбер чит илләрдә үз дәүләтләре булган милли азчылык белән үз дәүләтләре булмаганнары хәле арасында зур аерма бар. Беренче очракта проблема шушы дәүләттә инде әзер ризыкны тарату юлы белән мәдәниятне киңәйтү, уку-укыту системасын, матбугатны җайга салуга кайтып кала.

Икенче очракта без бөтенләй башка хәлгә тап булабыз. Монда культураны үстерергә кирәк, ә бу дәүләт ярдәменнән башка мөмкин эш түгел. Этнос үз билгеләрен үз дәүләте булмаса да саклап кала ала, әмма заман таләпләре дәрәҗәсендә алга бару әле үз дәүләтең булганда да бик катлаулы нәрсә, ә ул булмаганда бөтенләй дә мөмкин түгел. Каты итеп әйткәндә, бу очракта безнең алда милли азчылыкларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү мәсьәләсе булудан бигрәк, этносның үзбилгеләнүе яки деколонизациясе проблемасы тора. Моның классик мисалы — АКШта индеецларның хәле. Ә ул, әйтик, Германиядәге төрекләр яки Франциядәге гарәпләр хәленнән тамырдан аерыла. Индеецлар, аларның илен басып алган американнардан аермалы буларак, тарихи ватаннарында яши һәм Американың төп, тамыр халкы булып тора. Килмешәкләр белән өзлексез көрәштә аларның ничәмә буыны туып үсте. Индеецлар илбасарларның канун-нарын, гадәт-йолаларын һәм әхлакларын һич үзләренеке итә алмады. Бүген АКШ аларга резервацияләр булдырып һәм аларның мәдәниятен үстерүгә акчалар тотып, үз гөнаһларын юмакчы була. Ләкин борынгы этносның тамырына балта чабылган шул инде.

Төп, тамыр халыклар проблемасы — авыр һәм катлаулы мәсьәлә ул. Чөнки дөнья этносларыннан бик азы гына үз дәүләтләрен булдыра алган. Мәгаен, бу проблема башка бер җирдә дә Русиядәге сыман үткен тормый торгандыр. Монда йөздән артык төп, тамыр халыклар яши, аларның хокуклары танылмаган һәм канун белән якланмаган. Россия репрессияләнгән халыкларның хокуклары торгызылмаган Аурупадагы бердәнбер дәүләт булып калды.

Төп, тамыр халык булып шушы мәйданда житешкән һәм үзенең этник сыйфатларын, билгеләрен саклап калган этнос тора. Нигез сыйфат итеп төп, тамыр халыклар буенча БМО нотыкчысы бу халыкның кем тарафыннан булса да басып алынган булуын китерде. Шулай булганда урыслар Русиянең зуррак өлешендә төп, тамыр халык саналмый.

Төп халыкның күкрәгендә һәрвакыт үз хәленнән канәгатьсезлек хисе дөрли, аның тарихи хәтере әүвәлге бәйсез яшәгән көннәренә әйләнеп кайта. Шунда аның мөстәкыйль үсешкә, үз җиренә, тереклек итәргә кирәкле хәзинәләренә үзе хуҗа булу дәгъвасы калка. Туган телен үстереп, аны идарә һәм хөкем органнарында, мәдәни һәм башка максатларда куллану теләге көчәйгәннән-көчәя бара. Төп халыкның икътисади, социаль һәм теләсә нинди башка мәсьәләләре этник төс ала. Дөнья тәҗрибәсе моның бетмәслеген күрсәтә һәм шуна күрә аны чынбарлык буларак кабул итәргә кирәк тә.

Төп халык проблемаларын гамәлдә аның санына, ничек урнашуына карап, икътисади һәм сәяси хәлдән чыгып, төрле юллар белән чишәргә була. Шундый юлларның берсе — кануннар нигезендә төрле льготалар, дәүләт дотацияләре һ. б. бирү. Икенче юл — автономия бирү. Бу очракта автономия үз эченә, БМО нотыкчысы (докладчысы) тәкъдим иткән «Төп, тамыр халыклар хокукларының Бөтен Дөнья декларациясе проекты»на туры китереп, түбәндәге вазифаларны ала: Алар — «Белем бирү, информация, мәдәният, дин, сәламәтлек саклау, торак мәсьәләләре, социаль иминлек, борынгыдан килгән һәм башка төрле икътисади хезмәт төрләре, җирдән файдалану һәм ресурслар белән идарә итү, әйләнә-тирәне саклау, шулай ук автоном вазифаларны финанслау максаты белән эчке салым салу». Мөмкин булган хокуклардан тышкы сәясәт, оборона һәм акча мөстәкыйльлеге монда керми. Мондый автономия чынлыкта Гренландия эскимосларында бар. Саннары 32 мең генә булса да, аларның кануннар чыгаручы органы һәм ике дәүләт теле — датчан һәм эскимос теле бар.

Русиядәге хәлне бөтен дөньяда кабул ителгән нормалар белән чагыштырып карасаң, Русия житәкчелегенең кешенең иң гадәти хокукларын аңлалавына, үҗәтләнә-үҗәтләнә империя биләмәләрен сакларга тырышуына исең китә. БМО тәкъдимнәрен гамәлгә ашырса, Русия житәкчелеге, хәтта халыклар үзбилгеләнмәгәндә дә, әле илдә хәлне тотрыклы итә, хакимият челтәрен чын-чынлап яхшырта алган булыр иде. Бүген исә төп халыкларга бер генә юл — бәйсезлекләре өчен сәяси һәм икътисади чаралар белән көрәшү юлы гына кала.

Хәлнең фаҗигасе шунда күренә ки, Русия халыклары хәтта үз исемнәре белән аталган республикаларда да милли азчылык хокукларына ия түгел. Марий Эл, Чувашия һәм Удмуртия республикаларында милли хәрәкәтләр еш кына мари, чуаш, удмуртларның хокуклары өчен үз хөкүмәтләре белән көрәшергә мәҗбүрләр. Бу республикаларның хөкүмәтләре үз халыклары мәнфәгатен кайгыртучы булу урынына, «мәркәз» сәясәтен үткәрү белән шөгыльләнә. Русиядә бер яктан колониаль сәясәт, икенче яктан, шуңа тәлинкә тотып тору яхшылык дәрәҗәсенә куелган.

Төп халыкларның үзбилгеләнүе — мәсьәләне хәл итүнең иң гадел юлларыннан берсе. Хәлбуки, бу очракта проблема яшәп яткан дәүләт кысаларында халыкның автоном хокукларын гади генә киңәйтүгә караганда тамырдан үзгә булып чыга. Дәүләтчелеккә әйләнгәч, автономия сәяси нисбәтләрен үзгәртеп кенә калмый, ә моңарчы колак ишетмәгән яңа сәяси төшенчәләр дә китереп кертә. Мөстәкыйль, бәйсез дәүләтнең мантыйгы (логикасы), автономиянеке белән чагыштырганда, бөтенләй башка. Автономия мантыйгы — этник мантыйк: милли азчылык булган бер халыкны яклау вә саклау. Бәйсез дәүләт мантыйгы — милли мантыйк: бу дәүләтне хасил иткән барлык этнослар һәм ватандарларны яклау вә саклау.

Үзбилгеләнү барышында төп, тамыр халык төшенчәсе үзенең әүвәлге сәяси мәгънәсен җуя. Яңа гына оешып килә торган дәүләткә бу үзгәреш юлбашчысы булган төп халык белән генә түгел, шушы ук рольне дәгъвалаучы барлык этнослар белән дә санлашырга туры килә. Аннан соң, үзбилгеләнә торган этнос бу өермәгә үз җирендә яши торган башка халыкларны да өстери, башка берлеккә әверелә: халыкка әйләнә, ә аннары бүгенге кыйммәтләре күп яктан әүвәлгеләренә туры килеп торган милләт булып үсеп җитә. Нәкъ менә шушындый хәл Татарстанга хас. Монда төп, тамыр халык, этник төшенчә булып, сәяси роль уйнамый. Татарстанның бәйсез дәүләт булып үзбилгеләнүен тәэмин итүдә төп халык булган татарларга өстенлек бирү түгел, ә урысларга да татарлар хокукын булдыру уңыш китерер. Татарстанда татарлар һәм урыслар дәүләт хасил итүче этнослыкны дәгъва кылуларын ачык белдерделәр. Шул ук вакытта Татарстан монда тыгыз укмашып яши торган этносларның,— аларның саннары күп булуга карап кына түгел (мәсәлән, чуашлар 137 мең), ә аларның милли республикалары белән чиктәш булганлыгы аркасында да,— ул этносларның мәнфәгатьләрен истә тотмый кала алмый.

Җәмгыятьтә аерым бер категория кешеләр бар, алар — мигрантлар. Аларның проблемалары милли азчылыкныкыннан аерыла. Чөнки алар бу дәүләт ватандарлары түгел, бу җирдә утырып калырга ният итмиләр дә. Мигрантлар — этник түгел, ә социаль күренеш. Дорфарак итеп әйткәндә, ул — эшче куллар. Аларны язмыш җилләре бу милли даирәгә китереп ташлаган, ләкин алар үз мәнфәгатьләре белән яши. Аларның үз психологиясе, үз ихтыяҗлары була һәм алар төп этнослар белән генә түгел, теле, мәдәнияте һәм этник чыгышлары үзләрен берләштерә торган милли азчылыкларга карата да аерым бер мөнәсәбәттә тора. Балтыйк буенда бу проблема бик ачык күренде. Анда урыслар ике төркемгә бүленде: берсе хәзерге хәлгә ияләшергә, мәдәни даирәне кабул итәргә, үзенең этник кыйммәтләрен саклап калырга, икенче төрле әйткәндә, үзен милли азчылык кебек тотарга тырышса, икенче төркем шул дәүләт кануннары белән яшәргә җыенмый һәм шуңа күрә сәяси көрәшне яки ул дәүләттән китеп баруны артыграк күрә.

Моңа охшашлы хәлне төрле вариацияләрдә теләсә кайсы республикада очратасың. Татарстанда мигрантлар психологиясе бигрәк тә Чаллы шәһәре мисалында ачык чагыла. Бирегә үз заманында әйбәт акча эшләргә дип шактый күп очраклы кешеләр килеп төште. Аларны үзләренең кем балалары булуы, этник чыгышлары да кызыксындырмый, ә инде республиканың тарихы һәм мәдәнияте турында әйтеп тә торасы юк. Моңарчы Чаллыда саф тамырсызлык фикере яшәп килде. Бер буклетка, мәсәлән, «Яр Чаллы — КамАЗ шәһәре» дип язылган иде. Бу дуңгәләккә әйләнгән мигрант психологиясенең үзенә күрә бер тантанасы иде. Хәлбуки, Чаллының гына түгел, Татарстанның башка шәһәрләре кешеләренең дә аңында үзгәрешләр барганлыгы күз алдында. Ватанпәрвәрлек хисләре үскәннән-үсә бара. 1992 елның 21 мартындагы референдумда Чаллыда республиканың статусын күтәрү өчен сайлаучыларның 60,8 проценты тавыш бирде — бу Казандагыга караганда күпкә артык.

Русиядә этносара мөнәсәбәтләр гаять тә күптөрле. Балтыйк буенда моноэтник дәүләтләр кору юлыннан киткән булсалар,— бу бөтен Аурупада дип әйтерлек шулай,— Русия өчен бу юл мөмкин түгел. Русиягә дини фактор куәтле булган Урта Азия республикалары юлы да килешми. Хөкүмәт православие динен дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрергә күпме генә тырышмасын, дини дәүләт өчен социаль база юк. Өстәвенә, Русия этник һәм дини яктан бик чуар. Бер генә диннең берләштерү ролен уйный алуы мөмкин түгел. Русиядә үзбилгеләнү республикалар һәм өлкәләрнең бүгенге чикләрендә барачак, ә үзбилгеләнүнең объектлары булып төп, тамыр халыклар гына түгел, урыслар да торачак.

Үзбилгеләнү кешеләрнең үз дәүләтләрен булдырырга дип үз теләк-ихтыярларын ачык белдерүдән башлана. Ул теләк-ихтыяр мөстәкыйль сәяси анда, үзбилгеләнү өчен көрәшүче сәяси фиркалар (партияләр) һәм оешмалар, дәүләт белән идарә итәрлек кадрлар һәм структуралар булганда күренә. Андый берлек бер яки берничә этностан торырга, бөтен этносны яисә аның бер өлешен үз эченә алырга мөмкин, ләкин ул үзен тарих субъекты итеп тоярга һәм аның үзе дәгъва итә торган, үзе яши торган конкрет җире булырга тиеш.

**Халык төшенчәсе күпкырлы һәм ул күп мәгънәләрдә йөри: *1) җәмгыятьнең җитәкчеләр тарафыннан идарә ителә торган өлеше — аны «гади халык» дип йөртәләр. Болар гадәттәге сайлаучылар; 2) ватандарларын җәмгыятьнең синонимы — республиканың барлык халкын күз алдында тотып, без «Татарстан Республикасы халкы» дибез; 3) этнос синонимы — җиде миллионлы этносны күз алдында тотып, без «татар халкы» дибез.***

Безгә бу очракта әлеге төшенчәнең ике аспектын күрсәтеп үтү мөһим. Беренчедән, әлектә үз дәүләтләре булган этнослар бар. Аларны милләт дип әйтеп булмый, чөнки милләтләр чагыштырмача күптән түгел формалашкан һәм аларның әлектә күрелмәгән бик ачык үз шәкелләре була. Чыннан да, хәзерге милләтләр, борынгы халыклардан аермалы буларак, дөнья сәясәтендәге вазифалары белән үзара бәйләнгән, алар халыкара җәмәгатьчелекнең, икътисадның состав өлеше булып тора һәм алар арасындагы мөнәсәбәт халыкара хак-хокуклар белән тәртипкә салына. Бу хәл моннан 200—300 ел элегрәк юк иде әле. Тарихи күренешләргә хәзергечә анлауны китереп тыкмау өчен андый берлекләрне, этнос һәм милләттән аермалы буларак, халык дип атауның үз мәгънәсе бар.

Икенчедән, үз дәүләтен торгызырга яки үзбилгеләнергә омтылучы берлекне «халык» дигән аерым термин белән атауның әһәмияте зур. Андый берлекнең бергә укмашып яши торган мәгълүм дәрәҗәдә чикләре булган җире була һәм ул, полиэтник булып, шунысы белән этностан аерылып та тора. Бу мәгънәдә «халык» милләткә әйләнү юлында бер күчеш рәвеше була. Бу инде үз хокукларын автономия кысаларында киңәйтергә хыялланучы этнос кына түгел, ул инде дәүләтчелек дәгъвалый, ләкин аның әле дәүләт мәнфәгатьләреннән килеп чыга торган кыйммәтләрнең яңа системасы тумаган була.

Милләт халыктан дәүләт үзбилгеләнүенең тәгәлләнүе белән дә, дөньядагы милләтләр арасында үз урынын алуы белән дә аерылып тора.

Татарстанга әйләнеп карасак, без республикада бүгенге көндә татарлар, урыслар, чуашлар һ. б. лардан торган, гомуми җирдә бергә яшәргә риза булган, дәүләт, икътисад, мәдәният белән мөстәкыйль идарә итү өчен сәяси хокуклар алырга омтылган халык хасил булыр, дип раслый алабыз.

Башка илләр тарафыннан танылган, үз ватандарлыгы (гражданлыгы), тышкы сәясәте булган Татарстанның бөйсез дәүләт статусын республика халкы — Татарстан Республикасы милләте тәэмин итә.

Шуның белән этносның милли азчылык хәленнән халык, милләт һәм яна дәүләт булып формалашуы тәгәлләнә, ләкин аның белән әле милли проблемалар тәгәлләнми.

## 11. Милли азатлык һәм демократия

### Милләтнең азатлыкка таба хәрәкәте буларак, демократия

Милләт — кешеләрнең табигый берлеге һәм ул шәхесләрнең иҗади эшләвен таләп итә. Төркемнәр, сыйныфлар, катламнар чиге белән бикләп тормыйча, ул кешене, вак иминлектән югары күтәреп, тарихи, дөньяви, мәңгелек нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Мәдәнияттән, җәмгыятьтән читтә торган, язмышка буйсынган һәм төзү урынына җимерергә генә булдыра торган коллар милләтсез була.

Милли хокуклары булмаган халык өчен демократиянең бер мәгънәсе дә калмый. Шуңа күрә һәр халык өчен ул үзбилгеләнүдән башлана.

Халыкларның үзбилгеләнүе дәүләт корылышының приори рәвешләрен күз алдында тотмый. Бер төрле халыклар үз дәүләтләрен булдырып, башкалары мескен бичаралар хәлендә яшәргә тиеш дигән принципның дөньяда булганы юк. Теләсә кайсы халыкның тарихта үз кадере бар,

шуңа күрә, урыскамы анда, инглизгәме өстенлек биреп, чәчәнне яки шотландны кысарга беркемнең дә хакы юк. Үзбилгеләнүнең субъекты буларак, халык үзе генә аякка баса ала һәм ул үсешенең рәвешен сайлап алырга үзе генә хокуклы.

Милли мәсьәлә ул тактика мәсьәләсе түгел, ә принцип мәсьәләсе, һәм шуңа күрә аны өлешләп-өлешләп, баскычлап-баскычлап хәл итеп булмасына иманым камил. Ул хәл ителгәндә йә тулы күләмдә һәм беркемне дә аермыйча бөтенесе өчен дә хәл ителә, йә ил гел-гел милләтара тетрәнүләр эчендә яшәргә дучар булып кала.

Империя структураларыннан иртәрәк котылып, төрле хәлләр аркасында бәйсезлекне башкалардан иртәрәк алуга ирешкән халыклар да була. Моңа 1917 елдан соңгы Финляндия белән Польша мисал. Безнең чорда элеккеге Союздаш республикалар белән шул хәл кабатланды. Ләкин системада калганнар бер җепкә бәйләнгән. Империянең асылы шунда: ул бөтенесен дә иң изелгән халык дәрәҗәсенә куярга омтыла. Бу канунның үзгәрәсе юк. Моннан чик буенда урнашу да, этник составның нинди булуы да, халык саны да, нинди дә булса башка берәр фактор да коткарып кала алмый. Украина 1917 елдан соң халкы күпсанлы, экономикасы куәтле, уңайлы геополитик хәлле бер республика иде. Ләкин берни дә коткармады, 70 ел буе украиннар СССРдагы башка теләсә кайсы милләт хәленә төшерелде. Милли мәсьәлә хәл ителмәгән яисә өлешчә генә хәл ителгән системада бар халыклар да, иртәме-соңмы, барыбер хокуксызлыкта тигезләнәләр.

СССРда милли мәсьәлә һәрвакыт хәрби мәсьәләнең бер өлеше булып килде. Бу аңлашыла да, Казан ханлыгыннан башлап, бөтен яңа җирләр һәм халыклар басып алынды лабаса һәм корал көче белән тотып торылды. «Ирекле» кушылулар — ул соңрак уйлап чыгарылган идеологик кармак кына. Әүвәлрәк андый түбәнлеккә төшеп тормаганнар, халыкларны яулап алу зур дәрәҗә дип исәпләнгән һәм теләсә нинди сәясәтне дә шуның белән «аклаганнар». Шул хәл Россия халыкларында «мең еллык» патшалыкка каршы потенциаль куркыныч күрә торган фикерләүне китереп тудырган. Дәүләт эшлеклеләренең күпчелеге милләтара мәсьәләләргә сәясәтчеләрчә түгел, хәрбиләрчә якын килә, ягъни низаглар кызгач кына уяна да шундук коралга ябыша. Алар халыкларның тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынып азапланмый, иң әйбәт дигәндә дә, бу мәсьәләне бик тә берьяклы яктырткан дәреслекләрдән алган мәгълүматлар белән канәгатьләнәләр. Татарлар турында нәрсәләр генә язып бетермәгәннәр дә ул ялганнар кайларга гына барып җитмәгән. Шуннан соң дөньяда татарларны ни рәвешле күз алдына китерүләренә гаҗәпләнеп торасы калмый.

Русия житәкчелеге ят халыкларга карата хәрби сәясәтен ялган хөрриятнең идеологик пәрдәсе белән капларга тырыша. Демократия үзеннән-үзе милли мәсьәләләрне хәл итәчәк, дигән әкият таратыла. Әгәр ул шулай икән, Төньяк Ирландиядә, басклар илендә сугыш булмас иде, чәчәк атучы Квебек аерылырга омтылмас иде, Бельгия федерациягә кечеп маташмас иде, ә АКШтагы индеецлар турында без Фенимор Купер китапларын укып кына белгән булыр идек. Бик күпләр идеаль өлге дип санаучы Америка демократиясе ни өчен индеецларны канәгатьләндерми? — дигән гади генә сорау куеп карыйк, ди. Ни өчен иң демократик булган илләрдә дә халыклар үзбилгеләнү өчен көрәшә? Бар халыкларга да ярый торган үрнәк демократия буламы, әллә инде һәрбер халык демократиянең үзенә генә яраклы рәвешен сайлап аламы?

Демократия абсолют һәммәсен дә канәгатьләндерә торган булмый. Демократик режимны конкрет милли мәнфәгатьләрне истә тота торган дәүләт урнаштыра. Башка халыклар хокуклары бу очракта аңа читләтеп кенә кагыла. Билгеле, тоталитар режимнан аермалы рәвештә, демократик режим этник төркемнәргә үз мәдәниятләрен сакларга рөхсәт итә, демократик илләрдә этник чыгышың өчен эзәрлекләү юк, анда Кырым татарлары, Идел буе алманнары (немецлары) яисә ингерманланд финнәре проблемалары була алмый. Хәлбуки, кешенең яки этник төркемнең яшәргә булган хокукы белән халыкның лаеклы үсешкә хокукы арасында зур аерма бар.

Икенче бер әкият тә бар әле. Анысы, имештер, базар мөнәсәбәтләренә күчкәч милли проблемалар үзләреннән-үзләре хәл ителә, дип расламакчы. Алай гына да түгел, күп кенә сәясәт әһелләре демократияне, базар мөнәсәбәтләрен һәм милли проблемаларны хәл итүне бер-берсе белән тәңгәл күрә. Мондый караш чынбарлыктан ерак тора. Базар мөнәсәбәтләре бик иркенләп диктатура белән килешеп яши ала, алай гына да түгел, еш кына базар мөнәсәбәтләренә күчеш үзе диктатура урнаштыруны таләп итә башлый. Ә милли проблемаларга килгәндә,

базар аларны катлауландырып та җибәрергә мөмкин. Инде бүген үк хосусыйлаштыру милли төсмер ала башлады. Халыклар, аеруча аз санлы халыклар җиргә хосусый милек кертүгә борчылып тора, чөнки җир йөзендәге соңгы терәкләренең колак кагулары бар. Күп кенә төбәкләрдә төп халыкларның түбән квалификацияле эшче генә булуы сер түгел һәм, болай булгач, эшсезлек аларга беренче булып килеп кагылачак. Төрле республикаларның үзгәртеп кору мөмкинлекләре бертөсле түгел. Берәүләрнең икътисади структуралары базарга якынрак торса, икенчеләренең ераграк тора: берәүләрнең чимал байлыгы җитәрлек, икенчеләрнең бөтенләй юк. Кыскача әйткәндә, базар мөнәсәбәтләре милли тормышны җиңеләйтү урынына катлауландырачак кына.

Дөнья гамәле күрсәткәнчә, демократиянең югары дәрәҗәсе дә, икътисади бөтенлек тә үзләреннән-үзләре генә милли мәсьәләне хәл итми.

Хокукый дәүләт бишеге булган Бөекбританиядә Ольстер бар, югары үсешкә ирешкән Канадада — Квебек. Милли мәсьәлә аерым, мөстәкыйль мәсьәлә генә түгел, ә даими игътибар таләп итә торган гаять катлаулы мәсьәлә дә. Аның үзенчәлеге шунда: үз вакытында хәл ителмәсә, ул хокук нормалары һәм актларына бирешми башлый, физик катнашу, фәкыйрьлек һәм хокуксызлык хасил итеп, җәмгыять тормышын параличлый. Йогышлы чир сыман, ул бөтен иҗтимагый организмны агулый. Төбәкләрнең милли үзенчәлекләре җәмгыятьнең экзотик бизәге генә түгел, төрле хәрәкәтләр һәм «фронтлар» барлыкка китерә торган афәт тә түгел — дәүләтнең асылы, аның яшәвенең максаты һәм мәгънәсе ул.

Милли азатлык белән демократия арасында антагонизм килеп чыгуын кем генә теләр икән. Ләкин, аяныч ки, тормыш дигән нәрсә кайчак, миннән дә, синнән дә сорап тормыйча, бу мәсьәләне алга китереп сала: сала да еш кына шулардан икесенең берсен сайлап алырга мәҗбүр итә.

**Дөньяда демократиядән дә кадерлерәк берәр нәрсә бармы икән? Безнең заманда бу сорауның бирелүе үзе үк хәерсез күренүе мөмкин. Хәлбуки, Каталониядә, Көрдестанда яисә Татарстанда үзбилгеләнү хакына көрәшүчеләр өчен моның җавабы көн кебек ачык — алар, ике дә уйлап тормастан, бөтен кадерле нәрсәләр арасыннан милли азатлыкны сайлап алачак. Һәм «милләтче»ләрнең моңа дәлилләре җитәрлек булачак. Әйтик, татар халкы өчен, аның азатлыгын кем буса да: патша режимымы ул, милләтләрне кушу буенча коммунистик сәясәтме яки иске тәртипле, яңа лозунглы ялган демократ Русияме — барыбер түгелмени?! «Милләтче»ләр демократиянең халыкларга азатлык китерә торган кадәресе өчен көрәшә алып бара.**

**Милли азатлыкның үз кадере бар. Демократияне халыкларның үзбилгеләнүенә каршы куярга азаплану ул демократия өчен көрәш дигән күркәм сылтау белән азатлыкка каршы юнәлтелгән сәяси уеннан башка бернәрсә дә түгел. Милли азатлык булганда дәүләт корылышы демократик яисә авторитар булырга мөмкин, ләкин инде азатлык юк икән, демократия гомумән дә була алмый. Күп сәясәтчеләр милли азатлыкка омтылышны сепаратизм һәм экстремизм күренеше дип атыйлар, шул ук вакытта халык тарих субъекты булганда гына демократия була алганлыгы кебек гади хакыйкатьне башларына да кертеп карамыйлар. Демократия — халык хакимияте, ләкин ирексез халык тарихи процесстан читкә алып ташланган була. Милли азатлык — ул демократиянең тәүге сулышы да, аның нигезе дә. Гомумән, демократия яки милләтнең суверенитетына бәйләп карамый торган «саф» демократия — алдау ул. Урыс дөньясында, милли үзбилгеләнү проблемасы булмагач, төп мәсьәлә булып идеология килеп баса — ягъни кайсысын сайларга: коммунизмнымы, әллә антикоммунизмнымы, «капитализмнымы», әллә «социализмнымы»? Урыс булмаган халыклар өчен беренчел мәсьәлә булып азатлык мәсьәләсе тора, чөнки, тарих күрсәткәнчә, алар аны капиталистик Русиядә дә, социалистик Русиядә дә татымадылар. Ләкин бит ахыр чиктә урыслар да, башка халыклар да бер җеп белән бәйләнгән. Әгәр урыс демократиясе башкалар өчен ирексезлек булып калса, бу очракта ул кешенең этник чыгышы белән саилашып тормый торган яңа төр диктатурага әвереләчәк. Шуның өчен дә Русиянең демократлашу мөмкинлеге үзе үк милли-дәүләтчел үзгәртеп корулар белән бәйләнгән.**

Яшәп тора торган дәүләт һәрвакыт халыкның үзбилгеләнүе юлында киртә була, чөнки теләсә кайсы дәүләт тә үзенең ирешкән сыйфатларын һәм мәйданый бөтенлеген сакларга омтыла. Русиянең Англиядән, йә булмаса башка берәр демократик илдән аермасы шунда — Аурупа илләрендә милли азчылыкларның мәгълүм дәрәҗәдә азатлыгына ирешелгән һәм аларның ул азатлыкны киңәйтергә омтылышлары табигый күренеш дип кабул ителә. Ә Русиядә үзбилгеләнү теләген генә дә дәүләт җинаяте сыман кабул итәләр. Чын-чыннан демократик

дәүләт тоталитар дәүләттән шунысы белән аерыла да инде — ул халыкларның үзләре теләгән рәвештә үзбилгеләнүенә каршы килми, ә шуңа ярдәм итә.

Русиядә «демократия» дип, кагыйдә буларак, күпчелекнең фикерен ачыклый торган тавыш бирү процедурасын аңлыйлар. Урыслар 82% тәшкил иткәч, Русиядә милли мәсьәләләр гомумән булырга тиеш түгел дип карыйлар, чөнки һәр очракта да күпчелек урыслар ягында булачак. Бу — хөрриятнең механик күпчелек «хокук»ына нигезләнгән примитив рәвеше генә. Ул башка халыкларның хокуклары булырга тиешлеген танып маташмый, ул милли яисә социаль азчылыклар хокукларын һәм шәхес хокукларын бигрәк тә инде бар дип тә белми. Ул мәнфәгатьләр балансын яки аларны килештерүне белми, аңа консенсус төшенчәсе ят була. Ә халыклар үз мәнфәгатьләрен кайгырта башласа, бу рәвешле хөррият тормыш белән каршылыкка керә, һәм гаҗизлектән, күпчелек ихтыярын үтәү дәлилен китереп, көч кулланырга өнди башлый.

Демократия бары тик милли хокуклар контекстында гына эчтәлекле мәгънә ала. Социаль, милли максатлардан аерым торган «саф» демократиянең мәгънәсе бетә, ул тавышларны механик җыюга әйләнеп кала. Тарихи яктан демократик принциплар милли казанышлар буларак салынып киләләр. Либераллык идеяләре француз мәгърифәтчеләре тарафыннан эшләнә, гамәлдәге хокукый дәүләт Бөекбританиядә туа, хәзерге демократик нормаларның күбесен алман социаль демократлары бәян итә, федератив принциплар АКШта урнаша, референдумнар дөньяга Швейцария җирлегеннән тарала. Демократик принципларның үз конкрет милли чыганаклары һәм үз ияләре була. Алай гына да түгел, дәүләт корылышының бер рәвеше буларак, демократия милләт үсешенең табигый бер баскычы да булып тора.

Демократия — чиксез кадерле нәрсә, ләкин ул Аурупадагы империяләр таркалгач кына хасил була. Халыкларның үзләренә ярашлы хөррият рәвешенә баруларының тарихи бер логикасы бар. Демократияне халыктан көч белән тартып алып була, ләкин аны көч белән тагып булмый. Көчләп тагып урнаштырылган демократия гадәти диктатура булып чыга.

*Дәвамы киләсе санда*

**Дискуссия дәвам итә:**

## БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

# ТОРМЫШЫНА КҮРӘ ӘДӘБИЯТЫ...

Соңгы елларда илебездә барган сәяси үзгәрешләр мона кадәр яшәп килгән кануннарны, киртәләрне ватты-җимерде һәм тормышыбызны яңача бәяләү, аны үзгәрәк күзлектән чыгып аңлау юлларын киңәйтте. Үткәнебезгә, бүгенгебезгә аек акыл белән, чын дөреслек аша карап киләчәгебезне аныграк күзалларга һәм, үткәннәрдән гыйбрәт алып, тормыш турында тирәнтен уйларга мәҗбүр итте. Базар мөнәсәбәтләре тормышыбызның барлык өлкәләренә дә үтеп керде. Әлбәттә инде аның йогынтысы тормышның көзгесе дип саналган әдәбиятка да орынмыйча кала алмады. Ник дисәгез, әдәбият белән тормыш арасында кытай диварлары юк, алар бер-берсен тулыландырып, баетып, үзара даими тәэсир итешеп яшиләр. Бүгенге көндә, үткән тарихыбызны һәм әдәби мирасыбызны өр-яңадан бәяләү таләп ителгән чорда, язучыларыбыздан чын дөреслекне генә, хакыйкатьне генә тасвирлау таләп ителә. Язучыларыбыз арасында да кемнәрдер әмере буенча түгел, ә нәкъ менә үзләренең вөҗданнары, намуслары кушканча иҗат итүчеләр артты.

«Безнең тормыш. Безнең әдәбият» исеме белән бүгенге проза торышы турында башланып киткән бәхәс соңгы елларда безнең әдәбиятта дөнья күргән әсәрләр хакында барырга тиеш иде. Ләкин, кызганычка каршы, проза турында сөйләшү күбрәк Фоат Садриевның «Таң җиле» исемле романы тирәсендә һәм аны «үтереп мактау» рухында бара. Бу юнәлешне Ф. Галимуллин башлап җибәрде, Г. Тавлин күтәреп алды, башкалар дәвам итте. Ф. Садриев, күрәсең, йөзлекле бала булып тугандыр. Чөнки соңгы елларда бер генә әсәр хакында да, аның әлеге романы турындагы кебек күп итеп, югары бәя биреп язылганы булмады. Минемчә, моның сәбәбе ике: беренчедән, «Казан утлары»ның әлеге роман басылган санында «проза турында бәхәс башлыйбыз» дип язылды һәм кайберәүләр шул роман турында гына язарга кирәк дип аңладылар булса кирәк; икенчедән, роман хәзерге авыл тормышының безнең әдәбиятта әлегәчә, бик күтәрелмәгән нечкә якларын үзәккә алган һәм, әлбәттә, анда үзенчәлекле, кабатланмас геройлар бар. Ләкин, шул ук вакытта, мин үзем бу романны татар әдәбиятының иң югары казанышы дип санамыйм һәм ул соңгы елларда басылып чыккан башка әсәрләрне оныту, яки игътибар итмәү өчен сәбәп булырга тиеш дип уйламыйм.

Ә минем сүз XX гасырның иң зур һәм фаҗигале катаклизмнарыннан берсе булган 1941—1945 еллар Ватан сугышы чорына багышланган яңа әсәрләр турында. Белгәнебезчә, әлеге чор бик күп әсәрләрдә бәян ителгән булса да, сугыш чоры темасы безнең әдәбиятта үзенең йөрәккә, бәгырьгә кагылуы белән үткән авыр хатирәләрне һаман яңартып, искә төшереп тора. Үткән сугышның төрле якларын, авырлыкларын, афәтен һәр чор язучысы үз буыны ноктасыннан чыгып бәяли һәм аның яңадан-яңа кыйтгаларын ача. Ике тиран кабызган, миллионлаган гөнаһсыз кешеләрне корбан иткән бу сугышка соңгы елларда бәя үзгәргәч, татар

әдәбиятында да сугыш чоры тормышының бөтен тулылыгы белән тискәре һәм уңай якларын күрсәтеп, чагылдырып язылган әсәрләр иҗат ителде һәм басылып чыкты. Алар хәзерге әдәбиятыбызның аерылгысыз өлеше булып торалар.

Соңгы вакытта татар прозасында өлкән буын әдипләребез аерым бер үҗәтлек белән эшләделәр һәм аларның иҗатларына игътибар иткәннән соң, барысы өчен дә уртак бер юнәлеш барлыгы ачыкланды. Әйтик, А. Гыйләҗевнең «Яра» («Казан утлары», 1989, № 1), М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» (шунда ук, № 1, 2), Н. Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» («Идел», 1990, № 1, 2) повестьлары эчтәлекләре, сурәтле-фикерләү үзенчәлекләре, стильләре, телләре буенча төрле-төрле булсалар да, аларны уртак бер нәрсә берләштерә: бу — явызлыкка каршы көрәш, аны кабул итмәү, кире кагу.

Явызлык төрле киемдә була: ул — Ватан сугышыннан соңгы җәрәхәт тә, ул — Сталин репрессияләре калдырган кан сарку да, ул — ваемсызлык һәм ярага тоз салган бер вакыйга да булырга мөмкин. Хикмәт вакыйганың үзендә түгел, ә явызлыкның төрле-төрле төсләрдә, рәвешләрдә килеп тә, эчтәлеге уртак булуда. Ничек кенә яшәсә дә, ул барыбер кешегә каршы юнәлтелгән. Аның максаты — кешене изү, сыту. Югарыда санап кителгән өч повестьта да сүз дә шул хакта бара. Һәм иҗтимагый яңгырашлары буенча аларның аермалары шунда да. Без бу әсәрләргә игътибарны юнәлтик һәм сугыш чоры татар авылының, шул вакыттагы явызлыкка каршы көрәшнең язучыларыбыз тарафыннан ничек бирелүен кыскача гына карап үтик.

Югарыда аталган әсәрләр барысы да сугыш чоры татар тормышының безгә моңа кадәр мәгълүм булмаган якларын чагылдырып язылганнар дигән идек. М. Мәһдиев үзенең «Бәхилләшү»ендә халкыбызның рухын чагылдырган төрле күренешләр, вакыйгалар аша татар рухына якын гореф-гадәтләр, матур йолалар аркылы укучыны сугыш алды, сугыш чоры һәм сугыштан соңгы еллар авылына алып кайта. Ә А. Гыйләҗевнең «Яра» повестенда исә сугыш чоры һәм аннан соңгы еллар, дөресрәге, сугыш афәте тудырган аянычлы һәм көенечле вакыйгалар, халкыбызның яралары һәм шул яраларның бүген дә сызланулары үзәккә алынган. Н. Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» повесте тулаем сугыш елларының билгеле бер вакытына багышланылган әсәр. Монда автор безгә көчләп тагылган хакимиятнең гади кешегә никадәр чит-ят булуын, кеше намусын ничек таптавын, изүен, хәтта юк итәргә омтылуын бик тә тәэсирле итеп күрсәтә алган.

Әсәрләрнең язылу тарихлары төрлечә булган кебек, алар турында әйтелгән фикерләр дә төрлечә. Әйтик, Н. Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» повесте 1990 елда «Идел» журналының беренче саннарында дөнья күрде. Әсәрнең башында ук авторның кереш сүзе бирелә:

«Каберләр белән чуарланган сагышлы җир өстенә моннан утыз еллар элек якты нур төшкәндәй булды. Шифалы җил исте, күктә болытлар тарала башлады. Көне-төне камыт киеп тарткан хокуксызлар — ачлар, ялангачлар өметләнеп бәхет көттеләр». Автор әйтүенчә, әсәр 1965 елда ук язылып, заманында «Казан утлары»нда басылып та чыккан булган (1965, 12 сан). Дөрес, анда ул шактый «редакцияләнгән» вариантта һәм «Артта калган юллар» дигән башка исем астында бирелә. Хәзер исә язучы укучыларга әсәрнең имгәтелмәгән нөсхәсен тәкъдим иткән. Чынлыкның ни дәрәҗәдә ак, ни дәрәҗәдә кара булуын бүгенге укучы үзе хөкем итәр, әйтер дип фараз кыла автор. Беренче вариантында ул әсәрнең тикшерелүен һәм үзгәртергә киңәш бирүләрен, «ахырын яктырак, матуррак рухта тәмамларга» туры килүе турында да искәртә. Соңыннан инде, болытларның яңадан куеруын, җир өстендә яңадан караңгылыкның хакимлек алуына басым ясый. Һәм әлеге әсәрне башка беркайда да бастырмыйлар. Ә авторын төрлечә гаепләү, кысу, җәберләү башлана.

М. Мәһдиев һәм А. Гыйләҗев әсәрләре турында да төрле фикерләр әйтелгән, хәтта бәхәсләр дә тудырган язмалар басылды.

Менә «Социалистик Татарстан» газетасенең 1989 елгы 23 июль санында Җ. Рәхимовның «Иске юл ерак китмәс» исемле мәкаләсен алыйк. Автор монда М. Мәһдиев һәм А. Гыйләҗев иҗатларына карата шактый кискен, каршылыклы фикерен әйтә. Аларны үткәнне язу белән мавыгучылар, традицион авыл темасына ябышып ятучылар, бүгенге көн белән исәпләшмәүчеләр итеп күрсәтергә тели.

М. Мәһдиев иҗатына карата: «...ул көйләнмәгән сабан сыман һаман бер үк буразнага кайтып төшә. Аның амплуасы — сугыш алды һәм сугыш чорындагы авыл» — дип яза. Мәкалә авторы биргән бәя белән килешмичә, тәнкыйтьче Т. Галиуллин «Олы юллар искерми...» дигән мәкаләсендә («Социалистик Татарстан», 1989 ел, 24 сентябрь): «Хикмәт тематикада түгел, ә язучының кешелекне борчыган, иң кыен, иң четерекле мәсьәләләрне табигый һәм образлы итеп,

кабатланмас шәхес язмышлары аша сурәтләү сәләтендә»,— дип язып чыкты. Чыннан да, Т. Галиуллин әйткәнчә, бу әсәрләр чын мәгънәсендә заманча язылганнар.

М. Мәһдиев әлеге әсәрендә утызынчы еллардан алып бүгенге көннәргә кадәр татар авылын, андагы тормышны, яшәешне сурәтләү аша, шул вакытта илебездә барган сәясәтне, «коммунизм төзүче бөек совет халкының» никадәр алданып, кызганыч хәлгә төшүен күрсәтә. Сталинның тоталитар режимы астында яшәгәндә, Брежнев торгынлыгында йоклаганда, без бит чыннан да югарыда утыручы коммунистлар уйлап тапкан алдавычларга ышана идек. Илебезне дөньядагы ин алдынгы, ин демократик ил дип фараз кыла идек. Ә «Бәхилләшү» повестенда язучыбыз, сайлау күренешен генә тасвир үзәгенә алып та, җәмгыятьнен ул чактагы хәлен, андагы купшылыкны күрсәтеп, ирек вә демократиянең нинди аяныч хәлдә булуын ачып бирә.

Н. Фәттахның «Кырык дүртнен май аенда» повестенда да сугыш чоры татар тормышының иң аянычлы яклары, җәмгыятебезнен шул вакыттагы төзәлмәс авырулары яктыртылган. Автор зур осталык белән илдәге ачлык-ялангачлыкны, шул чорга хас чын дөреслекне образлы итеп күрсәтә алган. Чәчелми калган басулар, авылдагы хәерчелек, мал-туарның ит планына, заемга, налогка озатылуы ул, «халык дошманнары» төрмәсе, аннан көн саен мәетләр алып чыгу күренеше һ. б.— шул заманда булган чын дөреслекнең автор тарафыннан ачык итеп язылуы, чорның кырыс хакыйкатен күзалларга мөмкинлек бирә. Автор шулай ук төрле тормышта яшәгән (итле аш ашаган, ярты сынык икмәген күршеләре белән бүлешкән) кешеләрне дә эзләп таба. Игътибар итегез: ә бит әсәр 1965 елда ук язылган. Димәк, автор шул вакытта ук инде безгә бүген генә билгеле булган, исбатланган бик күп нәрсәләрне күргән.

Әсәр «Артта калган юллар» исеме астында беренче тапкыр дөнья күргәч «Казан утлары»ның баш мөхәррире Р. Мостафин ана бәя биреп, әсәрнең төп кимчелеге итеп «беръяклылыкны» атый. Аның фикеренчә, повестьта тулы дөреслек түгел, шуның бер кыры, бер өлеше генә чагылыш тапкан икән. «Н. Фәттахның әсәрендә без фактлар дөреслеге белән очрашсак та, гасырның олы хакыйкатен күрмибез»,— ди ул («Казан утлары», 1969, № 1). Нинди «олы хакыйкать»не күздә тоткан соң тәнкыйтьче? Мәкалә авторы үзе үк әлеге әсәргә (икенче вариантына) язган рецензиясендә җавабын да бирә, беренчел фикеренең киресен раслый. «...Турыдан-туры әйтергә кирәк: Н. Фәттах, сәләтле язучы буларак, ул чорда ук әлеге кырыс хакыйкатьне тойган, аңлаган, образлы рәвештә күрсәтә алган. Тәнкыйтьче исә «социалистик реализм тәгълиматына» таянып, ...язучыны кара буяу кушуда... гаепли. Әмма дөреслек тәнкыйтьче ягында түгел, язучы ягында булып чыкты»,— дип, Р. Мостафин үзенең яшьлек хатасын таный һәм язучының әсәренә дөрес бәя бирү юлына чыга. Үз әйткәненә фанатикларча ябышып ятмау үзе үк куаныч бит.

Ф. Мусин исә, шул елларда язылган «Яшь геройга йөз белән» мәкаләсендә әлеге әсәргә кагылып, үз фикерен шул ук тәгълиматка таянып дәлилли.

«Сугыш елы авылын сурәтләгәндә бу диалектиканы (автор, «геройның мохит белән диалектик бәйләнешен исәпкә алмау, ахыргы чиктә тормыш дөреслеге белән алмаштыруга китерү»не күздә тота) аеруча нык бозу факты белән без Н. Фәттахның «Артта калган юллар» исемле повестенда очрашабыз. Ул шулай ук яшь герой мәсьәләсен күтәрә һәм аны реалистик планда яктыртырга тели. Реализм, мәгълүм булганча, «детальләр дөреслегеннән тыш типик характерларны типик шартларда чагылдыруны таләп итә (К. Маркс и Ф. Энгельс об искусстве в двух томах, т. I, М., 1967, 6—7 бб.).

Энгельснең һәркемгә мәгълүм булган бу билгеләмәсендә характерның типиклыгы (димәк, дөреслеге дә) аның реаль шартларда күрсәтелүе белән бәйләнгәнлеге икърар ителә (Ф. Мусин. Тарих һәм заман.— Казан, 1974, 86 б.).

Ф. Мусин фикерен әле без күптән түгел җирдәге аллалар дип санаган авторитетларга таянып раслый, тик ул да «типик шартны» шул заман күзе белән карап, бутабрак, ялгышыбрак күзалдына китергән, минемчә. Повесть авторы монда да тәнкыйтьчедән тормышны тирәнрәк аңлавы, хакыйкатьне дөресрәк күзаллавы белән аерылып тора кебек. Ф. Мусин сүзен дәвам итеп: «Н. Фәттах повестенда сурәтләнгән күңелсез күренешләрне дә, әйтик, ачлы-туклы яшәгән кешеләрне дә, ...сугыш алды елы авылында житәрлек күрергә булган..., ләкин Н. Фәттах повестенда әлеге күренешләрне «барын бергә шулай» кушып тасвирлау белән килешү кыен. Бирелә житди рәвештә тормыш дөреслеге мәсьәләсе алга баса».

Әйе, «тормыш дөреслеге мәсьәләсе алга баса». Нәкъ менә шул хакыйкатьне повесть авторы укучыга күрсәтергә тырыша да инде. Аннары «барын бергә шулай кушып» дигән сүзләр белән дә килешәсе килми, чөнки Н. Фәттахның әлеге әсәре сәнгать әсәре икәнен дә онытмыйк. Хәзерге көндә тәнкыйтьче Ф. Мусинның «житди рәвештә тормыш дөреслеге мәсьәләсе алга баса» дигән сүзләре үзеннән-үзе сорау тудыра, үз-үзенә каршы килә. Тәнкыйтьче болай ди: «тормыш дөреслеген җыеп әйткәндә, А. Гыйләжев, Ә. Баянов һәм Н. Фәттах повестьларында авыл чынбарлыгын, авторларның әлеге катлаулы заманны бары үзләренең балачакта күргәннәренә нигезләнгән шәхси тәҗрибәләреннән генә чыгып аңлатырга теләүләреннән, бередә тарих тәҗрибәсен искә алмауларыннан килә...»

Бар да дөрес, әмма тагын тәнкыйтьче үзе язганча «берьяклы караш» килеп чыга түгелме? Хәзер һәркемгә мәгълүм, андый авыр шартларны сугыш кына китермәгән бит. Бу очракта кайбер язучыларның гына түгел, ә тәнкыйтьчеләрнең дә «тарих тәҗрибәсен искә алмавы» күренә. Һәм бу хәзер дә дәвам итә әле. Хәзерге, демократия чын мәгънәсен ала барган чорда, әлеге әсәрне һәм аңа охшаган башка әсәрләрне дә без икенче күзлектән чыгып укырга һәм, иң мөһиме, автор әйтергә теләгән фикерне дөрес аңларга тиешбез.

А. Гыйләжевнең «Яра» повестендә дә кешеләр язмышы, яшәеше, аларның эчке дөньясы, уй-өметләре гаять тәэсирле итеп, җанга кагылырлык итеп сурәтләнелгән. Бу повестьта да, М. Мәһдиев, Н. Фәттах әсәрләрендәге кебек авыл кешеләре, туган җир һәм аларның үзара мөнәсәбәтләре, сугыш чоры сәясәте бар. Монда явызлыкка каршы көрәш укучыны ышандырырлык итеп, сәнгатьчә төгәл бирелгән. Әмма авторның үзенчәлеге шунда: ул сугыш китергән җәрәхәтне, яраны һәм кешеләрнең шул явызлык белән көрәшүен безнең әдәбиятыбызда борынгыдан килгән олы мәхәббәт белән янәшә куя һәм мифологик детальләр аша ача. Никадәр генә авыр, яралы булса да, кешеләрнең бер-берсенә карата булган мәхәббәте ахыр чиктә явызлыкны җиңә.

Автор үзе дә әсәргә катнашып, кереп китә. Язучы түзә алмый, үз фикере, үз фәлсәфәсе аша нәтиҗә ясарга омтыла («Үзем» бүлеге). Фәлсәфә дигәннән, автор аны тагын бер урында матур итеп бирә: 1947 елда гел ир балалар гына туа. «Җир-ана — безнең кодрәтле тудыручыларыбыз, үзенең кыр-урманнары, диңгез-дәрьялары, чүл-таулары язмышын хәл итәрдәй ир-атлардан ятим калганын белеп, аналар карынына ир бәбәйләр генә җибәрде», — дип яза. Монда инде табигать һәм кеше мөнәсәбәте, җирдә һәр нәрсә төгәл, үз урынында булырга, тулы булырга тиешлеге мәсьәләсе күтәрелә, явызлыкка (монда сугыш китергән афәт, ирләрнең сугышта үлүләре) каршы икенче бер көч куела.

Әсәрнең тагын бер үзенчәлеге — язучының халык ышануларын бик оста файдалануында (Сөләйман картның Йомыры таш янына барып дога кылу күренеше, яки Габдулланың әкиятләрдәге герой кебек, кырык үлемне җиңеп исән калуы). Әсәрне укыган саен ахырын беләсе килү теләге артканнан арта. Габдулланың хәбәрсез югалуына әсәрдәге әти-әнисе кебек үк, укучы да ышанмый. Чөнки аның сөюе, илаһи мәхәббәте белән очрашасы бар. Һәм язучы бу очракта акыл ышанмаслык хәлләргә хисне буйсындыра. Өмет — ул мәхәббәт. Татар халкында вәгъдәгә тугрылыклы калу элек-электән үк килә, эпик бер җыр, дастан булып яши.

Габдулланың әти-әнисе белән очрашуы һәркемнең җанын тетрәндерерлек итеп бирелгән. Бу хәлдә кешегә күпме сабырлык, ихтыяр көче кирәк бит. Әти-әнисе дә танымаслык хәлгә килгән Габдулланы Зәйтүнәсе таный. Мәхәббәт үзенекен итә. Әлеге җирләрне укыганда «тормышта болай үк була алмый» — дип өстәл кагасың, ә тамак төбенә төер тыгыла, күңелнең иң төбендә яткан өмет дигән нәрсә,ниндидер әрнүле, газаплы моңсулык белән бөкә шуыша, дөньяга, безнең күңелләребезгә, ышанычка күчә. Әсәрдәге геройлар гына түгел, укучы, автор үзе дә көткән минутлар житә. Яшәү, тормыш, мәхәббәт җиңә.

Монда Гомернең атаклы «Одиссея»сындагы сюжетка охшаган бер чалым килеп керә. Анда да Одиссейнең хатыны 20 ел буе ирен көтә. Шулай вәгъдә биргән була. Ул «Одиссей инде кайтмады, көтү вакыты чыкты. Хәзер минем аның алдында күңелем чиста, саф» дип кияүгә чыгарга ризалык бирә. Ләкин бер шарт куя: Одиссейнең җәясен алып 12 балдак аркылы, аларны аудармыйча ук атарга куша. Шул кешегә генә чыгам» ди. Тидерүчеләр табылмый. Пенелопа белә, моны тик ире — Одиссей генә эшли ала. Хәерче киемендә сарайга килгән Одиссей Пенелопа куйган шартны үти. Кем икәнен әйтмәсә дә, Пенелопа ирен таный һәм аңа кияүгә чыгарга ризалык бирә. Бу сюжет сызыгы Лермонтовның «Гашыйк гарип» исемле әсәрендә дә үзәккә алына.

Тормышта явызлык белән көрәшүнең төрле якларын А. Гыйләжев мәхәббәт, мифология белән үреп бирсә, М. Мәһдиевтә ул юмор катыш көнелдәге моңсулык белән тормышыбызда булган детальләр аша чагылдырыла.

Сүз остасы әсәрнең исеме астында ук «Моңсу повесть» дигән ачыкламыш куйган. Чыннан да, әсәрне укып чыкканнан соң, күңелне ниндидер моңсулык били ала. Укучы да әсәрдәге геройлар белән бергә көлә, кайгыра, сөенә, уйлана. Әсәрнең яратып укылуы да, кыйммәте дә нәкъ менә шунда, минемчә. Автор үзе үскән, белгән мохит, балачагы, яшьлеге узган авылы белән хушлаша, шуңа да повестьның исемен дә «Бәхилләшү» дип куйган. Автор үзе дә бу уңайдан: «Без үскән, мин белгән татар авылы юк инде...» — ди. Әйе, бүгенге авылыбызның яшәеше, табигате, милли йөзе һәм андагы кешеләрнең эчке дөньясы үзгәргән бу чорда, әлеге әсәрнең язылуы һәм басылып чыгуы бик вакытлы булды, ул кирәк иде. Повестьның башында ук «нигә», «ни өчен» кебек сораулар туа, аларга җавап эзлисең, уйланасың... Әлеге әсәрендә ул безнең көнкүрештән югала барган «ипи пешерү», «ат җигү», «печән чабу» һ. б. шуның кебек манзаралар аша, үзе белгән, күргән, сиземләгән бу күренешләрне матур итеп, юмор белән сугарып укучыга җиткерә. Бу әсәрдә барысы да күз алдында: хыял да, куаныч һәм юаныч та... Ләкин болар һәммәсе дә күңелнең түрендә туган моңсу бер хис белән бергә үрелеп биреләләр. Кеше җанын, аның эчке дөньясын үзәккә алып, авыл тормышы, димәк, халык язмышы, аның гореф-гадәтләре аша автор татар халкының гасырлар дәвамында укмаша килгән милли характерына юл ала.

М. Мәһдиев әсәрләренең үзенә тарту көче халыкчанлыкта, халыкча уйлый, сөйли, аңлата белүендә. Язучының образлы фикерләү рәвешен, язуын — халкыбыз гасырлар буена тудырып килгән авыз иҗаты әсәрләренең, халкыбыз рухының үзенчәлекле дәвамы дип карарга кирәк.

М. Мәһдиев әлеге әсәрендә татар авылының бетүе, халкыбызның гореф-гадәтләренең онытылуы,үзебезнең миллилегебезнең юкка чыгуы — җыеп әйткәндә, авылга каршы алып барылган явызлыкның кайчан барлыкка килүен, ничек итеп аның азуын һәм менә кемнәрнең гаепле булу сәбәпләрен ачып бирергә омтыла. Ул явызлыкның без күрә алмаган якларын күреп безгә җиткерә, аңа һәм аңа булышучыларга каршы көрәшү өчен үткәннәрдән гыйбрәт алырга кирәклеген әйтә, кисәтә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: югарыда искә алынган повестьларда тарихны әйдәп баручы герой да, шәхес тә юк кебек. Әмма аларда халкыбызга гына хас булган үзенчәлекләрне үзенә туплаган, саклаган һәм бүгенге көнгә кадәр китереп җиткергән олы җанлы кешеләр бар. Әлеге әсәрләр татар теленең бөтен матурлыгын тоеп язылган иҗат җимешләре.

«Мондый әхлакый мираска бай халыкның башка мәмләкәтләр эчендә эреп, телен югалтып, билгесезлектә калырга хакы юк...» — дигән фикер уза әлеге әсәрләр буенча (Т. Галиуллин, «Социалистик Татарстан», 1989, 24 сентябрь). Бик тә дөрес, мәгънәле әйтелгән фикер бу фикергә кушылырга гына кала.

Хәзерге вакытта татар прозасы урында таптана дигән фикерләр, сүзләр күп ишетелә. Мин моның белән килешмәс идем. Һәрбер әдәбиятның туган, үскән, чәчәк аткан вакыты була. Бәлки проза без хыялланган югарылыкта, дәрәҗәдә түгелдер, ләкин ул яши. Татарстан китап нәшрияты ел саен язучыларыбызның дистәләгән проза әсәрләрен бастырып чыгара. Язучыларыбыз эзләнә, уйлана, иҗат итә.

Тагын шуны өстәп әйтәсе килә: кайбер сәясәтчеләргә һәм тәнкыйтьчеләргә караганда, язучыларыбыз үзләренең дөрес фикер йөртүләрен, алдан күрә белүчәнлекләрен күрсәттеләр.

**Илдар ХӘСӘНОВ,**
Казан дәүләт университеты аспиранты.

# АНАЛАР РУХЫ ИСӘН...

Фоат Садриев үз романында татар әдәбиятының элек-электән килә торган традицияләрен дәвам итә. Ул тирән иҗтимагый проблемалар күтәрә, җәмгатьчелекне борчыган мәсьәләләргә җавап эзли. Шул ук вакытта бу роман язучының әдәби осталыгы камилләшүен дә күрсәтә. Романдагы образлар нәкъ тормыштагыча, ышандырырлык итеп тасвирланган. Элегрәк әдәби әсәрдә кимчелекләрне ачып салу, җитешсезлекләрне тәнкыйтьләү «җәмгыятьнең ямана-тын сату» дип кабул ителде. Нәтиҗәдә әшнәлек, әдәпсезлек, миһербансызлык тамырын ныгытты, әхлаксызлыкка юл куелды. Бу яктан күзәткәндә, романда үз намусын саф, пакь килеш саклаучы Нуриасма образына тукталырга кирәк.

Нәкъ шушы төшенчәләргә Нуриасма бик үзенчәлекле карашта тора. «Кешелеклелек битлеге астында эш итүчеләр күп ул, кызым! Кемнәр белән икәненне уйла. Без төзегәнне сез җимерәсез дигән сүз бу!» Ни төзегән? Кайчан? Кем өчен? Төрле чигенешләр юлы белән язучы бу сорауларга җавап биреп бара. Нуриасманың яшь чагындагы фидакарь хезмәте, кеше баласын үзенекедәй якын күрүе, ирен ят хатын кулыннан аулап алуы, соңыннан, ирсез калып, балаларын намуслы булырга, дөресне ялганнан, хакны нахактан аерырга өйрәтүе — барысы да Нуриасма җилкәсенә төшә. Чыннан да, дөреслекне тану, сайлап алу җиңел эш түгел ул. «Ныклабрак уйлый башласаң, бөтенесе алдында да, аерым-аерым да гаепле. Кем генә гаепсез соң? Кайда иң гадел хөкемчең? Әйе, әйе, әнисе хаклы! Хөкемче бер генә: «Дөреслек!» — дип борчыла Нуриасманың кече улы Мизхәт. Роман геройларына үз юлларын табу җиңел түгел, киртәләр, каршылыклар туып кына тора.

«Кешелеклелек», «Миһербанлык» кебек төшенчәләр астында үзенең чын йөзен, кем икәнлеген яшереп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче Мәҗит Харисович Хөснуллин образы бирелә. Аны язучы башка персонажларга мөнәсәбәттә ача: «Халык җилкәсендә кәеф-сафа корып, җинаять өстенә җинаять кылып, үз башларын саклап яшәүчеләр менә шушы идарә йортыннан алып Мәскәүгә кадәр бер-берсе белән бәйләнгәннәр. Моны күреп торса да, соңлабрак аңлады Нуриасма». Аңлар өчен алны-ялны, көнне-төнне белмичә эшләгән заманда урын булдымы икән соң аңа? Янача аң, яңа тормыш кына Нуриасманы шушы нәтиҗәне ясарга этәргән дигән фикер туа.

Ф. Садриев үзенең персонажының теле белән кыю сүзне «боз кузгалгач» кына әйтсә, ә әдәбиятта инде 60 нчы елларда ук Ф. Хөсни «Утызынчы ел» романында Котдус Вафинын, урнаштырылган тәртипләргә каршы китереп, «тәртәгә типтереп» авылдан чыгарып җибәрә. Ә. Еникинең «Саз чәчәге» повестенда Шакир Мостафинны район партия конференциясе делегатлары секретарьлык эшеннән яшерен сайлау вакытында «тәгәрәтәләр». «Гадәт колы» хикәясендә язучы Шәймәрдән агайны үз-үзеннән кыйнаттыра һәм моңа ул аның эчке кичерешләрен ачып бирү юлы белән ирешә: «... эченнән генә: «Сакаллы дурак, сакаллы дурак, сиңа шул кирәк!» дип үзен сүгеп утыра бирде»,— дип тәмамлый ул әсәрен.

Язучы Ф. Садриев әсәр башыннан ук Нуриасма образын табигать белән бәйләп тасвирлый. Табигатьнең матурлыгы һәм кеше күңеленең сафлыгы — бу тәгъбирләр Садриев иҗатында янәшә куела. Романда табигать күренеше укучы күңелен әкренләп яулый, ул, үзе дә сизмәстән, үзенә бер төрле тирәлектә кала. Әсәрдән агылган уйчанлык, моң, сагыш, серлелекнең бер чыганагы — гасырлар кичкән, күп вакыйгаларның шаһите булган табигать. «Нуриасма гомере буе таңга, кояшка, җиргә табынды, аның өчен илаһи нәрсәләр шулар булды».

Геройның балаларга булган мөнәсәбәте дә туфрак, җир белән бәйле: «...адәм баласының кендеге, әнисе карыныннан өзелү белән, җиргә тоташырга тиеш...» Яки: «Бала туфракта аунап, шуны ашап үссен ул. Туфракта хикмәт. Үзебез дә шул туфрактан яратылган лабаса». Язучы шушы тәрбиянең нәтиҗәсе булган Нуриасманың оныгы — Марат образын бирә. Гаиләдә өченче бала булып, бик көттереп дөньяга килгән малай шәһәр шартларында һич савыга алмый, аны Фәрит әнисе Нуриасма тәрбиясенә авылга кайтарып куярга мәҗбүр була. Ә бер елдан соң кайтып сау-сәламәт улларын күргән ата-ананың шатлыгының чиге булмый.

«— Әни, Маратның аяк киемнәре кайда икән? — диде Нәсимә улын киендермәкче булып.

Нуриасма кул селтәде.

— Кирәкми, килен. Күрмисенмени: бөтенесе яланаяк. Алар көн саен туфракта аунап өйрәнгәннәр инде, берни дә булмас,— диде Нуриасма көлеп».

Кешенең туган җир белән бәйләнеше, туган ягына мөнәсәбәте — татар әдәбиятында күп еллар дәвамында чагылып килә торган, зур әһәмияткә ия булган тема. Безнең көннәрдә бу темага урта буын прозаиклары аеруча игътибар иттеләр. Туган якның шифалы тарту көчен ачу А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Р. Төхфәтуллин, М. Юныс прозасының тавышын, рухын билгеләде.

А. Гыйләҗевнең әдәби эзләнүләре тормышыбызны, әйләнә-тирәбезне сафрак, матуррак, кешеләрне олы җанлырак итеп күрергә теләү хисенә буйсындырылган иде. «Өч аршын җир» повестенда язучы кешенең туган җиргә мөнәсәбәте кебек җитди мәсьәләне күтәрде. Повесть — туган җир, туган якның кадере хакында, кешелеклелек турында тирән фәлсәфәгә корылган әсәр. Кайчандыр үч итеп, йорт-җирләрен яндырып, күмәк хуҗалык амбарларындагы икмәкне яраксыз хәлгә китергән Мирвәлине авылдашлары, шулай да, ахыр чиктә, үз яннарына сыйдыралар — картайган кешенең хәленә керәләр. Ә гомере буе туган иленә омтылган Шәмсегаянга өзелеп сагынган туган җирен күрү насыйп булмый. Аның тәне генә туган туфрагына, аның кочагына керә. Шәмсегаян җиреңнән төмен белеп, өзелеп сагынып, ана омтылса, Ә. Еникинең «Туган туфрак» хикәясендәге Клараны шул мөхиткә барып эләккәч кенә бу хисне тоя: «Бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир! Һәм Клара үз гомерендә беренче тапкыр моның буш сүз булмавын аңлап, шуңа искиткеч сөенде...»

Бу мәңгелек теманы без Г. Ахунов иҗатында да очратабыз. Монда Туган җир, Ватан темасы ана темасы белән үрелеп бирелә. «Бер анамны мир кулына калдырырлык булгач, ир исеме күтәреп йөрмим дә. Калиматкә ыстрам булсын, үзем күчәм әби янына!» — ди Фәйрүзә. Монда инде Фәйрүзәнең туган туфракка гына якынаюы түгел, ә Җир-анага, бигрәк тә Йөзлекәй карчыкка ихтирам, аны олылау дип кабул итәргә кирәк. Оныгы тарафыннан Йөзлекәй карчыкка булган мөнәсәбәт Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ендәге Акъәбигә карата да булса, аның: «Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде,— сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңладыгызмы?..» — дигән мөрәҗәгате җавапсыз калмас иде. Бу сүзләрдә халыкның үткәненә хөрмәт, аның гореф гадәтләрен ихтирам итү, онытмыйча саклап, алдагы буыннарга тапшыру мәсьәләсе куела. Хикәядә язучыны кеше күңеленең байлыгы, нечкәлеге сокландыра.

Кешенең эчке дөньясы, рухи байлыгы турында язылган әсәрләр турында сүз чыккач, Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестендәге ана образын читләтеп үтеп булмый. Монда ана образына сабырлык, чыдамлык, тыйнаклык хас. Халыкның тормышка карашы, яшәү фәлсәфәсе аның канына сеңгән. Ул — Йөзлекәй, Акъәбиләр шикелле үк халыкның гасырлардан килеп формалашкан иң әйбәт сыйфатларын үзенә җыйган, шуларны балаларына, оныкларына тапшыручы. Ул уларын халык рухы белән бәйләүче, тоташтыручы.

Әдәбиятта аналар турында сүз барганда, А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» әсәрендәге бөтен гомерен башкаларга багышлаган Бибинурны да читләтеп үтеп булмый. Повестьта вакыйгалар авыл өчен иң зур бәйрәм саналган сабантуе алды көннәрендә бара. (Чөнки ул заманда шуннан башка милли бәйрәмне билгеләп үтүне күз алдына китереп булмый иде.) Бибинур салам түбәле иске өе каршында бер ялгызы, аның күңел кичерешләре, ышаныч һәм өмет җепселләре, борчу һәм авылдашлары алдында кимсенү, гарьләнү тойгылары бер-берсен алыштырып тора. Кайсы өстен чыкса да, аңламаслык дәрәҗәдә үрелеп, чуалып, буталып беткәннәр. Әмма халык кешелеклелек бәрабәренә үз кичерешләреннән өстен, югары тора. Балаларының исән-имин, бәхетле булуларын гына тели ул. Әлеге эчке драмада Бибинурның күңелендә барган борчу һәм уйларның якалашуы тасвирлана. Повесть ахырында Бибинур бер ялгызы, урман чокырында кыргыйлашкан этлар өере уртасында кала. Авылдашларының битарафлыгы, якыннарының онытуы, туганнарының хыянәте шушы эпизодта сәнгатьчә гәүдәләндерелә.

Бибинур язмышы үзара ярдәмләшү, туганлык тойгыларын кадерләү, табигый кешелекле бәйләнешләре, кеше ихтыяҗына игътибарлылык кебек гади һәм аңлаешлы хакыйкатьләр турында җитди уйландыра.

Шунысы табигый: буыннан-буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм традицияләр вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аның

кыйммәте арта гына бара. Хәзерге әдәбиятта аларның замандашларны әхлакый тәрбияләүдә рухи чыганак булуларын ачуга басым ясала. Бу мәсьәләгә күбрәк авыл темасына багышлап язылган әсәрләрдә дикъкать ителә. Чөнки авыл халкы бик борынгыдан килә торган мондый хәзинәләрен үзендә саклаучы дөнья итеп карала.

Фән һәм техниканың яңа казанышлары шәһәрләрнең үсүенә, ә авылларның саны кимүгә, анда яшәүчеләрнең күбрәк, олы яшьтәге кешеләр генә булуына китерде. Авылның традицияләре һәм гореф-гадәтләре дә онытыла башлады. Нәтиҗәдә, рухи-әхлакый мирасны һәм традицияләрне ничек саклау бурычы килеп басты. Үткәндәге рухи тәҗрибәне саклау, аны бүгенге һәм алдагы, киләчәк буыннарга җиткерү ниятеннән чыгып, язучылар игътибарны шушы рухи байлыкны йөртүчеләргә мөрәҗәгать иттеләр. Чыннан да, ни өчен халык телендәге тарихи исемнәр йотыла (Каракош басуы, Атчабар кыры), гомер-гомергә ата-баба сөйләшкән, аңлашкан башкорт теле урыс теле белән алышына, бу сорауларны әдәбияттә Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять» хикәясе белән беренче булып күтәрә. Ә Фоат Садриевнең «Таң җиле» романында Нуриасманың кече улы Мизхәт шәһәрдә сигез сәгатьлек эш көненә, ике көнлек ялга кызыгып, әнисеннән узып авылдан китми. Нуриасма образы шулкадәр нечкә зәвык белән эшләнгән ки, ул үз балаларын гына түгел, шәһәр тәрбиясе алып үскән, белемле кыз Зөбәрҗәтне дә үзгәртә. Ә Акъәби исә балаларын авылга, туган нигезгә бик тартасы килсә дә, учагындагы утын күршеләргә генә калдырырга мәҗбүр.

Дин, милләт мәсьәләсе белән бергә күтәрелгән тагын бер четерекле проблема бар, ул да булса — тел. Татар, башкорт милләте халыклары кая гына барса да, каршылыкка очрады, беренче урынга урыс теле куелды. Акъәбинең Суфияны, Нуриасманың Шәрифҗаны бер үк язмышка дучар булган образлар. Күрәсең, хәл итәсе мәсьәләнең алда иң җитдие тора. Акъәби оныкларының әбиләренә эндәшерлек дәрәҗәдә дә үз телләрен белмәүләренә юкка гына пошынмыйбыз. Нуриасма бу киртәне күпмедер читләтеп үтә, чөнки ул оныгы Маратның телен ана телендә ачтыра.

Ф. Садриев ана образын шундый югарылыкка күтәрә, монда анын һәр сүзе, һәрбер ясаган хәрәкәте башка персонажлар өчен үрнәк булып тора. Төп героенын уйларын, кичерешләрен анын эчке, күңел дөньясы аша биреп, отышлы юлны сайлаган язучы. Әсәрдә автор детальләрне бик уңышлы кулланган: «Мизхәт яр буенда күзәткән йолдызларны, айны ул тәрәзә аша карап ятты». Димәк, ана белән улының уйлары, фикерләре бер юнәлештә, киләчәктә алар бертөрле булырлар дигән нәтиҗәне ясыйсы килә. Ә: «...Акъәби ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде». Монда Акъәбинең башыннан кичергәннәре кемгә дә булса барып ирешер дигән өмет юк, чөнки аны җансыз күңелле кешеләр чолгап алган.

«Ана күңеле балада, бала күңеле далада»,— ди халык, ләкин Ф. Садриев бу мәкальне үзенчәрәк борып куя: «Әнкәй — ул изге зат. Аны чат-чат үбеп булмый, анын алдында кайберәүләр кебек майка-трусиктан да йөреп булмый. Анын янында икәнен тою гына да берни белән алыштыргысыз бәхет»,— ди улы Фәрит әнисе турында.

Кешене соңгы юлга озату, анын бәхиллеген, ризалыгын алып калу мөселман халыкларында борынгыдан килгән изге йола. Шунын ачык мисалын «Таң җиле» романында очратабыз. Нуриасманың соңгы сүзен ишетергә барлык балалары, туган-тумачалары, күрше-күләннәре, бергә гомер кичергән якыннары җыела. Акъәбине күмү исә бөтенләй икенче шартларда бара. Чынлап та, Нуриасма бу тормышта зуррак уңышка, ихтирамга ирешкән һәм үзенең лаеклы алмашын җирдә калдырып китә.

Әсәрнең «таң җиле исү... табигать җанлану» белән тәмамлануыннан олы буынның хәер-фатихасын тапшырып дөньядан китүе белән дөньяви тормышка чик, нокта куелмый, ул дәвам итә, дигән мәгънә аңлашыла.

**Әлфия МОТЫЙГУЛЛИНА,**
педагогия институты аспиранты.

*Латин әлифбасы нигезендә*

*татарча уку күнекмәләре*

# ŞEVCENKO QAZANDA

Ukraina xalqьnьꞑ ʙөjek şaƣire, talantlь xudoƶnik, patşalьq samoderƶaviesenə qarşь armьj-talmьj kөrəşkən revolytsioner-demokrat T. G. Şevcenko yz ƣomerendə ʙeznen Qazan şəhərendə də ʙulьp ytə. Şaƣir yzeneꞑ „Kөndəleklər"endə jazьp kilgəndə Qazanda ʙuluьna da tuqtala.

Orenʙurg өlkəsendə un jьl sərgendə ʙulƣannan soꞑ, T. G. Şevcenko Astraxanƣa kilə həm 1857 nce jьlnьꞑ 22 nce avgustьnda, „Knəz Poƶarski" paroxodьnda, Idel ʙujlap juƣarьƣa jul tota. Şaƣir Idel ʙujь jarlarь kyrneşlərenə soqlana, xalьq çьrlarьn həm legendalarьn tirən ʙer dərt ʙelən tьꞑlьj, zur şatlьq ʙelən yzeneꞑ aldaƣь içad plannarьn təzi, „Kөndəleklər"enə jaza, rəsemnər jasьj.

12 nce sentəʙrdə tөnlə ʙelən paroxod Qazannan un caqrьmnar cittə tuqtьj.

Ikence kөnne irtə ʙelən Şevcenko Qazanƣa ʙarьь turьnda jaza. Tyʙəndə ʙez Şevcenkonьꞑ „Kөndəleklər"ennən şul urьnnь kiterep ytəʙez.

13 (sentəʙr)

## QAZAN ŞƏHƏRE

### MƏSKƏVNEꞐ BER POCMAƢЬ

Bu sөjləmne min ʙerence tapqьr 1847 nce jьlnь, mine feld'jeger ʙelən Orenʙurgga ozatqanda, Semʙer guʙernasьndaƣь pocta stansiəsendə işettem. Semʙer dalalarьnьꞑ nindider simez ʙer keşese mine ozatucьƣa Qazan şəhərenen maturlьqlarьn tasvir itkəndə yzeneꞑ tasvirlarьn şuşь өlger sөjləm ʙelən jomƣaqlap qujdь. Bygen irtə ʙelən min jьraqtan Qazannь kyrep aldьm, həm kyptənnən işetelgən sөjləm yz-yzennən iskə tөşte həm ixtiarsьz tel anь əjtep saldь. Paroxodnьꞑ jakor' taşlarƣa өlgerye ʙuldь, min jarƣa cьqtьm da, jegerme ʙiş tien tyləp tatar arʙasьna utьrьp, şəhərgə kittem. Qazan jьraqtan da, jaqьnnan da Məskəvneꞑ ʙer pocmaƣьn xəterlətə: cirkəvlərdən, kolokolnələrdən ʙaşlap, sajkalarƣa həm qalaclarƣa qədər — ʙөten çirdə, hərʙer adьmda aqtaşlь Məskəv joƣьntьsьn kyrəseꞑ. Xətta hic şiksez tatar zamannarь pamətnigь ʙulƣan Sөjemʙikə manarasь da miꞑa Suxareva ʙaşnəseneꞑ ʙer tuƣan seꞑele ʙulьp kyrende. Kremlgə iltə torƣan zur uram (ul, əlʙəttə, Məskəv uramь inde) yzeneꞑ nazlьlьƣь həm aƣac ʙykənnər çəjelgən mostovojь ʙelən Nevski prospektqa oşi. Bu uram өc grandioz ionik portiklar ʙelən ʙizəlgən gyzəl universitet ʙinasь ʙelən ʙaşlana.

Bu gyzəl ʙinaƣa məjdan çitməve ʙik qьzƣanьc. Ul alaj ʙulƣanda kyʙrək otьşlьraq ʙulьr ide həm Jekaterinanь maqtap çьrlavcь çьrcьnьꞑ monumentь işek aldьnda, qьzьl sьjьr melanxolik tөs ʙelən qarap tora torƣan keckenə ʙaqcada tormas ide.

Tantanalь odalar həm ʙytən tөrle qəʙaxət maqtavlar yrycenen statujasьn sьjьr ʙelən ʙergə ʙeraz qarap torƣac, min işek aldь arqьlь ytkəndə şaqtьj

kygelçem iəkle ʙer studentnь ocrattьm həm şuꞑar kyrə ul ʙu auditoriədə jaꞑa keşe tygelder digən qərarƣa kildem. Şul nigezdə min aꞑardan ul 1847 nce jьlnь Kief universitetьnnan Qazan universitetьna kycerelgən Posəda ʙelən Andruskonь xəterləmime dip soradьm. Ul xəterləmim dide həm miꞑa qart storoz Ignatjefqa mөraçəƣət itərgə kiꞑəş ʙirde. Min aꞑar өjrətye өcen ədəple genə itep rəxmət uqьdьm, ləkin, anьꞑ şuşь jaƣьmlь өjrətyen qullanunь kirəksez sanap, uramƣa cьqtьm. Uramƣa cьqqac min tonьq ʙaraʙan tavьşьn işettem həm çinajətcene çəza urnьna ozatucь quјь xalьq tөrkemen kyrdem. Bu qəʙaxət protsessiə ʙelən ocraşmas өcen min tьqьrьq-qa ʙorьldьm həm ʙu protsessiəne qararƣa jөgerycelər arasьnda arqasьna şarmanka asqan jəş ʙer qьz ʙelən qulьna tamʙurin totqan sələmə kiemle malajnь kyrdem. Miꞑa kyꞑelsez tygel, ə əllə nicek ajruca nacar ʙulьp kitte, həm min taƣьn jegerme ʙiş tiengə tatar arʙasь aldьm da paroxod-qa qajttьm.

Paroxodqa qajtqanda min julnьꞑ uꞑ jaƣьnda, Javьz Ivan patşa Qazannь alƣanda yterelgənnər sөjəge өstenə salьnƣan pamətniknь kyrdem. Portiklь itep eşləngən həm ʙaşь ujьlƣan ʙu piramida Javьz Ivan patşanьꞑ catьrь torƣan urьnƣa salьnƣan dilər. Kyꞑelsez pamətnik.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

### Гөлсем Мөхәммәдеваның тууына 90 ел

Тәрҗемәче һәм күп кенә әсәрләр авторы Гөлсем Мөхәммәдева (Өммегөлсем Даут кызы Мөхәммәдева) 1903 елның 19 сентябрендә Әстерхан шәһәрендә туа. Татар һәм урыс мәктәпләрендә укып, урта белем ала. 1919 елда үзе Әстерханда балалар укыта башлый. 1922 елда Әстерхан медицина институтыннан Казан университетының шундый ук факультетына укырга күчә. Бер үк вакытта Татарстан Халык Комиссарлары Советында тәрҗемәче булып та эшли. Шул чакта ул татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов белән таныша һәм 1923 елның җәендә алар гаилә корып җибәрәләр. 1927 елда Татарстан хөкүмәте Г. Ибраһимовны Кырымга дәваланырга җибәргәч, аның белән бергә Ялта шәһәренә китә. Кырымда яшәгән елларында (1927—32, 1934—41) Г. Мөхәммәдева техникумда укыта, Ялта сәнгать музеенда, Симферополь Архив идарәсендә, фәнни институтта, Кырым Язучылар союзында һәм «Кызыл Кырым» газетасы редакциясендә эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, ул эвакуация ташкыны белән Үзбәкстанның Сәмәрканд шәһәренә күчерелә. 1944 елда медицина институтын тәмамлый, 1958 елга кадәрле шифаханәдә врач булып, аннары фәнни институтта гыйльми хезмәткәр вазыйфаларын үти. 1956 елда диссертация яклап, биология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Егерменче елларда Г. Мөхәммәдева сәяси брошюралар тәрҗемә итә. Шулай ук Г. Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле зур тарихи хезмәтен урысчага тәрҗемә кылып, китап итеп бастыра. Утызынчы һәм сугыштан соңгы елларда кырым татар язучыларының һәм халык иҗаты әсәрләрен урысчага тәрҗемәли. Г. Ибраһимов турында «Зур тормыш» исемле истәлек китабы һәм «Яшьлек көннәре», «Эзләнүләр», «Олы юл» дигән документаль әсәрләр яза.

Г. Мөхәммәдева 1977 елдан бирле Казанда яшәп иҗат итте.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

*— Гаҗәеп катлаулы, үзгәреп торучан заманда яшибез. Базар мөнәсәбәтләренә күчә барган саен икътисад мәйданы ныграк кайный, бәяләр котырына. Бу хәл инде күптән матбугат дөньясына да бәреп керде. Менә 15 сентябрьдән 1994 елның беренче яртыеллыгына газета-журналларга язылу башланды. Язылу бәяләре арта торганлыктан, халыкның билгеле бер өлеше — әйтик, пенсионерлар, студент яшьләр һ.б.ның милли басмаларны уку-алдырудан мәхрүм калу ихтималы да үсә бара. Нәрсә, бу бәя дигәннәре һаман шулай үсә торыр микәнни? Моның чиге күренәме? Нәрсә эшли алабыз? Аның бит әле нәшер ителә торган газета-журналлар саны да артты, кайсын сайларга да белгән юк. Сез, министр буларак, шуларның һәркайсын укып, күзәтеп, фикер туплап барырга өлгерәсез микән? Бүгенге чуалчык заманда аларның эчтәлеге, тоткан мәсләге, юнәлеше Сезне канәгатьләндерәме?*

**Ислам Әхмәтҗанов, Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министры:**

— Шагыйрь Рөстәм Мингалимнең менә мондый шигъри юллары бар:

Дөнья безне сыный,
Утка терәп сыный...
Суга терәп сыный...

Һәм дә әлеге дөньяны, еламсырак бәбине буш имезлек биреп алдаган шикелле, алдап булмый шул. Икътисади киеренкелек, бәяләр котырынуы матбугат дөньясына да бәреп керде, дип дөрес әйтәсез. «Базар» сүзе кайбер басмалар өчен «каравыл!» рәвешендә яңгырый — кәгазь бәһасе күтәрелүдән туктамый, нәшрият чыгымнары арта, зыянга эшләргә теләмәгән элемтәчеләрнең хәлен дә аңларга мөмкин. Ләкин, ничек кенә кыенга туры килмәсен, бер генә басма да уфтанмый-сыкранмый, сайлаган кыйбласына тугрылыклы калып, әлеге болгавыр заманда халыкка хак сүз җиткерүдә хәлдән килгәннең бөтенесен эшлиләр. Бүгенгесе көнгә безнең министрлыкта 250 ләп исемдә газета һәм журнал теркәлгән. Шуларга тагын нәшрият эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукын алган 90 лап предприятиене дә кушсак, һәм тагын 15 предприятиенең шундый хокукны Россия Федерациясенең матбугат министрлыгыннан алганлыгын да искәртсәк, күренә ки, матбугат һәм нәшрият органнары кимеми, киресенчә, ишәя генә бара. Моны матбугат ирегенең, сүз ирегенең бер чагылышы рәвешендә кабул итәргә кирәктер.

Ләкин бу әле мәсьәләнең бер ягы гына. Икенчесе, көн саен арта барган вакытлы матбугат үзенең укучыларын табармы соң, дигән сораудан гыйбарәт. Турысын әйтеп сөйләшик, сорау җиңелләрдән түгел. Соңгы айлардагы матбугатка язылу нәтиҗәләре байтак мөхәррирләрне пошаманга төшерде. Кем әйтмешли, мөштәриләр саны күзгә күренеп кимесә, төшәрсең борчуга.

Моңа инфляция чире сәбәпчедер диярсез, бәлки. Акчаның дәрманы түбән, бәяләр артуына күз ияреп өлгерә алмый хәтта — боларның һәммәсе матбугат белән укучы арасындагы бәйләнешлы киеренкелектә тотучы сәбәпләр.

Газета яисә журнал мондый халәттә үз укучыларын (димәк ки, үз-үзен дә дигән сүз) ничек саклап калыр соң? Иң әүвәл үзенең бәясен (номинал кыйммәтен дип аңлыйк) күтәрү юлы белән. Тик моның белән генә инфляция җилен куып җитеп булмый. Икенче юл — дәүләт булышлыгына, бүтәнчәләтеп әйтсәк, дотациягә өметләнү. Әмма дәүләт кесәсе дә төпсез түгел һәм кайчан да булса әлеге дотацияләрнең бетәчәгенә шик юк. Инде килеп, өченче юл кала. Ул да булса редакциягә өстәмә керемнәр китерү юлларын эзләү һәм табу. Ягъни сәүдә-эшмәкәрлек белән шөгыльләнү, рекламага урынны күбрәк бирү юлы. Бездә генә түгел, ә бөтен дөньяда диярлек матбугат реклама хисабына яши.

Министрлыкта теркәлгән басмаларның да кайберләре реклама-игъланнар хисабына көн күрә. Әйтик, андыйлар рәтенә «Рекламная мозаика», «Казанская сорочка», «Бизнес-курьер», «Ваша реклама» кебек газеталарны кертергә була.

Бәяләр котырынуын моның белән генә дә җиңеп булмаска мөмкин. Дүртенче таяныч кала — газета яисә журналны гамәлгә куючылар кайгыртуы. Әгәр санап кителгән чаралар эшкә җигелми икән, бер генә басма да озак яши алмаска мөмкин.

Кызганыч, без торгынлык елларында матбугатны хуҗалык исәбе кулланып эшләүдән биздердек. Партия барча басмаларны диярлек үз канаты астына алып, акча юнәтү кайгысын онытты. Әлбәттә, мондый шартларда партиянең «кесә басма»ларына әйләнгән газета яисә журнал битләрендә үткен тәнкыйть, үткер сүз бөтенләй диярлек югалды. Буразнадан тайпылучыларны «авызлыклап» тордылар.

Укучы кайсы басмага өстенлек бирер — бу 15 сентябрьдә башланачак язылу барышында ачыкланмыйча калмас. Бер караганда йөзләгән басманың кайсысын сайларга да аптырарсың кебек. «Сез аларның һәркайсын укып барырга, бәяләп барырга өлгерерсезме?» — дип сорау бик урынлы. Җавабым әзер: өлгерәбез! Шәп язмаларга, каләмдәшләребезнең уңышларына ихлас күңелдән шатланабыз, нахак сүз, үлчәнмичә әйтелгән фикерне укыгач исә күңел бәләкләнә. Закон кысаларыннан тайпылган басмалар яки авторлар белән суд залларында да очрашырга туры килгәли. Сүз ирегеннән, матбугат ирегеннән явыз ният тә файдаланучылар, чынын әйтеп сөйләшик, очраштыргалый әле. «Шаккатыризм» чире татар телендә нәшер ителә торган кайбер басмаларга да хас. Юкны бар дип ышандырырга теләүчеләрнең гомере озын булмый. Ник дигәндә, бүгенге заманда кеше төгәл һәм туры сүзгә, хакыйкатькә мохтаҗ.

Укучының, бу иптәш тәнкыйть язмаларын өнәп җиткерми, күрәсең, дип уйлап куюы бар. Дөрес түгел. Тәнкыйть кирәкле шәйдер, дип шагыйрь белеп әйткән. Тик ул нигезле, кире каккысыз дәлилләргә нигезләнгән тәнкыйть булсын. Югыйсә бездә шәхесне кимсетеп, мәсхәрәләп пычрак атулар ишәеп китте. Вакытлы күренеш, җитлегү чорына хас сырхау дип кабул итик моны.

Матбугатка көзге язылу кампаниясе элемтәчеләр хезмәтенең гаять нык кыйммәтләнеп китүе белән аерыла. Әлеге уңайдан Татарстан хөкүмәте дотация бирү тәртибен үзгәртергә ниятли. Базарга кергәндә һәркем үзенә кирәкле акчаны үзе табарга тиеш — эш шуңа табарак бара.

... Кичә генә чуаш телендә чыккан «Сувар» газетасын күздән кичереп утырдым. Татарстанда яшәүче йөз утыз ике мең чуаш өчен яңа газетаны алу зур куаныч булгандыр. Яңа оешкан Әтнә, Кайбыч, Теләче, Ютазы районнары үз газеталарын оештырдылар. «Мирас», «Бизнес в Татарстане» кебек яңа журналларның киләчәге өметле. Шөкер, заманалар ничек кенә авыр килмәсен, яңа басмалар туып тора. Күпсенмик, тусыннар — халыкка сайлап укырга мөмкинлек булсын. Рухи азыксыз дөньясы да сансыз бит аның.

## ПРЕЗИДЕНТЫБЫЗ — ПОЧЕТЛЫ АКАДЕМИК

16 июль көнне Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Шәймиевкә Халыкара информация академиясенең почетлы академигы дипломы тапшырылды. Академиянең вице-президенты Э. Евреинов билгеләп үткәнчә, җөмһүриятебез Илбашы моңа республикада яңа җәмгыять төзүдә, тарихи үсешнең шушы катлаулы чорында кеше хокукларын яклауда постсоциалистик стройны урнаштыруда байтак кына катлаулы мәсьәләләрне мәдәниятле хәл итүдә күрсәткән аеруча зур хезмәтләре өчен лаек булган.

## «ОСТАНКИНО» КАНАЛЫ — ТАТАРСТАН ТУРЫНДА

10 августта Мәскәүнең «Останкино» каналы буенча «Хакимияттә кунакта» дип исемләнгән телевизион тапшыру булды. Ул Татарстан Президенты М. Шәймиев эшчәнлегенә, җөмһүриятебезнең мөстәкыйль үсеше мәсьәләләренә багышланды. Әлбәттә, проблемалар да читләтеп үтелмәде. Шунысы бәхәссез: әлеге тапшыру миллионлаган тамашачыларда зур кызыксыну, теләктәшлек, горурлык хисе уятты.

## «АЛТЫН УРДА» — АЛТЫН УРТАБЫЗ

9—10 июль көннәрендә Казанда Татарстан Фәннәр Академиясенең конференц-залында «Алтын Урда: тарихы һәм мәдәнияте» дигән темага халыкара фәнни конференция булып үтте. Татарстаннан тыш, анда Төркия, Америка, Мәскәү, Санкт-Петербург, Ташкент, Уфа, Бишкек, Ижау, Чабаксар, Новосибирск, Элиста һәм башка күп кенә төбәкләрдән килгән галимнәр катнашты.

Пленар утырыштан соң галимнәр секцияләргә бүленеп эшләделәр. «Тарих», «Археология, этнология һәм сәнгать», «Тел, әдәбият һәм халык иҗаты» секцияләрендә йөздән артык гыйльми доклад тыңланды. Докладлар татар, төрек, инглиз яисә рус телләрендә ясалуга карамастан, галимнәр арасында үзара аңлашу һәм Алтын Урда тарихына чын, дөрес бәя бирү кирәклегә хакындагы фикер өстенлек итте. Моннан 750 ел элек оешкан көчле һәм Евразия халыклары цивилизациясендә тирән эз калдырган бу дәүләт тарихын элеккеге рус һәм совет чоры фәнендәгечә гел кара буяулар белән генә күрсәтү чынбарлыкка туры килми. Алтын Урда дәүләт төзелеше һәм сәясәте рус дәүләтенә генә түгел, башка мәмләкәтләрнең дә матди, сәяси һәм рухи культурасына зур йогынты ясаган. «Алтын Урда — татар халкы тарихының аерылгысыз өлеше ул» — аерым бәхәсләргә дә карамастан, күпчелек галимнәрнең уртак фикере әнә шундый булды.

Конференция Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында Алтын Урданың олуг юбилеена багышланган тантаналы кичә белән тәмамланды.

Аннары бер төркем галимнәр, теплоходка утырып, Идел буйлап элеккеге Алтын Урда шәһәрләренә сәфәр чыктылар.

## ХӘЕРЛЕ ЮЛ, «ТАТФЛОТ»!

Татарстан җөмһүриятенең Министрлар Кабинеты Казан елга порты базасында «Татфлот» компаниясе төзү турында карар чыгарды.

Яңа статус коллективка икътисади элементләрне шактый киңәйтергә, транспорт коммерция оешмаларының киң хокукларыннан файдаланырга мөмкинлек бирә. Белгечләр транзит йөкләрне турыдан-туры диңгезгә алып чыгуның җайлаштырылган системасын эшлиләр. Ә бу — бик мөһим. Чөнки Татарстанда Төркия, Иран, Кипр, Греция, Италия, Германия һ. б. илләрнең эшлекле даирәләрен кызыксындырган промышленность продукциясе житәрлек. Хәзер йөк флотын «елга-диңгез» тибында комплектлаштыру бара. Шул уңайдан, республика хөкүмәте «Татфлот» компаниясен керем салымыннан азат итте.

## ЯҢА ПАРТИЯ

Мәркәзебез Казанда «Бердәмлек һәм тәрәккыят» дигән яңа партия төзелде. Ул Татарстанда тотрыклы иминлек урнаштыру һәм үзара килешеп эшләү, катнаш типтагы базар икътисадын формалаштыру, республикабыз хезмәт ияләренең тормыш хален яхшырту, социаль гаделлеккә ирешү, җинаятьчелеккә каршы көрәш, мөстәкыйльлек базасында демократияне үстерү, дәүләтчелекне ныгыту кебек мөһим мәсьәләләрне үзенең беренче чираттагы бурычлары итеп билгеләде.

Партиянең рәистәшләре итеп Рафаэль Хәкимов, Алексей Колесник, Ирек Фәхретдинов сайланды.

## СУПЕРМАГИСТРАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ

Татарстан хөкүмәте Париж — Мәскәү — Владивосток — Нью-Йорк халыкара автомагистраль төзелешендә катнашырга теләге

барлыгын раслады. Алты рәт машиналар йөрешле пыяладай тип-тигез юл Европаны Азия илләре, Япония һәм Америка белән тоташтырачак. Татарстан туфрагында әлеге трасса хәзерге Мәскәү — Түбән Новгород — Казан — Екатеринбург автомобиль юлы янышнан үтәр, дип фараз ителә.

## I БӨТЕНДӨНЬЯ ТӨРКИ ЯШЬЛӘРЕ КӨННӘРЕ

Казандагы «Идел» җәйләвендә Беренче Бөтендөнья төрки яшьләре көннәре (6—16 август) булып узды. Анда Төркия, Кытай, Әфганстан дәүләтләреннән, Хакасия, Кабарда-Балкар, Әзербайҗан, Чувашия, Башкортстан, Дагыстан, Молдова һәм башка җөмһүриятләрдән күпсанлы яшьләр килгән иде.

Бөтендөнья төрки яшьләре көннәре анда катнашучылар күңелендә истәлекле хатирәләр калдырды. Алтын Урданың 750 еллыгына багышланган тантанада катнашу, изге Болгар җиренә сәяхәт кылу, төрки яшьләр ассоциациясенең IV корылтаен уздыру, Сабантуйда көч сынашу яшьләрне дуслык, бердәмлек байрагы астына тагын да ныграк туплады.

Корылтайда Халыкара төрки яшьләр оешмасының штаб-квартирасын Казанда булдыру турында карар кабул ителде.

## ТУКАЙ ТУРЫНДА ФИЛЬМ

Танылган режиссер — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Зарипов халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай турында 20 сериялек телевизион нәфис фильм төшерү эшләрен башлап җибәрде. Шартлы исеме «Тукай дөньясы» дип исемләнсә дә, әлеге фильмдагы вакыйгалар шагыйрьнең биографиясен сурәтләү белән генә чикләнмәячәк. Режиссерның раславына караганда, анда Рәсәйнең ачлык елы, чукындыру вакыйгалары сәнгатьчә эшләнештә күрсәтеләчәк. Фильм халык дөньясын ачып салачак, аның авыр, катлаулы тормышын чагылдырачак.

Фильмны иҗат итүгә танылган әдәбият-сәнгать әһелләре — язучы Гариф Ахунов, драматурглардан Туфан Миңнуллин, Ризван Хәмид, композитор Фасил Әхмәтов, артистлардан Ринат Тажетдинов, Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев, Хәлим Җәләлов һ. б. тартылган. Тукай образын экранда Фәрит Бикчәнтәев гәүдәләндерәчәк.

Фильмның беренче өлеше Апас районы җирләрендә төшерелә башлады инде.

## КЕЧЕ СӨНДӘ — ФӘРИТ ЯРУЛЛИН МУЗЕЕ

31 июль көнне җөмһүриятебезнең Мамадыш районындагы Кече Сөн авылында татар музыкасын «Шүрәле» балеты аша бөтен дөньяга таныткан композитор Фәрит Яруллин музее ачылды. Билгеле булганча, бу авылда яшәгән бер гаиләдән берьюлы өч танылган композитор чыккан: Зәһидулла Яруллин һәм аның уллары Фәрит белән Мирсәет Яруллиннар. Зәһидулла ага — мәшһүр Салих Сәйдәшевнең беренче мөгаллиме, «Тукай маршы» белән музыка сәнгатендә мактаулы урын билгән шәхес. Мирсәет Яруллин исә татар музыка сәнгатендә беренче мәртәбә «Кеше» ораториясен иҗат итеп, җөмһүриятебезнең М. Җәлил бүләгенә лаек булган иде, бүгенге көндә ул — Идел буе һәм Урал ягы композиторларының региональара йорты директоры. Шуңа күрә әлеге музейда аларга кагылышлы экспонатлар да байтак.

Музейны ачу тантанасында Мамадыш районы хакимияте башлыгы Илгизәр Ибраһимов, җөмһүриятебезнең Мәдәният министры урынбасары Мөҗип Низамиев, Татарстан милли китапханәсе директоры, Татарстан халык депутаты, язучы Разил Вәлиев, Татарстан дәүләт музее директоры Геннадий Муханов, композитор Әнвәр Бакиров һ. б. чыгыш ясады.

Фәрит Яруллинның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгән язучы Рашат Низамиев исә музейга «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан «Фәрит Яруллин» исемле роман-хроникасын автограф белән бүләк итте.

Тантанада Татарстан җөмһүриятенең Премьер-министры урынбасары Илгиз Хәйруллин катнашты.

## «КЫЗЫЛ АЙ» ...КАЛЫКТЫ

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Бөтентатар «Кызыл Ай» җәмгыяте 79 нчы сан белән теркәлде. Билгеле булганча, мондый оешма күп кенә мөселман илләрендә байтактан яшәп килә. Төркиядә аның, мәсәлән, йөз еллык тарихы бар. Ә менә Татарстанда мондый җәмгыять яңарак кына — мөстәкыйльлек алгач кына оештырылды.

Бүгенге көндә Казан шәһәренең Комлев урамындагы 14 нче йортында урнашкан «Кызыл Ай» җәмгыяте үзенең тарафдарларын барлый. Җәмгыять җитәкчесе — язучы Мәдинә Маликова. Шәфкатьле, олы йөрәкле, киң күңелле кешеләрне бергә туплап, бу җәмгыять бәла-казага дучар булучыларга, мохтаҗларга ярдәм күрсәтергә җыена.

## ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗ ДАНЫН ЯКЛАП

Алма-Атаның (Казагыстан) данлыклы «Медео» стадионында «Азия тавышы» дигән халыкара фестиваль үткәрелде. Анда БДБ илләреннән, Филиппин, Мадагаскар, Кытай, Иран, Төркия һәм башка мәмләкәтләрдән, шул исәптән Татарстаннан килгән җырчылар үзара бәйге тотты. 620 башкаручыдан 25 җырчы финалга узды. Россия һәм Татарстаннан бары тик бер генә кешегә — якташыбыз Эльвира Розалига гына шундый бәхет елмайды. Ул тиздән Япониядә һәм Латин Америкасында җөмһүриятебез данын яклап чыгыш ясаячак.

## МАЙКОПТА — ТАТАР МОҢНАРЫ

Адыгей Республикасы башкаласы Майкопта июль аенда төрки халыкларның этнографик-мәдәни фестивале булып үтте. Бәй-

рәмгә чит илләрдән, БДБның төрле төбәкләреннән күп кенә танылган артистлар һәм ансамбльләр килгән иде. Махсус чакыру буенча фестивальдә Татарстаннан җырчылар, Казандагы С. Сәйдәшев исемендәге «Иҗат» берләшмәсенең сәхнә осталары һәм Балтачтагы «Гөлләрем» ансамбле дә (җитәкчеләре — Рәниф Вахитов белән Радик Михайлов) катнашты.

Фестивальдә Адыгей Республикасы Президенты А. Джаримов, Мәдәният һәм туризм министры А. Ханаху катнаштылар. Татарстанлылар аларга милли түбәтәйләр, чәк-чәк һәм Чаллы сәүдәгәрләре — бертуган Ринат, Рәфис, Нәфис Кашаповлар биреп җибәргән өч манаралы-айлы мәһабәт сәгатьне бүләк иттеләр. Бүләкләр тапшырылганда Татарстан Гимны да яңгырады.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА — ИНГЛИЗЧӘ

Финляндиядә Бөтендөнья язучыларының халыкара очрашуы булып үтте. Анда Мәскәүдә яшәүче татар язучысы Миргазиян Юныс та катнашты һәм инглиз телендә татар әдәбияты турында чыгыш ясады.

## МУЛЬТФИЛЬМ ТӨШЕРҮЧЕЛӘР ӘЗЕРЛӘНӘ

Татарстан Республикасының Кинематография дәүләт комитеты тәкъдиме белән, Казан художество училищесендә рәссам-мультипликаторлар бүлеге ачылды. Монда, дүрт еллык курста, профессиональ мультфильм төшерүчеләр әзерләнәчәк.

## ЯЗУЧЫ ТУРЫНДА КАЙГЫРТУ

«Татнефть» берләшмәсе генераль директоры Ринат Галиев Баулы районының Кызыл Яр авылына ялга кайткан танылган язучы Фәнис Яруллин янында булды. Ул аңа чит илдән кайтарылган махсус коляска, язу машинкасы һәм магнитофон бүләк итте.

## ТАТАР МӨГАЛЛИМНӘРЕ АРТАЧАК

Самараның ике педагогия училищесендә дә татар группалары ачылды. Аларның һәркайсы үзенә 15 әр кеше кабул итте.

## «ТУРАН» ҮЗЕНӘ ЧАКЫРА

Казанның Г. Тукай музеенда «Туран» коммерция галереясе эшли башлады. Ул өч залга урнашкан. Әлегә ул — милли сынлы сәнгать әсәрләрен, халык осталарының кул эшләрен сата торган бердәнбер урын.

## ТАТАР РӘССАМЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

Мәскәүнең «Мир» галереясендә татар рәссамы — бабасы ягыннан Казан егете Равил Хәлимовның шәхси күргәзмәсе ачылды. Равил үзе Кытайда туган, безнең илдә белем алган, бүгенге көндә Мәскәүдә яши.

## УРАЛДА — ЯҢА НӘШРИЯТ

Магнитогорск каласында «Магнит» нәшрияты оешты. Беренчеләрдән булып анда танылган татар композиторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рафаэль Бакировның «Уралда туган моңнар» исемле җыентыгы басылып чыкты. Әлеге мәҗмугада көйләр остасының 30 дан артык җыры урын алган.

## ГАЗЕТА ИСЕМЕН ҮЗГӘРТӘ

Республика тормышындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр уңаеннан һәм «Советская Татария» газетасы редколлегиясе соравын искә алып, Татарстан Югары Советы Президиумы «Советская Татария» газетасының исемен «Республика Татарстан» дип үзгәртергә карар бирде.

## ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

А. С. Пушкинның остазы, урыс шагыйре Г. Р. Державинның тууына 250 ел тулу көне бик күп урыннарда зурлап билгеләп үтелде. Бу уңайдан безнең җөмһүриятебездә дә данлыклы якташыбызның исемен мәңгеләштерү буенча кызыклы чаралар комплексы эшләнде. Аерым алганда, шагыйрьнең туган җирендә — Лаеш районының Державино авылында аңа һәйкәл куярга, халыкара әһәмияткә ия булган музей булдырырга, бу янындагы бакча-утарын торгызырга, яңа төзеләчәк яңа мәктәпкә аның исемен бирергә, булачак 40 йортлы яңа урамны «Державин проспекты» дип йөртергә карар кабул ителде.

## ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗНЕҢ МИЛЛИ ИНВЕСТИЦИЯ ФОНДЫ

Татарстан Республикасының Милли инвестиция фонды эшли башлады. Ул хәзер халыкны үзенең акцияләренә яздыра.

Президент Указы белән барлыкка килгән фондның оештыручылары — дәүләт милке белән идарә итү комитеты, хосусыйлаштыру фонды, коммерция банклары.

Милли инвестиция фонды хосусыйлаштыру барышында гражданнарны социаль яклауны, базар мөнәсәбәтләрен көйләүне, Татарстан экономикасын дөньяга танытуны күз уңында тота.

# ГАЗАП ҺӘМ ӨМЕТ

Шәһәр-авылларыбызда, ниһаять, яман чорда җимерелгән мәчетләр кабаттан торгызыла башлады. Халык үз иманына кайта.

Оҗмахтай туган авылым — Мөслим төбәгенең Яңа Сәет авылында әле генә тергезелгән мәчетнең Ае мондагы гаҗәеп табигатькә нур өстәгәндәй булды. Аны ачу тантанасына мөхтәрәм мөфтиебез Тәлгать Таҗетдиннең Уфадан үзе килеп фатиха бирүе, мәчет ачылыр көннәр алдыннан вафат булып куйган Яңа Сәет мулласы — әткәм Госманның каберенә могътәбәр картларны алып барып Коръән укуы онытылмас бер хатирә булып калды.

Без үз тарихыбызга, газиздән дә газиз нәсел тамырларыбызга орына башладык бугай.

Уфада яшәүче якташыбыз, гаять тә үзенчәлекле рәссам Р. Кадыйровның «Орыну» дигән рәсемен караганда җанымда кош уянып, канатларын тылпырдаткандай булып куйды.

«Казан утлары» бүген шул рәсемнең үзәк өлешен — фрагментын гына тәкъдим итә.

Әмма бу рәсемгә күз төшереп кенә калмасагыз иде. Үз гомерендә ат урынына җигелеп эшләүдән башканы белмәгән, барып Ходайга ялварырдай мәчете дә калмаган әбинең кулларына җентекләбрәк карагыз. Оныгы аның шул мең газаплы учларына үзенең нәни кулларын салган. Күзләре күккә карый... Әбинең хәсрәтле һәм өметле күзләре оныгына текәлгән. «Ходай бар ул, балам! Дөреслекнең урыны — биектә!» — дип васыять әйтә сыман бу Әби — Ана».

Безнең буын аналары әйтелмәгән васыятьләрен үзләре белән алып киттеләр. Алар нинди генә якты сүзләр әйтсә дә аңламастай, ишетмәстәй буынга әверелеп җиттек шул...

Шаять, ишетә дә, аңлый да башлар яңа буыннар.

Әнә бит рәсемдәге мәчетнең тәрәзәсендә зәңгәр ут яна, салават күпере өмет белән балкый.

Озак елларга сузылган олы газапка өметнең, иманның орынуы бу.

Уйлы кеше бу рәсемгә битараф калмас.

**ЗӨЛФӘТ.**

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосурәте

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган галим һәм тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллин.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Бөтендөнья татар конгрессы.** Стенографик отчет.
Казан, Татарстан Министрлар кабинеты басмасы. 1993 ел.

Үткән ел Казанда шаулап-гөрләп Бөтендөнья татар конгрессы узган иде. Халкыбыз тарихында беренче мәртәбә һәм киң колач белән үткәрелгән бу тантаналы вакыйга гаять зур сәяси әһәмияткә ия булды. Шуны истә тотып Татарстан Министрлар кабинеты конгресс материалларын аерым китап итеп басып чыгарды. Анда барлык чыгышлар һәм кабул ителгән карарлар, мөрәҗәгатьләр тупланган. Шулай ук һәр илдән килгән кунаклар исемлеге дә бар. Җыентыкның соңгы өлешендә конгресс күренешләрен тарихка кертеп калдырачак фоторәсемнәр урнаштырылган. Китапның күләме 18,5 табак, тиражы 5 мең данә.

**А. Х. ХАЛИКОВ. «Болгармы яки татармы?»** Мәкаләләр.
Казан нәшрияты, 1993 ел.





«Безне кем дип атарга: болгармы яки татармы?» Шуның ише сораулар милли матбугатта да, җәмәгатьчелектә дә соңгы елларда шактый еш күтәрелде. Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителә торган бу яңа китап күпмедер дәрәҗәдә әнә шул сорауларга җавап бирәчәк. Ул татар халкының килеп чыгышы һәм аның атамасы турындагы күпсанлы фәнни-популяр хезмәтләр авторы, тарих фәннәре докторы А. Х. Халиков тарафыннан язылган. Китапның күләме 6 табак, тиражы 100 мең данә.

Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 нче китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

Бәясе 30 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог